


# КАЗАН УТЛАРЫ

8
АВГУСТ
1979

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ һӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

8
АВГУСТ
1979

## Бу санда

**Ф. САФИН.** Алма бакчасында. Шигырьләр . . . 3
**А. РАСИХ.** Сынау. Роман . . . . . . . . . . . 9
**Р. ГАТАУЛЛИН.** Яңа шигырьләр . . . . . . . . 85
**Х. ӘЮПОВ.** Тик без генә. Шигырьләр . . . . . 91

ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

**Г. БӘШИРОВ.** Кара төндә нур чәчеп... Хикәя . . 94
**Ш. ХАММАТОВ.** Сугышта сыналган әдәбият . . 128

ДУСЛАР ЖЫРЫ

**ЧЕРКЕЗ-АЛИ.** Мин октябрь баласы. Шигырьләр . 139
**ӘШРӘФ ШӘМИ-ЗАДӘ.** Бер тамчы су. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 140
**РИЗА ФАЗЫЛ.** Низамига. Шигырь . . . . . . 141
**СЕИТУМЕР ӘМИН.** Җиvана. Шигырь . . . . . 141
**БИЛАЛ МАМБЕТ.** Ана һәм Ватан. Шигырь . . . 142
**ЮНЫС ТИМЕРКЫЯ.** Вәгъдәсе бар икән. Шигырь . 142

ОЧЕРКЛАР

**Т. ӘЙДИ.** Атомны йөгәнләүче . . . . . . . . 143

ӘДӘБИ ОСТАЛЫК ТУРЫНДА

**Ф. ХӨСНИ.** Орлыклар кая төшә . . . . . . . 151

СӘНГАТЬ

**Р. ХАРИС.** Татарстан артистлары Италиядә һәм Мальтада . . . . . . . . . . . . . . . 166

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ф. ГАЛИМУЛЛИН.** Әдәбият фәне үсеше турында. 174

СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

**М. МӨХӘММӘТ.** Тукайның садә дусты . . . . 177

КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА һәМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Якты эз (Б. Әлменовның якты истәлегенә) . . . 179

МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

**Украин халкы һәм әдипләре иҗатыннан . . . . 181**

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Җ. ТӘРҖЕМАНОВ. Мин язуны ничек ташладым . 185**

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189**

Редакциянең адресы. Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-69, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (баш редактор урынбасары), **Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Туфан Миңнуллин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, Ф. Кадыйрова.*

Производствога бирелде 24/IV-1979 ел. Басарга кул куелды 4/VII-1979 ел. ПФ 13217. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83300 экз. Заказ Ц-174. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1979 ел.

## Фәннур Сафин

# АЛМА БАКЧАСЫНДА

### Татарстан!

Татарстан, синең хөрмәтеңә
ярышырга әзер юргалар.
Табыныңда дәртле «Әпипә» бар,
ә теләсәң, моңлы җыр агар...

Уйларымны минем сизәсең син,
Татарстан — алтын Ватаным. —
Давылларны узып очып бара
ераклардан муллык бәйрәмеңә
чакырып язган ярсу хатларым.

Мин аларда яздым сине данлап,
хыялларны иркен һәм зур дип.
Халкым теләкләрен язсам да тик,
куйдым гади генә «Фәннур» дип...

### Яхшылык

Казан күген, Идел киңлекләрен
сыйпап узган төсле ак болыт,
рәнҗүләрне чиста кулы белән
юып ала икән яхшылык.

Хыялларга күпме киртә куйдык,
кирәгеннән артык сак булып.
Матурлыкка матур дип, кинәнеп
бер соклану үзе яхшылык.

Ныклык теләп безгә, йөрәк кушкан
хаклык якларына чакырып,
таш өстендә борын төртә үлән —
җирдән безгә дигән яхшылык.

Дөнья киң.
Шуңадыр аны
Кискәләгән челтәрләр:
Милләтләр,
Илләр,
Сыйныфлар,
Меридианнар,
Бутәннәр.

*Әхсән Баянов. «Челтәрләргә карап».*

Кайный янар таулар, суга дулкын,
ил өстенә ишелеп төшә тау.
Бер яшьтәшем үзенең кордашының
муенына үлчәп ишә бау.

Тимер рәшәткәле тәрәз аша
сузып богау кискән кулларын,
замандашым кар бөртеге хәтле
яктысына тилмерә дөньяның.

— Бу җиһанның бер-бер ноктасына
нур булыр,— дип,— шигырь юлларым,—
уйласам да, читлектәге кошны
азат иткән кебек буламын...

## Дөнья...

Кемдер дәшми шәһит китә,
тугры калыр өчен.
Кемдер яши тугры сүзне
ярып салыр өчен.

Кемдер яши, тыныч кына
гомер үтсен, диеп.
Яки минем алда дөнья
тезен чүксен, диеп.

Кемдер яши «сөям...» дигән
бердәнбере өчен.
Һәм кемгәдер күкрәгеннән
ялкын өрер өчен...

Шул кемнәрдер өчен бу җир
борчыла, сөенә.
... Бер карадан киенә ул,
бер актан киенә...

## Яр буенда алмагач

*Шагыйрь дуска*

Син алмагач, дустым, яшь алмагач,
алсу алма пешә җаныңда...
Алмалары берни белмәсә дә,
алмагачы күрә барын да...

Зилзиләне күрә, бураннарны,
күрә дусын давыл екканын.
Яшереп елый...
Таңгы алмаларга
каян килсен инде чык тагын!..

Син алмагач, дустым, яшь алмагач!
Тамырларың җиргә береккән.
Убылудан бары шул тамырлар
йолып калган элек-электән...

Канат-ботакларың ныгыр, ләкин
тамырларың ныгыт иң башта.
Үз бакчаңда бит син, — икеләнмим, —
ул бакчада бәлки син патша!

... Ә алмалар берни тоймый әле,
алмагачы күрә барын да...
... Яр буенда үскән алмагач син,
тик алмалар — ботагыңда түгел,
алмаларың пешә җаныңда...

## Ядкарь

Кызыл алма ак чәчәктән
истәлек булып калган...
Синең өчен мин дә — чәчәк,
и киләчәк-күзалмам!..

Синең өчен дә бер чәчәк
минем гомер, и каләм!..
Син булганга, шатлыгымны
җиргә күмми китәләм.

Алмаларым калыр җирдә —
кызыл ярда кызарып.
(Кемдер өзәр гамьсез генә,
кемдер узар кызганып...)

Калыр бәхет, якты сагыш...
(Калмас бит кара ялган?)
Ул алмалар — минем яздан
Бер ядкарь булып калган.

## Чын сөю

*Баллада*

Пешкән алмаларын күтәрергә
инде түзәр хәле калмагач,
үз алмамны, зинһар, дип ялвара
көзге ачы җилгә алмагач.

Җил үзә дә ташлый кыз алдына, —
алъяпкычы тулган бит инде!
Кыз алманы алып кабып карый,
ул үзе дә алма шикелле...

Оялудан янган йөзе — алма.
Сөйгәненнән монда ул качып,
курку катыш татлы уйга талды,
тотылган күк нидер урлашып...

Өз, сеңелем, алсу алмаларны,
сөйгәнеңә илт син аларны.
Алмада ул таң һәм шәфәкъ күрер,
чын сөюне аңлар аннары!..

## Алма бакчасында

Туп-туп коела алмалар,
«Син!» дип барсам — җил исә.
Ул алманы мин үзем дә
өзәр идем, югыйсә.

Өзәр идем...
һәм әйтерсең
гомер буе, бер генәм,
кычытканга чагыла-чагыла
мин алмага үреләм.

Ә ул алма йолдыздан да
югарырак икән бит!
Юкка җанны ышандырам
беркөн буем җитәр дип.

Җиталмагач, өмет өзеп
күзләр түбән карады.
... Күктән эзләгәнмен икән
җирдә яткан алманы!..

## Оҗмах

Безне юллар очраштырды
Көндез түгел, кичкырын.
Шатланыпмы, шаярыпмы:
— Куып җит! — дип кычкырдың.

Эңгерләрдән зәңгәрләнгән
Кырларга йөгердек без,
Дөньяның шушы почмагын
Оҗмах итеп күрдек без.

Кояштай якты бәхетне
Кызганып түгел бер дә,
Качтык икәү онытылып,
Качтык иң аулак җиргә.

Планеталар кавышкандай,
Куллар кулны алганда,
«Өзеләм!..» дип тирбәлделәр
Нәни кыргый алмалар...

Сүзләр түгел, күзләр иде
Аңлашу чаралары.
Яшерәлми иде серне
Хәтта төн каралары.

Хәзер белдек, соңлап белдек,
Чын мәхәббәт булган ул.
... Төн... Кыр... һәм мин...
Сагышымнан
Уянмасын, дим, авыл...

## Йөгерә еллар

Ярсу идек, яндык-көйдек,
Хискә күңел шундый бай, —
Ерганаклар ера-ера
Йөгергән малайлардай.

Хыялдагы мәхәббәтең
Елмаеп дәшкән чакта,
Кояш үзе килә иде
Айсыз кичләрдә хәтта.

Язгы ташкын кебек идек, —
Җан тоташ язлар иле.
Җемелдәгән һәрбер йолдыз
Безнеке генә иде.

Инде хәзер тынычландык,
Гомерләр генә елдам. —
Ашыга-ашыга йөгерә еллар
Малай чактагы сыман...

## Җырчы

*Илһам Шакировка*

Салкын акыл белән кайнар йөрәк,
яр дулкыннар белән алыша.
Мәңгелек гамь белән битарафлык,
дулкын белән дулкын ярыша.

Корылык белән яңгыр тамчылары,
ашлык белән ачлык тартыша.
Көн корабы баткач төн-диңгезгә,
төн җиңдем дип ләкин ялгыша...

Төн диңгезен кичеп чыга кояш,
яшәү белән үлем сынаша...
... Башын тоткан җырчы:
ничек барын
сурәтлим, дип, гади җыр аша?!.

## Күңелдә

Җан түрендә ак бураннар,
тагын нидер бар кебек...
Көннәр җепкә асылып язга
кергән мамык кар кебек...

Алмагачлар шау чәчәктә!
Ә күңелдә — кар иле...
Ник очрашкан көндә, сылу,
калдырып киттең мине?!

## Сүз әйтмәгез

Җәберсетеп дәшмәгез,
рәнҗетмәгез толларны!
Ай үсәсен көн эчендә
үсеп килә уллары!

Яши алар Ил белән.
(Кем ничек өйрәтмәде!..)
Кайбер кызларга биргесез
сәдәдер йөрәкләре...

Сафлык яклы идек без,
шулай булып калыйкчы?!
— Тол тарихы — Ил тарихы... —
дияр беркөн тарихчы...

Елатмагыз, какмагыз,
сүз әйтмәгез толларга!
Җавап бирәсегез булыр
узып киткән елларга...

## Уйчан көз

Мин — уйчан көз.
Кемдер бәлки
яздыр, таңдыр яисә —
кайдадыр бит дулкын кага,
йомшак җылы җил исә...

Мин — уйчан көз.
Кемдер бәлки
карама я усактыр.
Кемдер шәфәкъ балкышыдыр
яки төнге учактыр...

Мин — уйчан көз...
Мөгаен, бу
начардыр... я әйбәттер.
Көздә — кайгы дигән сүзләр —
ышанмагыз, гайбәттер...

Миндә уңыш муллыклары,
төсләр, хисләр байлыгы;
саллы, салмак фикерләр һәм
кичерешләр саулыгы.

Мин — уйчан көз.
Уйлар белән
күңелләрне җылытам.
Чык түгел ул, хисләр тама
җил тибрәткән яфрактан!..

## Кал моңнарым булып

Син — кояшлы көнем, хыялдагы өнем,
бердәнберем, Ләйләм минем дип,
риза булсаң әгәр, ал таңнарга кадәр
гел янәшә барыр идем бит.

Синең белән бергә менеп биек үргә,
басар идек дөнья алдына.
Чәчәкләрне күр син, такыялар үр син,
сөюдәнме алар ал гына?..

Син гаҗәпкә калма, күңелемне аңла,
күзләремә тутырып кара да.
Ялгызлыктан йолып, кал моңнарым булып, —
тик йокысыз төннән арала!

## Атилла Расих

# СЫНАУ

РОМАН

### ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

1



Зариф улына катгый рәвештә, сиңа өч көн срок бирәм дисә дә, моның мөмкин эш булмаганлыгын үзе дә тиздән аңлады. Фәрит гаиләсе янына кайтырга булган хәлдә дә, эшеннән бу арада гына чыга алмый иде. Ата чигенде, тик шулай да улы яныннан хәзергә китмәскә булды. Һәрхәлдә, егетнең исенә семьясы барлыгын, ниһаять, акылга утырырга кирәклеген тукып торуны ул үзенең бурычы санады. Барыннан да мөһиме хәзергә аның табылуы, исән-сау булуы һәм, кемгә дә булса өйләнеп-нитеп, аяк-кулын богауга тыкмавы әйбәт иде.

Бүген ул иртәнге чәй янында иң соңгы козырьларын чыгарып сөйләшергә булды. Гадәттәгечә, чәйгә сәгать алтыда утырдылар (Фәрит җидегә, кайвакыт иртәрәк тә эшкә китә иде). Сүзне Зариф башлады. Фәрит кичә пешкән токмачлы ашны бик тәмләп ашарга керешкәч, ул:

— Миңа бүген төне буе йокы заты кермәде, — диде.

— Нигә?

— Синең турыда уйладым. Гаиләң, балаларың, киләчәгең турында баш ватып яттым.

— Бу эшең юкка, киләчәгем турында уйлауны син миңа калдыр инде, әти.

Зариф ачы итеп көлеп куйды.

— Ах, ничек ансат кына. Тик онытма, мин исән чакта һаман минем улым булып каласың син. Телисеңме-теләмисеңме, мин синең кайгың, синең шатлыгың белән яшим. Хәер, син балаларың турында ул кадәр борчылмыйсың. Гамәлең шуны әйтә.

— Күптән сөйләшенеп, күптән аңлашылган нәрсәләр турында тагын сүз башладың.

Дәвамы. Башы журналыбызның җиденче санында.

— Мин әле, аңлаштык, синең әйткәннәргә мин ышандым дигәнем юк.

— Анысы инде синең эш, эти. Ә үземнең ни эшләячәгемне бик яхшылап аңлаттым, югыйсә.

— Минә озын сүзнең кыскасы шул, улым, синең эшләгән җирендә хатыныңны, балаларыңны ташлап качканыңны белмиләр булса кирәк. Әгәр дә минем сүземне гелән-гелән аяк астына салып таптыйсың икән, синең начальствоң белән сөйләшергә мәҗбүр булам.

Фәрит, ашавыннан ук тукталып, куе кашларын югары күтәрде.

— Син нәрсә... этиме син миңа, әллә...?

— Мин сиңа эти, балаларыңның бабасы да.

— Кызык синең фәлсәфәң, эти.

— Фәлсәфәм, улым, нәкъ үзем дөрес дип тапканча. Өйләнгәнче уйларга кирәк иде барысын да.

— Ә син үзең соң уйлаган идеңме әнине алганчы?

— Уйламаган идем. Ләкин мин ул хатамны авыр җәзалар күтәреп булса да акладым. Һәм без әниең белән бергә булдык, сезне, балаларны сынык канатлы ятимлектә кимсетмәдек. Менә шул.

— Үзең яратмаган кеше белән яшәү — ул бит икейөзлелек.

— Син бит аны яратып өйләндең.

— Яратып өйләндем, тик яратмаганлыгымны соңыннан белдем.

— Димәк, мәхәббәтең сүрелде?

— Юк, ул бөтенләй булмаган.

— Ник соң алайса өйләндең?

— Әй, кайдан беләсең, эти, ялгышасыңны. Яшьлек юләрлеге...

— Инде үзеңнең ялгышың өчен балаларыңнан җәзасын күтәртмәкче буласыңмени? Кара, ул ялгышкан да — ычкынасы, ә сабыйлар гомер буе ятимлек азабы кичерергә тиеш.

— Син обывательләрчә фикер йөртәсең, эти. Ә үзең коммунист, әле җитмәсә райисполком председателе булган кеше. Бәлки минем дә бәхетле буласым киләдер. Бәлки минем дә җаным телләгән, үземә тиңем бардыр. Ник әле син мине әллә кайчан булып узган домострой ысуллары белән акылга утыртырга җыенасың?

— Әгәр дә синдә әз генә, минә әз генә, тырнак очы кадәр генә, кешегә хас вөҗдан дигән нәрсә булса, син бәхетле була алмаячаксың, улым. Сиңа фәлсәфәң балаларыңны ятим калдырырга рөхсәт бирә. Ләкин вөҗданың рөхсәт итмәячәк. Аны бел. Сүземне тыңла, мин синнән күбрәк яшәгән кеше, тәҗрибәм дә күбрәк, аны бел.

Фәрит ашның тәмен бөтенләй тоймаса да тәлинкәсен бушатты. Ясалган чәен чокырыннан бер генә чөмерде дә аягүрә басты.

— Директор белән секретарьне күрергә теләсәң, бик соңга калма,— диде ул чәнчеп, — алар өйлә вакытларында Казанга китәләр.

Бу, мине күндерә алмадың, эти кеше, алай гына да түгел, карарым катгый, мине бу юлымнан беркем дә яздыра алмас, дигән мәгънәне аңлата иде.

Зариф конторага кереп улының башлыклары белән сөйләшергә батырчылык итмәде. Ул, Фәрит шундый, балаларына карата гамьсез, каты бәгырьле бер кеше икән, аның гаиләсенә кире кайтуыннан ни файда, дип уйлады. Бүген кайтыр, ә иртәгә тагы чыгып китәр. Карт, булмаса кайтырга кирәк, яңадан ике-өч көн аңлатырга тырышып карыйм да, аның балалар атасы хисен бер дә кузгата алмасам, кайтып китәм. Араларына кереп йөрмим, эш миннән калмады, булдыра алганның барын да эшләдем. Соңыннан үзенә үпкәләр, дигән фикергә килде.

Ләкин ул улын каты бәгырьле дип юкка гына гаепли иде. Фәриткә Әлфияне үзенеке итәргә комачаулаган әйбер ул балалары турында уйлау, шулар өчен вөҗдан газабы кичереп яшәү иде.

Әле Галиәкбәр килгәнче Фәриткә Әлфия янында бик еш булырга туры килде. Кыз егетне ярата. Фәрит уенча ул барысына да риза. Төрле чаклар булды. Бер вакыт алар мәхәббәт исереклегеннән тәмам онытылып диванда озак, бик озак үбешеп утырдылар. Икесенең дә йөзләре кызышкан, күзләре тонган, куллары, хәтта барлык сыннары калтырый иде. Фәрит, хисләр ташкынын артык тоткарлый алмас булып, Әлфиянең гүзәл гәүдәсен күтәрде дә илтеп караватка салды. Кызның күзләре ярым йомык, үзе елмайган килеш ята иде. Фәритнең каны кызып китте, ул, тәмам шашынып, Әлфияне үзенеке итү өчен әзерләнде. Ашыгып пинҗәген салып ташлады. Һәм шул чак кинәт... кинәт аның күзләренә каршыдагы тәрәзәнең пәрдә белән капламаган кап-кара өлешендә ниндидер башлар күренде. Юк, башлар түгел, аңа дүрт күз текәлгән иде. Тукта, нинди таныш күзләр соң болар, дигән уй узды Фәрит башыннан. Я хода, бу бит аның балалары тәрәзәдән карап тора. Алар, әти, син нишлисең, син бит безне онытырга тиеш түгел, диләр. Нәрсә бу? диде агарынган Фәрит, ашыгып тәрәзә янына барды. Ләкин тәрәзәдә кышкы давыллы төн авазы гына ишетелә, урман гына шаулый, бернинди кеше заты юк иде. Әмма буласы эш башкарылды: Фәрит уянып киткәндәй булды һәм хисләре акылына буйсынды.

Эшкә баргач, Фәрит туп-туры фабрика территориясенә кереп китте. Үзе кереп чыгарга тиешле цехларда булып, байтак кыдырганнан соң, ул сынаулар уздырыла торган корпуска якынлашты. Исәбе профессорны күреп, эшләрнең барышы турында сөйләшү иде. Картның кайтканына, Әлфия әйтүе буенча, өч көн булды инде, тик көндәлек ыгы-зыгы аркасында моңарчы вакыт табып Фәрит аның белән бер дә очраша алмады.

Корпуста чебиләр чыелдавы колак тондыргыч иде. Фәрит тирә-юнена карана-карана читлек батареялары арасына узды. Каршыга оператор кыз килеп чыкты. Ул бүген аерата көр күңелле күренә. Фәритне сәламләгәч:

— Теге профессорның эше мантый бит,— дип куйды.— Башлы икән.

— Әле монда юкмы үзе?

— Биредә. Теге яллы егет белән үз читлекләре тирәсендә маташалар.

— Ә яллы ничегрәк соң?

Кызый сипкел баскан йөзен җыерчыкландырып елмайды.

— Эшли әлегә. Корпустан чыкмый ята.

Фәрит иркен сулап куйды. Чөнки Рәмзи өметләрне акламаса, бөтен планнар җимереләчәк иде. Шуңа күрә Фәрит егеткә барлык яхшылыкны эшләргә тырышты да бит. Авансын бирдертте. Кызыл почмактан тулай торак бүлмәсенә күчертте. Әйе, барысы да егет тырышып эшләсен өчен, КамАЗын сагынмасын өчен.

— Идәндәге чебиләр белән эш ничегрәк соң? — дип сорады ул.— Профессор, үсә төшкән саен аларны сирәгрәк утыртырга кирәк, ди.

Фәрит тәҗрибә уздыручыларны эзләп читлек батареялары арасында югалды. Баш зоотехник аларны очратканда кулына сумала тамчысыдай күзле аксыл-сары чеби тоткан Галиәкбәр Рәмзигә нидер аңлата иде. Баш зоотехник белән ул чебине читлегенә куйгач, кул биреп исәнләште.

— Сезне күрергә һич вакыт таба алмадым, гафу итегез,— диде Фәрит.— Ишетүемчә, тәҗрибәне бөтен шартын җиткереп уздыра башлагансыз.

— Барлык шарты ул кадәр үк җитеп бетми әле, Фәрит туган,— диде профессор. Әлфия белән мәгълүм сөйләшүдән соң, аның бит әле булачак кияве күргәне юк иде. Шулай булса да, Әлфиянең шушы кешене яратуы сәбәпле, аның күңелендә Фәриткә карата туганлык хис-

ләре барлыкка килгәнен, хәзер инде бу чибәр, төз гәүдәле, унган затка, улым, дип дәшергә әзер торганлыгын тойды. Ләкин артык туарылырга ярамый иде. Чөнки яхшы түгел. Ул:

— Сезнең вакыт юк, беләм, — диде. — Миңа да Казанда дөнья кадәр эш йөкләп җибәрделәр.

— Сезнең мондагы эшегез дә бик житкән, — дип куйды Фәрит.

— Шулаен шулай да, үтенәләр бит. Үтенгәч, ничектер, баш тартып булмый. Житмәсә эше шундый матавыклы булып чыкты, хәзер хәтта урманга чыгарга да вакыт калмады.

Фәрит ирексездән этисенең дә һәр көн урманга чыгып кергәнлеген хәтерләде. Эченнән: «Юк, юк, адәм көлкесенә калганчы, барысын да, барысын да Әлфиягә әйтергә кирәк», — дип уйлап алды. Фәритнең күзе читлекләр янында маташкан Рәмзигә төште.

— Ну, Рәмзи, элекке белгечлегеңне искә төшерәсеңме?

— Ничава, искә төшә бераз.

— Рәмзи тырыша, тырыша, — диде профессор, сүзгә керешеп. — Әйтәсе дә юк, күз генә тимәсен.

— Су үткәрә белүнең дә кирәге килеп чыккалый, Фәрит Зарипович, — диде, һаман әле читлек эченә кулын тыгып ниндидер эш кылган Рәмзи. — Менә автопоилка начар эшли иде, кул тигәч төзәлде. Ә бит оста кулы тимәсә, йөрер идегез аптырап!

Рәмзинең тырышып эшкә керешүеннән барысы да риза иде. Ләкин бу эшнең сәбәбен беркем дә анык белми. Фәрит элекке белгечлеген сагынган, шуңа күрә, дип уйлый. Башкалар исә гомумән эш сөючән кешедер дигән фикердә. Хәлбуки Рәмзи барлык көчен куеп житәкчесе Әлфия атасы булганга күрә эшли иде. Әлфиянең ашханәдә, эти сезне көтә, диюе аңа атакага ташланырга фәрман булып яңгырады. Ул бу сүзләрдән соң үзен гүзәл кыз янында кебек хис итте. Шундук аның игътибарын җәлеп итү, Әлфиягә бөтенләй якынаю өчен ул үзенең картка да ошарга тиешлеген аңлады.

Профессор белән сөйләшүдән дә бигрәк кызны күрү өчен эрсезләнеп, ул беренче көнне үк Әлфияләргә барып чыкты. Сылтавын тапты, тәҗрибә методикасы турында төпченеп утырды. Мәгәр ул күңеле белән үзенә хәзергә әз генә дә игътибар итмәгән кыз янында иде.

Өченче көнне дә сылтау табып профессор янына сугылды. Фабрикада ул көнне Әлфияне күрә алмаган иде. Өйдә туйганчы карый алды. Әле житмәсә, Әлфия каршысына ук утырып, профессордан анысынмонысын сораша-сораша чәй эчү бәхетенә дә иреште.

Өченче тапкыр килгәндә карт өйдә юк — Казанга очкан иде. Отыры шәп. Рәмзи Әлфия белән дә уртак тел тапты. Сынауда кулланылачак азыкны ниндирәк рәвештә анализларга кирәклеге турында сөйләште. Хәзер инде Әлфия аңа үз итеп, һәрхәлдә, иптәш итеп, артык якын булмаса да, химая белән карый иде. Рәмзи кызның сөйләвен тыңлый, үзе аның гүзәллегенә сөклана, эчтән генә: «И ходаем, бер генә суырып үпсәң иде шул татлы иреннәрне», — ди. Ул икенче көнне дә Әлфияләргә барды. Бу юлы исәбе кыюрак эш кылу иде. Янәсе, ниндирәк кыз ул, нидер өмет итәрлекме, әллә бик авыр нәрсәме. Дөресен генә әйткәндә, ул Гөлфиясен югалтканнан соң, КамАЗ кызлары белән чуалгалады, гитараның ул даирәдә ни кадәрле абруй казанганлыгын шунда белде дә инде. Әйе, аңа КамАЗ кызлары белән танышырга да, йөрешергә дә туры килмәде түгел, ул кызларның төрлесе бар иде. Бар иде үзләрен бик нык тотучылары, булды кукрәгенә кул салу белән изрәп төшүчеләре дә. Шундыйларның берсе белән Рәмзи беренче тапкыр үзенең ирлек көчен сынап, егетлеген дә югалтты. Инде тулай торакта тәҗрибәлерәк «картлардан» ишеткәннәрен хәтерләп җенси көчләре белән артык мактанган каһарманнардан үзенең һич тә ким түгеллеген белгәч,

ул хатын-кызга тагы да ныграк һөҗүм итә торган булып китте. Кемдер аңа дөньяда бирелми торган хатын-кыз юк, тиешле шартлары булсын да, син нык торып, үзеңә кирәкне даула, дигән иде. Хәзер инде Рәмзи бу кагыйдәне дөрес дип тапты. Исәбе, әгәр җае чыкса, тагы бер бәхет сынап карау иде. Чиратта профессор кызы.

Рәмзи Әлфия квартирына хәзерләнеп, ныклы планнар корып барды. Тик, бәхетсезлегенә каршы, профессор өйдә булып чыкты, кызына ул Казан хәбәрләрен сөйләп утыра иде. Рәмзинең планнары шулай җимерелде. Ул тиз генә сылтау табарга тырышты. Хәер, сылтаулар эзләп маташуының кирәге дә юк иде. Картның Рәмзине бик күрәсе килгән икән. Ул егет килеп керү белән, сугылуының сәбәбе белән дә кызыксынмастан, төпченеп сынауларның барышын сораша башлады. Ярар, дип уйлады ул чак Рәмзи, теге планнарны киләчәккә калдырыйк, бер җае чыгар.

Хәзер ул һәр көнне, эштән кайтып ашап-эчкәч, поселокны бер әйләнә, һәм, нинди булса да берәр сәбәп табып, профессор янына кереп чыкмый калмый. Галиәкбәр исә гадәттә корпуска сәгать иртәнге жидегә килеп житә, һәм анда сәгать ун-унберләргә кадәр кайнаша, аннан соң кайтып китә, үзе генә Әлфия бүлмәсендә калып, Эльвира Хәкимовнаның диссертациясен кулына ала. Ә бүген исә ул үзенә ял көне ясады. Фабрикадан кайтышлый ук урманга таба юнәлде, көннең гаҗәп матур булуыннан файдаланып, урман һавасы суларга булды.

2

Урман юллары да зәңгәрсуланган, анда яткан кар дым тарткан, яз үзенең галәмәтләрен сиздереп тиз-тиз Кама елгасына якынлаша. Агач кәүсәләре дә төсләрен үзгәрткән инде. Нарат агачлары арасында күренгәләгән усакларның ботакларына яз үзенең яшел сулышын өргән, ә каеннарны исә тагы да ныграк, күз камашырлык дәрәҗәгә житкереп, агарткан. Ябалдашлары әллә кай югарылыкларга менеп киткән наратларның да ылыслары Галиәкбәргә тагы да яшелләнә, тагы да сагызлана төшкәндәй тоелды. Ләкин барыннан да ныграк дикъкатьне җәлеп иткәне кошлар тавышы иде. Әле килүнең беренче көннәрендә тын гына утырган урман, хәзер сирәк-мирәк саескан кычкырып куюы белән генә түгел, ә әллә ни кадәр, Галиәкбәр исемнәрен дә белеп бетермәгән, кошлар тавышы, кошлар чыр-чуы белән җанланып тора иде.

Юлда бер кем дә күренми, поселок артта калды. Фабрика территориясенең дә бер почмагы күренде дә, тагы агачлар арасында күмелеп юкка чыкты. Карт башта кошлар чыр-чуын тыңлап барды, аннан, уйлары белән булышып, тәмам онытылды. Хәзер ул монда килүенә шат иде. Ул мәшгулият кешесе. Кайчандыр башкарылып та производствога кертелмичә калган үзенчә житди бер хезмәтен төгәлләү аның өчен хәзер җан азыгыдай иде. Бу аның бөтен төссез-котсыз тормышын ямьләндереп җибәрде. Житмәсә әле шактый әйбәт ярдәмче дә килеп чыкты. Яраткан кызым Әлфиям янымда, булачак кияү (ул үзе дә сизмәстән елмаеп куйды) шулай ук Галиәкбәргә хөрмәт белән, олылап карый. Хәзер чираттагы житди эш, ул да булса, Эльвира Хәкимовнаның докторлык диссертациясен тикшереп чыгу. Галиәкбәр монда килгәч тә, гадәтенчә, аны башта гомуми тәэсир тусын өчен башыннан ахырына кадәр артык төпченмичә укып чыкты. Хезмәт ярыйсы кебек күренде аңа. Ул диссертацияне икенче тапкыр кулына алып, бу юлы инде экспериментлар турында язылган өлешен бик нык тикшереп, Эльвира үзе әйтмешли, әйбәт бәйләнчеклек белән укырга кереште. Андагы таблицаларны, биометрик исәпләүләрне Әлфия бухгалтериядән алып кайткан арифмометрда тикшерергә кереште.

Бик мөһим, күп нәтиҗәләр чыгарылырга тиешле беренче таблицада ук ул үзен сөртенеп егылгандай тойды. Шашып калды. Ничек исәпләгән соң моны Эльвира? Әллә инде арифмометр дөрес җавап күрсәтмәме, дип уйлады башта. Хисаплауларны логарифмик линейкада кабатлады, ләкин машинада бернинди дә гаеп юк иде. Карт куркынып, бәлки минем тикшерү ысулым ялгыштыр дип шомланды. Кабат-кабат таблицаны тикшерде. Ләкин, кызганычка каршы, ул әз генә дә ялгышмый иде. Күпме генә тапкыр арифмометр тоткасын әйләндерергә туры килмәде профессорга. Һич шик юк, Эльвира Хәкимовна буталып беткән иде. Юк, юк, профессор, доцент цифрларны ясалачак нәтиҗәләргә туры китерергә тырышып, фальсификация юлына баскан дигән фикердән ерак иде. Андый эшнең һич булуы мөмкин түгел. Мәгәр факт шул: диссертант бик-бик зур хаталар җибәргән.

Картның башында бу эшкә алынуына күңелне газаплый торган ачы бер үкенү туды. Аннан ул членкор Петров ничек җибәргән моны, ничек күрмәгән дип, хәйран калды. Хәер, ул галимгә сиксән тулып узган иде шул инде. Галиәкбәргә бу цифрларны тикшереп утыруы авыр, ә аңа ничек дип уйлыйсың? Шул чак профессор «диссертантларга фарыз эшләр» дигән мәзәкне хәтерләде. Анда мондый эш тә кушылган: «Диссертацияне тикшерергә яшь галимгә бирмә, ул кояш яктысына ныграк калкып чыгар өчен артык бәйләнчек булучан. Син аны карт кешегә бир. Ул бәлтерәгән, ялкаурак та, мондый әйберләрне күп укып туйган да була».

Ләкин алынган эшне башкармый булмый. Галиәкбәр һич иренмичә диссертацияне йокы исәбенә төннәрендә Әлфиягә йокларга комачауламас өчен кухняда тикшереп утырды. Дөнья кадәр хата тапты. Һичшиксез, диссертант ясалган нәтиҗәләрнең күбесен үзгәртергә тиеш дигән фикергә килде. Хәтта әле Эльвира Хәкимовнага өстәмә берничә сынау да уздырмый булмас.

Көндезен, кичен, хәтта төннәрен дә эшләп профессор шундый нәтиҗә ясады. Ниһаять, биш көн эчендә авыр эш тәгәлләнде. Галиәкбәр җиңеләеп калгандай булды. Ләкин профессор шул җиңеллекне тойган хәлдә дә бу газаплы тырышлыгының нәтиҗәсе турында шомланып уйларга мәҗбүр әле. Кем белә аны?!. Галиәкбәрнең ихлас күңелдән ярдәм итәргә теләвен ничек кабул итәр доцент? Карт урман эченә кергән саен шул турыда ныграк уйланды. Чөнки, ни әйтсәң дә, Галиәкбәр Эльвираны шундый хәлгә куячак ки, доцент, бик тырышканда да, диссертациясен вакытында тәгәлли алмаячак. Димәк, ул быел яклый алмый. Ләкин, аның каравы, хезмәте бушка китмәячәк, картның күрсәтмәләрен искә алып эшләсә, диссертациясе өчен ханымның беркайчан да вөҗданы газапланмаячак. Бу мөһим түгелмени?!

Ул акыллы хатын булса, шатланырга гына тиеш инде юкса, дип уйланды Галиәкбәр. Ләкин күңел түрендә, ә аңлармы соң, дигән шик һаман кыбырдап ята бирде.

Карт бу турыда озак уйланды. Ахырда уйларыннан тәмам туеп, арып, кул селтәде. Әйдә, ул миннән үтенде, мин аның үтенечен башкардым. Инде калганы үзеннән. Минем институтка кире кайтасым юк, мин хөр һәм намуслы кеше. Бары вөҗданым кушканны гына эшләдем.

Галиәкбәрнең аяклары соңгы елда ничектер үзен тыңламый башладылар. Ни сәбәптән бу? Юкса бөтен Европаны атлап узган иде бит алар. Бер исәпләсәң хәйран калырлык: Иделдән Эльбагача! Күрәсең, картлык шулдыр инде, дип уйланды ул. Ләкин үзен күңеле белән һич картайган санамый иде. Күңелгә боз катлавыдай тынычлык кабыгы гына ябышкан. Яшьлекнең дуамаллык газаплары, юкка-барга януөтәләнүләре бетте хәзер. Галиәкбәр, байтак әгъзалары еш-еш авырткалавына карамастан, картлыкны яшьлеккә караганда кешенең матуррак бер чоры дип исәпли иде. Кеше картайган көнендә тынычланып

кала, рухи һәм мәгънәви камиллеккә ирешә. Әлбәттә, ул бу фикерен беркемгә дә ачыктан-ачык әйтергә базмый. Чөнки тәгаен аннан көләчәкләр. Ләкин аның бу мәсьәләдә иманы камил иде. Кешенең картлык чоры рәхәтлекләрен күрә алып, ләкин әле картлык маразмысына[1] кадәр дөнья куюын ул бәхет дип саный иде. Ул шундый фикердә, чөнки аның гомумән алганда организмы таза-сәламәт бит. Ә йөрәк шаяргалый икән, анысы табигый хәл.Ниләр кичермәде ул йөрәк! Картлык сәламәтлек белән бергә атласа гына кешенең парлак чоры булуы турында ул ни өчендер уйлап бетерми иде.

Эльвираның диссертациясеннән карт күңеле белән арынып, Лиганасы янына юл тотты. Ул нәни сары песнәге, мысыр күгәрчене турында уйлап бара башлады. Аны төрле кыяфәтләрдә күз алдына бастырды, аның истә калган кызык сүзләрен күңеленнән кабатлап көлемсерәде. Лиананың таудан шуганда шатланып көлүе аның колакларында әле дә яңгырап тора иде.

Чана турында хәтерләгәч, карт көрсенеп куйды. Сафураның балага чана илтмәве бик ихтимал. Ул аның булдыксызлыгын күп, бик күп тапкырлар хәйран калып күзәтте бит инде. Әле алай гына да түгел, ул, валлаһи, әтисен гаепли башлар. Шулай. Гаҗәп кешеләр бар икән дөньяда. Сафура кебекләр беркайчан да ясаган гаепләрен үз өсләренә алмыйлар. Ниндидер җаен, сәбәбен табалар. Кемнеңдер гаебе аркасында булды бу хәл диләр. Эгоизмның иң патологик[2] бер формасы бу!

Галиәкбәр артык кызып китүен тойды. Эченнән генә үзеннән-үзе көлде дә, ярар, пластинканы алмаштырыйк инде, диде.

Ул, әкрен барам дип уйласа да, шактый кызу бара, имеш. Алда үзеннән дә әкренрәк баручы берәү күренде. Кыяфәтенә караганда шулай ук олыгайган кеше. Кулын артка куйган, башын игән, бөкересен чыгарып, күрәсең, шулай ук тирән уйларга чумып бара. Галиәкбәр, кызыксынып, шуны куып җитәр өчен адымнарын кызулый төште.

«Карасана, бу бит әлеге, улын эзләп килгән карт», — диде ул якынлаша төшкәч, Зарифны танып. Теге вакытны, урманда йөргәндә ул кеше Галиәкбәргә исемен дә әйтте, тик профессор аны оныткан иде инде.

Якынлаша төшкәч, Зариф аяк тавышлары килгән якка борылды, һәм профессорны көтеп каршы алды.

— Нихәл, кордаш, син китмәдеңмени әле, — диде Галиәкбәр.

— Исәнме. Китмәдем әле. Чукынсын барысы да! Малайны семьясына кире кайтара алмый интегәм.

Галиәкбәр дәшмәде. Зарифның улын һичбер җайга килә алмый торган тәрбиясез бер кеше итеп күз алдына китерде.

Гәпне картның авырткан нәрсәсе турында алып баруны килештермичә, ул үзенең Казанда булып кайтуын әйтте.

— Ниләр бар соң Казанда? — дип сорады Зариф.

— Әллә ни юк. Онык-кызым янында санаторийда булдым. — Ул Лиана турында ачылып сөйли башлады. Ләкин тыңлаучы катнашсыз, сөмсере коелган хәлдә, кулларын артка куйган килеш, аска карап, үзгәрешсез-нисез тын гына баруында булды. Галиәкбәр аңа Сафура турында да, институт турында да сөйләүне кирәк тапмады.

Бераздан Зариф сүзне үзе башлап җибәрде.

— Менә мин карап-карап торам да кешенең үзгәрүенә хәйран калам, — диде. — Бетте бит әй, адәм баласында намыс-миһербан. Кайда карама, анда — алдашу, дәрәҗә, байлык өчен көрәш. Кая барабыз без, ә?

---

[1] Маразм — организмның таркалуы.
[2] Патологик — сырхау, чирле.

— Син, кордаш, артыграк... утрировать итәсең. Без синең белән менә намуссыз кешеләрмени?

— Белмим, белмим. Мин үземнең күргәннәремнән чыгып әйтәм. Кемәсең кибеткә, үз кеше булсаң, сиңа кирәк әйбер табыла, үз кеше түгел икәнсең — шомытыр башы! Кайда барма, я ришвәт төрт, я берәр файдаң тиярдәй кеше, я әшнә бул. Кая барабыз без, ә?

Галиәкбәр бу кешенең вакытында райбашкарма председателе булып, аннан, үзе әйтмешли «не за што, не про што» сөрелү тарихын белә иде инде. Әнә шул авып төшү кәсафәте бу кешенең бөтен гомерен агулаган, дигән фикерендә калды.

— Син бик артык зур гомумиләштерүләр ясыйсың, кордаш. Кирәкми, андый нигилизм, мыгырданып, сукранып яшәү ул бит, кешенең җанын корт кебек кимерә. Сәламәтлекне сакларга кирәк.

Зариф Галиәкбәргә иреннәрен кыскан килеш кенә елмаеп карап куйды.

— Әйдә, җәһәннәмгә китсен барысы да, минем сәламәтлек кенә саклансын дипме?

— Юк, нигә алай? — диде Галиәкбәр үпкәли төшеп. — Хикмәт бары шунда, сезнең гомумиләштерүләрегез бик аз фактларга таянып ясалган.

— Димәк, мин үз күзләремә ышанмыйча, кемнеңдер күп фактларга таянып ясаган нәтиҗәләренә ышанырга тиеш. Юк инде, Галиәкбәр туган (ул профессорның исемен хәтерендә калдырган икән), без инде бик озак еллар югары инстанцияләрнең авызына карап кына яшәдек. Үзебез уйламау аркасында томана булып беттек. Каян килгән дип уйлыйсыз сез гомуми апатия. Я, әйтегез? Хәзер күп кеше бит бөтенләй үз эченә бикләнде. Агымга эләгергә генә ашкына. Чөнки йөзеп каядыр барып чыгу мөмкин эш түгел. Ә агымга эләгеп, әле синең оҗмахка керүең дә бар. Бәхетең булса, билгеле. Бу бит инде, егетләр, обывательлек баткагына этеп керту дигән сүз. Ни бәхәс юк, ни фикер көрәше. Барысы әзер, теге сез әйткән күп фактларга таянып нәтиҗә ясаучы иптәшләр эшли синең өчен. Ни өчен бездә шул кадәр эчкечелеккә биреләләр, ни өчен бездә хатын алыштыру белән мавыгалар. Мин идеаллар тупикка терәлгәнлектән дип уйлыйм. Ә ул тупикны кем ясаган? Сез хуплаган күп фактны белүчеләр.

Галиәкбәр, түзә алмыйча, ха-ха-хайлап көлә башлады.

— Сезнең мунча ташы тәмам шартларлык булып кызган икән. Алай ярамый. Сез бит, белүемчә, үзегез партия члены да.

Бу юлы Зариф профессорга ачулы бер караш ташлады.

— Әллә минем партоешмага хәбәр итәргә уйлыйсызмы? Адресын бирәм. Рәхим итегез. Тик аның бернинди файдасы чыкмас. Мин сезнең белән бу темага сөйләшүемне таначакмын. Ә шаһитлар юк. Әллә сез мине, ил үзгәргәндә, һәр кеше яңа сыйфатлар алганда, читтә калган дип уйлыйсызмы? Минем вөҗданым үземне саклау өчен теләсә нинди юл сайларга рөхсәт бирә.

— Сез юкка минем турыда шулай уйлыйсыз, кордаш. Мин просто үзем белгән дөреслекне аңлатырга тырышам.

— Мин дә аны нәкъ сезнең кадәр генә аңлата алам. Белмәссең, мин әле яхшырак та төшендерә ала торганмындыр бәлки.

Галиәкбәр сүз дәшмичә уйланып барды. Кешенең үз-үзен сөючәнлеге, эгоизмы никадәр көчле! Ул үзен гаделсезгә кыерсытылган зат дип исәпләсә, аңа идеалларың да, кыйблаң да берни түгел! Хәер, кешесенә караптыр анысы да. Галиәкбәр үзе дә һич гаделсез рәвештә институттан сөрелде түгелме соң? Тик аның башына да килгәне юк көфер уйлар.

Алар шулай байтак вакыт икесе дә эчтән дулкынланып, янәшә бара бирделәр.

— Ярар, — диде, ниһаять, Зариф, — бу темага сөйләшергә теләмисез икән, мин сезгә аны көчләп тага алмыйм. Семья-көнкүреш хәлләренә кайтыйк. Сезнең карчык вафат дидегез бугай?

— Әйе, вафат булып китте шул, моннан ике ел элек.

— Минем алай үлүен үлмәде, тик бу малай актыгы аны үтерер инде, мөгаен. Егетнең семьясын ташлап качу хәбәре килеп житү белән ул түшәккә ауды. Болай да стенокардия приступлары була иде. Инде тәгаен башы бетә шул малай актыгы аркасында.

— Нигә шул кадәр авыр кичерә соң? Дөньяда булмый торган хәлмени? Бәлки ул бәхетен эзләп киткәндер?

— Балалары жәл. Тилмерешеп торалар. Үзләре берсеннән берсе, илаһым, матурлардыр. Акыллылар. Әтиләрен өзелеп яраталар. Хәзер инде бөтенләй бетерештеләр. Һәр көн иртә торгач, әти, әти, әти кайтмадымы дип, елыйлар икән. Ә безнең йөрәк авырта, безнең дә елыйсы килә. Ятим калдылар бит инде фактически.

Галиәкбәр тирән итеп сулап куйды. Ул Лианасын хәтерләде. Аның иптәшләре чана шуып уйнаганда япа-ялгызы читтә бөрешеп басып торуын күз алдына китерде.

— Шулай икән, — дип куйды, — сезнең тормышның да жае киткән икән, алайса.

— Житмәсә малай үзе безнең балалар арасында төпчегебез, иң яратканыбыз иде. Кадерләп тәрбияләп үстердек. Әнисе инде бичара, улым, Фәритем, дип өзелеп торды. Үз авызыннан өзеп ашатты...

Галиәкбәр картны бүлдерде.

— Туктагыз, кем дисез исемен?

— Кемнең?

— Соң улыгызның инде.

— Әйтәм ич — Фәрит, аты коргырының исемé. Ул менә шушы кош фабрикасына килеп баш белгеч булып урнашкан.

Галиәкбәр артык бара алмас булып тукталып калды. Йөрәк кинәт каты чәнчешеп авыртып китте.

— Ни булды? — диде Зариф, картның йөрәген тотып туктап калганына сәерсенеп.

— Йөрәк, йөрәк, — диде Галиәкбәр. — Ул шулай кайчагында барахлит итә. Хәзер узар.

Алар юл уртасында туктап, бер-беренә текәлгән хәлдә, авырткан йөрәкнең рәткә керүен көттеләр. Ниһаять, профессор иркен бер сулыш алды. Авырту басыла төште.

— Кесәдә валидол-мазар, я нитроглицерин йөртергә иде йөрәк чирле булгач, — диде Зариф.

— Онытылган шул, өйдә калган, — диде Галиәкбәр.

Алар борылып әкрен генә килгән юлларыннан кире поселокка таба юнәлделәр. Галиәкбәрнең Зарифка Фәрит турында сиздермәскә көче житте. Аның Фәритне бик яхшы белүен, алай гына да түгел, егетнең кызына тәкъдим ясавын, инде эшнең бик зурга киткәнлеген, аларның барысы да, шул жөмләдән Галиәкбәрнең үзе дә, туй турында уйлануын әйтмәскә булды. Ләкин хәзер бер нәрсәне генә аңламыйча баш ватып азаплана иде. Ул да булса: Әлфия беләме соң бу хәлләрне? Ул бит бер генә тапкыр да кызыннан егетеңнең узган тормышын беләсеңме соң син дип сорамады. Гажәп, нигә сорамагандыр?! Ә кыз боларның барысын да белгән булса? Белгән хәлдә дә кияүгә чыгарга атлыгып торса. Әллә бәлкем... Галиәкбәр ни дип тә уйларга белмәде. Бары ул чын күңеленнән Әлфиясе, аның бердәнбер күз тоткан кадерле кызы, бәхетсезлеккә генә очрап харап булмасын иде дип кайгыра иде.

Галиәкбәр, никадәр арыган булмасын, поселокка кайту белән Әлфияне күрер өчен фабрика территориясенә кереп китте. Вакытка караганда, Әлфиянең эш сәгатьләре бетмәгән, лабораториясендә булырга тиеш. Галиәкбәргә сынаулар уздыру дәверенә территориягә керү өчен пропуск бирелгән иде. Ул, аякларының авыртуына карамастан, соңга калмагаем дигәндәй, корпуслар арасыннан юлсыз-нисез, аксый-туксый ашыгып баруында булды. Менә ул ике катлы җыйнак кына таш бина, аның өске катында лаборатория, аста азыклар эшкәртү урыны. Анда — төрле болгатчыклар, май эретү өчен җылыткычлар. Стеналарга он тузаны кунган. Бинага кергәч, карт бераз машиналар тавышына һәм карангылыкка ияләшә алмый аптырап калды. Күрәсең, лампочкаларның барысы да яндырылмаган. Карт кармаланып алга китте. Монда ул һаман ашыга иде әле. Менә ул, ачык ишектән кереп, яктыга эләкте. Шактый текә баскычтан өскә менә башлады. Хәзер машиналар тавышы ишек артыннан тонык кына булып ишетелә. Аның каравы, өстә Әлфиянең шатланып көлүе, үзенең иптәшенә гамьсез рәвештә нидер сөйләве колакка керә. Карт артык менә алмас булып, урталыкта туктап калды. Кем белә, бәлки Әлфия бу хәлне белмидер, ә? Әгәр белмәгән булса? Ничек кабул итәр соң ул мондый дәһшәтле хәбәрне? Тик барыбер әйтергә кирәк. Юкса, соң булуы бар.

Галиәкбәр тагын бер баскычка өскә күтәрелде, һәм тагы икеләнеп тукталып калды. Тукта, ничек дип белдерер соң әле ул? Болай капылт кына әйтеп булмый бит. Нииндидер әзерлек кирәк. Аны шушы авыр хәбәрне ишетүгә әзерлисе бар. Юкса, белмәссең, әллә ни белән бетәр.

Профессор тагы бераз уйланып торды да, аның бер карарга килеп, баскычтан кире төшә башлады. Хәзер, аның фикеренчә, башта Фәритне күрергә, аның күзләренә туп-туры карап барлык дөреслекне сорарга, инде аннан соңын күз күрер.

Шулай да профессорның күңел түрендә: «Мондый ук ялган була алмас. Фәрит акыллы егет, интеллигент. Ул үзенең кем икәнлеген танытмыйча торып, Әлфиягә тәкъдим ясый алмас. Бу мөмкин эш түгел», дигән ышаныч ята иде. Хәлбуки, мондый гоманның да очы очка ялганмаганлыгы сиземләнә кебек хәзер. Димәк, Әлфия мәхәббәт исереклегеннән тәмам башын югалтып, кеше гаиләсен җимерү кебек җинаятькә кадәр барып җиткән... Юк, монысы да һич мөмкин түгел. Галиәкбәр Әлфияне белмимени? Ул аның нинди очракта нәрсә уйлаячагына кадәр белеп тора, ә инде нинди гамәл кылачагы турында әйткән дә юк.

Галиәкбәр уң аягына тагы да көчлерәк аксый төшеп, каударланып, территория аша узды да, контроль капкадан чыгып китте. Фабриканың конторасы янында директорның кара «Волга»сы күзенә чалынды. Директор әле һаман Казанга китә алмаган икән дигән уй картның күп уйлары арасында буталып башыннан узды.

Галиәкбәр ашыгып контора баскычыннан менә башлады. Аның исәбе хәзер ук Фәритне күреп, аның белән ачыктан-ачык сүз башлау иде. Ләкин бу мөмкин булмады. Чөнки баш белгеч бүлмәсендә беркем дә юк, хәтта ул бикле иде. Профессор аптырап ишек янында торганда, картка ислемай исләрен бөркеп, янынннан директорның секретаре Лиза узып китте. Ул бераз баргач, тукталды да елмаеп сорады:

— Сезгә Фәрит Зарипович кирәк идеме?

— Әйе, ул кирәк иде.

— Ул директор кабинетында. Иптәш Гатауллин Казанга китәр алдыннан баш белгечләр белән киңәшмә уздыра.

Галиәкбәр сүз дәшмәде, янбашларын уйнатып көяз генә кәс-кәс атлаган Лизаны берни дә күрми торган караш белән озатты.

Туташ коридор буйлап шактый ерак киткәч кенә искәрде: озак булыр микән соң киңәшмә, дип сорарга кирәген уйлады. Хәер, дип куйды ул, машинасы инде көтеп тора ич, озакка сузылмаска тиеш.

Галиәкбәр кинәт гәүдәсендә талгын, сулкылдап тора торган ару, хәлсезлек тойды. Балтыр итләре дә шактый нык сызлый иде. Ул коридор очында күренгән артсыз утыргычка юнәлде. Сулавы авыр. Гомумән, аңа бик авыр иде. Ул хәзер бик кадерле кешесенең суга батуын күзәткән хәлдә, бернинди дә ярдәм күрсәтә алмаган бер кеше кебек иде.

— Күрәчәгең булса, күрәчәгең булса, — дип авыз эченнән иреннәрен чак хәрәкәтләндереп кабатлады ул утыргач. Бүген ул урманнан йөреп кергәч, саф баш белән бик әйбәтләп Эльвира Хәкимовнага хат язмакчы иде. Хатның кайбер урыннарын ул күңеленнән әзерләгән дә иде инде. Ләкин хәзер зур өр-яңа кайгы барысын да җилдәй өреп чыгарды. Бары үзе генә дәһшәткә әверелеп, камил хуҗа булып, бөтерелеп уйный башлады.

Шулай хәрәкәтсез шактый утыргач, карт, ниһаять, үз-үзеннән, сүзне нидән башларга соң? — дип сорады. Кинәт бер ишектән фабриканың баш бухгалтеры килеп чыкты. Бу пумала башлы кеше профессорга таныш. Ачык чырай белән туп-туры Галиәкбәр янына килеп кул бирде, картның нишләп монда утыруы белән кызыксынды.

— Монда утырмагыз, профессор, — диде, — килешмәгәнне. Әйдәгез безнең бүлмәгә.

— Рәхмәт, мина монда да начар түгел, — диде профессор. Чыннан да, аның хәзер беркемне дә күрәсе килми иде. Бераздан аңа эссе булып китте. Ул бүреген салып тәрәзә төбенә ташлады, бишмәт изүен ычкындырды.

Юраганы дөрескә чыкты, киңәшмә озак бармады. Бер унбиш минутлар узмагандыр, директор кабинеты ачылып китте, шаулашып фабриканың баш белгечләре, директор үзе, аның урынбасары чыктылар. Профессорны күрү белән барысы да аның янына килде. Исәнләштеләр. Олыгая башлаган, такыр башлы, тулы яңаклы директор, нинди йомыш, Галиәкбәр абый, дип татарча сорады. Ул юлга җыенган, шуңа күрәөске киемнәрдән иде инде.

— Мин менә Фәрит Зариповичны... — диде Галиәкбәр һәм, үзе дә аңламастан, һич кирәк булмаса да, елмаеп куйды.

— Рәхим итегез, — диде Гатауллин, — Фәритне сезнең карамакка тапшырам, теләсә нишләтә аласыз, сезнең ихтыяр.

Фәрит ак тешләрен балкытып сөйкемле елмайган килеш, профессорга текәлгән иде. Директор үзен озата чыккан кешеләр белән берлектә, аскы катка төшеп китте. Фәрит исә һаман елмаеп, Галиәкбәргә:

— Әйдәгез, рәхим итегез, — дип, ишекне ачып, кабинетына керергә ишарә ясады.

Бүлмәгә керү белән Галиәкбәр шактый коры тон белән хәзер үк ишекне бикләп алырга кушты.

Фәрит сәерсенде, мәгәр шомланып картның әмерен үтәде.

— Сезнең белән минем сүз бик җитди булачак, — диде профессор, өстәл янындагы буш утыргычка утыргач. Фәрит хәвефле бер эшнең якынлашуын тойды. Шунда ук үзен тынычландырырга теләде.

— Теге сынаулар турындамы? — дигән булды.

Профессор сынау һәм нәфрәт ташып торган күзләре белән Фәритнең матур, ләкин хәзер ничектер ачу китергеч хаинлек чагылган йөзенә сүзсез генә карап торды.

— Юк, сынаулар турында башка вакытта. Хәзер мин сезгә менә нәрсә әйтергә тиеш. — Ул тертелеп калды. — Менә нәрсә... Бүген урманда бер олы кеше белән очраштым. Ул сезнең этиегезме?

Фәрит агарынып китте, җилкәләрен җыерып куйды, әйе, аңа хәзер барысы да аңлашыла. Тик аның хөкемендә вакытны сузу чарасы гына калды.

— Бер дә әйтә алмыйм, Галиәкбәр Хафизович, урманда олы кешеләр күп булыр ул.

— Кара кыска туннан, боярка бүректән...

— Бәлки шулдыр...

— Димәк, әтиегез биредә сезнең?

— Әйе, ул моннан бер атналар чамасы элек... кунакка килде.

— Кунакка?

— Ну, кунакка дип, — Фәрит күзгә күренеп каушый башлады. Ә Галиәкбәрнең күзләрендәге нәфрәт очкыннары аның саен көчәя барды.

— Менә нәрсә, — диде Галиәкбәр еш-еш сулап. — Сез, аның сөйләвенә караганда, үзегезнең хатыныгызны һәм балагызны калдырып, дөресрәге, алардан качып, аларны ташлап килгәнсез икән монда. Шул дөресме?

Фәритнең агарынган йөзе кинәт кызара башлады. Бу гаҗизлектән туган яшәү, котылу өчен эчке бер омтылыш иде. Ул кресло таянсаларындагы терсәкләрендә күтәрелә төшеп, кинәт башын калкытты.

— Әйтегезче, Галиәкбәр ага, мин сезгә шәхси тормышым турында ни өчен отчет бирергә тиеш әле?

Фәрит артык каты кычкырып әйтте сүзләрен.

— Кычкырмагыз, — диде карт, шактый тыныч калып. — Әгәр мин сезнең өчен профессор гына булсам, ул отчетны бирмәскә хакыгыз бар. Ләкин мин Казаннан килгән бер белгеч кенә түгел... мин, аңларга тиеш сез, аңларга тиеш, мин сез кулын сораган кызның әтисе дә.

Галиәкбәр буылып ютәлләргә кереште. Ул йөрәгенең, күкрәк читлегеннән чыгып китәрдәй, каты тибүен тоя, хәтта ишетә, ә колакларында телеграмм баганалары чыңлаган авазлар яңгырый иде.

Фәрит башын аска иде. Ул да еш-еш сулый, һәм үзенең котчыккыч бер кабахәтлек эшләвен һәм хурлыклы рәвештә фаш ителгәнлеген күңел сызларлык ачык итеп тоя иде. Ул Галиәкбәргә карамыйча гына: «Гафу итегез мине зинһар өчен, — дип мыгырданды. — Әтинең сезгә әйткәннәре дөрес, ул мине алып китәргә килгән...»

Галиәкбәр үзе өчен иң мөһим һәм авыр сорауны бирергә җөрьәт итте:

— Сезнең шундый кеше икәнлегегезне... Әлфия беләме?

Дәһшәтле тынлык урнашты. Җавапның нинди булуы, карт фикеренчә, җан бәясенә торырлык бер нәрсә иде. Фәрит башын күтәреп, ниһаять, картка текәлде.

— Юк, белми ул. Мин аңа әйтмәдем.

— Димәк, сез аны алдагансыз?

— Юк, мин аны алдамадым, мин бары әйтмәдем генә.

Карт нәфрәтле бер елмаю белән Фәриткә:

— Әйтмәү ул бу очракта — шул ук алдау, кем... — диде.

— Мин хатыным белән яши алмадым. Мин аны яратмадым. Аннан бизеп, тәмам алҗып, бернигә дә карамастан, качып китәргә мәҗбүр булдым...

— Андый хәлнең булуы бик мөмкин.

— Аннан менә монда килдем. Ә монда Әлфия. Мин аны бик яраттым. Әле дә мин аны җанымнан кадерлерәк бер фәрештә итеп саныйм. Мин аны сөям. Минем әле мондый мәхәббәтне үз гомеремдә татыганым юк иде... Сез аңларга тырышыгыз. Менә шул ратуым аркасында, аны, Әлфияне, югалтудан куркып мин... яшерергә мәҗбүр булдым. Әйтсәм, ул мине яратмый башлар, минем мәхәббәтемне йөрәгеннән йолкып алып ташлар дип курыктым.

Егетнең әйткәннәрен һич өнәмичә башын селкеп утырды карт.

— Андый мәхәббәтне чын мәхәббәт дип атамыйлар. Сезнең мәхәббәт ул эгоист мәхәббәте.

— Ни өчен? — диде Фәрит бик аптырап.

— Чын мәхәббәт ул яраткан кешеңә яхшылык эшләргә ашкынудан гыйбарәт. Сез Әлфиягә, интим тойгыларыгызны ачу белән бер үк вакытта, кем булуыгыз турында да әйтергә тиеш идегез.

— Мин курыктым.

— Сез үзегезгә начар булмагае дип курыккансыз. Мондый курку эгоистка гына хас.

— Юк, алай түгел. Мин аның үземне шулай ук яратканлыгын белдем. Мин аның бәгыренә канлы яра ясап, аның күңелен җәрәхәтләүдән курыктым.

— Әгәр башта ук әйткән булсагыз, бәлки ул сезгә башкачарак карар иде.

Фәрит биреште.

— Әйе, мин гаепле, теләсәгез нишләтегез, — диде.

Галиәкбәрнең күңеле бераз тынычлангандай булды. Һәрхәлдә, ул үзенең хәлне дөрес бәяләвен егеттән дә икърар иттерде. Ләкин әле картны куркыткан тагы бер нәрсә бар иде, Галиәкбәр шуңа күчәргә булды.

— Ярар, монысы миңа аңлашылды, — диде ул. — Инде мин сезнең белән ирләрчә сөйләшмәкче булам.

Фәрит аңлады.

— Бу хакта тыныч була аласыз.

Ирексездән Фәритнең күз алдыннан барысы да кино тасмасындагы кадрлар кебек бер-бер артлы узды. Булды андый мөмкинлекләр. Ләкин Фәритнең вөҗданы аңа бу хокуктан файдаланырга ирек бирмәде.

— Юк,— диде Фәрит,— монысы турында минем намусым пакь, чиста.

Галиәкбәр урыныннан торып өстәлдә яткан бүреген кулына алды. Пальто төймәләрен ашыкмыйча гына каптыргач, башына бүреген киярга онытып:

— Бүген сәгать җидедә сез безгә киләсез һәм минем алдымда Әлфиядән гафу үтенеп, барлык дөреслекне сөйләп бирәсез! — диде.

Аның йөзе бу минутта аерата карт, үзе бетерешкән кебек тоелды Фәриткә. Галиәкбәр, иелә төшеп, һәм элеккедән дә ныграк аксаклап, бүлмәдән чыгып китте.

Бүген, иртәнге яктан буранлап торса да, өйләгә таба көн тәмам ачылып, җылынып китте. Хәзер өй кыекларыннан тамчылар тама, тротуар читләренә өелгән карлар чәрдәкләнә үк башлаган.

Галиәкбәр өйгә кайтып керү белән Эльвира Хакимовнага хат язарга теләгән иде. Кайтып өстәлдә Әлфия әзерләп калдырган табынны күргәч, гаҗәпсенеп әле бүген иртәдән бирле үзенең ашамаганлыгын хәтерләде. Ләкин аның ашыйсы килми иде. Аракы эчкәч кенә аш аппетитлырак булыр кебек тоелды. Кечкенә кастрюльдәге ашны ул газ плитәсенә җылынырга куйды, үзе олы якка чыгып, сервантны ачты.

Аракысы төбендә генә калган шешәне тоткан килеш, ул озак вакыт онытылып идән уртасында басып торды. Аңа Казанда Сафура белән яшәү ифрат авыр иде. Ул үзенә монда тынычлык табарга теләде һәм тапкан кебек тә булды. Ләкин нәрсә килеп чыкты соң? Нәрсә булып бетәчәк бу тамаша? Ярый ла Әлфиянең бу авыр кичерешләрдән соң канатлары сынмаса! Ярый ла ул үзенең гүзәллеген, гүзәллегенә лаек әйбәт горурлыгын һәм барыннан да битәр кешеләргә ышанычын югалтмаса.

Карт шул турыда уйлый иде.

## 4

Әлфия бүген чак кына соңгарак калып кайтты. Галиәкбәргә аның күңеле гадәттәгедән дә күтәренкерәк кебек тоелды. Кыз, кайтып керү белән, иртәге көнгә дигән ашын салды. Чәй кайнатып, чәй алдына коймак пешереп алды. Табын янында, шат күңелле кешегә хас булганча, өзлексез көлкеле хәбәрләр, вакыйгалар сөйләп утырды. Ә чәйдән соң бик тиз генә савыт-сабасын да юып куйды, ит пешкәнче утырыйм әле дип, әтисе янына телевизор карарга чыкты.

Сәгать җиденче ярты иде инде. Галиәкбәр әледән-әле кул сәгатенә караштыргалап Фәрит турында уйланды. Килерме, юкмы? Картның сүзен тыңларга йөрәге житәрме? Әллә шүрләп, дөреслекне сөйгәненнән һаман яшереп ятармы? Бер караганда ул килергә тиеш иде кебек, әкем белә. Бәлки хәзер барысы да бетте, барыбер кызына карт үзе әйтер дип килергә куркыр. Сәгать уклары җидегә якынлашкан саен картның күңелен билгесезлек ныграк борчый бара иде.

Әмма барысыннан да куркынычрагы, Әлфиянең бу хәбәрне ничек, ни рәвештә кабул итүе иде. Монысын инде Галиәкбәр бер ничек тә юрый алмады. Чөнки анысы кызның егетне ни дәрәҗәдә ярәтуына бәйләнгән булырга тиеш. Мәсәлән, ул үзе никадәр яратмасын, сөйгәненең үзенә хыянәт ясап яшәвен белсә, мәхәббәтен шундук нәфрәткә әйләндерә алырга сәләтле кеше дип исәпли. Хәер, дип уйланды ул телевизор караган арада, хәзерге яшьләрне белмәссең. Карт телевизор карый, андагы бозды тимер аяк шуучы парлардан күзен алмый, үзе һаман, һаман, инде менә күпме вакыт, бер үк нәрсә турында баш вата. Ниндидер үзгәрешне Әлфия дә сизенде. Әле бая чәй янында ук, ул сөйләгәнне картның гадәттәгечә җөпләп, игътибар белән тыңламавына ирексездән игътибар итте бит ул.

— Әллә син авырыйсыңмы, әти? — диде борчылып.

— Юк, юк, — диде Галиәкбәр, — диссертация... Сөйлә, сөйлә.

Шуннан Әлфия, аның сәер халәтенә артык игътибар итмәстән, сөйләвен дәвам иттерде. Хәзер исә ул, әтисе белән янәшә утырып, җилдәй бөтерелгән тимер аяк шуучылар белән мавыкты, хәтта әтисе турында бөтенләй онытып та җибәрде.

Сәгать җиде тулырга биш минут калды. Галиәкбәр йөрәгенең авырттырып тибә башлавын тойды. Менә ул озакламый килеп керер һәм Галиәкбәр көткән, куркып көткән хәлләр башланыр.

Ул урыныннан торды да түземсезлек белән коридорга чыкты. Ишек янына килеп аяк тавышларын тыңларга кереште. Кемдер аскы ишектән керде. Ишекнең шапылдап ябылуы ачык ишетелде. «Шул» дигән уй килде картның башына, чөнки сәгать угы нәкъ җиделе цифр өстенә менгән иде инде. Энә минут күрсәткече калтыранып уникеле өстеннән узды... Тик баскычтан менүче кеше Әлфия квартирасына тукталмады, күрше ишек звоногын басты. «Юк, булмады инде болай булгач», дип уйлады Галиәкбәр, күңелендә Фәриткә карата нәфрәт ни кадәр артмасын, аңа хәзер ничектер җиңелрәк булып китте. Теге баягы дәһшәт сөремнәре хәзер профессорның күңелен борчымый иде. Ул яңадан кызы янына телевизор карарга кереп утырды.

Галиәкбәр инде Фәритнең бүген килмәячәген үзе өчен ачыклагач кына, кинәт кемдер озаклап ишек звоногына баса башлады. Икесе дә бердәм утырган урыннарыннан күтәрелделәр.

— Үзем, — диде Әлфия, һәм җиңел адымнар белән ишек ачарга чыгып китте.

Карт барлык игътибарын хәзер коридорга юнәлткән иде. Кызының ишек ачу белән шатланып «Фәрит» дигәнен ишеткәч тә Галиәкбәр, үзе дә тоймастан, телевизорны сүндерде.

Бүлмәгә алдан Фәрит, аның артыннан Әлфия килеп керделәр. Фәрит салмыш иде. Аның күзләре ялтырый, йөзенә кызыллык йөгергән, ул профессорга, һич югында, әдәп саклап булса да игътибар күрсәтмәде, өске киемнәрен салмастан, стена буендагы диван-караватка барып утырды.

— Әл-фия, — диде ул тотлыга төшеп. Тукталып торды. — Әл-фия! Аның шушындый хәленә хәйран калган кыз һичбер нәрсә аңламыйча аңа сүзсез текәлде.

— Сиңа сөйләмәдеме этиең?

— Нәрсә сөйләмәдеме? — диде тәмам аптырашка калган Әлфия. Ул бер мәл Фәрит шулай юри шаярта дип тә уйлаган иде, тик аның чыннан да эчкән булуын аңкып торган аракы исеннән сизгәч, ни әйтергә дә, ни уйларга да белмәстән, гаҗиз булып торды.

— Минем турыда, — диде Фәрит. Аның теле бәйләнгәнлеге хәзер бик ачык сизелә иде. — Минем турыда, — диде ул кабатлап, — минем сине моңарчы алдап, хатыным, ике балам бар өстеннән сине алдап, мин егет кеше, дип йөргәнем турында берни дә әйтмәдеме?

Әлфия кинәт илереп этисенә мөрәҗәгать итте.

— Эти! Нәрсә сөйли ул?

— Нәрсә сөйләсә дә, сабырыңны югалтмыйча гына тыңла әле, кызым.

Кыз атылып Фәрит янына килде, аның иңбашларына кулларын салды.

— Нәрсә сөйлисең син, Фәрит, кабатла әле, кабатла!

Фәрит, йокысыннан уянып киткәндәй, башын артка ташлап тузган чәчләрен дуылдатып алды. Һәм кинәт маңгае белән Әлфиягә терәлеп тынып калды. Аның әледән-әле иңбашларын сикертүе генә үкси башлаганлыгын аңлата иде.

— Эти, нишли бу, нәрсә сөйли? — диде Әлфия. Хәзер инде егетнең шыңшып елавы ачык ишетелде.

— Минемчә, ул, кызым, үзенең моңарчы сине алдап йөрүен бик ачык итеп әйтеп бирде, — диде карт. Фәритнең елап утыруы аның ачуын китерә иде. Әйтми түзмәде:

— Егетлек түгел бу, Фәрит. Син үзеңнең күренекле белгеч булуыңны да онытма.

Әлфия егетнең култык асларыннан эләктереп алды, артык гасабиланганда гына була торган көч-гайрәт белән аны урыныннан күтәреп торгызды.

— Фәрит дим, акыллым, син бүген аллә нишләгәнсең, әйдәле юын. — Ул аны юыну бүлмәсенә җилтерәтеп алып чыгып китте.

Бераздан соң кызның «яле», «менә шулай» дигән сүзләре һәм краннан шарлап су акканы ишетелде. Галиәкбәр Әлфиянең ышанмавын, егет бу сүзләрне бары исерек баштан гына әйтә дигән фикердә булуын аңлады, катнашмады, сабырлык белән азагын көтте. Әлфия белән Фәрит янадан бүлмәгә керделәр.

— Я, айныдыңмы, Фәрит, — диде Әлфия. Ул әле һаман башын иеп урталыкта басып торган Фәриткә елмаеп дәшергә дә үзендә көч тапты. Аны ипләп кенә кәнәфигә утыртты. Күзләренә туп-туры карап:

— Син бит ул сүзләрне исерек баштан гына... шулай бит? — диде. Егет, ыңгырашкан хәлдә, чәчен ике куллап артка сыпыра башлады. Чәч юеш, бармак араларыннан су тама иде.

— Я, әйт, шулай бит, — диде аңа Әлфия, бу юлы нелә төшеп. Кызның йөзендә ялыну, хәтта мескенлек чагылып китте.

— Мин сиңа ул сүзләрне исереклектән әйтмәдем, Әлфия, мин сине артык яратам, шуңа күрә моңарчы дөресен әйтә алмадым.

Әлфиянең кинәт төсе үзгәрде.

Син мине алдап йөргәнсең булып чыга бит. Синең хатының, балаларың...

Әлфия, артык берни дә әйтә алмастан, йөзен куллары белән каплап, Фәриттән читкәрәк китеп, диванга утырды. Галиәкбәр ашыгып кызы янына барды.

— Кызым, аппагым, тыныч кына, тыныч кына, — диде ул. Ни өчендер аның башыннан сыйпый башлады. Ләкин кыз еламый иде. Ул кулларын йөзеннән кинәт алды да тирән хәсрәт чагылган күзләрен тутырып, Галиәкбәргә төбәлде.

— Мөмкин булса, әти, безнең икебезне генә калдырсана.

Әйе, Галиәкбәр бая Фәриткә минем алда Әлфиягә үзең турында әйт дигәнгә күрә генә чыгып китмәгән иде. Мондый чакта өченче кешенең арада буталып йөрүе әйбәт түгел. Галиәкбәр: «Шулай, кызым, дөрес, үзегез аңлашыгыз», — диде дә коридорга чыгып киенә башлады.

Ишек ябылып, чыртлап бикләнгәч, Әлфия Фәриттән сорады:

— Миңа үзеңнең хатының, балаларың турында сөйлә.

Фәрит кулларын сузып Әлфияне кочакларга теләде булса кирәк. Ләкин Әлфия җитез генә урыныннан купты да телевизор янындагы утыргычка барып утырды.

— Әлфия, ышан, әгәр синдә миңа карата кеше буларак әз генә хөрмәт калган булса... Мин сине бик-бик яратам.

— Алдау белән мәхәббәт бергә була алалармы?

— Менә, күрәсең, була икән ич. Мин бары сине артык яратканга күрә генә үземнең хатынымны ташлап килүемне...

— Хатынымны һәм балаларымны...

— Әйе, хатынымны һәм балаларымны ташлап килүемне әйтмәдем. Мине яратмый башларсың дип курыктым.

— Мин синнән моны көтмәгән идем. Димәк, сереңне әти белмәгән булса, миңа әйтми яши бирер идең, ә мин сиңа һаман ышанып йөрер идем. Шулаймы?

— Мин аны сиңа, вакыты җиткәч, әйтми калмас идем, Әлфия.

— Вакыты? Кайчан соң аның вакыты? Шул җитми торып ник әйтергә булдың соң але?

— Әйтергә мәҗбүр иттеләр.

— Кем итте?

— Әтиең.

— Ничек инде? — диде Әлфия аптырап, — ул ничек сине мәҗбүр итә ала?

Фәриткә барысын да, үзен эзләп әтисенең монда килүен дә, бүген картларның урманда очрашып сөйләшүләрен дә, аннан соң Галиәкбәрнең Фәрит янына кереп катгый рәвештә ультиматум ясавын да сөйләргә туры килде.

Әтисенең башта ук үзенә әйтмәве Әлфияне бераз хафага төшерде. Тик ул эшнең асылын белмичә торып, дуамал нәтиҗәләр ясарга ашыкмады. Сәбәбе булгандыр, дип уйлады.

Шактый коры гына ул Фәриттән сораша башлады.

— Хатының нинди кеше?

— Бик начар кеше.

Әлфия һич үзенә хас булмаганча ачы елмаеп куйды.

— Шуңа күрә аннан качтыңмени? Ә балаларың? Алар да начармы?

— Син, Әлфия, мине алай рәнҗетмә!

— Нигә, мин сорыйм. Син кайчаннан бирле инде бездә? Син әле алимент түләүдән дә качып йөрисеңдер?

— Мин алиментка дигән акчаны җыеп барам. Берьюлы җибәрермен дип уйладым.

— Анысы нигә тагы?

— Чөнки мин аларга үземнең кайда икәнлегемне хәбәр итәргә теләмәдем.

— Курыктың, шулаймы?

— Әйе, курыктым. Монда килер, тагы миңа якты дөнья бетәр дип курыктым.

— Гаҗәп! Аның белән кешеләрчә шартын җиткереп аерылышырга мөмкин түгел идемени?

Фәрит, тотлыга-тотлыга, үзенең фаҗигасен озын-озак итеп сөйли башлады. Әлфия аны бүлдерми тыңлады. Ләкин кызның йөзендә хәзер элекке мөлаемлелек юк иде. Ниһаять, сүз беткәч, ул әйтте:

— Фәрит! Әгәр син миңа башта ук, танышканда ук, мин хатын аерган кеше, минем ике балам бар, — дисәң дә мин сине барыбер яратыр идем. Мәхәббәтнең ялгышуларны кичерерлек көче бар. Ул бары ялганны гына кичерә алмый.

— Мин бит бары әйтергә генә кыймадым, Әлфия, аңла...

— Син миңа бу турыда ничектер сүз чыккач, шаярган булып хәтта паспортыңны да күрсәттең. Хәтерлисеңме? Менә кара, мин егет кеше дидең.

— Хәтерлим.

— Бу коточкыч алдау түгелмени, Фәрит?

— Бу коточкыч алдау. Тик мин синнән бик-бик үтенәм. Кичер мине.

— Мондый зур хыянәтне кичерә алмыйм мин. Минем вөҗданым моңа рөхсәт бирми, Фәрит.

Фәрит бөтенләй айнып китте. Ул кулларын сузган килеш Әлфиягә таба атлады. Аның янына житкәч, тезләнеп кызның аякларын кочып кичерүен үтенә башлады. Аңа һич игътибар итмәстән, Әлфия, үз алдына сөйләнгәндәй, әйтте:

— Син минем бөтен якты өметләремне юкка чыгардың, Фәрит. Мин бит сине ихлас күңелдән сөйдем. Мин инде җилбәзәк үсмер түгел. Минем яратуым бик җитдиярату иде. Мин җүләрләнеп сиңа үземә ышанганнан да артык ышандым. Сине насыйбым, үземнең киләчәгем дип уйладым. Ничек шундый хыянәттән соң сезгә, ирләргә, ышанырга була. Я әйт?

Әлфиянең кинәт аскы ирене калтырана башлады. Күзләренә яшь тулды. Ул өстәлгә ауды да үксеп еларга тотынды. Фәрит исә кинәт аягүрә басты. Кызны каты итеп кочаклады. Ләкин моннан Әлфиянең егеткә булган нәфрәте артты гына. Ул барлык көченә Фәритне этеп җибәрде.

— Кит минем янымнан, кабахәт җан! Моннан соң якыныма киләсе булма!!

Фәрит каушап артка чигенде. Кая барырга белмичә, бәлки әле бу истерика[1] узар дигәндәй, урталыкта таптанып торды. Ләкин аның чыгып китмәвен күргәч, Әлфия ашыгып коридорга узды, ишекне төбенә кадәр ачып, чәрелдек ят бер тавыш белән кычкырды:

— Вон отсюда, кабахәт!!!

Галиәкбәр урамнан йөреп кайтканда Әлфия елаудан кызарып беткән күзләрен билгесез бер нәрсәгә текәгән хәлдә һаман өстәл янында утыра иде әле. Ул этисенең кайтып керүенә игътибар да итмәде.

## 5

Әлфиянең Фәриткә әйткәннәре ихлас күңелдән иде. Аның Фәриткәчә беркемне дә сөйгәне булмады. Күрәсең, билгеле шартлар кызны шулай тәрбияләгәннәрдер. Сафура белән бер үк гаиләдә үссәләр дә, Әл-

[1] Истерика — гасабиланып, шашынып холыксызлану.

фия апасыннан үзгә тәрбия — инсафлылык һәм тыйнаклылык тәрбиясе белән сугарылып үсте. Өйдә, әнисе янында, күбрәк булу да тиешле йогынты ясагандыр бәлки. Инде укый башлагач та ул Сафура кебек бер селтәнүдә барлык дәресен тәгәлләп үз ихтыярында кала торган сәләтле кеше булмады. Ул озаклап баш ватканнан соң гына, үзен каткат тикшереп, әгәр янында берәр кеше булса, аңардан шулай ук каткат сорашып, тәмам барысына да төшенгәч кенә, эшкә керешә. Өйгә бирелгән дәресне шулай озаклап тәгәлләгәндә инде йоклар вакытның килеп җиткәнен сизми дә кала иде. Аның дуслары күп булмады. Күрше кызы Әкълимә белән ахирәтләр иде алар. Әкълимә исә үзе дә юаш кына, оялчан гына, тыйнак һәм әрсезләнүне сөйми торган бер кыз иде. Әнә шул кыз белән алар бакчада да, мәктәптә дә бергә булдылар. Бергә курчак уйнадылар, тау шудылар, катокка йөрделәр, хәтта кинотеатрларда да янәшә утырдылар. Тик югары мәктәптә генә бергә булырга туры килмәде. Унынчы классны тәмамлар алдыннан Әкълимә бер исерек шоферның корбаны булды. Машина астына эләкте. Имгәнгән, изелгән хәлдә өч көн үлә алмыйча ятты, аннан мәңгегә күзләрен йомды... Бердәнбер кадерле дустыннан аерылу Әлфия өчен гомер буена яралары төзәлми торган авыр фаҗига булды. Бу югалтуны ул бик авыр кичерде. Күңелендә һәр даим бушлык тоеп яши башлады. Аңа бу бушлыкны тутырыр өчен кем белән булса да, тик үзен аңлый ала торган дус күргән берәр яшьтәш кирәк иде. Әлфия бу чакны җитлегеп килгән кыз. Аның түшләре тулышып тора. Бу йомры тыгыз нәрсәләр кызны оялта, шул ук вакытта талгын рәхәтлеккә ашыра, күңелне оета иде.

Көннәрдән бер көнне әниләре ике кызын да каршысына утыртты да кыз баланың интим тормыш нечкәлекләрен аңлата башлады. Әлфиянең исә болар турында әле укыганы да, ишеткәне дә юк иде. Шул чагында ничектер аның күзләре Сафурага төште. Әлфиянең гаҗәпләнүенә каршы, бу нәрсәләр Сафура өчен яңа түгел, имеш, әйтерсең лә Сафура бу мәсьәләдә әнисе кадәр генә түгел, ә артыграк та белә.

— Кызларым, сез икегез дә үсеп буйга җиттегез. Үзегезнең хатын, ана булырга тиешлегегезне, ил, кешеләр каршында җаваплы икәнлегегезне бер генә минутка да онытмагыз, — диде ул. Аның әйтүенчә, адәм баласының сыйфаты иң беренче чиратта ана кеше сыйфаты белән билгеләнә. Ана — ул кешене тудыручы, аны күкрәк сөте белән туендыручы гына түгел, ул аңа иң әйбәт тойгылар сеңдерүче. Ата кеше дә бик мөһим урын тотучы, ләкин аның бурычы ана белән баланы саклаудан гыйбарәт, ягъни кешелекнең сакчысы ул.

Сүз шушы җиргә җиткәч, Әлфиянең әле дә хәтерендә, Сафура түзмәде:

— И әни, сине философия укытучысы итеп кенә куярлык икән, — диде. Әлфиянең бит алмалары кызыша башлады. Сафураның ана сүзләренә шулай уен-көлке аша каравына ачуы килде. Үзе исә әнисенең һәрбер сүзен, якын күреп, күңеленә сеңдерә барды. Мәгъмүрә кызларына ир-ат белән мөнәсәбәт турында сөйли башлады. Аныңча, менә шул мөнәсәбәттә чагыла иде инде кыз баланың күркәм горурлыгы. Ул егетләр белән дә дус булырга тиеш. Егетләрне үз итеп, чын иптәш һәм яклаучы итеп карарга тиеш. Ләкин шул ук вакытта ир-атка хас бер кимчелекне дә онытмаска тиеш. Аларда нәсел арттыру, нинди генә юллар белән булса да, шуңа омтылу инстинкты бик көчле. Бу җан иясенә хас бер инстинкт, күп очракта мәхәббәткә үрелмәгән хәлдә үсә, ул күп очракта мәхәббәт тойгыларына буйсынмастан, хәтта кайбер вакыт аңа капма-каршы рәвештә дә яши ала. Мондый үзенчәлекне ихтыяр көче белән дә бик күп ир-ат җиңә алмый. Бик күп очракта ир кеше, бик намуслы булса да, үзенең изге тойгылары белән җенси канәгатьләнү теләген гармониядә саклый алмый. Менә калганын сез үзегез аңларга тиеш

инде, балалар. Аннан соң Мәгъмүрә балаларына үзе эшли торган бала табу клиникасындагы хәлләр турында сөйләп китте. Ничәмә кыз уйнаштан бала китергән. Бәлки ана киләчәктә үз бәхетен үзе табар, ләкин андый балалар бит «әтием бар!» дигән бик кирәкле, горур тойгыдан мәхрүм булып үсәчәкләр. Аларның күңелләре китек булачак һәм ул, гомер буе, күләгәндәй, синнән калмаячак.

Мәгъмүрә кызларына ул көнне бик күп киңәшләр бирде. Күрәсең, буйга җиткән кыз бала моңа мохтаҗдыр. Әлфия, әледән-әле оялып кызарынса да, ул вакыт әнисен ихлас күңелдән тыңлады һәм ул сүзләрне беркайчан да онытмады. Алай гына да түгел, ул аларны һәр вакыт гамәлдә кулланды.

Ул сигезенче класста укыганда ук тугызынчы, унынчы класс малайлары аңа игътибар итә башлады. Кайбер азгынраклары хәтта аны кочакларга, үбәргә дә чамалап карады. Тик Әлфиянең талканы коры булды. Ул андый салам сыйракларны бик тиз акылга утырта иде. Дөресен генә әйткәндә, аның үбешеп карыйсы килә. Чөнки класстагы кызлар үзләренең кемнәр белән үбешкәнлекләрен әйтеп, әнә ничек мактаналар. Бәлки ул бик татлы нәрсәдер. Әйе, Әлфиянең бер тапкыр гына булса да күңеленә ошый төшкән егет белән үбешеп карыйсы килә иде. Тик ул курыкты. Изрәп төшәрмен, егет миннән башкасын таләп итәр дә мин каршы тора алмам, гомерлек бәхетсезлеккә дучар булырмын дип курыкты. Шулай ул һәрбер үзенә мәхәббәт изһар иткән һәм үзен үбәргә чамалаган егетне яныннан куа торды. Инде институтка кереп укый башлагач көтелмәгән бер хәл булды. Ниндидер мөнәсәбәт белән уздырылган кичәдән кайтышлый, үзен озата килгән егет рөхсәтсез-нисез Әлфияне урамда кочаклады да һич абайламастан иреннәреннән суырып үпте. Кыз бермәлгә һушыннан язгандай булды. Күзләрен ачып каршында авызын ерып торган егетне күргәч, сиптсыз алчакны өзгәләп ташлардай булды. Селтәнде дә чалтыратып яңагына сукты, һәм, тырт борылып, китеп тә барды. Ә иртәгесен егет тораңтагы иптәшләренә бу вакыйганы сөйләгәндер, ахры, шул көннән соң егетләр Әлфиядән шүрли башлады. Инде кайбер шуграклары Әлфиягә йомышлары төшеп сүз башлаганда, кайчак мут күзләрен уйнатып, әмма яңакларын каплап сөйләшә торган булдылар. Әйе, Әлфия үз тирәсендәге егетләргә үзе белән сак мөгамәләдә булырга кирәклеген шулай төшендерде. Мәгәр үзе дә бер нәрсәне аңлады. Үбешүдән генә алай изрәп оеп китми икән ласа Әлфия! Шулай итеп, беренче үбелү аңа ниндидер кыюлык китерде. Ул үзен егетләр янында кыюрак тота башлады. Күңеленә якын тоелганнары белән уйнады, шаярды, мәгәр үбешсә дә бик сайлап кына, артыгын һич рөхсәт итмичә генә.

Дөрес, егетләр белән дә озаклап йөргән чаклары булды. Тик мәхәббәт идеме соң әле бу? Мәхәббәт түгел, бары бәйләнчек ир-аттан саклану чарасы гына иде. Чөнки бераүләре килде, икенчеләре китте. Ихтимал теге, әнисе әйткәнчә, нидер өмет итеп йөргәннәре дә булгандыр. Инде өметләре акланмагач, андыйлар җайлырак, күндәмрәк кемсә эзләп читләшкәннәрдер. Бик ихтимал, бәлки кызыйның үзендә дә гаеп булгандыр. Артыграк коры булмадымы икән Әлфия? Чөнки соңыннан ул, кешеләр белән аралашып, шактый тәҗрибә туплагач, шуны аңлады: егетләр артык кырыс, чебен тимәс чер итәр мимозалардан куркалар, андыйларны өнәмиләр икән. Ихластан сөйгән егеткә өмете өзелерлек бер генә тупаслык та эшләргә кирәк түгел. Ир-ат шул чагында гына кызга тартыла һәм бу якынлык тирән мәхәббәткә дә әйләнеп китүе мөмкин.

Әлфия үсә-үсә, җитлегә-җитлегә менә шуларны белде. Тик шулай да аның башын югалтып сөярлек бер генә кешесе дә булмады. Бераүләр якынайды, икенчеләр ераклашты. Ә айлар айларны, еллар елларны алыштырды. Гомер уза торды. Көннәрдән бер көнне Әлфиянең кү-

ңелендә «мин карт кыз бит инде» дигән дәһшәтле бер фикер туды. О, ул бу хәлнең нәрсә икәнен укып та, ишетеп-күреп тә белә иде. Хәтта кияүгә чыкмау аркасында акылына зәгыйфьлек килгән карт кызларны күргәне дә бар.

Боларын аңа акылы шулай сөйли иде. Әйе, кияү турында, киләчәк тормышы турында җитдирәк уйланырга акылы куша иде. Ләкин акыл белән хисләр гармониядә булмаса, болай гына тормыш корырга кирәк дип, кияүгә чыгулар ул фригизм[1] бәхетсезлеген кичергән хатыннарга гына ярый. Хәлбуки, Әлфиянең акылы гына түгел, кайнар тойгылары да аның мәхәббәткә, үз гомерендә бер генә тапкыр булса да кайнар мәхәббәткә сусаганлыгын исенә төшереп торалар иде. Ләкин сөйгән кешене заказ буенча ясатып буламени! Шулай гомер уза бирде. Инде институт еллары артта сагынып сөйләргә истәлек булып кына калды. Бөгелмәдә кош фабрикасында бик авыр узган, Әлфия беренче чирканчык алган хезмәт елы да онытылды. Янә анда тәҗрибә тупларга киткән ике ел да узды. Инде, ниһаять, менә бирегә, Кама кош фабрикасына килеп урнашу, эшне көйләп җибәрү чоры, бик мәшәкатьле көннәр. Ул да үтте...

Кошларны читлектә үстерү мәсьәләсе куелгач, бу эшне булдыра алмавын белдереп, баш зоотехник эшеннән китте, яңа белгеч эзләү башланды. Нинди генә кеше килер икән инде дип, барысы да төрле гоманнар корган чак иде. Көннәрдән беркөнне көндезге аш вакытында барлык белгечләрне һәм сменадагы эшчеләрне директор кабинеты каршысындагы конференц-залга чакырдылар. Зал алдындагы өстәл янында директор белән янәшә чибәр генә кара тутлы бер яшь кеше утыра иде. Халык җыелып бетү белән Гатауллин торып, гадәтенчә, һәр вакыт тирләүчән такыр башын зур кулъяулыгы белән сөртте дә:

— Иптәшләр, без соңгы вакытта аерата зарыгып көткән белгеч килде. Таныш булыгыз, безнең баш зоотехнигыбыз Фәрит Зарипович Еникеев, — диде. Фәрит җитди кыяфәттә торып басты, сизелер-сизелмәс кенә ияк кагып куйды. Әлфия кинәт күңеленең ни өчендер дүрт итеп тетрәнеп китүен тойды. Була бит шундый сөйкемле кешеләр! Фәрит тә әнә шундый ягымлы булып күренде кызга. Бу кыска җыелыш Фәритне таныштыру өчен иде, ләкин директорның белгечләргә, эшчеләргә әйтәсе сүзе бетәмени! Гатауллин эш буенча сөйләп алды. Моңарчы вакытлыча баш зоотехник хезмәтен башкаручы Елена Ивановнага да сүз бирелде. Хәтта «тавышыгызны ишеттерү өчен генә булса да» дип Фәриткә дә сүз бирделәр. Әлфия яңа белгечтән күзләрен алмастан, аны тыңлап утырды. Русчасы әйбәт иде егетнең, житез, елдам кеше булса кирәк, ни арада фабрика турында шул кадәр күп мәгълүмат җыеп өлгергән диген әле син! Хәтта кайбер цехларда бүген үк эшләнергә тиешле нәрсәләр турында да әйтергә җөрьәт итте Фәрит. Әйткәннәре, чыннан да, кирәкле нәрсәләр иде. Кыска, ләкин ышандырырлык итеп, чак кына көлемсерәп, бик тыйнак кыланып сөйләде. Тәгаен әйткән сүзләре һәм үзен тотышы белән үк ул көнне Фәрит барлык залның мәхәббәтен яулап алгандыр. Менә шулай булды беренче танышу. Ә аннан соң алар якыннанрак эш вакытында, лабораториядә таныштылар. Әлфия комбиазык пробасына аксымга Кьельдаль ысулы белән анализ ясый иде. Фәрит килеп керде. Ул бу юлы үзенең лаборатория, анализлар өлкәсендә дә шактый белемле һәм тәҗрибәле икәнлеген күрсәтте. Әлфия белән күптәнге иптәшләрчә тыныч кына һәм кызны якын күреп татарча сөйләште. Сораулар бирде. Каян, нинди уку йорты бетергән... Әлфиянең дә егет турында шактый нәрсәләр беләсе килде, ул да сорашты.

Әйе, бу очрашу, икәүдән-икәү сөйләшү аларны шактый якынайтты. Ә өченче тапкыр очрашканда аларның клубта, кино караганда урын-

---

[1] **Фригизм** — хатын-кызда очрый торган салкынлык, дәртсезлек чире.

нары янәшә булып чыкты. Әле көз башы иде. Кино бетеп урамга чыккач, Әлфия үзенең зур бер хата ясавын, плащ киеп чыкмавын искәрде. Инде яңгыр узар бәлки дип, түбә кыегына ышыкланып торганда аның янына Фәрит килеп чыкты.

— Яңгырдан куркасызмы? — диде ул. — Әйдәгез, минем өстемдә плащ, житмәсә әле зонтикны да кыстырып чыкканмын.

Ул зонтын ачты да Әлфияне каплады. Алар шулай бер зонт астында кайтырга чыктылар. Әгәр Әлфия хәзер барысын да хәтерләсә, шул көннең алар язмышында хәлиткеч бер мәл икәнлеген белер иде. Алар шуннан соң һәр вакыт дусларча якын мөнәсәбәттә булдылар. Ә бераздан аларга яз шатлыгыдай, көтелгән ак җилкәнле диңгез корабыдай гүзәл мәхәббәт үзенең исерткеч куанычларын бүләк итте.

Олы мәхәббәт бик нык сагынылган, зарыгып көтелгән бер тойгы булгангамы, Әлфия Фәриткә бик тиз ияләште. Әйтерсең лә алар бала вакыттан бирле бергә булганнар, бер-берсен яратып үскәннәр. Ничектер алар бик тиз, ым кагу белән аңлаша башладылар. Араларында бер генә дә бәхәс, үҗәтлек булмады аларның. Күрәсең, психологик бердәмлек бик көчле иде. Әлфия хәзер үзен дөньяда иң бәхетле кеше итеп сизә башлады. Эштә дә, көндәлек тормыш ыгы-зыгыларында да ул һәрбер җәрәхәткә, бәрелү-сугылуга каршы нык тора, сыкранмый, бирешми. Чөнки әйтеп бетермәслек якты бәхет аны, һәрдаим үз канат астына алып, хәвеф-хәтәрләрдән саклагандай иде.

Әлфия Фәритнең барлык булганын яратты: аның кызу-ныклы адымнарын да, төз атлет гәүдәсен дә, дулкынланып торган кара, ләкин ничектер яктылык төшкәндә аерым урыннары көрән төскә кереп елкылдаган куе чәчләрен дә... Колак йомшагына кадәр төшерелгән һәм кинәт кыек киселгән бакенбардлары да, куе кара кашлары да, озын керфекле эчкерсез елмаю белән балкыган күзләре дә, хәтта очы чак кына икегә аерылып торган кимерчек борыны да, чит-читләре өскәрәк күтәрелеп киткән, шуңа күрә егетнең йөзенә ягымлылык, якты чырайлылык биреп торган иреннәре дә — барысы-барысы да Әлфиягә искитмәле гүзәл, дөньяда тиңе булмаслык сокландыргыч булып күренәләр иде. Ул Фәритнең киң текә маңгаеннан үбәргә ярата иде. Фәрит исә Әлфиянең чокырланып торган бит очларыннан үбә.

Әйе, ул көннәрдә Әлфия үзен бәхетнең иң югары дәрәҗәсенә ирешкән кеше дип уйлый иде. Ул шат, көләч, аңа һәркем иң әлек әйбәт яклары белән чагыла. Ләкин аның күңелендә йөрәк түрендә — Фәрит, Фәрит саклана. Гадәттә үсмер чакны гына була торган, язгы ташудай, дуамал сөю килде кызга ул чакны. Әле ул мондый ук көчле тойгыларны кичергәне юк иде. Менә шундый иде Әлфиянең Фәриткә булган мәхәббәте...

Ләкин... бу мәхәббәт, өстенә авиабомба төшкән биек таш йорт кебек, бер мизгелдә гөрселдәп җимерелде. Инде шундый гали мәхәббәтнең күз ачып йомган арада юкка чыгуы кызның күңеленә нинди авыр җәрәхәтләр ясаганын аңлавы авыр түгел.

6

Эльвира Хәкимовнага институт канцеляриясеннән хат китереп тоттырдылар. Ул профессор Максудовтан иде. Күңеле белән доцент аннан хат көтә иде инде. Ни өчендер ул, Галиәкбәр диссертацияне күп дигәндә ике көндә укып чыгар да, шундук хат җибәрер яки телеграмма сугар дип өметләнгән иде. Инде икенче атна китте... Ниһаять, ул хат менә килде, ул Эльвираның кулында. Ул, әлбәттә, Эльвира өчен шатлыклы булачак. Эльвира тиз арада хезмәтен тиешенчә бастырып, төпләтеп, Мәскәүгә җибәрәчәк. Чөнки Эльвираның үз хезмәте камил икәнлегенә

нигездә шиге булмады. Инде Галиәкбәрдән ул да карап чыгуын үтенгән икән, бары ышанычы тагын да артсын өчен генә.

Эльвира үз кабинетында яшел постау белән тышланган болындай иркен өстәле янында ялгызы гына гыйльми журналлар актарып утыра иде. Конвертны ерту өчен ул прибор янындагы карандашлар, каләмнәр белән бергә мәрмәр савытка тыгып куелган кәгазь кискечне алды. Кискеч тә, Эльвира утырган иркен кәнәфи һәм шуңа тәңгәл өстәл кебек үк, борынгы заманнан калган әйбер, фил сөягеннән ясалган иде. Кайчандыр революциягә кадәр үк ул әйберләр шушы кафедрада булганнар. Кайчандыр институтка пар ат җиктереп кенә килә торган профессор файдаланган бу әйберләрдән. Буыннан-буынга күчә торгач, менә ул Эльвира Хәкимовна кулына килеп эләккән. Хәер, мөдир бүлмәсе башка иде инде хәзер. Бүлмә генә түгел, институтның бинасы үк яңа, сугыштан соң гына салынган.

Эльвира фин пычагына охшатып ясалган кискечне почмагына кертеп конвертны ертты да дәфтәр битләренә язылган хатны ачып укый башлады. Картның кулын ул әйбәт таный. Алты ел бергә эшләделәр, күп тапкыр профессорның язган методичкаларын, эш планнарын күчерергә туры килгән иде хатынга. Ул бик вак итеп йөгерек кулдан яза.

Эльвира хатны бар игътибарын җигеп укый башлады. Ләкин аның өмет чаткысы җемелдәгән күзләре, чак кына ачылып, елмаерга җыенган матур иреннәре кинәт рәвешләрен үзгәрттеләр. Хатынның йөзе агарганлыгы хәтта үзенә дә сизелде кебек.

— Ужас! — дип куйды ул хаттагы искәрмәләрнең әле беренче битендә язылганнарын укып чыккач. Ул хаттан аерылып, кафедраны моннан сиксән ел элек оештырган көрәк сакаллы профессорның каршы стенадагы портретына карап торды. Алтын йөгерткән рамлы портреттан аңа күзлек аша карт галим текәлгән иде. Ләкин Эльвира аның турында уйламады, карт галим хәтта аның күзләренә дә чалынмады. Ул хәзер бары үзенең диссертациясе, үзенең докторлык дәрәҗәсе турында гына уйлады. Батырчылык итеп ул хатның икенче битенә күчте. Кашлары җыерылды, күз карашлары сүрәнләнде. Ул, әледән-әле тукталып, башын чайкап тора, яки «я хода» дип әкрен генә мыгырданып куя. Инде ашыга-ашыга укый башлады: әйтерсең җимерелеп төшәргә торган күпердән үтә, әйтерсең ашыкса зур афәттән котылачак.

Хатны укып чыккач Эльвира шактый тавышланып: «Суйган мине бу карт», — дип куйды. Аның хәзер шушы вак хәрефләр тутырылган кәгазьне ертып ташлыйсы килә иде. Моны бер кем дә, хәтта ул үзе дә, күрмәскә тиеш. Инде нишләргә дип сорады ул үз-үзеннән. Карт аңа, артык борчылмыйча, тыныч кына, ашыкмыйча гына хезмәтне тулыландырырга, аннан төзәтергә, дөрес нәтиҗәләр ясарга кушкан. «Мондый хезмәт гомердә бер кабат кына башкарыла, гомер буе вөҗдан газабы кичермим дисәгез, минем сүзләремне тыңлагыз. Соңыннан рәхмәт әйтерсез әле бәлки», — дип язган карт. Әйе, ул язуын язган да, ләкин нинди сәбәпләр аны шул кадәр тырнак астыннан кер эзләргә мәҗбүр итте икән соң дигән фикер килде доцентның башына. Юкка чыгарыйм дисәң, кайсы хезмәтне пычратып булмый ул! Эльвира, эчке ихтыяҗга буйсынып, үзенең өстәле яныннан китүен һәм әрле-бирле бүлмә буенча йөренә башлавын да тоймады. Ул төрле юллар белән үзен акларга тырышты. «Кызык кеше булып чыкты безнең «бабай», дип уйланды ачы көлемсерәп. Диссертациянең, профессор гына түгел, ә членкор тарафыннан тикшерелеп чыгуын белми микәнни? Ул бит минем белән генә бәхәскә керми, минем консультантым членкор белән дә бәхәскә керә. «Ахмак» — дип куйды аннары ул ясалма бер чыркылдау белән. Ләкин, ни әйтсәң дә, Галиәкбәр сан материалы белән эш иткән. Ул бит исәп-хисапта зур хаталар киткән дип бара, моны исбатлар өчен бик күп мисаллар китерә. Шуңа күрә картның «бөрчә чүпләвен» бер

селтәнүдә генә әйләндереп салып булмый, аның ни дәрәҗәдә дөрес тикшерәнлеген белергә кирәк башта. Эльвира шул кадәр үзенә ышанган иде ки, ул инде диссертациядәге цифрларны яңадан тикшергәндә картның көлкегә калачагын хәзердән үк сизенеп, эчтән явыз шатлык белән хозурлана башлады. Карт тагы: «Хатта гына барысын да әйтеп бетереп булмый, мин төзәтелергә тиешле урыннарны кулъязма тексты да билгеле бардым. Зинһар диссертациягезнең миңа җибәргән нөсхәсен игътибар белән карап чыгыгыз», — дигән. Ләкин кайда ул диссертация? Югыйсә, карт бит аны «хат белән бергә салам» дигән.

Эльвира өстәлдәге телефоннан канцеляриягә шалтыратты. Ләкин кулъязма килмәгән иде. Бәлки ул өенә җибәргәндер дигән фикергә килде хатын. Шундук Сафурага телефоннан шалтыратты. Ләкин профессор өендә беркем дә юк иде — җавап бирүче булмады. Галиәкбәрнең хатын өстәл тартмасына салып бикләгәч, Эльвира кафедра лабораториясенә кереп китте. Һәм, бүген дәресләре булмавыннан файдаланып, көне буе шунда кайнашты. Ул кич кырын тагы канцеляриегә шалтыратып кулъязма турында сорашты. Килмәгән иде. Өмет иртәге көнгә калды. Ләкин, кызганычка каршы, иртәгесен дә почта институтка кулъязманы китермәде. Эльвира тагы Сафурага шалтыратты. Ләкин тагы өйдә кеше юклыгы гына мәгълүм булды.

Эльвира кичке алтыларда институттан туп-туры җәяүләп кенә Галиәкбәрләр квартирасына китте. Мөгаен, ул диссертацияне, институтта югалу куркынычы бар дип, үз өенә җибәргәндер дигән уйда иде хатын.

Бергә эшләгән чакта Эльвираның профессор квартирында булганы бар. Ул чакта әле хатыны Мәгъмүрә дә исән иде. Эльвира барысын да күз алдына бик ачык китерә. Аны бик тәмле «киңү» пәрәмәче белән сыйлаган иде Мәгъмүрә.

Эльвира, әз генә дә онытылмаган ишектән кереп, өске катка менә башлады. Нигәдер ишекне тиз генә ачмадылар. Әллә, вакыт шундый соң булса да, эштән кайтмаганмы профессор кызы?

Ниһаять, эчтән кыштырдау ишетелде. Сафура «кем бар?» дип сорады. Өстен алыштырган вакыты булгандыр, ул ишек төбендәге кешенең хатын-кыз икәнлеген белгәч кенә ишекне ачты. Аптырап калды, баш иеп кенә исәнләште. Аның исәбе эшне ишек төбендә сөйләшеп кенә бетерү иде, тик Эльвираның күңелендә хатын-кыз кызыксынучанлыгы моңа комачаулады. Эльвира, бик үз иткән бер кыяфәт саклап, ишек ачылу белән эчкә үк узып китте. Сафура аны таный иде. Каршылык күрсәтергә кыймады, өйнең җыештырылмаган булуына гафу гына үтенде. Ә өй, чыннан да, туздырылган, теге кем әйтмешли, эт абзары хәлендә иде.

— Әле генә эштән кайттым, һич өлгереп булмый, — диде хуҗабикә җыелмаган урын-җирен йөнтәс одеал белән ашык-пошык каплап.

— Шулайдыр инде, ялгыз чакны мин үзем дә өйгә әйләнеп тә карамыйм, — диде Эльвира. — Кайчак ирем командировкага китә, мин блаженствую, шул чак бер эш тә эшләмим.

— Юк, минем просто вакытым юк. Аннан бу арада ничектер авырып торам. Суык тигән. Утырыгыз, пожалысты. Сез әти турындадыр инде?

Эльвира Сафура тәкъдим иткән урынга барып утырды да:

— Әйе, шулай, — диде. — Мин сезнең әтиегезгә карап чыгарга үземнең диссертациямне җибәргән идем, хаты килде, ә кулъязма һаман юк. Ул, минемчә, сезгә җибәргәндер. Шулаймы?

Сафура өстәлдәге әле һаман юылмаган савыт-саба өстенә ябылган газеталәрне төзәткәләде дә:

— Мин өйдә чагында китерүче булмады, — диде. — Бәлки почтальон күршеләргә калдыргандыр.

— Ул инде аны җибәрсә посылка итеп яки, һич югында, кисәкләп бандероль рәвешендә җибәрер иде. Сезгә извещение килмәдеме?

— Юк, — диде, аптырый төшеп Сафура, — мин һәр көнне эштән кайтышлый почта әрҗәсен карыйм. Юк, күргәнем юк.

— Бәлки ул шунда кысылып күзгә чалынмый калгандыр, ә? — диде һаман өметен өзмәгән Эльвира, — бәлки без аны карарбыз.

— Юк, бу эш бөтенләй киրәксез, — диде Сафура кырт кисеп. — Мин шундый игътибар белән карыйм ул почта ящигын, хәзер карауның һич кирәге юк.

— Шулай дисезме?

— Ну конешно. Беләсезме, аннан мин сезгә аптырыйм да, ничек инде шундый серьезный хезмәтне районга, анда да әле инде эштән чыккан бер картка җибәрергә була?

— Ничек инде, — диде Эльвира бик аптырап.

— Аңлашылмыймени? — диде Сафура, күзләрен кыса төшеп. — Безнең эти бит ифрат картайды, ифрат бетерешte хәзер. Анда инде башланды старческий маразм. Кая шундый кешегә диссертацияләр карап утырырга. Мин белмим, — диде Сафура үзенең ихлас күңелдән хәйран калганлыгын мимикасы белән белдереп.

— Юк, мин алай димәс идем, — диде Эльвира, — минемчә, Галиәкбәр Хафизович бик әйбәт выглядит, таза, нык әле.

— Әй, — дип куйды Сафура, гадәтенчә бармакларын гына селкеп, — ул әллә нигә бер, анда да аз арада күрешкәндә генә шулай тоела. Просто хорохорится. Сез аны минә өйдә чагында күрсәгез иде. Просто ужас, бөтен нәрсәне бутап бетерә, куйган әйберен таба алмый интегә. Әйтәм ич, эти безнең бик-бик картайды. Аннан тагы аның холкы да үзгәрде. Һичбер тиеш булмаган нәрсәләргә тыгылу дисеңме. Ансынмонсын ошатмыйча мыжгулар, вак-төяккә бәйләнеп үзәккә үтүләр. Ужас! — Сафура түзә алмыйча, моннан да артыграк булуы мөмкин түгел дигәнне аңлату өчендер, өй эчен яңгыратып көлеп тә алды.

Шул көлүгә ияреп, Эльвира да ирексездән көлемсерәде.

— Бәйләнчеклек бар инде анысы, бар, бар, — диде ул. Аның йөзе тагы җитди бер кыяфәт алды. — Алай-болай, чыннан да, адресын ялгыш язып, әллә кайларга җибәрмәде микән ул минем диссертацияне, ә? Сезнеңчә ничек?

— Андый эшнең булуы бик мөмкин. Әйтәм ич, тәмам бәлтерәде инде дип. — Сафура утыргычын Эльвирага якынрак тартып утырды. — Беләсезме, миңа шул кадәр авыр хәзер эти белән. Просто нишләргә дә белмим инде. Кайчагында башыма тинтәк уйлар килә. Әллә, мин әйтәм, әгине шул картлар йортына гына тапшырырга микән, дим.

— Ну што сез, — диде Эльвира куркынып, — алай эшли күрмәгез. Юк, юк. Мин аңламыйм, ул шул дәрәҗәдә үк мыжгык бер бабайга әвереллдемени?

Сафура тирән итеп көрсенде.

— Әверелде шул.

— Һич уйламаган идем, — диде Эльвира. Аның күңелендәге тойгылары икегә аерылып, шул ике тойгы үзара бәрелешкәндәй булдылар. Аларның берсе шул картлык склерозы аркасында минем эшне тикшерәм дип, профессор барысын үзе бутагандыр әле, мин асылда дөрес исәпләгәнмендер дигән тынычлану хисе иде. Икенчесе исә: шул бутау-онытулар аркасында ул минем диссертация кульязмасын югалтмады микән, дигән дәһшәт.

Эльвира Хәкимовна өенә тирән борчуда кайтып керде. Сафурага керү аның борчуын отыры арттырды. Өйдә иренә бөтен хәлне ачыктан-ачык аңлаткач, ул әллә Максудов янына барып кайтыйм микән, диде. Ире аның зур урында эшләүче, тынычлыгын беренче сикәлтәләрдән соң ук югалтмый торган, җитди бер кеше иде. Ул: «Юкны сөйләмә, бары-

сы да жайланыр. Мин бит профессорны беләм. Ә кызы аңа бәя биргәндә ялгышырга может», — диде.

Ләкин доцентның күңел түрендә чишелмәгән төен һаман шул көенчә калды.



7

Эльвира Хәкимовна әле яңа гына чыгып киткән иде. Көтмәгәндә тагы ишек звоногы чылтырады. Сафура сукранып ишекне ачып җибәрде һәм Димканы күреп җиңелчә аптырау кичерде.

— Ничек болай? — диде ул. — Без бит бүген очрашырга сөйләшмәгән идек.

Ләкин егетнең кыяфәте бик җитди иде. Ул Сафураны гадәттәгечә үпмәде дә, кулын да кысмады, телдән генә исәнләште дә өске киемнәрен сала башлады. Чишенеп беткәч кенә җавап бирде.

— Мин синең белән бик җитди итеп сөйләшергә тиеш.

— Әйдә уз, — диде Сафура бераз сәерсенеп. Алар, олы якка чыгып, диван-караватка утырыштылар. Күрәсең, егетнең килеп кергән шәпкә үк барысын да актарып ташлыйсы килми иде. Ул һич көтелмәгәндә:

— Ничек соң, хәлләр ничегрәк, — дип сорады.

Сафура көлә башлады.

— Шулмы җитди сүзең? Бик әйбәт. Менә мең бәла белән әҗәткә биш сум акча таптым.

— Мин үзем дә кеше исәбенә яшим, — диде Дмитрий көлемсерәп. Егет матур зәңгәр күзләрен, әйтергә кирәк, балаларча гөнаһсыз саф карый торган күзләрен, ниндидер мөһим сүз әйтергә җыенып, Сафурага текәде. Сафура түзмәде, аның киң, көчле күкрәгенә башын куйды. Аннан ул күтәрелеп егетнең ияк очыннан бер үпте дә башын тагы Дима күкрәгенә салды. Аңа моннан да рәхәт мизгел юк иде. Ул инде егеткә тәмам күнеккән, аның уйнаклап торган мускулларын да, зур һәм апак шәфкатьле кулларын да, хәтта исен дә ярата иде. Ул аныкы, ул аңа әйтеп бетергесез рәхәт минутлар бүләк итүче, һәр вакыт аңа яхшылык теләүче, Сафурадан бер генә нәрсәсен дә кызганмаучы, табигать тарафыннан ир-егет сыйфатларын бик мул алган бер кеше. Сафура, Димкага бөтен гәүдәсе белән сыенган хәлдә, пышылдап кына аңардан сорап куйды:

— Я, әйт, нинди җитди сүз?

Дмитрий идәнгә туфли үкчәләрен генә тидереп, аяк очларын селкетеп торды.

— Мин сиңа соңгы тапкыр тәкъдим ясарга килдем.

— Минемчә... — диде Сафура, башын егетнең күкрәгеннән алып. Ләкин ул сүзен тәгәлләмичә калды, егет тагы башлады.

— Мин артык булдыра алмыйм, Софа. Аңлыйсыңмы син, юкмы? Мин мондый эшне яратмыйм. Син аңларга тиеш. Мин синең белән бөтенләйгә, гомергә кушылырга телим. — Ул бераз тынып торды, аннан тагы да дулкынланыбрак тезде. — Мин сине бик яратам. Миңа башка беркем дә кирәкми. Син мине аңлыйсыңмы? Мин болай яши алмыйм. Я без гомергә кушылырга, я булмаса инде бер-беребезне онытырга тиеш. Мин сине бик яратам. Менә шул.

— Әллә мин сине яратмый дип уйлыйсыңмы? Оныттма, безнең хәзерге мөнәсәбәтләребез хатын-кыз өчен хәвефлерәк. Ул һәр вакыт мондый хәлдә күбрәк рискка дучар. Шулай да мин моңа барганмын икән, димәк, сине бик-бик ратканга күрә генә.

— Шулай булгач? Нинди логик нәтиҗә чыгарасың соң син моннан?

Сафура бөтенләй җитдиләнеп китте. Хәзер аның егеттән олырак булуын читтән карап торган һәрбер кеше аңлар иде.

— Моннан шул нәтиҗә: безгә нинди генә хәлләрдә дә реалистик тойгыны югалтмаска кирәк.

— Мин, Софа, барын да уйладым. Барын да җиде тапкыр үлчәдем, бер тапкыр кистем. Сиңа бәлки аңлашылмыйдыр. Ләкин әйтим, миңа синең квартираң да кирәкми, профессор кызы булуың да кирәкми. Миңа бары син үзең кирәк. Мин бүген шуны ачык тойдым, мин синнән башка яши алмыйм.

— Дима, кадерлем, акылыңа кил. Әле без андый эшкә бара алмыйбыз. Нәрсә кирәк сиңа тагы? Без болай да бергә бит. Төкерәм мин күршеләргә, бүгеннән башлап сиңа үземдә кунарга рөхсәт итәм. Җае туры килгәндә, синдә кунгалармын. Без бит болай да бергә. Сиңа ни кирәк тагы, Дима акыллым?

— Миңа андый мөнәсәбәт ошамый. Бу бит азгынлык, әгәр беләсең килсә... Бер я ике була ала андый очраклы хәл. Ә озакка китсә...

— Реалист түгел шул син. Син, Дима, рәхәттән исергәнсең, башыңны югалткансың. Ә тормыш иту ул уен түгел.

— Минем синең белән тормышымны гомергә бәйлисем килә, Софа. Минем беркайчан да болай яратканым юк иде...

— Мин бит синнән олырак.

— Булсын, — диде егет кыю рәвештә.

Сафура үртәлеп күзләрендә очкыннар уйнатып алды.

— Булсын! Хәзергә безнең яшь арабыз сизелми ул кадәр. Ә бер егерме елдан соң нәрсә булыр? Яшьрәкләргә күзең төшә башлармы?

— Син булсаң, беркайчан да, беркемгә дә төшмәс. Мин ант итәм, намусым белән ант итәм.

Сафура иреннәрен нык кыскан килеш күзләре белән генә мыскыллап елмайды. Хәзер ул егетне ирештерү белән генә шөгыльләнә иде инде.

— Онытканеыңдыр бәлки, мин ана кеше, минем Лианам бар.

— Булсын, — диде егет шундый ук кыю һәм батыр тавыш белән, — мин Лиананы беләм. Язылышкан көнне ук, мин аңа үз фамилиямне биреп, аны үз кызым итәм.

— Инде болай тагы, — диде Сафура һаман эчкәрәк керә биреп. — Мин сизенәм бит, туйдан соң ук син бала табуымны таләп итә башлаячаксың. Нинди ирле-хатынлы тормыш инде ул, әгәр балаң да булмаса, шулай бит?

— Шулай.

— Шулай ул, ләкин мин артык бала теләмим. Аяк-кулым болай да богауда. Минем үзем теләгәнчә хөр, рәхәт яшисем килә. Һич югында, минә үземнең хатын-кыз чибәрлегем бар чагында. Нигә миңа ул газаплар, стресслар[1]. Минем барысына да хокуклы буласым килә. Бирә аласыңмы миңа үзем теләгән тормышны?

Дмитрий уйга калды. Ул, күрше өлкәләрнең берсеннән килеп, Казанда калган егет иде. Тәрбияне авыл укытучысы гаиләсендә алды. Ул бернинди оригиналь максатлар белән яшәми, күпчелек кебек гади гаилә бәхетен бәхет дип саный, шул ук миллионнарның бәхетсезлек дип санаганын ул да бәхетсезлек дип атый. Сафура максатларын болай шәрәләндерә башлагач, ул аптырап калды. Кызның әйткәннәрен башына сыйдыра алмас булып, сирәк аксыл кашларын җыерды һәм җилкәләрен сикертеп, ни әйтергә белмәүдән үзенең матур елмаюын балкытып Сафурага текәлде.

— Мин сиңа, Софа, ирләрнең кулыннан килердәй барлык бәхет, шатлыклар вәгъдә итәм. Әлбәттә, мин гадәттән тыш берни дә эшли алмам, тик кеше эшли алганын вәгъдә итәм.

---

[1] Стресс — тетрәну.

Сафура бу сүз боткасыннан арыган иде инде. Ул урыныннан ук торды.

— Бүген син миндә кунарсың, шулай бит? — диде.

— Әйе, әгәр рөхсәт итсәң. Әтиең кайтып кермәсме?

— Кермәс, — диде Сафура коры гына. — Мена без нәрсә турында уйлашыйк әле. Өйдә, бәхетсезлеккә каршы, ашарга берни дә юк икән.

— Нигә, бәрәңге кыздырабыз.

— Аңа бит бәрәңге, май, суган кирәк түгелме соң?

— Анысы да юкмы?

— Әйтеп торам ич. Бүген әҗәткә бераз акча таптым, ә кибетләргә сугылырга вакыт табылмады.

— Алайса, чәй кайнатып эчәрбез. Икмәгең бармы?

— Катып бетмәгән булса...

— Зарар юк, безнең тешләр үткен бит.

Сафура күлмәген салды да өйдә кия торган чалбарын кия башлады. Аңа чалбар килешә. Ул, кайбер хатыннар кебек, чалбар кигәч кабак тутырылган капчык кебек булып күренми иде.

Чәй кайнатырга дип, алар кухня якка чыгып киттеләр. Хәзергә әлеге Дмитрий башлаган сүз туктап торды.

Кухняда гадәттәге тәртипсезлек. Егетнең моңа эче пошып китте.

— Софа, синең залдагы өстәлең дә, мондагысы да пычрак савыт-саба белән тулган. Мин шуларны юыйм әле.

— Әгәр бик телисең икән, — диде Сафура, ышанырга да, ышанмаска да белмәгән бер кыяфәт белән. Егет пинжәген генә түгел, галстугын, ак күлмәген дә салып ташлады. Майкачан гына калып, калорифер колонкасын кабызды, биленә алъяпкыч бәйләде һәм мәз бетеп тәлинкәләр, чынаяклар юарга кереште.

— Яратмыйм пычрак савыт-саба торуын, — диде ул. Сафура эченнән генә, менә ике төрле караш хәзер үк үзен сиздерә башлады, ә мин бит андый нәрсәгә түзәм, дип уйлады. Ул:

— Син, Димка, саграк кылан, чатната күрмә, — диде кинәт. — Юкса теге тагы әниең төсе, фәлән-фәсмәтән дип мыжгый башлар.

Ләкин Сафура егетнең мондый эштән чирканмаганлыгына, сак кылануына игътибар итми кала алмады. Аның күңелендә, мондый ярдәмчең булса, начар түгел дигән тонык бер яктылык чагылып алды.

Чәй кайнаган арада, егет кухнядагы гына түгел, олы яктагы пычрак савыт-сабаны да юып өлгерде. Сафура корытылган, ялт иткән чынаякларны олы бүлмәдәге сервантка илтеп урнаштыра башлады. Чәйнек кайнап чыкканда инде кухня эче чеп-чиста, Димка өстәл клеенкасын юып корыткан, барлык җирдә арулык, күңелле тәртип урнаштырылган иде.

— Я, менә шулай булса начармыни? — дип сорады Димка. Алар мул итеп салып, таш чәйнектә грузин чәе пешерделәр дә, әле эчке өлеше ул кадәр катмаган икмәкне кисеп, шикәрле чәй эчәргә керештеләр.

Сафурага кинәт күңелле булып китте. Әйе, аңа барысын да кемдер әзерләп бирсә һәр вакыт рәхәт була. Күрәсең, шуңадыр ул, үзе булышмаган хәлдә дә, һәр кеше аңа булышырга, аның турында кайгыртырга тиеш, дигән ышаныч белән яши иде. Юк, бу ышаныч кына түгел, бу инде табигать үзенчәлегенә әйләнгән иде.

Чәй янында Димка Ульянов өлкәсендәге туып-үскән авылы турында сөйләде. Аның бер ягында куе урман, икенче ягында кечкенә күренсә дә болай үзе тирән, балыклы елгачык ага икән. Белсәң андагы табигать матурлыкларын! Искиткеч. Киттекме минем әниләр янына җәен шунда? Танышып кайтырсың. Алар бик гади, бик әйбәт кешеләр. Аннан

алар, чын мәгънәсендә, интернационалистлар. Синең татар кызы булуың аларда әз генә дә тискәре эмоция[1] тудырмаячак.

Аннан Дима, әти-әнисен мактап, аларның, менә Дима институт бетереп эшли башлавына карамастан, аңа әле һаман студент чагындагы кебек ай саен акча җибәреп торуларын сөйләп алды.

— Хатта ачык итеп яздым. Инде, мин әйтәм, сезнең ярдәмгә мохтаҗ түгел. Сезгә үзем җибәреп торачакмын озакламый. Ләкин нишлисең, янәсе, син әле аякка ныклап басмаган, өс-башың да фәкыйрь. Ә без, картлар, безгә әллә ни кирәкми.

Сафура эченнән генә әти-әнием шундый булса иде дип уйлады. Тик:

— Алар дөрес язалар. Синең ул акчадан баш тартуың әдәплелек күрсәтү йөзеннән генә булгандыр инде билгеле, — дип кенә куйды.

— Ничек инде? Бер дә аннан түгел. Просто миңа оят алардан акча алу.

— Син бер кагыйдәне белмисең. Кеше хайваннан нәрсәсе белән аерыла, я әйт?

Дима, бу бик мәгълүм нәрсә дигәндәй, кулларын җәеп елмайгач, Сафура аңа үзе җавап бирде.

— Кеше хайваннан шул ягы белән аерыла: ул якын кешесеннән көчлерәк икән, көч белән уртаклаша, акыллырак икән — акылы белән, ә бай икән — байлыгы белән. Бу гади, үзеннән-үзе аңлашыла торган кешелек законы. Шуңа күрә әти-әниең синнән баерак икән, алар сиңа акча җибәреп торырга тиешнең дә тиеше, юкса, бу кешечә булмас иде, бу хайванча булыр иде...

— Мондый хикмәтле законнарны белмим. Минемчә, алар үз авызларыннан өзеп җибәрәләр.

— Пенсионерлармы?

— Юк әле, икесе дә эшли.

— Шулай булгач. Алар синнән бер өч тапкыр күбрәкаладыр әле. Синең бит эш хакың бик аз.

Анысы, чыннан да, шулай иде. Дима эшләгән заводта квалификацияле һәрбер тырыш эшче яшь инженердан күбрәк акча ала иде. Бу уңай белән егет Сафураны бик таралган бер анекдот та сөйләп көлдерде. Янәсе, авырулар психиатр врачка күренергә чират торалар. Врач берсеннән кем булып эшлисез дип сорый. Теге базарда ит чабучы, ди. Врач моның әйткәнен язып куям дигәндә генә, авыруны алып килгән кеше, аңа ышанмагыз, ул үзен бөек затка исәпләп акылыннан язды, ул бары гади инженер гына, ди.

Дима, өйләнешү турындагы сүзен кичке чәй алдында кузгатмаса да, Сафура янына түшәккә яткач тагы башлады. Бу юлы үзенчә дипломатик алым кулланды. Күптән инде сизенеп килә ул: Сафура физик эшне өнәми. Шулай ук бу хәлнең нидән килеп чыкканын да төшенә кебек иде. Сафура, аның фикеренчә, физик эшкә күнекмәгән, ул булдыксыз, андый эш аның өчен артык авыр тоела. Ихтимал, бу Сафураның физик эш акыл эшеннән түбәнрәк дигән ялгыш бер карашыннан килеп чыккандыр. Физик эш ул түбән дәрәҗәдәге кешеләр миссиясе дип, син үзеңне еллар буе тәрбияләә әле: идән юу, керләр уу, я булмаса, авыр сумкалар күтәреп, базарлардан, кибетләрдән кайту сиңа күңелле эш булып тоелыр микән? Бик ихтимал тагы, хатын-кызның хезмәт өлкәсендә үз урыны бар, ул гүзәл җенес, аның эше үзенең гүзәллеген саклау, дигән карашның күтәренке, дөресрәге, эгоистик, бер күренешедер. Бу, Димка фикеренчә, Сафураның зур кимчелеге иде. Ләкин мәхәббәт сукыр була диләр бит. Әгәр яшь кеше мәхәббәт утларында дөрләп яна башлаган икән, аңа сөйгәненең бернинди кимчелеге дә комачау түгел.

[1] Эмоция — тойгы, хис, дулкынлану.

Ул аны гафу итә. Чөнки яраткан кешеңнең кимчелекләрен күреп, аны кайнар хисләренә каршы куярлык көч бар икән синдә, бу инде мәхәббәт түгел, бу инде исәпкә корылган мавыгу. Хәлбуки, Дмитрий әле моңарчы бер кайчан да сексуаль[1] рәхәтне татымаган кеше, Сафураны чын күңеленнән ярата иде. Ул үзенең төп максаты итеп Сафура белән мәңгегә кавышуны куйды. Ул бу юлы сүзне үзен Сафурага ярдәмче, аның җитешмәгән якларын тулыландыручы, әгәр инде шулай атарга тели икән Сафура, Дима гаиләнең барлык авыр эшләрен башкаручы сыйфатында яшәүче кеше булачак дип исбат итәргә кереште. Әлбәттә, мондый сүз Сафурага ошый иде. Чөнки ул бит үзе дә шуна омтыла. Ләкин шулай да Сафура беренче тойгыга бирелмәде, һәм, үзенык инанганнардан чыгып, Димкага берни дә өзеп әйтмәде.

— Ашыкма, ашыкма, — диде, — сиңа хәзер рәхәт түгелмени? Мин бит синең теләкләреңә бернинди каршылык күрсәтмим.

— Ләкин минем теләгем зуррак. Мин синең белән үземнең язмышымны бәйлисем килә.

Сафура бер сүз дә дәшмәде, егетнең уйларын икенче юнәлешкә бору өчен, Диманың муеныннан бик каты иттереп кочты да, икесенең дә тыннары бетә башлаганга кадәр, егетнең иреннәреннән үбеп торды.

Димага, яшь таза кешегә, каны уйный башлау өчен шул җиткән иде. Ул, бөтен дөньясын онытып, үзенең шашкын хисләренә бирелде.

Эшкә соңга кала яздылар. Дмитрий ашамастан-эчмәстән, заводына чабар өчен ишеккә таба юнәлгәндә, Сафура аны бер генә минутка туктатты.

— Дима акыллым, — диде ул, түбәнчелек белән үтенеп, — син бүген эштән кайткач минә шушы чананы Лианага илтә алмассың микән. Минем һич вакытым юк. Шеф дөнья кадәр эш йөкләде. Баланың чанасы юк. Һаман илтә алмыйм. Һаман кала да кала. Бала интегә торгандыр чанасыз.

Дмитрий юлны сорашты һәм шатланып риза булды. Дөреслектә моңарчы бара алмавының сәбәбен Сафура үзе генә белә иде. Ул санаторий хезмәткәрләренең үзенә тәнбиһ белән, яратмыйча карауларыннан курыкты. Аның гаҗәп сыйфатларыннан берсе — чит кешеләр каршында абруен сакларга тырышу. Чит-ят кешеләрнең һәрбер авыр сүзе аның күңелен яралый иде.

## 8

Фәрит теге фаҗигале кичне Әлфия квартирыннан сөрелгәч, үзенә урын таба алмыйча, арып хәлдән тайганчы, караңгы урманда йөрде. Төн болытлы, караңгы, җитмәсә, сыбызгы җил агач башларын селкетеп, ара-тирә Фәритнең өстенә кар тузаны сибеп исә. Ичмаса, бер кеше генә булса да очрасынчы юлда! Хәер, анысы Фәрит өчен әйбәтрәк тә иде әле. Аның беркем белән очрашасы да, сөйләшәсе дә килмәде бу минутларда. Ул үзе белән сөйләшеп, үзен табалап йөрде. Аның хәзер баягы исереклеге беткән. Аракының күңелдә, йөрәктә зәһәр агуы гына калган. Шуңа күрә Фәриткә хәзер икеләтә авыр иде.

Ул башта үзен гаепләү белән мәшгуль булды. Ләкин үзе генә гаепле идеме соң? Ул бит барыбер әйтми калмаячак иде. Әлфиянең үзен шул дәрәҗәдә үк яратуын белгән булса, бәлки ул башта ук әйткән булыр иде. Юк, монда ул үзе генә гаепле түгел, монда очраклылык та гаепле, дип уйлады Фәрит. Фәритчә, гаепнең бер өлеше әтисенә — Зарифка да, төшә иде. Ничек инде олы кешегә ир белән хатын арасына кереп, кыбырсып йөрергә ди? Әгәр ул Фәритне эзләп килмәгән булса,

---

[1] Сексуаль — җенси мөнәсәбәткә бәйләнешле.

үзенең улын түбәнсетмәсә, адәм хурлыгына калдырмаса, барысы да бит әйбәт булып бетәчәк иде.

Фәрит, әлбәттә, шул «әйбәт бетүне» күз алдына ачык кына китерә алмый иде. Ләкин кызына ул үз ирке белән барын да, барын да ачыктан-ачык сөйләячәк иде. Менә ант, икмәктер!

Фәрит, тәмам айнып һәм хәлдән таеп, өенә таба юнәлгәндә уйларында бары атасы белән генә булаша иде инде. Ул аңа әйтәчәк. Бик каты итеп әйтәчәк. Улыңны пычракка салып син таптаттың диячәк. Алай гына да түгел, син аны гомерлек бәхетсезлеккә дучар иттең, диячәк.

Тик Фәритнең үкенеченә каршы, ул квартирасына кайтып кергәндә этисе өйдә юк иде. «Әйе, онытылган икән» дип уйланды Фәрит. Ул этисенә үзе, бүген клубта сугыш турында картина була, син андый фильмнарны яратасың, теләсәң бар, дигән иде. Шик юк, карт киногa киткән. Фәрит, кухняга кереп, этисе кыздырып калдырган кетердәвек бәрәңгене чемченеп бер-ике капты да, термостан агызып кайнар чәй эчә башлады.

Ул кинәт изрәп үзенең йокысы килүен тойды. Кичерелгән авыр, җәфалы минутларның нәтиҗәсе иде бу. Калгып киткәләде. Аннан, соңгы көчен җыеп, пинжәген салды, туфлиларын, шнурларын чишмичә генә, аяк белән сыдырып ишеккә таба чөйде. Чалбарын салырга хәле калмады, утлар сүндерергә дә онытып, ятагына ауды.

Зариф кинодан кайтып кергәндә ул тирән йокы дәрьясына чумган иде. Улының ярым чишенгән хәлдә йоклавын күреп, ата аптырый төште. Җитмәсә, Фәритнең утыргыч артына җайсыз эленгән пинжәге дә идәнгә салынып төшкән. Карт аны кием элгеченә илтте. Бермәл әллә малайның чалбарын салдырыйм микән дип уйланды карт, тик уянып китүен теләмичә, бары идәнгә шуып төшкән юрганын гына ипләп өстенә ябарга булды. Ул, утларны сүндереп, кухня якка чыкты. Термосны селкеп карады. Аның бушаганлыгын белгәч, плитәгә чәйнек куйды. Үзе исә сигаретын кабызып, тәмләп тәмәке көйрәтә-көйрәтә уйга калды.

Сугыш турындагы картина аңарда сугыш истәлекләре уяткан иде. Һәрбер яшьтәш-кордашыдай, аның истәлекләре арасында иң тирән эз калдырганы Ватан сугышы булды бит. Зариф фин сугышы алдыннан ук кече командир буларак сборга алынган иде. Фин сугышында да, ул бетеп, ел да ике айдан соң башланган Бөек Ватан сугышында да катнашырга туры килде. Әйе, сугышта кичергәннәре аның беркайчан да онытылмас. Аерата авыры, әйтергә кирәк, аның өчен дәһшәтлесе кырык беренче елда булды. Сугыш буенча укчы полкта хезмәт иткән Зариф лаеш шулпаларын аз чөмермәде. Ләкин исендә нык сакланганы кырык беренче ел булды. Шул елның көзендә камалыштан чыкканда немец кулына эләкте ул. Аны һәм иптәшләрен бәләкәй район шәһәрендә бер таш өйнең тынчу подвалына кертеп яптылар. Зарифлар куып кертелгәндә бу урын әсирләр белән тулы иде инде. Аяк асты пычрак, нәҗес исе тамак төбенә утыра. Кешеләр бер-берсенә сыенып үрә басканнар, утырып торырлык урын калмаган. Кыскасы, кешеләрне фашист шушы таш подвалга мичкәдәге тозлы балык кебек шыплап тутырган. Әсирләрне шунда өч көн ашатмыйча, эчертмичә тотты дошман.

Ничек түзелгәндер дип башын чайкап куйды Зариф узгандагыларны искә төшереп. Дүртенче көнне әсирләрне подвалдан куып чыгардылар һәм, кечкенә шәһәрнең урамнарыннан хурлыклы рәвештә уздыргач, көнбатышка таба олы юл буйлап әйдәделәр. Һәр авылда, һәр торак пунктта аларга үзләре кебек үк йончыган, котсыз, арт путалары ычкынган шинельдән, пилоткалары колакка кадәр төшереп кидерелгән, сакаллы әсирләр төркеме кушыла бара иде. Күрәсең,

Зарифның бәхетеннәндер инде, ике километрга сузылган колонна көне буе атласа да билгеләнгән урынга барып җитә алмады. Җитен чүмәләләре генә күренгән ачык калку яланда кунарга туктаттылар. Менә шунда инде Зариф, төннең болытлы булуыннан файдаланып, качарга карар кылды. Барыбер үлем, дип уйлады ул. Үлсәм, ичмасам, дошманнан котылырга омтылып үлим. Ул ике рус егете белән сөйләште. Алар да шуңа риза иде.Ләкин качар вакыт җиткәч буш араны берәм-берәм кичәргә курыктылар егетләр, бары бергә тотынышып качсалар гына бу эшкә ризалыкларын белдерделәр. Зариф аларның икесен ике кулы белән тотты һәм алар шулай, өчәүләшеп бергә бөкерәйгән килеш, чүмәләдән чүмәләгә күчеп бушлыкны кичә башладылар. Бәхетле мизгел булган, ахры,—сакчының бу урынны күзәтмәгән чагыдыр бәлки, яисә безнең совет халкына хәерхаһ немец торгандыр сакта. Һәрхәлдә, Зарифлар үр артындагы корыган елгага төшеп җиттеләр һәм көнчыгышка таба сузылган шул чокыр буйлап җан фәрман чаба башладылар. Күпме чапканнардыр, мәгәр хәлдән таеп өчесе дә берьюлы чирәмгә ауды.

Шуннан соң алар немецлар кулына эләкмәс өчен юлсыз-нисез атлап, туп-туры көнчыгышка карый юл тоттылар. Тамак туйдыру өчен караңгы төшкәч кенә авылларга сугылдылар. Зарифның исәбе, мөмкин кадәр тизрәк фронтны кичеп, үз ягыбызга чыгу иде. Ул иптәшләре дә шундый ук фикердә дип уйлады. Тик ялгышкан булып чыкты. Күрәсең, алар ул заманда шактый таралган «кияүләп» калуны кулайрак күргәннәр. Ашарга сорап, аерым өйләргә ялгыз гына керергә кирәклегеннән файдаландылар. Бер авылда Зарифтан яшеренеп калдылар. Зариф үзе тамак ялгап чыккач, иптәшләре керергә тиешле өйләргә сугылса да, аларны тапмады. Шулай итеп, Зарифка фронтны япа-ялгыз үзенә генә кичәргә туры килде. Әйе, ул хәвефсез исән-сау чыкты, һәм бик теләп, хәтта шатланып дошманга каршы сугышты, үчләрен алды.

Әле кәефләнеп тәмәке тартканда ул шул узган көннәрне хәтерләде. Авыр чакларны күз алдына кабат-кабат китереп: «Ничек түзелгән! Түзсә дә түзәр икән адәм башы», — дип баш чайкап аптырап утырды.

Ул кичтән үк үз әйберләрен барлап куйды. Төнне шытырдавык раскладушкада авыр төшләр күрә-күрә бастырылып йоклады. Иртә тору белән калган салкын бәрәңге белән бераз тамагын туйдырды да, улы биргән өй ачкычын өстәлгә куеп, Фәриткә кыска гына записка язганнан соң, чыгып китте. Аңа биш белән алты арасында олы юлдан уза торган автобуска өлгерергә кирәк иде.

Фәрит әтисе борып калдырган будильник чылтыравына уянып китте. Сәгать нәкъ җидене суга иде. Торып тиз генә плитәгә чәйнек, калган аш куйды, инде чалбар үтүкләргә җыенганда өстәлдә яткан өй ачкычы астындагы кәгазьгә күзе төште. Фәрит әтисенең өйдә юклыгын әле генә абайлады. Юкса раскладушканың җыелып, стенага сөялеп куелганын күргән иде ич. Ни өчендер әтисен онытkan иде егет.

Язулы кәгазь... Анда әтисе өйгә кайтып киткәнлеген, вакытыннан алда улын уятып мәшәкатьләргә теләмәвен, семьясын, эти-әнисен онытмаска кирәклеген язган. Соңыннан: «Әгәр инде тагы синең янга килә калсам, ялгыз гына килмәм, — дигән.—Хуш, сау бул, сәламәт яшә», — дип өстәгән.

Фәрит аның болай үзенә сиздермичә генә китеп баруын яратмады. Төксе кыяфәт белән электр үтүген розеткага тоташтырды. Ул, кичә әтисенә каты бәрелергә күпме җыенмасын, бүген ул эшнең булмый калуына шат иде. Чөнки күңелдәге яраларны тагы бер актару гына икәнен Фәрит аңлый.

Помарланып беткән чалбарын үтүкләгәндә тагы кичәге хәлләрне башыннан кичерде. Аның Әлфияне күрәсе килә дә, килми дә иде. Күрәсе килә, чөнки кызның үзенә карашы бәлки үзгәргәндер, гафу итмәсә дә, бәлки ул кадәр үк нәфрәт утларына тотмыйдыр дигән өмет иде. Ә күрергә теләмәве исә, артык оятлы булуы аркасында иде, тагы кичәге хәл бүген дә кабатланыр, йөрәк нәкъ кичәге кебек телгәләнер дип, куркудан иде.

Фәрит анык карарга килеп, иртәнге чәен эчте дә эшкә китте һәм бүген көнен цехларны тикшерүдән башламады. Бүлмәсендә утырганда, аптыравына каршы, профессор шалтыратты. Ул сыналудагы чебиләр янында икән инде.

— Мин сезне тыңлыйм, эш нидә? — диде Фәрит коры гына һәм рәсми тонда. Әйтерсең кичәге хәлләрнең берсе дә булмаган, Галиәкбәр аңа чебиләр азыгына кушып бирә торган үлән онында каротинның ифрат аз калганлыгын һәм тиз арада каротинны алыштыра торган витамин А табарга кирәклеге турында шулай ук тыныч кына әйтте. Өстәп, бүген контроль группаны үлчибез, кереп чыгарга тырышыгыз, дияргә дә базды. Фәрит эчтән: димәк, ул да нәкъ минем кебек уйлый, — дигән фикергә килде. Шәхси мөнәсәбәтләр хезмәт мөнәсәбәтенә зыян китерергә тиеш түгел. Егетлек шунда.

Фәрит, А витаминны бармы дип, азык складына шалтыратты. Ул бик аз калган икән, шулай да эксперименталь цехка профессор сораган кадәресен хәзер үк җибәрергә боерды. Хәзер инде азык әзерләү цехында, профессор киңәше буенча, гадәти комбиазыкка аерым болгаткычта өстәмә премикс кушудан тыш, тагы ике төр азык та өстиләр. Нормалар яңа, Максудовча.

Аннары Фәрит өйләгә кадәр, буш ара табып, читлекләр куелган корпуска сугылды. Профессор азык әзерләү цехына киткән иде. Аны Рәмзи каршы алды. Фәрит белән Әлфия арасындагы хәлләрне егет әле анык белми иде. Алай гына түгел, ул алар арасындагы элеккe мөнәсәбәтне дә тоймады. Бу көннәрдә эш белән шул кадәр мавыккан иде ки, хәтта Әлфия турында да сирәгрәк уйлый башлады. Алар кичә генә профессор белән бергәләп китапханәдә булдылар. Профессор, гыйльми китапларны карап чыккач, шуларның кайберсен тиз арада укырга кушып Рәмзигә тоттырды. Аңлашылмаган нәрсәләрне сорарга тартынма, диде. Монысы ярап куйды. Әлфия белән очрашу өчен тагы бер сылтау чыкты.

Хәзер ул Фәритне идарә пультында китап укып утырган килеш каршы алды. Сәламләшкәч, баш зоотехникка эшнең барышы турында сөйләп китте. Сынаулар хәзергә ярыйсы гына нәтиҗә бирәләр. Үлчәнгән контроль группа әйбәт артым күрсәтә. Димәк, профессор ысулын читлектәге барлык кошлар өчен файдаланырга була.

Фәрит читлектә утырган чебиләрне рәттән тикшереп йөри башлады. Аның үткен, тәҗрибәле күзләре һәрбер үзгәлекне тиз эләктерәләр. Ул шулай корпус эчендә профессор кайтканчы йөрде. Читлектәге чебиләрне тикшереп чыккач, корпусның икенче өлешендәге, идәндә тәрбияләнә торган кошлар янына керде. Чебиләрнең һәр өч бүлектәгесе дә бер үк яшьтә. Хәзер Фәритне борчыган нәрсә идәндә тотып үстерелгән чебиләрнең читлектәгеләргә караганда шактый тере һәм таза булуы иде. Әле җитмәсә читлектәгеләрнең үлем-житеме күбрәк. Хәер, дип уйланды ул, профессор чебиләре идәндәгеләрдән калыш-мыйлар. Кыяфәтләре дә, артымнары да ким түгел. Кызык бу, кызык. Тик шулай да күңелдә бу карт белгечкә карата ниндидер авыр тойгы ята. Нәфрәтме бу? Кимсетелүе, хурлануы өчен үч алырга теләүме?

Бераздан профессор кайтып керде. Фәрит аның йөзенә игътибар итми кала алмады. Күренеп тора, карт төнен йокысыз уздырган, аның күз төбендәге шешемнәре тагы да зурая төшкән, җыерчыклары тагы

да тирәнәйгән, ә яңаклары суырылып калган. Ул бүген сакалын да бик ашык-пошык кына кырган булса кирәк, яңагында ак төкләр бик күп күренә.

Ул, Фәриткә артык төбәлмичә, салкын гына исәнләште. Фәритнең дә артык ачылырлык җае юк иде. Әгәр хезмәт шартлары кушмаса, ул аңа карамас та иде хәтта — профессор килеп керү белән, моннан борылып чыгып китәр иде.

Ләкин мондый дуамаллыкка аның бернндә дә хокукы юк шул. Профессорга баш иярга мәҗбүр булды.

— Җибәрделәрме? — дип сорады ул витамин турында.

— Әйе, булды, — диде Галиәкбәр ничектер ачулы бер тавыш белән. Фәрит бераз тынып торды. Кулларын халат кесәләренә тыгып сүзнең дәвамын көткән профессорга ул тагы бер тапкыр карап алды. Дөресен генә әйткәндә, алар хәзер кичәге хәлләрне искә төшерүдән икесе дә куркалар иде. Чөнки, барыннан да мөһимрәге, шәхси мөнәсәбәтләр түгел, ә хезмәт мөнәсәбәте. Инде дә аңа шәхси мөнәсәбәтләр килеп кысылса, ул, динамит кебек шартлап, бөтен эш барышын җимереп ташларга сәләтле.

Алар шулай бер-берсенә карашып тора бирделәр.

Бу белгечләр арасындагы хикмәтле үзгәрешне Рәмзи, яшьләргә хас ни хәтле игътибарсыз булмасын, күрми кала алмады. Ул хәтта эшеннән тукталды. Ике кеше арасыннан кара мәче узуын ул ачык тоя башлады, ләкин ни сәбәптән шулай булганын гына төшенә алмады.

— Минемчә, — диде, ниһаять, сүз башлап Фәрит, — сезнең тәҗрибәне читлектәге барлык партиягә күчерергә вакыт. Хәзер азык та, башка шартлар да бер төрле булса, эш җайлырак барачак.

Профессор ризасызлыгын белдереп баш селкеде.

— Иртә әле.

— Ни өчен? Сезнең уңай нәтиҗәләрегез ачык күренә бит инде.

Профессор, эчке, авыр хәсрәт басып китәргә торган соңгы көчләрен туплап булса кирәк, бермәл читкә карап дәшмичә торды да, шул ук салкын тонда, әмма бераз кыюлана төшеп әйтте:

— Сез әгәр минем экспериментлардан канәгать икән, ул эшне тагын да җәелдерә төшәргә рөхсәт бирегез.— Галиәкбәр Фәритнең баш иеп куюын «мин сезне тыңлыйм» дип аңлады, сүзен дәвам иттерде. — Монда без минем ысулның бер ягын гына, асылда азык составына кертелергә тиешле коррективларын һәм этәчләрне аерым үстерүне генә сыныйбыз. Ә бит әле яктылык режимы, җылылык режимы бар. Ул яктан да сынаулар уздырылырга тиеш.

— Моның өчен ниләр кирәк?

Галиәкбәрнең йөзенә ачулы елмаю чыкты.

— Ниләр кирәк? Сез бит белгеч.

— Димәк, аерым бина?

— Әйе, менә бу бүлекнең якынча өчтән бер өлешен стена корып аерып алырга кирәк. Ашату да, барлык башка режим да мин тәкъдим иткәнчә булсын.

— Ә аңа киткән чыгымнар үзләрен акларлармы соң?

— Институтта уздырган экспериментлардан чыгып хөкем итсәк, акларга тиеш. Теге вакытта мин вольерда уздырылган тәҗрибәләр белән чикләнергә мәҗбүр булдым. Чөнки бер фабрика да шул, сез өреккәндәй, чыгымнардан куркып ризалык бирмәде. Безнең план бар, фәлән-төгән, безнең фабрика андый тәҗрибәләр ясау урыны түгел, диделәр. Кыскасы, гадәттәгечә фәнни ачышны производствога кертү бик җиңел эш түгеллеген беләсез бит. Шулай итеп, минем тәкъдимнәр ул вакытны, бюрократия лабиринтларында адашып, юкка чыктылар.

— Мин аны күз алдыма китерәм, — диде Фәрит. Аңа хәзер профессорның тәкъдимен кабул итсә, карт белән союзга кереп, дирекция алдында аны барлык көченә якларга туры киләчәк иде. Алай гына да түгел, трест алдында да ул житди сөйләшүләр уздырырга тиеш, ә бу җиңел нәрсә булмаячак. Син, экспериментаторство белән мавыкканчы, башта булган методларны кулланып, кеше ирешкән уңышларны казан, димәсләрме?

— Яхшы, — диде ул, — мин хәзер өзеп берни дә әйтә алмыйм. Уйланырмын, башта дирекция белән киңәшеп карарга кирәк.

Бу турыда артык сөйләшүнең мәгънәсе калмаган иде. Фәрит картның кичәге хәлләрне искә төшермәвенә, эченнән аңа рәхмәтләр укып, һәм шундук сүз азагына шуны күзгатмагае дип куркып, кош караучы хатынга кайбер кисәтүләр ясады да, ашыгып чыгып китте.

## 9

Галиәкбәргә Фәрит белән сөйләшкәндә үзенең тынычлыгын саклау өчен аз көч түгәргә туры килмәде. Кадерле кызын алдап, Әлфияне дә, профессорны да җан әрнеткеч кичерешләргә дучар иткән кешене хәзер аның бөтенләй күрәсе дә килми иде. Кичә ул кич кайтып керү белән Фәритнең фаш ителүе кызына нинди авыр газаплар китерүен яхшы аңлады. Ул аны нинди генә сүзләр белән юатмады! Көчле иде Әлфия, әтисе алдында сер сынатмаска тырышып, үзен кулга алды. Хәтта әле гадәттәгечә тыныч кына итеп төрле вак-төяк хәбәрләр дә сөйләп утырды. Ләкин йокларга ятулары белән, Галиәкбәр ширма артындагы кызының тавышсыз гына елавын ишетеп калды. Кечкенә чагында да Әлфия шулай елый иде. Әтисенең хәтерендә, ул үзенең бу өйгә үги булуын беренче тапкыр белгәч, шулай бер почмакка кереп, кешеләрдән яшеренеп, тавыш чыгармыйча гына, елап утырды. Мондый елау аерата үзәккә үткеч бер елау иде. Шул чакны әти-әнисе аны чиратлашып юаттылар. Мәңге-мәңге үз балалары дип караячакларын, алар өчен Әлфиянең бик кадерле булганлыгын аңлатырга тырыштылар. Мәгәр бу ярдәм итмәде. Әти-әнисе белән сөйләшкәндә кыз сабырлыгын саклый алды, тик алардан аерылу белән тагын да үз эченә бикләнә торган булды, тагын еш-еш тавышсыз гына елады. Әле дә Галиәкбәр кызының елап ятуын аңлагач, йөрәге әрнегән хәлдә ятагыннан башын күтәрде.

— Кызым, аппагым, тынычлан. Кирәкмәс. Нигә үзеңне шулай бетерәсең. Синең бит әле барысы да алда. Бик үтенәм, кызым, елама, ул күз яшьләре агызырлык бәндә түгел. Вакытында беленүенә шатлан, кызым. Юкса... — Ул сүзен әйтеп бетермәде, Әлфиянең сүз катуын шәйләп тынып калды.

— Әти, син бик җиңел карыйсың, — диде Әлфия, — күрәсең, синең яшьтәге кешегә шулай булып күренә торгандыр инде.

— Кызым, кадерлем, алай димә. Мин синең хәлеңне аңлыйм. Ләкин кеше нинди очракта да кайгы-хәсрәтне җиңәргә тиеш. Чөнки ул синең файдага түгел.

— Әй, әти, нәрсә файдалы икән дип уйларлыкмыни соң минем хәлләр!? — диде Әлфия ачынып. Карт ни дип тә җавап кайтарырга белми аптырап калды. Шуннан соң алар бик озакка тындылар. Галиәкбәр кыз еламыймы икән дип барлык игътибарын җигеп тыңлады. Мәгәр берни дә ишетә алмады. Кыз я елавыннан туктаган, я бөтенләй тавышсыз гына елауга җайлашкан иде.

Әйе, кызга бик авыр, авыр иде. Әйтәсе дә юк. Хәзер иң яхшысы аны борчымыйча үз ихтыярына кую булыр. Ул акыллы, көчле ихты-

ярлы. Бер тынычланыр әле, дип уйлады Галиәкбәр. Тик үзе дә төнне йокысыз, бер ягыннан икенчесенә әйләнеп, бурсаланып уздырды.

Мәгәр Әлфия тынычланырга тиеш дип ул ялгышкан иде. Иртәгесен ул шат бәхетле Әлфия урынына, бөтенләй өшәнеп, хәтта картая төшкән кызын күреп имәнеп китте. Күзләрендә — өметсезлек кенә. Әйткән сүзне аңына җиткерә алмыйча интегә. Нинди генә эшкә тотынса да, ярты юлда онытылып, бер ноктага текәлә, күңелсез уйларга бата.

Галиәкбәр аны тагы тынычландырырга, алай бирешергә ярамаганлыгын аңлатырга кереште. Ләкин кыз «калдыр мине, әти» диде. Әйе, аның хәсрәте профессор уйлаганнан зуррак иде шул.

Аның үз гомерендә мондый зур, кадерле нәрсә югалтканы юк иде. Әкълимә үлде — авыр булды. Әнисе үлде — бик авыр булды. Ләкин бу кадәр үк газаплы түгел иде ул югалтулар.

Әлфиянең эшендә дә кинәт үзгәрүенә игътибар итми калмадылар. Лаборантка кыз Әлфия лабораториягә барып керү белән:

— Әллә авырыйсызмы? — дип сүз башлады.

— Күрәсең, шулайдыр, — дип куйды Әлфия.

— Врачка, врачка, Әлфия апа, — диде кыз. Ләкин ул Әлфия апасыннан бу турыда артык берни дә ишетмәде. Бары ничектер саңгырау тавыш белән «башланган анализларны бүген бетерергә тиеш син» дигән сүзләрне генә ишетте.

Лаборантка кызга Әлфиянең торыш-кыяфәте үк шактый сәер тоела иде, ул ни сәбәптән шулай килеп чыкканлыгын төшенә алмыйча аптырады. Ниһаять, күңелгә төште, озак баш ватканнан соң кем белән булса да каты гына ачуланышкандыр, дигән дөреслеккә шактый якын бер фикергә килде.

Ә Әлфия чыннан да авыру иде. Аның җаны гына түгел, хәтта тәне, башы да авырта. Эшкә килгән шәпкә ул моны сизмәде. Ләкин өйлә якынлаша башлаганда, башының чатнап авыртуына тәкатьсез калып, берни дә эшли алмас булды. Бу — артык көчле тетрәнү нәтиҗәсе. Кыз медпунктка кереп тормады. Терлекчеке булса да, ул үзе дә врач иде бит — тиешле даруларны эчте, эш белән мавыгырга, барысын да онытырга тырышты.

Ләкин никадәр генә ихтыяр көчен җикмәсен, никадәр генә тынычланыр өчен дәваланмасын, эшнең көе китте. Көндезге аш вакытында өенә кайтты. Ләкин, үзе дә сизмәстән, ашап алу урынына караватына ауды. Аның ялгызлыкта күңеле бушаганчы елыйсы килде. Мендәргә башын тидерү белән үксергә кереште. Аның болай еламаганына ике ел узган иде. Юк, алай гына да түгел. Әнисе үлгәндә ул бу кадәр үк кычкырып еламады. Хәзер исә мендәр почмагын тешләп, авырткан башын чайкый-чайкый онытылып елады.

Шулай байтак вакыт узды. Сәгать бергәме, әллә яртыгамы бөтен бүлмәне яңгыратып бер тапкыр сугып куйды. Кинәт кемдер ишек звоногын шылтыратты. Әлфия яшьле күзләрен тутырып ачты һәм тын гына ятуында булды. Кем булыр? Әтисе микәнни? Алай дисәң, ул бит киткәндә, мин әбәткә кайта алмам, ашханәдә ашармын, дигән иде. Бәлки әле болай гына, күршеләрдән берәрсе әйбер сорап торыргадыр. Ләкин ишек төбендәге кеше алай тиз генә кире китәргә уйламый иде. Ул звонок төймәсенә озаклап басты. Әлфия урыннан торды, башына шәлен урады һәм «Кем бар?» дип ишеккә таба юнәлде. Почтальон кыз булып чыкты. Телеграмма тоттырып кул куйдырды да ашыгып түбән төшеп китте.

Әлфия каты елаудан соң әле айнымаган иде. Аңа барысы да томан аша чит, ят булып күренә. Бүлмәгә кереп караватына утыргач кына, телеграмманы укырга кирәктер дигән фикергә килде. Кемгә атап сугылганын да абайламастан, кәгазь тасманы ертып укый башлады. Башлагач, укып чыкмый булмады. Телеграмманы Казаннан, терлекчелек

институтыннан этисенә ректор җибәргән. «Галиәкбәр Хафизович, мөмкин булганча тизрәк кайбер мәсьәләләр турында минем белән сөйләшергә кайтуыгызны үтенәм. Гыйниятуллин» дигән.

Әлфия институтны тәмамлар алдыннан гына, вафат булган элекке ректор урынына куелган Гыйниятуллинны яхшы белә иде. Телеграмманы өстәлгә ташлады да, тагы байтак вакыт онытылып караватында утырды. Әкренләп тынычлана башлады. Беренче этәргеч лабораториягә бармый булмый дигән уй иде. Әйе, аннан башка ярдәмчесе үзе генә өлгермәячәк. Ә пробаларга анализны бүген үк тәгәлләргә кирәк. Әлфия борчыла төшеп сәгатенә карады. Вакытның шактый икәнен, ашыкмаса бөтенләй соңга калу ихтималын уйлап, ул инде хәзер соңга калудан курыккан хәлдә, салкын су белән битен тиз генә юды, көзге алдында башын, күзен рәтләде һәм каударланып киенә-киенә ишеккә юнәлде. Инде чыгып китәм дигәндә телеграмма исенә төшеп, ул кире керде. Экспериментал ь корпус юл өстендә генә бит. Хәбәрне кертеп чыгарга кирәк, бәлки ул этисе өчен бик мөһимдер.

Әлфия корпуска барып кергәндә, анда бары идарә пульты янында артсыз утыргычтагы Рәмзине генә күрде. Егет терсәкләре белән өстәлгә таянган, китап укый.

— Әти кайда?

Егет, озын чәчен чайкый төшеп, Әлфиягә борылды. Аның йөзенә шундук елмаю йөгерде.

— Һо, бигрәк мин күрергә теләгәндә генә килеп чыктыгыз.

Әлфия, егеткә туры карамаска тырышыбрак, тагы сорады.

— Әти кирәк иде миңа. Ул кайда?

— Директорга керәм дип китте. Карагыз әле, Әлфия Галиәкбәровна, бик әйбәт булды бит әле сезнең килеп чыгуыгыз. Менә шуны аңлатып бирегезсәнә, што-то баш җитми. Ничек итеп комбикормга тиамин микъдарын исәпләп чыгарырга, ә?

Әлфия китапка иелде, ләкин шундук лабораториядәге ашыгыч эшләре исенә төште.

— Хәзер бер дә вакытым юк шул, Рәмзи.

Рәмзи аягүрә басты, йөзенә ялвару чалымнары чыгарып, Әлфияне җиңелчә генә кочты.

— Ну, сез бит беләсез аны, Әлфия Галиәкбәровна, дим. Ну?

— Беләм, ләкин вакытым юк, акыллым, — диде Әлфия читкәрәк китеп. Ләкин ул егетнең якын күрүеннән, хәтта җиңелчә кочарга батырчылык итүеннән, үзе дә сизмәстән, рәхәт бер халәт кичерде. Яшь, нык, таза егет иде Рәмзи, җитмәсә, күңелне сыйпый торган куштанлыкны да белә икән үзе.

Әлфия, күзләрен кыса төшеп елмайды да, телеграмманы Рәмзигә сузды.

— Әти кайту белән, менә шуны бирәсез!

Рәмзи телеграмманы алды, кызның җилсенгән күзләренә әле яңа гына игътибар итте.

— Ни булды, — диде ул хафаланып, — күз авыртамы әллә?

— Күзләрем авыртып тора шул, — диде Әлфия үзе дә сизмәстән тагы елмаеп. Кинәт борылды да корпустан чыгып китте.

— Менә сиңа, — дип куйды Рәмзи, аскы иренен бүлтәйтеп. «Ничава, — диде аннары эчтән генә, — бер минем кулга төшми калмассың. Чынлап керешкәндә, бервакытта да теләккә ирешми калмадык анысы».

Галиәкбәр исә озак көттермәде. Борчулы, төшенке кыяфәттә киткән кеше, яшьләр кебек җил-җил атлап, дәртләнеп кайтып керде.

— Шаулама, мәсьәләне иртәгә кабыргасы белән куябыз.

Рәмзи берни дә аңламыйча, картка сорау белән текәлде.

— Иртәгә Казаннан начальство килә. Тәҗрибәләрне комплекслап

өйрәнергә мөмкинлек сорыйбыз. Аннан безнең эшләр киң колач җәячәк.

Рәмзи хәзер профессорның ни турыда сүз алып барганлыгын аңлый иде. Әйе, ул да шат, шактый кызык бит тәҗрибә уздыру. Яңалыкның нәтиҗәсе әйбәт булса, шактый күңелле икән ул!

Рәмзи профессорга кызы калдырган телеграмманы сузды. Карт, халат кесәсеннән күзлеген алып киде дә, телеграммага бик озак уйланып карап торды. Бу эшнең серенә һич төшенерлек түгел иде. Теге диссертация буенча дисәң, ни өчен ректор телеграмма җибәрә? Галиәкбәр бу көннәрдә Эльвира Хәкимовнаны еш кына искә ала башлаган иде. Ул бераз каушый төшеп аңардан хат көтте. Инде кульязма да, хат та барып җиткәндер. Хәзер доцентның профессор әйткәннәргә мөнәсәбәте кызыксындыра. Бу эшнең төрлечә булып бетүе мөмкин иде. Әгәр акыллы булса, дип уйлады профессор, рәхмәт хаты җибәрер. Аннан җиң сызганып эшкә керешер. Ә акыл җитмәсә? Әйе, ул хатынның дулап ахмак нәтиҗәләр ясавы да мөмкин иде бит әле. Галиәкбәр фән өлкәсендә үзенең озын-озак узган елларында андый эгоцентристларны[1] күрмәдемени? Галиәкбәр шуңа күрә Эльвирадан хатны бераз каушаган хәлдә көтә иде. Ә монда телеграмма. Җитмәсә әле ректордан. Галиәкбәр бу табышмакны һич чишә алмыйча телеграмманы күкрәк кесәсенә тыкты да үз эшенә керешә.

Алар күзгеләр ярдәмендә яктылыкның һәр читлеккә тигез төшүенә ирешергә телиләр — кварц лампалары белән читлек эчләренә ультрафиолет нурларын мөмкин кадәр тигез төшерергә тырышалар иде.

Эш арасында карт өзлексез баш ватарга мәҗбүр булды. Ни сәбәптән аңа ректор бу телеграмманы җибәргән? Юк, тиз генә Казанга кайтып булмас, дигән фикергә килде ул. Мондый авыр вакытта Әлфиянең бер үзен калдырып булмый, ә аннары тагы иртәгә трест башлыкларының ризалыгын алса, һәм тиз арада зур экспериментка керешергә туры килсә? О, ул чакны инде Галиәкбәр эш көйләнгәнче — кимендә бер ай Казанга кайта алмаячак. Булмады. Иртәгә үк: «Бу эш мөмкин түгел», — дип телефоннан шалтыратырга кирәк. Ул үзенең шундый катгый карары белән килешеп бераз тынычланды. Эшенә чумды. Тик озакка түгел. Кинәт арып киткәнлеген тойды да читлекләр арасында торган артсыз утыргычка утырды.

## 10

Казаннан килгән трест башлыклары фабрика белән танышканнар, экспериментал цехта да булганнар, хәзер инде ашханәдә көндезге аш ашыйлар иде. Галиәкбәр алар белән йөрмәде, болай да кичәлебүгенле һава бозылгангамы аяклары аерата авырта башлаган иде. Ул булачак сынаулар турындагы сүзен нигезлерәк итеп җиткерү өчен, алдан ук директор кабинетына керде дә, әйтәчәк сүзләренең планын яза башлады. Казанлылар ашап кайтканчы шактый вакыт узды. Алар башта фабрика җитәкчелеге белән киңәшмә, аннан кичкырын эшчеләр белән җыелыш уздырырга тиешләр иде.

Казанлылар килеп кергәндә Галиәкбәр эшен бетергән иде инде. Әле генә кабинетка кергән кешеләрнең өчесе дә кайчандыр Галиәкбәрнең үзендә укыган белгечләр булып чыкты. Берсе — трест начальнигы, шактый калынайган, зур башлы, кыскарак аяклы Глушко Григорий Яковлевич; икенчесе инспектор — зоотехник Хатыйп Салиев, өченчесе — шулай ук трест зоотехнигы буйчан Тамара Петровна Григорьева иде. Барысы да кайчандыр Галиәкбәргә кошчылык фәне бу-

[1] Эгоцентрист — үз-үзен сөюче, эгоистның иң әшәкесе.

енча имтихан биргән, ягъни гомерләрен багышлаган эшнең беренче әлифбасын Галиәкбәрдән алган кешеләр. Алар керү белән профессорны таныдылар, бер-бер артлы килеп остазлары белән исәнләштеләр. Тресттан килүчеләр арасында Фәритнең шәриге Закирҗанов кына юк иде. Ул грипплап калды, диделәр.

Трест директоры, күрәсең, ишеткәндер. Беренче сүзне Галиәкбәргә рәхмәт әйтүдән башлады. Пенсионер булуына карамастан, производствога ярдәм итү — ул зур батырлык. Хәл-әхвәлләр сорашкач, гадәткә кереп киткән кагыйдә буенча, белгечләр бөтенләй төп эшкә бәйләнеше булмаган нәрсәләр турында сөйләшеп алдылар. Трест начальнигы үзенең күптән түгел генә Японнягә барып кайтуы, андагы бройлер производствосының ничек куелганлыгы турында сөйләде. Соңыннан бер мизгел тынлык булып торды. Димәк, тиешле микъдарда сүзнең кереш өлеше башкарылды, димәк, төп мәсьәләгә күчәргә була.

Фабрика директоры киңәшмәне ачык дип белдерде һәм кайбер нәрсәләрне ачыклау өчен сүзне Фәриткә бирде. Аны игътибар белән тыңладылар. Мәгәр, Галиәкбәрчә, аның чыгышы белән канәгатьләнмәделәр. Эшләр болай барса, квартал планы өзеләчәк. Аннан соң берничә цех начальнигы чыгып, трест ярдәмен эстәп сөйләде. Сүз ветврачка бирелде. Ул исә чебиләрне артык тыгыз утыртырга тырышу тенденциясен тәнкыйть итеп чыкты. Бу, беренчедән, травма, авитаминоз [1] арттыра, аннан, иң мөһиме, инфекция була калса, фабрика котчыккыч югалтуларга дучар ителәчәк.

Ниһаять, сүзне трест директоры Глушко алды. Галиәкбәр аның студент чагын бик начар хәтерли иде. Тик хәзер бу үзенең бәясен бик яхшы белеп тыныч кына сөйләгән, юантык кеше әз генә дә студент эһелен хәтерләтми. Ул фабрика җитәкчеләренә бик каты шелтәләр ясады. Аерата баш зоотехникны каты тәнкыйть утында яндырды. Ничек инде юллар өзелергә торганда кирәкле запасларың булмасын! Техник май юк, ни пычкы чүбе, ни биологик актив матдәләр. Аннан ни өчен идәндә тәрбияләнгән чебешләр үстерүдә яңа прогрессив ысуллар кулланылмый? Ни өчен чебешнең яшенә карап аңа мәйданны үзгәртмәскә? Алдынгы фабрикалар ул ысулны кулланып нинди зур уңышларга ирештеләр.

Галиәкбәр аңыг белән һич теләмәсә дә, хисләре белән Фәритне тәнкыйть итүләренә эчтән шатлана иде. Әйе, бераз гына җәза да кирәк андый кешегә. Ни өчен булса да...

Инде төп мәсьәләләр тикшерелеп беткәч, Гатауллин профессорга карап ымлады да: «Тәкъдимнәр ясау теләге белән хәзергә бездә кунакта ятучы профессор Максудов Галиәкбәр Хафизович сүз сорый,— диде. Аннан ул дустанә елмаеп: — Сезнең нәрсә анда?» — дип куйды.

Профессорның директорга ачуы килеп китте. Әйтерсең берни дә белми. Юкса, аның белән кичә үк сүз булган иде. Гатауллин ул чак ачыктан-ачык: «Мин мондый эшкә кул куя алмыйм», — диде. Фәрит тә, Галиәкбәр дә булачак экспериментлар нигездә әйбәт бер ысулны производствога кертү икәнлеген аңлатырга тырыштылар, тик директор күнмәде, кырт кисеп «булмый» диде. Ниһаять, бик озак бәхәстән соң, ул менә иртәгә Казаннан начальство килә, әгәр алар фәрман бирә икән... анда карап карарбыз, дип бераз ипкә килә башлады. Хәзер инде ул барысын да оныткан. Янәсе белми. «Сезнең нәрсә анда, имеш?»

Галиәкбәр юри үчен алу өчен сүзне шуннан башлады.

[1] Авитаминоз — азыкта ситаминнар юклыктан килеп чыккан чир.

— Кичә без баш зоотехник белән бергәләп иптәш Гатауллинга кереп бу мәсьәлә турында нык кына сөйләшкән идек. Ул трест башлыкларыннан уза алмаганлыгын әйтте, — диде.

Галиәкбәр артык озынга сузмастан, ләкин мөмкин кадәр аңлаешлы итеп, үзенең институтта чакта эшләнгән эшләрен, ләкин ул хезмәтнең эксперимент көенчә шулай калуын, хәтта гыйльми матбугатта да чагылмавын, ләкин максатка ирешү өчен инде артык күп нәрсә кирәкмәгәнлеген, бары бер тапкыр киң пландагы комплекслы эксперимент уздырырга гына кирәклеген, хәлбуки монда андый шартларның булуын, иптәшләр теләсә, уздыру мөмкин икәнлеген сөйләп чыкты.

— Бу эшне эксперимент дип түгел, ә табылган яңалыкны тормышка ашыру, производствога кертү дип тә аңларга була,— диде ул ахырда. — Чөнки минем өчен барысы да ачык. — Ул җиңелчә елмаеп: — моны инде, иптәшләр, минем сезгә дип әзерләгән соңгы бүләгем дип аңларга да була, — диде.

— Ни өчен соңгы бүләк? — диде трест директоры. — Әле без сездән күп нәрсәләр көтәбез, Галиәкбәр Хафизович.

— Юк инде, — диде профессор юаш кына, — артыгына көч калмады. Тормыш законнары... үзегез беләсез.

Ул урынына утырды. Бераз тынлык булып торды.

— Мөмкинме миңа? — диде Фәрит.

— Я, әйтеп кара, — диде Гатауллин.

— Мин трест житәкчелегенең мондый экспериментка рөхсәт бирүен үтенәм, — диде ул. Гатауллин аның фикерен белә иде инде. Әле генә директорның башына сәер бер уй килде. Бу егет барлык көченә профессорны яклый, аның кияве булырга җыенудан түгелме соң бу? Ул озын колактан Фәритнең Әлфияне яратып йөргәнлеген ишеткәләгән иде инде. Шулай уйлаганнан соң, Гатауллинның ачуы Фәриткә карата отыры нык кабарды. Кирәк бит шулай производство интересларын шәхси мәнфәгатьләрдән түбәнрәк куярга, ә?!

Фәрит исә сүзен дәвам иттереп, профессор һич үзенең сәламәтлеге белән исәпләшмәстән, кунакка килгән җиреннән фабрикага яхшылык итү өчен, бары, бары шуның өчен, эшкә керешүе, диде. Инде ул алып бара торган сынаулар, һич икеләнүсез әйтергә була, уңай нәтиҗә бирәләр.

— Ә ул сынаулар тәмамландымы соң әле? — дип сорап куйды директор.

— Юк әле,— диде профессор, Фәрит урынына үзе җавап биреп.

— Ләкин сынаудагы бройлерлар күзгә күренеп үсәләр. Алар арасында бөтенләй үлем-житем юк диярлек. Ләкин хикмәт шунда, — диде Фәрит, — әле бу экспериментка профессорның барлык идеяләре салынып бетмәгән. Бу әле, әйтергә була, комплексны өйрәнүнең бер өлешен генә үз эченә алган сынау. — Фәрит ниләр эшләнгәнен һәм ниләр эшләнергә тиешлелеген аңлата башлады. Гатауллин тагы түзмәде:

— Болар турында профессор бик әйбәт аңлатты инде. Нигә кабатланырга?!

— Кабатлауны кирәк дип саныйм, — диде Фәрит. Аның үзен директорның дорфа рәвештә бүлдерүе үпкәләтте, — кабатлауның сезгә кирәге бар дип исәплим мин, чөнки сез һич урынсызга шундый изге бер эшкә каршы киләсез.

Директор, тынычлыгын югалта төшеп, утырган урынында кыбырсып алды. Фәрит сүзен бетергәч, ул аңа гына карап ясалма тынычлык белән әкрен генә әйтте:

— Минем борчылуым урынсызга түгел, баш зоотехник. Син алай дип тыңлаучыларда ялгыш фикер калдырырга тырышма. Эш бит

шунда, сезнең бу сынауларыгыз зур чыгымнар сорый. Ә ул сметага кергән нәрсә түгел. Аннан аклыймы соң әле ул үзен? Сезнең бит бу сынауларыгыз тәмамланмаган. Ничек итеп бер эш тәгәлләнми торып, нәтиҗәләре ачыкланмыйча күп акча түгәргә була? Менә безгә трест,— ул трест башлыгына карап алды, — читлектә асрауны сынап карауны такты. Ә бит ул әле ни әйтер? Минем ышануымча, ул безнең менә монда менеп утырачак әле. Гатауллин зур йодрыгын муен чокырына куйды. — Уздырыгыз башлаган эшегезне, анык мәгълүматлар алыгыз. Исәпләгез. Аннан күз күрер. Эшне дәвам иттерергәме, юкмы, карарбыз!

Әлбәттә, директор да хаксыз түгел иде. Чөнки план өчен иң беренче чиратта ул җавап бирәчәк бит. Ләкин шул ук вакытта Галиәкбәр директорның бер нинди тәвәккәл эш кылырга теләге юклыгын да тойды. Әйе, ул сизенә. Үз гомерендә хезмәтен гамәлгә ашыру өчен мондый җитәкчеләр белән аз бәхәсләшмәде ул. Гатауллин чынлыкта бернинди хәвефле эш ясамаячак. Чөнки профессор тәкъдим иткәннәр башланган эшне тирәнәйтү генә бит!

Казан кунакларыннан Хатыйп Салиев сүз сорады. Бу егетне Галиәкбәр шулай да яхшы хәтерли әле. Егетнең ул чак йөзе һәр вакыт май сөрткәндәй ялтырап тора, еш-еш бетчәләгән була иде. Ул мондагылардан яшьрәк, әле соңрак институт тәмамлаган, Галиәкбәрнең хәтерендә шуңа күрә калгандыр да. Тик белгеч исемен алган бу егетнең нинди кеше булып формалашуын белми иде Галиәкбәр. Егет аягүрә басты да туп-туры Фәриткә текәлде. «Димәк, — дип уйлап алды Галиәкбәр, — аларга үзләренең укларын атарга мишень табылды. Алар Фәриткә төзәячәкләр, ә миңа атачаклар. Шулай да кызык».

Хатыйп, чыннан да, сүзен Фәриткә бәйләнүдән башлады.

— Бик кызык килеп чыга, — диде ул. — Әйтерсең фабриканың баш зоотехнигы трест директорының сүзләрен бөтенләй ишетмәгән дә. Ә бит Георгий Яковлевич бик ачык итеп Фәрит Зариповичның кимчелекләрен тәнкыйть итте. План тулмау куркынычы астында яши хуҗалык. Ә шундый чакны, экспериментлар белән мавыгып, көчләрне бүлгәләргә мөмкинме икән? Мин аңламыйм. Парадокс килеп чыга. — Ул карашын Галиәкбәргә юнәлтте. Елмаеп куйды. Галиәкбәр аның үзенә дә кадалачагын уйлап егетнең студент чагында әйтерлек тырыш булмавын, хәтта Галиәкбәргә имтиханны ике тапкыр бирүен хәтерләде. «Әллә шул вакыттагы хәтер калуларын күңелендә саклаганмы бу егет» дигән күңелсез уй узды картның башыннан. Хатыйп исә дустанә елмайды да сүзен тагын башлап китте:

— Мин, мәсәлән, Галиәкбәр Хафизовичның тәкъдимнәре бик әйбәт булуына әз генә дә шикләнмим. Аның бройлер үстерүне безнең шартлардан чыгып камилләштерү өлкәсендә эшләвен без студент чакта ук күреп белә идек. Аңа һәртөрле ярдәм күрсәтелергә тиеш. Ләкин мин шуны әйтергә тиеш: эксперимент бу хуҗалыкта уздырылмасын. Күреп торасыз бит, Галиәкбәр Хафизович, бу хуҗалык әле яңа гына аякка басып килә. Яшь фабрика, аның әле үз стиле, үз алымы да юк. Ул үзе экспериментта тора дип әйтергә була. И шундый оештыру чоры барганда, ул сынаулар уздыру урыны була алмас кебек. Матрешка кебек... — Ул үз алдына көлеп куйды — Матрешка, матрешка эчендә тагы матрешка, анысы эчендә тагы, тагы... Мин уйлыйм, бик җитди эшне мондый хуҗалыкта уздырып, сез, шиксез, аны һәлакәткә илтәсез. Минемчә, сезнең шәп, отличный эшегезгә бик шәп хуҗалык сайларга була. Шул ук безнең трестта. Ул менә дигән нәтиҗәләр бирәчәк. Мин ышанам. — Ул трест директорына текәлде. — Шулай бит, Георгий Яковлевич?

Ләкин трест директоры дәшмәде, аның йөзендә хәтта бер генә тамыры да тибрәнмәде. Хәлбуки аның кул астында эшләүче яшь белгечкә

ачуы килә иде. Ул белгечнең чыгышында ниндидер үзенә карата ялагайлык, тәлинкә тоту, ярарга тырышу тойды. Әйе, бу сыйфатлар кешедә күзгә күренерлек дәрәҗәдә тупас чагылышлы булса яратмый иде директор.

Сүзне сынаулар уздырыла торган корпустан кергән икенче цех начальнигы алды. Бу яшь, чандыр зоотехник бик кызу сөйләшә — аның әйткәннәре пулеметтан яуган пулялар кебек тукталмастан сибелеп тордылар.

— Эксперимент бик әйбәт нәрсә ул — әзләнү, яңага, прогресска ашкыну... Чөнки моны бездән чор, фәнни-техник революция таләп итә, тик, мин әйтми кала алмыйм, ул эксперимент дигән нәрсә безнең цех эшчеләренең эш хакына, ягъни кесәсенә кермәсен иде. Менә күрдек, Фәрит Зариповичның читлектәге чебиләре шактый кырылды бит. Әгәр эксперимент шундый зур югалтуларга китерә икән, безнең эшчеләр быел премиядән колак кагачаклар, эш хаклары да кимиячәк. Кисәтергә кирәк, эшчеләр болай да мыгырданалар инде, ә ул тәҗрибә тагы да киңәя төшсә, нәрсә булыр? Эштән китә башлаячаклар. Болай да эшче көче белән хәлләр кыен. Башларыннан сыйпап кына, юмалап, көйләп тотабыз бит эшчеләрне...

— Шуннан нинди нәтиҗәгә киләсең инде син? — диде түземе беткән Фәрит.

Цех начальнигы Фәриткә салкын бер караш ташлады.

— Нәтиҗә ачык.

Ул утырды. Директор бүлмәсендә уңайсыз тынлык урнашты.

Галиәкбәр өчен хәзер планнарның җимерелүе көн кебек ачык иде. Чөнки каршы якның дәлилләре артык көчле. Бер ни эшләр хәл юк! Мондый рифларга Галиәкбәр үз гомерендә шулай ук күп тапкыр бәрелеп вәйран булган кеше. Хәзер инде, күрәсең, башкалар өчен дә хәл ачык, бары аңа соңгы рәсми сүз генә кирәк. Бу сүзне трест директоры Глушко әйтәчәк. Утырыштагылар, тыңларга әзерләнеп, трест директорына текәлделәр. Ләкин, күпчелек көткәнчә, директор кырт кисеп үз фикерен әйтүне кирәк санамады. Ул ни өчендер төпченеп сораша башлады.

— Галиәкбәр Хафизович, ни өчен сез корпусның бер өлешен бүлеп алырга кирәк булачак дисез?

Галиәкбәр, барыбер уен оттырылды дигән фикерендә калган хәлдә, салкын гына җавап бирде:

— Чыгышымда аңлатырга тырышкан идем. Күрәсең, тиешенчә барып чыкмагандыр. Эш шунда, Георгий Яковлевич: уздырылачак экспериментлар, женескә карап, аерым тәрбияләү, махсус ашау режимыннан тыш, микроклиматны да күздә тота. Минем нормаларым башкачарак. Яктылык режимы да, температура, дымлылык, вентиляция дә. Ә андый үзенчәлекле режимны изоляциясез ничек ясарга мөмкин?!

— Ә ничә баш чебеш булырга тиеш?

Галиәкбәр анысына да тыныч кына җавап бирде.

— Ә ничә читлек?

Галиәкбәр әйтте.

— Ә ничә ярус булачак?

Галиәкбәр ул сорауга да җавап бирде.

Глушко сорау артыннан сорау яудыра башлады. Галиәкбәр ирексездән: «Әллә бу сораулары белән мине стенага китереп терәмәкче булamы»,— дип уйлады. Тик, тынычлыгын саклап, трест директорының һәр соравына ачык җавап бирә барды. Директор өчен барысы да ачыкланды, ахры. Ул бераз уйланды да:

— Әйтегез әле зинһар, ә нигә сезгә корпусны бүләләргә?— диде.

— Ничек инде, — диде профессор. Ул, мин бит сезгә бик тәфсил-

ләп аңлаттым, димәкче иде, ләкин өлгермәде, Глушко төенне һич көтелмәгәнчә чиште.

— Ә бөтен корпуста уздырсагыз ни була?

Профессор яктырып китте.

— Әйтик,— диде Глушко,— корпусның бер яртысында сезнең читлектәге кошлар, ә икенче яртысында — идәндә үстерелә торганнары. Бер үк режим. Азык та бер, микроклимат та бер. Шулай булмыймыни?

Профессор бермәл бу шаяртамы әллә, дип тә уйлап куйган иде. Ләкин бер дә шаяртуга охшамый. Карт елмаюын яшерә алмыйча:

— Бу искиткеч булыр иде, әгәр мөмкин эш икән. Тик мин куркам. Әле кечкенә генә эксперименттан да шүрлибез бит без.

— Биредә риск юк дисез бит бер дә?

— Мин сезгә үземнең институт вольерында уздырган тәҗрибәләрем һәм аларның нәтиҗәләре турында теләсәгез тагы бер тапкыр сөйли алам.

— Юк, сез галим кеше,— диде Глушко,— әгәр без сезгә шундый җитди эксперимент уздырырга ирек бирсәк, барлык җаваплылыкны өстегезгә алып эшкә керешер идегезме?

Галиәкбәр бик яхшы аңлый иде. Әңгәмәнең кульминациясе иде бу. Барысы да профессорның ничек дип җавап бирүенә бәйләнгән хәзер. Ирешелгән эш я сүтеләчәк, я тагы да үрләп алга китәчәк.

Галиәкбәр үз күңелендә яшьлектәге кебек дәрт һәм ашкыну туганлыгын тойды. Күкрәген киерә төште.

— Һичшиксез керешер идем,— диде.

Глушконың утырыш барышын бөтенләй үзгәртеп җибәрүенә башта аптырый төшкән Гатауллин, трест директорының фикере сүз сөрешеннән ачыклана төшкән саен, шомлана барды. Ул, каршы килү өчен Глушконы да, Галиәкбәрне дә тыярга теләп, күңеленнән әллә ничә дәлил әзерләде. Түзмәде, профессорның артык батырланып китүен күргәч:

— Ә сез пенсиядә түгелме соң инде хәзер, Галиәкбәр Хафизович,— диде, — сез бит, юридик күзлектән караганда, бернинди җаваплылыкны өстегезгә алмыйсыз.— Аннан ул: «Сез инде яшь кеше түгел, эш башларсыз да үзегез авырып-нитеп китәрсез», димәкче иде. Ләкин тукталып калды, чөнки сизенде: әйткәннәре дә карт кешенең хәтерен калдырырга җитәрлек иде.

— Юридик якны җайлар өчен, без сынау чорына договор төзи алабыз, — диде Галиәкбәр.

— Сез, димәк, шабашник хәлендә буласыз, шулаймы?

Утырыштагыларның кайберсе көлә башлады. Тынлык урнашкач, профессор тыныч кына җавап бирде:

— Мин пенсиягә чыктым дип җәмгыять каршында җаваплылыгымны югалтмадым әле, иптәш Гатауллин. Миндә вөҗдан дигән нәрсә бар. Бар тагы доктор дигән гыйльми дәрәҗә. Ил биргән дәрәҗә!

— Сез бит партиясез?

— Сез партиясезләрне идеалсыз кешеләр дип уйлыйсызмыни?

— Гафу итегез зинһар, — диде фабрика директоры. Глушконың күз карашы аңа нинди ахмаклык ясап ташлавын тулысынча җиткерде. — Мин бит болай гына, шаяртып кына. Иптәш Глушко үзе хуплап торганда, мин сезнең инициативагызга каршы килә алмыйм. Тик монда кайбер нәрсәләрне генә ачыкларга кирәк. Бу сынаулар сез эш алып барган шул ук корпуста уздырылырга тиеш, ләкин ул бу партиядән бушагач. Бу бер. Инде икенчесе — акча мәсьәләсе. Режимга үзгәреш кертеләсе булгач, бу өстәмә чыгымнар белән бәйләнгән. Бу сумманы трест бирмәсә, үпкәләмәгез, мин берни дә вәгъдә итә алмыйм.

— Юк, бары сездән генә, — диде Глушко кырт кисеп. — Трест эше

түгел бу. Бу эш сезнең файдага эшләнә, тиешле акчасын да сез табыгыз. Алай гына түгел, профессорны үзегезгә эшкә алынган кеше итеп формалаштырыгыз, пенсиясенә өстәп эш хакы да түләгез.

— Юк, — диде Гатауллин, аскарак караган хәлдә башын чайкап, — мин мондыйга бара алмыйм. Нәчә читлек кенә ясатасы бар. Өстәмә азык. Биологик актив матдәләр... Юк, юк, башыма мондый җаваплылыкны алалмыйм.

— Ә без сезгә башкача ярдәм күрсәтәчәкбез. Аңлагыз. Кызык бит, әкәмәт кеше! Эш мантыйса, сезнең тәҗрибәне бөтен республикага таратачакбыз. Инде без уздырсак, даны бит, егет, сиңа тәтемәячәк!

— Юк инде, Георгий Яковлевич, мин шөһрәт артыннан куу яшеннән уздым. Миңа план тулса, шул җиткән.

## 11

Фәрит әтисе язып калдырган записканы тагы кулына алды. Ул әле генә киңәшмәдән кайткан иде. Ни өчендер бүген артык арытты. Хәсрәткә бирешмәү өчен үзенне һаман киеренке тоту шулай итә, ахры. Ул язуны укып чыкты. Тагы күңелне авыр кичерешләр тырнарга керешге. Әтисе, инде килә калсам, ялгыз гына килмәм, дип язган. Нәрсә бу, бары куркытумы? Улыннан ниндидер үч алумы? Фәрит бу сүзләрнең мәгънәсенә төшенми иде әле. Кинәт ул, бәлки Фәһимәне, балаларны монда алып килергә җыенадыр, дип шомланды. Чыннан да, мөгаен, шулдыр әле картның исәбе. Теге вакытны да сөйләнгән иде. Ну, эти, ну, эти! Аның улын кисәтмәстән-нитмәстән таң тишегеннән китеп баруы да ачу китергеч бер хәл — тиешеннән артык рәхимсезлек, кансызлык иде, Фәритчә. Ул бит әнисенә күчтәнәч, балаларга дип һәр эш хакыннан калдыра барган акча җибәрмәкче иде. Әнисе, балалары каршында аның турындагы фикер тагы да начаррак булачак инде. Хәер, ул әле бу күңелсезлекне бер кадәр төзәтә ала: иртәгә үк, шимбә көн булудан файдаланып, иртәнге яктан ук әнисенә посылка салачак, балаларына акча җибәрәчәк. Хәзер адрес яшерүдән мәгънә юк, барыбер фаш ителде инде. Моңарчы ул андый күңелле эшне башкара алмады, чөнки кайда икәнлеген белдерергә ярамый иде. Инде барлык ялган өметләр өзелде, Фәрит, барлык гөнаһларын ачып, халык алдына шәрә килеш чыгып баскан кешедәй хәзер.

Язу тагы өстәлгә ташланды. Нәрсәдер ашарга кирәк иде. Фәрит моңарчы гел Әлфия белән яшәде. Әлфия һәр вакыт Фәрит белән иде. Үзе белән очрашмаганда да Фәрит аны гел күңелендә, йөрәк түрендә саклый иде. Шуңа күрәдер, ахры, ул ялгызлык газабы тоймый яшәде. Ә менә бүген, квартирасында япа-ялгызы калгач, аңа ифрат авыр булып китте. Әйтерсең болай да хәттин ашкан хәсрәт йөгенә ялгызлык авырлыгын бастырып куйдылар.

Фәрит хәрәкәтләренә акыл идарәсен җикмичә генә, механик рәвештә, эшкә генә кия торган кара костюмын салды, галстугын чишеп утыргыч артына элде, якасы карала башлаган ак күлмәген дә шунда ташлады. Өй өчен булган буй-буй, зәңгәр саржа чалбарын киеп, үзенә аш пешерергә кухня якка чыгып китте. Фабрикага урнашу белән, ул аш пешерү мәшәкатьләрен җиңеләйтү өчен скороварка сатып алган иде. Ашы ярты сәгатьтә әзер була. Тик бәрәңге әрчеп, ит турарга гына иренмә. Бу юлы да шундый пешекчелек эшенә керешергә уйлады. Ләкин бүген бәрәңге әрчергә дә, суыткычтан ит алып турарга да көче җитмәде. Көче дә җитмәде, теләге дә булмады. Ишек төбендә торган капчыктан ике зур бәрәңге алды да, инде боларны нишләтергә икән дигәндәй, өстәлгә куеп, аптырап калды. Аның башында хәзер үзгандагы көннәр җанлана иде.

Моннан җиде ел элек Фәрит институтны тәмамлап бер шәһәрчеккә китте дә, кош фабрикасында эшли башлауның беренче көннәрендә үк күңеленә хуш килгән бер кыз белән танышты. Кыз үзенең уенчаклыгы, һәр чак көр табигате белән егетләрнең күзенә чалынырлык иде. Көләч иде ул, гамьсез, шук иде. Һәм акылсыз да, ямьсез дә түгел. Түгәрәк битле, матур зәңгәр күзле, кап-кара кашлы һәм тулышып торган иренле кыз иде ул. Фәрит шуның белән йөри башлады. Аларга бергә булу бик күңелле, бик рәхәт. Егет, гомерендә беренче каттыр бәлки, шушы Фәһимә алдында үзен иркен, рәхәт тота иде. Алар ике айга якын йөрделәр. Көннәрдән бер көнне (җир йотсын иде ул көнне!) Фәрит әти-әниләренә үзенең шушы арада өйләнәчәген белдереп хат язды. Әтисе дә, әнисе дә егетнең эшне болай коры тотуын теләмәделәр. Өйгә кайтып килүен үтенделәр. Барыннан да элек аларның ничә ел буена читтә торып артык сагындырган төпчек уллары белән яшиселәре килә иде. Анңары тагы өйләнүнең, аерата йортка керүнең нәрсә икәнен беләләр картлар. Ул бит чит гаиләгә керү дигән сүз. Ярый ла тиз арада үз булып китә алса, ярый ла егет каената өендәге гореф-гадәтләргә тиз ияләшсә... Картлар барын да үзләренчә уйлады. Фәриткә артык ашыкмаска, кыз белән ныграк танышырга киңәш бирделәр. Ләкин ул чакны Фәрит инде үзен камил җитлеккән, акыллы ир заты дип исәпли иде. Алай гына да түгел, һәр яшь кешегә хас булганча, үзен йолдызларга буе җитәрлек зур әһел мин хәзер дип уйлый иде. Янәсе үз язмышын үзе хәл итә алачак, борчылмагыз сез, картлар!

Әтисе дә, әнисе дә бу эшкә хәйран калды. Алар, дөресен генә әйткәндә, егет өйләнергә мәҗбүрдер, эшләр тирәнгә киткәндер, соңдыр хәзер, дигән фикергә килделәр. Һәм, искечә әйткәндә, егеткә фатихаларын бирделәр, бергәләп Оренбур ягына киттеләр. Туй булды. Картлар Фәрит өчен берни дә кызганмадылар — зурдан кубып, күп акча тотып, табыннар уздырылды. Кыз ягы да, ким-хур булмасын дип, аңа да шәп мәҗлес уздыру өчен булыштылар.

Фәһимә ашказаны чире белән күптән азап чигүче әнисе белән генә яши иде. Әтисе фронттан кайтып, җиде ел яшәгәч, үлеп киткән, ике абыйсы һәм бер апасы башка чыкканнар. Туй узу белән үк Фәрит кыз өендә калды. Картлар Бакалыга кайтып киттеләр. Шулай итеп эш егетнең әти-әнисе уйлаганча барып чыкмады, егеткә яңа гореф-гадәткә ияләшергә туры килде. Әйбәт идеме соң йортка керү? Моның турында Фәрит соңыннан кайта-кайта уйланды. Бәлки шуннан башлангандыр да әле минем хатам, дип баш ватты ул. Ләкин бергә яши башлауның беренче айларында, хәтта беренче елында, егетнең күзенә ак-кара күренмәде. Ул үзен рәхәтлек диңгезендә итеп тойды, иң бәхетле кешеләрдән санады. Кайнанасы Гөләндәм апа бер елдан соң ук гүр иясе булды. Үзләренә аерым өйдә яшиләр иде алар. Иркен ишегалды, артта алма бакчасы да бар. Өй бер катлы гына булса да, бик зур, урамга сигез тәрәзә караган. Мирас дәгъва итеп килгән туганнары белән Фәһимә эшне үзе йөртте: өйнең яртысын сатты да шул акчаны биреп барысын да ризалатты. Хәзер өй тарайды, мәгәр аның мәшәкате дә кимеде. Фәһимә өйнең тулы хокуклы хуҗасы булып калды. Баштарак хатынның акылы да, намусы да җитте, ул бер тапкыр да Фәрит алдында үзенең хуҗабикә икәнлеген сиздермәде. Әйе, беренче балалары Ләйлә туганда әниләре Гөләндәм дә исән иде әле. Бәби карауда аның ярдәме тиде. Тик бала туып өч ай да узмады, ул үлеп китте. Хәзер инде бөтен ышаныч әле ул вакытны сау-сәламәт Фәритнең әнисенә калды. Ул Бакалыдан Фәритләргә килде. Егет шулай ук үзен аямыйча гаилә өчен тырышты. Билгеле, хәзер элекке кебек түгел иде тормыш, аның күләгәле яклары ачыла башлады. Җитәрлек акча табарга, өйгә өзлексез күз-колак булып торырга, өй эшләренә, бала карауга муеннан чумган Фәһимәгә ярдәм итәргә кирәк. Болар барысы бергә җыелып

Фәритне мәхәббәт исереклегеннән тиз айныттылар. Хәзер аңа рәхәтлек, канәгатьләнү хисе бирүче нәрсә ул да булса — үзенең аталык вазифасын әйбәт итеп башкару иде. Инде янә бер елдан икенче бала Марат дөньяга килде. Ләкин бала туып берничә ай узганнан соң Фәһимә гаҗәп бер төстә үзгәрә башлады. Ул күзгә күренеп тулыланды, тазарды. Монысына Фәрит ул кадәр игътибар итмәде. Бусы, аныңча, ул кадәр эч пошыргыч нәрсә түгел. Әмма хатынның табигатендә, холкында эч пошарлык үзгәрешләр башланды. Фәрит мондый хәлне башта Фәһимәгә вакытыннан алда килгән физиологик бер яңа чор, ул узар дип уйлады. Ләкин алай булмады. Хикмәт хатынның карашларында, моңарчы, күрәсең, тыелып торган табигатендә, холкында иде.

Авыр иде аларның икесенә дә. Тик шулай да шундый караңгы, ямьсез, яңгырлы-болытлы көннәрдә дә кайчак кояш елмайгалый бит. Андый вакытларда алар элеккечә, өйләнешүнең беренче елындагы кебек, дусларча сөйләшәләр, тормыш кирәк-яраклары турында планнар коралар, йөрешә торган дусларына кунакка баралар, һәм, кагыйдә буларак, икенче көнне үк ут ягып кычкырышалар иде. Мондый вакытны җәнҗалны башлаучы Фәһимә була. Ул Фәритнең кичә, кунакта, тиешсез кыланышларын искә төшерә, я булмаса инде кунакка бәйләп кайчандыр булып узган, инде Фәрит күптән оныткан, ләкин уенчак Фәһимәнең хәтерен калдырган берәр вакыйганы казып чыгара. Хурлау, кимсетү, каргау һәм хәкарәтләүләр башлана... Фәрит мондый әрләүләргә бары балалары хакына гына түзә. Гаилә тынычлыгы изге бер нәрсә булып саналган семьядагы тәрбия Фәрит өчен бердәнбер дөрес закон иде. Гаиләнең таркалуы — аның өчен, кеше буларак, юкка чыгу.

Ләкин балалар өчен булган түземнең дә чиге була икән. Фәрит башта хатыныннан качып йөри башлады. Һәрхәлдә, мөмкин кадәр аңа азрак күренергә, аның белән азрак сөйләшергә омтылды. Моны исә Фәһимә үзенчә аңлады. Хәзер инде ул Фәритне ачыктан-ачык кеше алдында хурлауга күчте. Бәлки мин аны эштән чыгарып ялгышканмындыр, дип уйлады Фәрит. Чыннан да, икенче бала туып, бер ел узмады, Фәритнең анасы йөрәк авыртуы белән газаплана башлады. Хәзер аны озакка һәм еш-еш чакыртып булмый иде. Фәрит хатынына, балалар бераз аякка басканчы, эшеннән чыгып торырга киңәш бирде. Моңарчы саклык кассасында эшләгән Фәһимә эшен ташлады. Хәзер ул һәр вакыт өйдә, һәр вакыт балалар белән һәм мондый тормыш аны отыры чыгырыннан чыгара. Шуңа күрә, балалар бакчага үзләре йөри башларлык булгач, ул тагы саклык кассасына керде. Ләкин шушы арада нинди генә үзгәрешләр булмады!

Инде менә Фәритнең этисе «килсәм ялгыз гына килмәм», ди. Ни дигән сүз бу? Димәк, Фәрит үзен газап чиктерә торган хатын белән яңадан кушылырга, аның хурлауларын, мыскылларын тыңлап яшәргә тиеш буламы? Әйе, балалар җәл, ләкин кемгә авыррак соң? Гаиләдәге тынычсызлык, татусызлык шулай ук балаларны рәнҗетмимени, аларның калебләренә шулай ук гомерлек тирән яра салмыймени?! Фәрит бит болар турында бик күп, бик күп тапкырлар уйлаган кеше.

«Юк, мондый эшкә рөхсәт, юл куярга ярамый», — дигән катгый бер фикергә килде Фәрит. Ул бүген үк Фәһимәгә хат язып җибәрергә булды. Хатта барысын да аңлатырга. Алтын таулары вәгъдә итсәләр дә, Фәрит ул хатын белән яшәмәячәк! Менә шундый хат язарга тиеш ул. Берни дә өмет итмәсен! Фәритнең газап кичерүләре болай да җиткән. Әгәр ул килә калса, Фәрит моннан тагы китәчәк. Башын алып китәчәк, җәһәннәмгә, әллә кайларга, тик ул хатын белән артык беркайчан да яшәмәс!

Шундый катгый карарга килеп, бәрәңге әрчергә кирәклеген дә, үзенең ач булуын да бөтенләй онытты Фәрит. Яңадан бүлмәсенә керде, китап шкафыннан кәгазьләр алып өстәл янына урнашты.

Ул хат башында бүгенге числоны, елны һәм хатның кайсы җирдән җибәрелгәнен хәбәр итте. Бераз баш ватканнан соң, «Фәһимә» дигән сүзне дә язып куйды. Ләкин хатны шома гына башлап китә алмады. «Фәһимә» дип язу белән хатынын күз алдына китереп бастырды. Менә ул: Фәрит көзге каршында галстук бәйләп торганда алгы бүлмәдән килеп чыга. Туп кебек түм-түгәрәк, кулларын бөеренә куйган, ә күзләрендә — зәһәрлек. «Бик көязләнәсең, чибәр егет, бүген дә сөяркәң белән очрашасың бармыни?» Нинди сөяркә? Нигә шулай ахмаклана бу?.. Фәрит хатынына карый. Чынлап сөйләшәме бу? Әгәр чынлап булса, аның үзенә дә бик авырдыр. Ул, галстугын бәйләп бетерә дә, елмаеп аның күзләренә карый. Күзләрен яшь элпәсе каплаган хатынның. Димәк, чынлап торып ул Фәритне үзенә хыянәт итеп яши дип уйлый. «Фәһимә, Фәһимә, ди Фәрит, хатынының тулы иңбашларыннан тотып, ник син шундый булмаган нәрсәләр сөйлисең? Нигә бу мине дә, үзеңне дә шулай газаплау? Син минеке генә булган кебек, мин дә синеке генә». Фәһимә күзендәге яшь элпәсе тагы да ныграк ялтырый төшә. «Алдашма, алдашма, беләм мин сине. Кара! Үз гаебен яшерү өчен минем алда ничек юхаланган була! Әнә Ильясларда теге яшь хатынга ничек селәгәеңне агызып карап утырганыңны оныттыңмыни? Әллә белмиләр дип уйлыйсыңмы? Бөтен кешегә мәгълүм синең бозыклыгың! Танышбелеш, күргән саен, син аны катырак тот, ди. Фәрит йөрергә ярата башлады соңгы көннәрдә, диләр...» Монысы инде чеп-чи ялган! Фәһимәнең хыял җимеше болар барысы да!

Фәрит тагы кәгазьгә текәлде. Үзен язылачак хат турында гына уйланырга мәҗбүр итте.

«Хәзер инде миңа, эти килеп киткәннән соң, кайда яшәгәнлегемне яшерүдә мәгънә юк. Әгәр син әз генә акылыңа килеп, безнең киләчәгебез һәм балаларның тынычлыкта үсүен теләсәң, миңа ышанырсың...»

Фәрит тагы уйга калды. Бушлыкка текәлгән килеш тагы чуалчык уйлар лабиринтында адашып йөри башлады.

## 12

Фабрикадан бер километр ераклыкта олы юл уза. Анда бетон плитәләрдән ясалган махсус будка — автобус туктый торган урын бар. Рәмзи ун минуттан артык инде шунда Чаллы автобусын көтеп тора. Кулында юл капчыгыннан башка берни дә юк. Аркага асу өчен җайланган шул «сидор»ын чайкый-чайкый әрле-бирле йөренгәли. Иркенрәк бер ара килеп чыкты. Тәҗрибәдәге чебиләргә тиешле азык әзерләнде, инсоляция[1] ясалды, инде хәзер Чаллыга барып, анда торакта калган әйберләрне алып кайтырга була. Профессор үзе кош караучы хатын белән сөйләште, үзем дә булышырмын, диде. Менә нинди профессор! Пычрак, кара эштән дә чирканмый.

Көндезге ике иде бу. Ул Чаллыда күрәсе кешеләрен күреп, барасы җирләренә барып йөргән арада, торактагы иптәшләре дә эштән кайтыр, бүген ул алар белән төнне уздырыр, ә иртәгә инде иртүк беренче автобуста яңадан фабрикага кайтыр.

Узган ике атна эчендә иптәшләрен сагынды егет. Әле аларны берәм-берәм күз алдыннан кичерде. «Нишләп яталар икән чукынмышлар?!» дип елмайды.

Рәмзи хәзер мондагы көндәлек эшкә тәмам күнекте шул. Профессорның сөйләвенә караганда, сынаулар әле тагын җәелергә, катлауланырга тора. Димәк, ул зур белгечләр кул астында шактый вакыт эшләячәк.

---

[1] Инсоляция — махсус электрлампалар белән нурландыру.

Ул арада, әлбәттә, Рәмзи абзагыз аягына нык басып китәр. Инде аннан соң берәр цехка башлык итеп куйсалар да курыктым юк!

Киләчәк тормышы турында уйланганда, ул бер дә аның көтелмәгән дәһшәтле чоңгылларын күз алдында тотмый иде. Хәер, аның үз юлында да бер хәтәр сикәлтә булып алды алуын, ләкин моннан ул кадәр тетрәнеп калмады кебек егет. Бары үзенең моңарчы ялгышканлыгын, ә моннан соң инде акыллы булачагын гына раслады. Ул, артык яшь булмаса да, бар нәрсәгә яшүсмерләрчә җиңелрәк карый иде әле.

Шулай, дип уйлады ул тагы баягы мәсьәләгә кайтып, монда калырга була. Эш хаклары ярыйсы. Продукт мәсьәләсенә килгәндә тужы начар түгел. Квартир да алып булса. Кыскасы, ярый, ярый. Әлфияне күз алдына китереп, елмаеп куйды егет. Алда, киләчәктә үзен көткән татлы минутлар турында һаман шулай елмайган килеш уйлану күңелле аңа. Уйлары белән мавыгып, кинәт килеп туктаган автобустан чак кына колак какмый калды. Әгәр татлы хыяллары тагы берничә секунд дәвам итсә, китеп барачак иде юньсез. Рәмзи атылып автобус ишегенә ташланды, инде ябыла башлаган калай ишекне каерып диярлек, эчкә үтте. Халык күп түгел иде. Утырырга урын да табылды. Инде хәзер теләсәң нинди уйлар дәрьясында күпме йөзсәң дә була. Тәрәзәдән карап, агачлыклар һәм яланнарның, чокыр һәм үрләрнең бер-бер артлы алышынып торуларын күңеленә теркәмичә генә күзәткән хәлдә, Рәмзи ләззәтле хыялларына теләгәнчә агылырга ирек бирде.

Юк, ул Әлфия турында гына уйламады. Үз авылына да кайтып килде. Әти-әнисе белән дә күреште. Алар колхозда ярыйсы гына торалар. Хәзер анда да начар түгел. Әйдә, үзләре белгәнчә яши бирсеннәр... Ул Казанга да барып кайтты. Анда аның туган абыйсы яши. Завмаг. Рәмзине теге чакны бик тә каты сыйлап җибәрде инде! Җәйгә пароходка утырып кына барасы булыр — бер кунак булып кайтырга кирәк... Иөри торгач, уйларында янадан армиягә дә алынды егет. Элек аны техникумның беренче курсын бетергәч тә алганнар иде. Анда да, баштарак авыр булса да, соңыннан күнегелде — үз подразделениесендә менә дигән солдат булды... Нәрсә кирәк тагы? Үз теләгәнен булдырмый калмый егет. Төкерә ул дөньясына!

Автобуста бер сәгать чамасы барырга кирәк иде. Егерме-утыз минуттан соң Рәмзи йокымсырап китте. Ул күзләрен ачканда автобус яңа шәһәр, ак шәһәр, КамАЗ шәһәре Чаллы урамында иде. Күп катлы өйләр бер-бер артлы тезелеп киткән. Киң, гүзәл урам иде аның күз алдында. Чыңлап узган өр-яңа трамвай тавышы колакка чалынды. Ул да булмады, җиңел машиналар автобусны бер-бер артлы җилдереп уза башладылар. Рәмзи ирексездән бу якты, үзе салышкан шәһәрне бик сагынганлыгын тагын бер кат тойды. Хәзер Чаллы урамнарыннан бер узу үзе бер гомер! Искитмәле бер хәл иде бу яңа Чаллының ике йөз илле мең кешелек заман шәһәре булып, тиз арада калкып чыгуы. Рәмзи һәм аның кебек егетләр салды аны. Рәмзи колхоздан качып беренче тапкыр килгәндә биредә берни дә юк иде диярлек. Аякка ябыша торган сутлы балчык, актарылып ташланган күз җитмәс бушлыклар, җилекләреңә үтә торган күшектергеч суык... Шул гына иде. Күпме кешe шуңа күнә алмыйча качты, күпме кеше янадан килде... Төзүчеләрнең тик Рәмзи кебек умыртка сөяген тәшкил иткәннәре генә түзеп эшләде. Һәм менә нәрсә килеп чыкты ахырда! Рәмзи Яңа Чаллыны үз шәһәре дип исәпли. Аның күңелле чыңлап торган житез трамвайлары агачлар утыртылган, асфальтланган киң урамнарыннан узганда, егеткә бик тә күңелле, бик тә рәхәт иде. Менә автобус Рәмзиләр торагы урнашкан тугыз катлы таш бина яныннан уза. Эх, туктатасы иде хәзер шунда! Моның һич мөмкин булмаган бер хәл икәнлеген аңы белән белсә дә, егет торак йортының алтынчы катындагы тәрәзәләргә текәлде. Бәлки берәр иптәше өйдәдер, бәлки ул тәрәзә янындадыр? Тик тәрә-

зәдән беркем дә карамый. Күрәсең, иптәшләре барысы да эштә, төзелештә әле.

Рәмзи автовокзалдан күпчелеге соры агач өйләрдән торган иске Чаллыга таба юнәлде. Монда аның авылдашлары тора. Кош фабрикасына китәр алдыннан ул үзенең кадерлерәк әйберләрен шуларда калдырган иде: каракүл якалы өр-яңа кышкы пальтосы, бары ике тапкыр киелгән шәп яшькелт трико костюмы...

Киемнәрен ул авылдашларында озакка дип калдырды. Һәрхәлдә, аның фабрикада урнашып калырга нияте икеле-микеле булды. Ничегрәк каршы алырлар бит! Шулай булгач, ул кире кайтса да, киемнәр көзгә кадәр шушында сакланырга тиеш иде. Чөнки яхшыга кияргә аның торакта тагы бер костюмы бар әле. Ул әйбернең кадерен крестьянга хас булганча белеп, аларны полиэтилен капларга пөхтәләп салды, хәтта нафталинлап, капчыкның авызын тегеп үк куйды. Торакта аның ике пар туфлие һәм резин аслы киез итекләре дә бар. Инде бер капчык күлмәк-ыштан турында әйткән дә юк.

Рәмзи, иске шәһәр урамнарына кергәч, юлда очраган хатын-кызларның сын-кыяфәтләрен бәяли-бәяли атлаганда да шуны уйлап барды: бу тамаша әйбернең барысын да алып китеп булыр микән соң?.. Иске шәһәрнең кар басып киткән тротуарлары буйлап бераз баргач, юл өстендәге бәләкәй генә такта алачыктагы сыра киоскысына кереп тәмләп кенә бер савыт сыра эчте һәм балык котлеты капты.

Авылдашлары эштә иде. Ярый, бәхеткә каршы, авылдашның әнисе — карт әби килгән икән, ишекне шул ачты. Аннары мәктәптән балалар да кайтып керде. Алар шактый икән. Моңарчы Рәмзи абайламаган иде: ике кыз бала, дүрт малай. Житмәсә барысының да яшьләре бер тирәдә диярлек. Ләкин егеткә бала-чага белән артык булашырга туры килмәде, әйберләрен рәтләп төргәнче, әби белән үзенең туган авылы турында сөйләшергә кирәк иде.

Ул, авылда йорт аша гына яшәүче бу Шаһидә әбинең үзенең озын чәченә өнәмичәрәк каравын тойса да, берни сизмәгәндәй, эти-әниләре турында, авыл турында сораша башлады.

— Әтиең дә, әниең дә бик рәнҗиләр сиңа, — диде Шаһидә әби.

— Ни өчен? — диде гаҗәпсенеп Рәмзи.

— Хат салмаган өчен. Әниең бер көнне: «Кешеләрнең балалары атна саен хат яза, безнеке генә әллә нинди булып чыкты», — дип әйтте.

— Һе, пфе, — диде Рәмзи йөзен чытып, — әнигә әйт: хат язмый икән, значыт әйбәт яши диген. Ә андый-мондый күңелсезлек була калса, миннән хәбәр үз вакытында барып житәр.

— Алай бит яхшы түгел, балакай, — диде әби. — Әти-әниеңә начар хәбәр генә язгач, яман була ул. Яхшысын да язып шатландыр син аларны.

— Яхшымы-түгелме, минем неписаный закон шундый, — диде Рәмзи. — Каян табып бетерим мин вакыт. Эшлә дә, кызлар артыннан да йөр, жыелышларны да калдырма. Кая китә ул!

Әби Рәмзинең сүзне уенга боруын, мондый гәптән мәгънә чыкмаячагын аңлады. Ул күзләре белән генә елмаеп: «И жүнсез», диюдән башка җавап тапмады. Бераздан:

— Чәй эчәсеңме соң, юл килеп тамагың кипмәдеме? — диде. Әйберләрен төреп маташкан Рәмзи бик житди иде.

— Бездә чәй эчү гадәте юк ул, — диде. — Сусасак аракы кабабыз, ә иртәгесен махмырны сыра белән басабыз.

Әби тешсез авызын жәеп бу юлы көлеп үк куйды.

— И, ахламун, телеңә салын инде шулай, әниеңә кайтып әйтермен әле менә!

Рәмзи бер сүз дә дәшмәде. Киемнәрен төрде дә, эниләрне күрсәң, сәлам әйт, дип чыгып та китте һәм килгән юлыннан ук кире Яңа Чаллыга юл тотты. Иөге авыр түгел иде, трамвай көтеп торасы килмәде, язгы җепшек һаваны күкрәк тутырып сулый-сулый, капчыкларын сөлге белән бәйләп җилкә аша салган хәлдә елдам гына баруында булды.

Аның иптәшләре әле эштән кайтмаган. Ул, әйберләрен лифт янында утыручы Зояга калдырыр да, үз юлын дәвам иттерер. Белмәссең, бәлкем теге нәмәстәкәй эштән кайткандыр инде.

Чыннан да, бераздан үзен якын дусларча каршы алган Зойка-Сойкага әйберләрен калдырды да, бәхет сынап карау өчен, шул ук лифт әрҗәсенә утырып төшеп тә китте.

Ул соңгы вакытларда бик актив рәвештә бер рус кызы белән йөрде. Кыз Рәмзине үз итте, яратты һәм артын-алдын уйламастан бирелде. Волгоградлы Соня атлы сылу, күрәсең, бу чибәр егеткә зур өметләр баглагандыр. Ул инде Рәмзине бөтенләй якын күреп, әйтик, үзен аның хатыны сыйфатында хис итеп, яши башлаган иде. Ләкин Рәмзинең андый уйлар башына да кереп чыкканы булмады. Ул кызга үзе китәр алдыннан кая юл тотасын да әйтмәде. Шулай яхшырак иде аныңча. Китте, бетте, онытылды, вәссәлам. Ләкин әйтүе генә җиңел икән. Рәмзи ни кадәр каты бәгырьле булмасын, фабрикада уздырылган көннәрдә кызның язмышы уйландыргалады егетне. Һәрхәлдә, кызның хәзер нишләве, Рәмзи турында ниләр уйлавы кызыксындырды. Кызлар тулай торагы Рәмзиләрнекеннән бер чат арырак, шундый ук биек өйнең икенче катында иде. Ышанычы аз булса да, егет торакка керде, һәм, һич уйламаганда Соняны өйдә очратты. Кызның тамагы шешкән икән. Больничный биргәннәр, ул япа-ялгызы өйдә калган. Моны Рәмзи шулай ук лифт ишегe каршысындагы өстәл янында утыручы, үзенә таныш тетя Галядан белде.

Ишек шакылдатуга Сонянын «керегез!» дигән нечкә тавышы ишетелде. Ничектер якын, хәтта күңелне эретә иде бу тавыш. Рәмзи шул ук минутта каны кызышып китүен, рәхәткә омтылып, тыны кысылуын тойды. Ул ишектән башын тыкты да бик юаш бер кыяфәт белән:

— Мөмкинме? — дип сорады. Кыз үзенең караватында ята иде.

— О, д'Артаньян! — диде кыз. Рәмзине ул шулай атый иде. Бу исем аңа «Өч мушкетчы» фильмыннан соң ябышып калды. Ни өчен? Каян килеп ул кино каһарманына охшасын? Монысын Рәмзи бөтенләй аңламады. Мәгәр аны Соня гына түгел, бөтен бригада членнары шулай атый башлады. Чыннан да, бәлки ул өстенә курткасын, аякларына кунычын кайтарып төшергән резин итекләрен кигәч, мыеклы һәм озын чәчле булганга күрә бераз шул Дюма романында яшәгән французга охшыйдыр. Әмма Рәмзи үзе моның белән килешергә һич теләми иде. Ләкин берни эшләр хәл юк, кушамат дигәнең сагыз кебек ябышучан нәрсә бит ул.

— Мин ул, Сонечка, — диде Рәмзи. Ашыгып барып кыз яткан караваt читенә утырды һәм аның кулын учларына алды. — Авырыйбызмы?

— Тамак шеште, — диде кыз, авыру икәнлеген сиздерү өчен мөмкин кадәр әкрен, шыгырдавык тавыш чыгарып. — Син кая киттең?

Рәмзи тирә-юненә карап алды. Кыз чыннан да ялгыз иде — ишек янындагы киемнәр элгечендә бары аның гына мех пальтосы эленеп тора.

— Ә, — дип куйды ул, — булды инде шунда...

— Мин өченче көн Сашикны күргән идем, ул сине бөтенләй китте дип куркытты.

— Менә салага, — дип куйды Рәмзи үзе белән бер бригадада эшләгән егет адресына. Юкса аларга әйтелгән иде бит. Беркем дә Соняга Рәмзинең кая китүен ычкындырырга тиеш түгел!

Рэмзи, эле генэ исенэ төшкэндэй, иелде дэ кызның кайнар иренен үбеп алды.

— Юлэр, — диде кыз, артык каршылык күрсэтмэсэ дэ, — авыруым йогар эле менэ.

— Йокмас, — диде Рэмзи, тагы иелде дэ бу юлы кызның иреннэрен бик озак суырып торды. Кыз буыла башлап көчкэ башын борып өлгерде.

— Син нэрсэ, акылыңнан яздыңмы эллэ?

— Сагындым мин сине, Сонечка. Әйдэме... кызлар югында...

— Син нэрсэ? Чынлап тилермэгэнсеңдер бит? Алар хэзер кайтып керэчэк...

Рэмзи белэгендэге сэгатенэ карады да:

— Ну, эле ярты сэгатьсез кайтмый алар,— диде. Ул атылып ишек янына барды да оясындагы ачкычны ике тапкыр борып алды.

— Аңлыйсыңмы шуны, миндэ бик югары температура!

— Зарар юк.

Рэмзи чишенэ үк башлады...

Соняның иптэш кызлары кайтып кергэнче алар бераз сөйлэшеп утырырга да өлгерделэр.

— Миңа нииндидер көтелмэгэн нэрсэ булды, ахры. Синнэн балага уздым булса кирэк, д'Артаньян, — диде кыз.

— Юкны сөйлэмэ, — диде Рэмзи, — ул алай тиз булмый.

— Мин үземне-үзем синнэн яхшырак белэ торганмындыр инде.

Рэмзи уйга калды. Менэ син, күрэчэгең булса. Юк, мондый эшкэ юл куелмасын!

— Син, давай, Соня, — диде Рэмзи, — эгэр чыннан да шулай икэн, чарасына кер. Эш алай бармаячак.

— Мин эле үзем дэ анык кына белмим. Бераз көтик, аннан сөйлэшербез. — Соня, кинэт күтэрелеп, Рэмзигэ тулы, ак кулларын сузды да: — Син бит мине яратасың, д'Артаньян? — диде. Кызның йөзендэ, күзлэрендэ өмет, ышаныч һэм ялвару чагыла иде.

— А как же, — дип куйды Рэмзи, — э баланы төшерт. Аны бел. — Кыз бу минутта аңа чыннан да кызганыч тоелды. Бу тулы тэнле, соры күзле штукатурчы кызны Рэмзи алты айдан бирле белэ иде. Ул беренче күрешүдэ үк аның кэефенэ хуш килгэн иде. Соңыннан башка беркемгэ карамыйча гел Соня белэн генэ була башлады. Мэгэр башта кыз, Рэмзи моңарчы белгэн кызлардан үзгэ буларак, бик каты торды һэм үз дигэненэ Рэмзи моннан ике ай элек кенэ ирешкэн иде.

Рэмзигэ хэзер Соня кызганыч та, чак кына хэвефле дэ тоелды. Ул үзенэ кулларын сузып ашкынган Соняның муеныннан кочаклады, һэм, бик кайнар булмаса да, тагы иреннэреннэн үбеп алды.

## 13

Рэмзи Соня яныннан эшче кызлар кайта башлагач китте. Чөнки үзе белэн бергэ эшлэгэн иптэшлэре дэ озакламый кайтырга тиеш иде. Белмэссең, алар өерлэре белэн бэлки кая да булса китеп барырлар. Лэкин Рэмзинең борчылулары урынсыз булып чыкты. Егетлэр эштэн кайткан, бүген бер кая да җыенмыйлар, чөнки телевидениедэ кызыклы хоккей матчы.

Дуслары Рэмзине шаулашып каршы алды. Шундук бөтенесен сораша башладылар. Һэркем аның адресына шаян, чэнечкеле сүз эйтеп калырга ашыкты. Бу өч бүлмэле квартираның һэр бүлмэсендэ өчэрдүртешэр булып яшэүче яшьлэр барысы да бер бригадада эшлилэр. Бригадир, семьялы булганга күрэ, аерым яшэде. Башта вагонда торды,

аннан мена соңгы елны аңа әйбәт квартира бирделәр. Егетләр барысы да бер ук хокук белән файдаланалар. Ләкин шулай да Рәмзи белә, һәр коллективтагыча, алар арасында сайланмаган башлык бар. Бередә ул кеше — дөньяны күп күргән, усаллыкка да усал, яшьләрдән үзенең тәҗрибәсе белән дә өстенрәк булган Сан Саныч иде. Рәмзи килеп кергәндә, ул юыну бүлмәсендә булган. Тиздән чыгып Рәмзине күргәч, ул гадәттәгечә җитдилеген югалтмастан, ике сүзнең берендә сүгенү сүзләрен кыстырып, Рәмзине юрамалый әрләргә кереште:

— Син нәрсә... киттең дә дусларны оныттың... Кош фабрикасына китәм, имеш... Мине өлкән белгеч итеп куялар... Сезгә атна саен кош ите җибәреп торам, имеш... Җибәрдең... Эх, син...

Сан Саныч үзенең сүзләрен бик сәкыймле гыйбарәләр белән ныгытып барса да, Рәмзи моңа күнеккән, хәтере калмады. Әгәр үзара гәптә сүгенү сүзләре җитәрлек кулланылмаса, әңгәмә тозсыз аш ашау кебек тоела монда.

— Ну, озаккамы? — диде, ниһаять, Сан Саныч уеннан җитди сүзгә күчеп.

— Бер кич кунам. Әйберләр алып китәргә генә кайттым.

Егетләрнең күбесе аш хәстәрләргә чыгып китте. Рәмзи белән Сан Саныч бүлмәдә икәүдән икәү калдылар. Хәзер инде «карт» (Сан Санычны шулай атыйлар иде) сүгенеп сөйләшми, үз итүчәнлек күрсәтә, сүгенсә дә әллә нигә бер генә, анда да үзе бик яраткан сүзләрен генә кабатлый иде. Рәмзи фабрикадагы эшләре турында сөйләгәч, үзе сораша башлады:

— Безнең бригадир китә бит, — диде Сан Саныч, яна хәбәр итеп.— Мена әллә кая олакмаган булсаң, сине бригадир итеп куярлар иде. Хәзер яңа бригадир эзлиләр.

— Сине куярга кирәк, Сан Саныч.

— Юк,— диде, әле яшь булуына карамастан, башы пеләшләнгән, йөзен эре сипкел баскан чандыр рус. — Мине куймыйлар. — Ул үзе яраткан сүгенү сүзләрен тагы кушып алды. — Мин бит салырга яратам. Ә нәрсә, ашамагач та эчмәгәч, бу дөнья нигә ярый!

— Ә безнең тегендә ул яктан бик коры закон, — дип куйды Рәмзи.

— Ә, интеллигенция ул... Болай булгач барып чыгасың инде, д'Артаньян. Ну, бүген син кайткан хөрмәткә салабызмы соң?

— Мин бер литр куям, — диде Рәмзи бик батырланып. — Калганы сездән.

— Получка алмаган бит әле, — дип тагы тәмләп сүгенеп куйды Сан Саныч.

Егетләр кухнядан кастрюльләр, табалар күтәреп, үз бүлмәләренә берәм-берәм керә башладылар.

— Эй, братва! — дип кычкырды Сан Саныч, бөтен өч бүлмәгә дә ишетелерлек итеп, — д'Артаньян бер литр куям, ди, ашамлыкларыгызны барыгыз да давай безнең бүлмәгә!

Сан Саныч Рәмзигә әмер тоны белән:

— Бар, төшеп мен кибеткә, — диде. — Ул кайчак бик тиз бетә.

Рәмзи курткасына үрелде.

— Әле бар идеме соң?

— Бар иде, тик аны момент алып бетерәләр.

Егетләр кастрюльләр, җамаяклар, тәлинкәләр күтәреп, бүлмәгә керә башлады. Рәмзи стенага эленгән сумканы алды да ишеккә ашыкты. Ул үзен биредә кинәт бәйдән ычкынгандай җиңел тоя иде. Лифтта төшеп урамга чыгу белән какырына-төкеренә кибеткә ашыкты.

Шешәләр бушап, егетләр кәефләнә төшкәч, Сан Саныч:

— Сигез борынга бер литр нәрсә ул, — диде, — бу инде кортны ко-

тыртып кына кую. Д'Артаньян кайткан көн икән, мин, егетләр, өлеш кертәм. Әйдәгез, саранланмагыз.

— Ә хоккей матчы? — диде Саша. Рәмзинең бу тәбәнәк, зур башлы, төптән юан егет белән әле теге Соняга ачык авызланып сер әйтүе турында сөйләшәсе бар иде. Ләкин ул анысын соңгарак калдырырга булды.

— Иптәшегез кайткан көнне дә инде хоккей карап утырмагыз, — диде.

— Дөрес, — диде Сан Саныч, — д'Артаньян иртәгә иртүк китәм, ди.

Барысы да «карт»ны хупладылар, барысы да диярлек получкага кадәр дип саклаган сәмәннәрен чыгара башлады.

— Ярый бу, — диде Сан Саныч, акчаларын ашыкмыйча гына санагач, — яңадан ике литрлык. Ул Сашага текәлде. — Алырга чыгып керүне синнән үтенәбез инде, синьор. Онытма, бер-ике пачка «Аврора» да кыстыра кер.

Саша һич карулашмыйча шул ук сумканы алды да өстенә ялтыравык зәңгәр курткасын киеп, «Чао» дип чыгып китте.

Егетләргә иртәгә иртәнге җидедән үк авыр ашыгыч эшләр башкарырга кирәк иде. Ләкин йоладан нәрсә көчлерәк соң бездә? Әйдә, эшләнер әле. Иптәш кайткан икән, бер утырып күңел дә ачмау, ул инде бик зур хыянәт.

Бераздан төянеп Сашок та кайтып керде. Мәҗлес кызганнан-кызды. Хәтта бер ноктада җәнҗал өермәсе дә чак кына кузгалмый калды. Кемдер анда эшендә халтурить иткән дә иптәшенә сылаган, ә хәзер хәтер калулар хәмер сулышы башка менә башлагач, калкып өскә чыкты. Ләкин, барысы бер булып, бу янгынны дөрләп кабынганчы ук, сүндереп өлгерделәр. Сүз тагы үз җаена агыла башлады. Ул башлыча төзелештәге егетләр өлешенә чыккан эш турында барды. Кайчак читкәрәк чыгып киткәләп, сүз хатын-кыз мәсьәләләренә дә кагылгалады. Сары авызлы малайларны үзенең һәр вакыт җиңү белән бетә торган маҗараларын сөйләп шаккаттыручы кеше биредә әлеге Сан Саныч иде инде. Егетләр аны тыңлаган саен хәйран калалар. Кай ягы белән шул кадәр хатын-кыз мәхәббәтен яулый бу өтек пеләш. Ни төс, ни кыяфәт, ни буй. Хәер, телгә бик оста шул Сан Саныч. Егетләр белән сөйләшкәндә бик дорфа телле булса да, хатын-кыз алдында күгәрчен кебек гөрләп кенә тора инде. Гитара уйнап әллә нинди, беркем белмәгән, беркем моңарчы ишетмәгән мәхәббәт җырларын үзенең тенор тавышы белән моңлы итеп җырлап сихерли иде ул кызларны. «Ах, Сан Саныч, тагы бер, тагы бер», — дип кенә торалар иде аны тыңлаганда. Күрәсең, шул кирәктер хатын-кыз күңелен табу өчен. Рәмзи юкка гына гитара сатып алып тырышып-тырышып уйнарга өйрәнә башламады ич.

— Я, ничек соң син, тегендә ярыйсы «чувиха» таптыңмы үзеңә? — диде Сан Саныч, Рәмзинең ниләр уйлаганын сизенгәндәй. Рәмзи җавап бирергә өлгермәде, карт өстәп куйды: — Анда бәрәңге корсаклар гынадыр инде!

Рәмзи күзләрен ялтыратып баш бармагын тырпайтты.

— Во, нindиләр бар анда!

— Ну, ну, йоклап калма, алайса, егет.

Рәмзи, елмая төшеп, Әлфияне күз алдына китерде.

— Тик андый кошларны тиз генә электерү җиңел түгел шул, Сан Саныч, — диде.

— Бик югарыдан очалармыни?

— Шулайрак шул.

Сан Саныч кулларын уып куйды.

— Ә син үҗәтләнебрәк, үҗәтләнебрәк.

Рәмзи җилкәләрен җыерды.

— Булдыра алганча тырышып карыйбыз инде анысы.

— Бик дөрес. Эшче сыйныфына тап төшерергә ярамый.— Алар шаркылдап көлеп алдылар. Кинәт барысыннан да катырак көлгән Сашок Рәмзинең күзенә чалынып китте.

— Ә син шулай да, Санька, дусларча эш итмисең, егет. Нигә Соньkaга минем китүем турында әйттең?

Сан Саныч тагы сүзгә тыгылды:

— Әллә син аны күрдең дәме инде?

— Күрдем генә түгел... — диде Рәмзи. — Ну, эш андамени!

— Менә эт, этнең дә эте! Болай булгач, синнән кеше чыга, — диде Сан Саныч.

— Ну шулай да син, Санька, нигә аңа минем киткәнлегемне әйттең? Әллә аны үзеңнеке итәргә исәп бар идеме?

— Кит әле, — диде Саша сүгенеп. — Ул бит болай гына ычкынгандыр, бернинди андый-мондый максат белән түгел.

— Санька, — диде Сан Саныч, исерек күзләрен кыса төшеп һәм бармак янап, — онытма!

Рәмзинең исәбе Саньканы бераз өркетү иде, ләкин, кайсыдыр сүзне бөтенләй башка якка алып китеп, әңгәмәгә бөтенләй яңа юнәлеш бирде.

Егетләр шактый йомшарганнар иде. Берәрсе чыгып китеп ахмаклык ясамасын тагы дип, Сан Саныч тышкы ишекне бикләде дә ачкычны кесәсенә салды. Ул шундый иде. Ул шул ягы белән егетләрне нинди генә күзгә күренеп торган хәвеф-хәтәрләрдән коткарып калмады. Хәер, сыйланган көнне аңа рәнҗиләр дә иде. Тик иртәгесен картка рәхмәт әйтәләр, аңа хөрмәтләре тагы да арта төшә иде егетләрнең.

Бераздан Сан Саныч үзенең моңлы көйләрен гитарада уйнап җырларга керешге. Егетләр калыга да башладылар. Таралышырга вакыт иде. Кайберәүләр үз бүлмәләренә чыгып йокларга ятты. Ә Рәмзи белән Сан Саныч әле һаман йокламыйлар. Аларның берсе бөтен дөньясын онытып моңлы романслар җырлый, икенчесе исә шуны бирелеп ихлас күңелдән яратып тыңлый иде.

Алар сөйләшмичә, музыка белән мавыгып шулай бик озак утырдылар. Ә иртәгесен егетләр бөтен төркемнәре белән Рәмзине автобус тукталышына озата китте. Слесарьларның эшкә соңга калу куркынычы бар иде. Әйберләрне тукталыштагы эскәмиягә куйдылар да, Рәмзи белән саубуллашып, эшкә йөгерделәр. Рәмзинең кәеф шәптән түгел иде.

## 14

Галиәкбәргә Казанга барып кайтмыйча мөмкин булмады. Ни әйтсән дә, институтның ректоры чакыра иде аны. Үзе белән ничә ел бергә эшләгән, аңа күпме тапкыр ярдәм кулын сузган һәм Галиәкбәрнең сүзен күпме тыңлаган кеше. Аның үтенечен җавапсыз калдыру ул, иң кимендә, мәнсезлек булыр иде. Ә Галиәкбәр исә андыйга күнекмәгән.

Рәмзи Чаллыдан кайтып, эшенә керешкәч, профессор аңа:

— Син йөреп кайттың, инде миңа чират, — диде.

— Казангамыни тагы?

— Әйе. Чакыралар. Мин анда озак тормам.

Уздырыла торган сынаулар белән эш көйләнгән иде инде. Рәмзи бу эшнең серләренә төшенгән, укып, сорашып күп нәрсәне аңлаган, аның табигый сәләте хәзер профессор кул астында башланган экспериментны уздыру мөмкинлеген бирә. Ләкин Галиәкбәргә Казанга китә алу шартларының иң мөһиме — Әлфиянең кәефе иде. Әлфия исә, картның шатлыгына каршы, үзен җиңә алды булса кирәк — һәрхәлдә, әтисенә шулай тоелды — хәзер ул элекке халәтендә. Димәк, барысы да

тәртиптә, дип уйланды профессор. Һәр яктан аның җаны тыныч булачак. Ә Казанга кайтса, ул тагы үзенең җан парәсен, сары песнәген — Лиананы да күрә бит әле. Картның онык кызын уйламаган, сагынмаган берәр көне бар идеме икән?!.

Ул шул ук көнне, конторага кереп, Фәриткә үзенең Казанга барып кайтырга тиешлеген әйтте. Кызына Фәрит кабинетыннан гына шалтыратты. Фәрит исә, машинаның буш булуыннан файдаланып, картны директор «Волга»сына утыртты да, аэродромга озатты.

Әтисе, лабораториягә шалтыратып, үзенең Казанга очарга җыенуын әйткәч, Әлфиягә кинәт авыр булып китте. Аның бүген кичен аулакта гына әч серләрен ачып әтисе белән киңәшәсе килгән иде бит. Ул инде менә ничә көннән бирле үзен шушы эшкә әзерләп, ниһаять, бүген катгый карарга килгән иде. Шуңа күрә әтисенең «китәм» дигән сүзләре барлык планнарны җимереп ташлады.

Хикмәт шунда, Әлфиянең күңелендә моңарчы булмаган ниндидер шик-шөбһәләр туа башлады. Бу астыртын гына кузгалган вөҗдан газабы иде. Әйтерсең ул ярамаган эш эшләп ташлады — үзенең алдына килеп тезләнгән, гафу үтенгән газиз, кадерле сөйгәненә карата миһырбансызлык күрсәтте. Менә шундый икеләнүләр сыкрата башлады аның күңелен.

Әлфия башта мондый тойгы белән, үзенең чигенмәслек нык логикасына таянып, көрәшеп тә карады. Ләкин акыл ярышында бу чигенмәслек кагыйдәләр җиңүгә ирешсә дә, аның күңеле сызлаудан туктамады. Алай гына да түгел, киресенчә, артканнан-арта барды.

Кыз булып узган хәлләрнең барысын да җанландырып, инде менә ничә тапкыр күз алдыннан кичерде. Фәритнең аны алдап эш итүен — ир була торып, бала атасы була торып, моны куркакларча, хаиннәрчә яшереп йөрүен берәмтекләп алга салып бәяләде. Әйе, Фәрит кыз каршында коточкыч җинаять эшләгән иде. Моңа Әлфиянең иманы камил. Тик... тик Фәритнең озын керфекле, яшь белән тулы ялваручан күзләре, аның саф күңел белән Әлфиянең тезләрен кочып гафу үтенүе, күз алдыннан һич китмичә, күңелне сыкратып, үзәккә үтәләр. Әлфиянең вөҗданы телгә килгәндәй була һәм әйтерсең: «Алай ярамый, син артык рәхимсез кыландың... Син бит хәлнең бөтен нечкәлекләрен белергә теләмәдең, бары аның тышкы кабыгына карап кына үзеңнең каты хөкемеңне чыгарырга ашыктың», — ди.

Әлфия шулай икеләнеп калды. Аның баштагы катгый карарлары какшый башлады, күңеленә үзенең хаклы хөкем чыгаруы турында шик күләгәсе инде. Хәзер аңа бик якын бер кеше белән киңәш-табыш итәргә кирәк иде. Биредә әтисеннән дә якынрак кеме бар соң?! Ләкин менә ул хәзер тагы Казанга китте. Галиәкбәрнең: «Мин, кызым, китәм хәзер», — дигән сүзләрен ишетү белән, Әлфия ялгызлык газабын кичерә башлады.

Моңарчы ялгызлык дигән нәрсә аны бу кадәр үк авыр йөк булып интектермәде. Әлфиянең: «Кайчан кайтырсың соң?» — дигән соравына карт: «Белмим, — диде дә: — озак тормам бәлки», — дип өстәде. Бу ачык әйтелмәгән вакыт арасы күңелне баскан йөкне тагы да авырайта төште кебек. Әлфия эш көненең калган өлешендә никадәр генә онытылырга тырышмасын, барыбер аны авыр уздырды. Онытылып китеп, моңарчы һич булмаганча, бер колбаны идәнгә төшереп ватты. Үлчәү янына утыргач, аны көйли алмыйча тирләп-пешеп чыкты. Кызның нормаль хәлдә булмавын ярдәмчесе дә тойды. Ул аның һәрбер хәрәкәтен аерата бер игътибар белән күзәтә башлады. Сизмиме соң хатын-кыз бер-берендәге үзгәрешне! Лаборантка кыз соңгы көннәрдә баш зоотехникның бөтенләй керми башлавын шәйләгән иде инде. Бу юлы Әлфиянең үзгәрүе шуңа бәйләнгән булырга тиеш дип уйлады.

Эш бетәргә бер сәгатьләр чамасы кала лабораториягә Рәмзи шалтыратты. Ул, әйтүенә караганда, китап укыганда ниндидер бер аңлашылмаган нәрсәгә барып төртелгән икән. Эштән соң берәр сәгать узгач, Әлфия янына керергә рөхсәт сорый. Әлфия бу яңа зоотехникның үзенә карата гадәти булмаган бер мөнәсәбәт корырга теләвен аңламый түгел. Ул аны артык якын җибәрергә ярамаганлыгын да ниндидер эчке сиземләү белән тоя. Тик бу юлы кыз, өйгә кайткач, бөтенләй дүрт стена арасында япа-ялгыз калачагын, клубта киносы да юк бит бүген җитмәсә, дип уйлап алды. Шуңа күрә егеткә китабын алып килергә рөхсәт бирде, ачык булмаган нәрсәләрне шунда чишәрбез, диде. Һәм, әйтергә кирәк, ул телефонда сөйләшкәч үк егетнең шалтыратуын да, үзенең аңа килергә рөхсәт бирүен дә онытты. Тагы Фәрит турында, тагы үзенең шик-шөбһәләре турында уйлана башлады. Ниһаять, эш көне бетте. Стенадагы түгәрәк сәгатьнең гадәттән тыш әкрен кыймылдаган угы кирәкле, көтелгән вакытны күрсәтте. Әлфия, тиз генә киенеп, ашыга-ашыга фабрика территориясенә чыкты, әйтерсең ул лабораториядән китсә, үзен богаулап торган авыр уйларыннан котыла, ирек рәхәтенә ирешәчәк.

Әлфия утыз беренче корпус янында көтмәгәндә Фәритне очратты. Егетнең талчыккан, ләкин әле дә ягымлы тоелган йөзен күргәч, йөрәге, татлы якын нәрсәгә орынгандай, оеп китте. Ләкин бу хис яшен ташыдай ялтырады да шунда ук юкка да чыкты, күңелдә ниндидер шомлы үкенү газабы, ул да түгел, бары кайтарып булмый торган югалту газабы гына калды. Ул Фәритнең йөзенә карарга базмады. Фәрит тә, күрәсең, аны күргәч тетрәнгән, барысын да хәтерләгән иде, ул да күз чите белән генә кызны бер сөзеп алды да, башын түбән ия төшеп, тагы да кызурак атлап китте. Кыскасы, бу очрашу кызның болай да авыр кичерешләрен арттырды гына. Аның һаман көйрәп торган вөҗдан газабына хәзер Фәритне кызгану тойгысы өстәлде. Егетнең суырылып калган ябык йөзе, ничектер хәзер иенкерәк булып калган гәүдәсе кыска арада гына күзгә чалынса да, күңелдә, тимер кыздырып баскан эзләрдәй, тирән булып уелдылар. «Мин, аны-моны абайламастан, артыграк кыландым, аның кешелек сыйфатларын аяк астына салып таптадым. Үзең сөйгән, киләчәгеңне аңа тапшырырга әзерләнгән кешегә карата шулай булырга ярыймы соң?»

Фабрика территориясеннән чыккач үзен кая куярга белмичә, Әлфия башта поселок уртасындагы таштан салынган клуб бинасына таба юнәлде. Бүген фильм булмаячагын белмәгәндәй, махсус тактага ябыштырылган белдерүләрне бик озаклап укып вакыт уздырды. Аннан ул поселок кибетенә китте. Анда азык-төлек тә, промтовар да саталар иде. Хәтта телевизор, пианино кебек культура товарлары да бар. Әлфия исә күлмәк-күнчәк тирәсендә бик озак маташты. Бу күлмәк ничегрәк икән дә, тегесе ничегрәк булыр дип, кибеткә килеп чыккан танышлары белән киңәшеп алды. Шулай анда байтак таптанганнан соң, максат сизелмәсен дигәндәй, кирәкмәсә дә ике йөз грамм хәлвә үлчәтте һәм, ниһаять, кибеттән чыгып китте. Артык барып сугылырлык урын да калмады инде поселокта. Якын танышы врач кыз Чаллыга китте. Әлфия ихтыярсыздан квартирасына кайтырга мәҗбүр иде. Ул ишек төбенә җиткәч кенә анда үзен көтеп торган Рәмзине күреп, аңа килергә рөхсәт иткәнлеген хәтерләде. Үзен елмаеп каршылаган егетне күрү ничектер кызның күңеленә җылылык иңдергәндәй булды. Әйе, ул ялгызлыкта калмаячак бит әле, ни әйтсәң дә, янында бер иптәш булачак.

Алар баскычтан өскә менеп киттеләр. Әлфия Рәмзинең артык тырышлык күрсәтеп үзенә, һич кирәкмәсә дә, ярдәм итүенә илтифат бирмәде. Юкса, Рәмзи ачкычны тиз генә Әлфиядән алып ишек бигенә иелде. Ишекне төбенә кадәр ачып җибәреп, иркен елмая-елмая, куштанланып, ярарга тырышып, «пожальте» дип кулын эчкә сузган килеш

Әлфияне алдан кертеп җибәрде бит. Боларның берсе дә Әлфиянең күзенә чалынмады. Аның башында тагы Фәрит кенә хөкем сөрә, ул гына күңелен биләгән иде. Нигә аны очраткач та курмәмешкә салышып узып китәргә инде?! Янына барырга да күзләренә туп-туры карап әйтергә иде: Фәрит, әйдәле, безнең арадагы җепләр бөтенләй өзелгәнче, тагы бер аңлашыйк, дияргә иде. Әйтерсең без турсаерга гына торган үсмер балалар.

Рәмзинең тәчеләнеп «пожальте» диюе соңрак барып житте Әлфиягә, һәм ул уянып киткәндәй булды. Егетнең кыланышына ирексездән сүрән генә елмаеп җавап бирде. Пальтосын салып элгәч, монысына башы җитмәгән егеткә ул:

— Сез, Рәмзи, эчкә кереп газета карый торыгыз, — диде. — Ә мин чәй куйыйм.

Рәмзи курткасын салып элгәч, эчке бүлмәгә узды. Өстәлдә яткан журналны кулына алды. Аныңча, Әлфиянең үзен болай җылы каршы алуы ярыйсы, өметләндерерлек фал иде. Чәйләп утырасы да булгач, димәк, кердең-чыктың түгел, ярый бу, ярый, дип уйланды егет. Рәмзи журналдагы матур, буяулы сурәтләр белән булашып утырган арада, эшен бетереп, Әлфия дә бүлмәгә керде.

— Кул юасызмы? — диде. Егет Әлфиянең гүзәллегенә сокланып телсез калды. Ни арададыр Әлфия күлмәген алыштырырга да өлгергән — өстендә алсу чәчәк төшкән ситсы халат иде. Ләкин ул шундый чак, матур итеп тегелгән, кызның бөтен тән гүзәллеге «менә без» дип күзгә кереп торалар. Рәмзинең башына күңелне оета торган кайнарлык күтәрелә башлады. Ул шунда ук кызга ташланып аның кайнар, тере тәнен кочагына алудан үзен зур авырлык белән генә тыеп калды. Тез буыннарының һәм кулларының җиңелчә калтырануын тойды егет. Сулышы кысылып, аска текәлде.

Егетнең кинәт агарынып китүен күреп, Әлфия курка калды.

— Нәрсә, әллә кәефегез юкмы, Рәмзи? — диде.

Ниһаять, Рәмзи үзен ипкә китерде.

— Юк, болай гына, — диде урыныннан торып, — хәзер кул юып керәм.

Ул туалет бүлмәсендә шактый озак торды. Әйе, аңа кул юган арада тынычланырга кирәк иде. Ул бүлмәгә кире кергәндә өстәл өстендә пар бөркеп чәйнек утыра иде инде. Әлфия өстәл кырына алды белән сөялеп икмәк кисә. Аның ак муенын, нечкә билен, янбашларын күрү белән Рәмзинең күңеле тагы бер уйнаклап алды. Аңарда кызны арттан гына килеп кочып алу теләге кинәт туып, сүнде. Ашыгып эшне бозудан куркып, егет тыелды. Әлфия:

— Утырыгыз, Рәмзи! — дигәч ул утыргычка чүкте һәм үзе алып килгән, моңарчы өстәл читендә яткан китапка үрелде.

— Минем алай эчәсем дә килми әле, — диде ул, — так разве только за компанию.

— Эчәбез, эчмичә теге! — диде кыз. — Йомышыгыз качмас әле.

Рәмзи эчтән генә: «Эх, чибәркәй, белсәң иде син минем йомышымны», — дип уйлады.

— Сыеграк ясамадыммы сиңа чәйне?

— Бик шәп, — диде Рәмзи, ләкин аның күз карашы Әлфиянең матур кулларына ябышып калды.

Әлфия исә һаман үз уйлары белән мәшгуль иде. Ул Рәмзине кыстап ашаткан арада да атлан май һәм хәлвәне аның алдынарак куеп, егетнең үз өендәге кебек иркен тотуын үтенгәндә дә, һаман Фәрит белән булып узган фаҗигале, тетрәткеч хәл турында баш ватты. Аһ, шуларның барысын да алып ташларга иде, аларның барысы да төш кенә булган булса иде!

Егетнең ни арададыр үз янына ук күчеп утырганын Әлфия сизми дә калды. Башта кыз биленә үтеп кергән җылылык рәхәтен тойды. Ул гына да түгел, аның уң балтырына да җылылык йөгерде. Әлфия егетнең кайнар кулын үзенең билендә сизде, ә аягы балтырына тигән хәлдә булуын аңлады. Ул башта сискәнеп китте. Ләкин аның авыр уйлары шунда ук юкка чыкты, кыз зиһенен җыйды. Егеткә кырыс бер караш ташлады да аның кулын биленнән каерып алды.

— Энекәем, — диде Рәмзинең соры ялтыр күзләренә туп-туры карап, — утыргычыңны үз урынына куй әле. Син бит миңа эш буенча ярдәм сорап килгән кеше.

Рәмзинең йөзеннән мәгънәсез елмаюы китмәсә дә, битләренә кызыллык йөгерде. Оялудан да бигрәк аның кызга ачуы кузгалды. Юк, мондый осечканы белми иде әле ул... Ләкин ул югалып калмады.

— Гафу үтенәм, мин сезне шундый чебен тимәс... дип уйламаган идем.

Ул элекке урынына күчеп утырды да кызарынган йөзен, янып торган елтыр күзләрен Әлфиягә текәде дә русча әйтте:

— Сез, минемчә, үзегезне артык югары бәялисез!

— Бәлки шулайдыр, — диде Әлфия, шулай ук русчага күчеп, — бәлки мин һәр нәрсәдә артыграк бөгәмдер... Ә кул салырга — ни, ни.

Рәмзи мыскыл белән елмайды:

— Билегезгә кулым тигәннән масса үлчәвегез кимемәгәндер бит?

— Кимеде,— диде Әлфия кырыс кына.— Ярты тоннага кимедем.

Рәмзи шаркылдап көләргә тотынды. Баягы киеренкелек йомшарган иде хәзер. «Бәлки әле яңадан бер көчлерәк һөҗүм ясасаң...» дип уйланды егет. Ул озак уйлап баш ватарга яратмый иде, утыргычын тагын Әлфия янынарак күчерде һәм тагы кулын кызның биленә сузды.

— Нишлисез сез, оятсыз,— диде Әлфия кинәт ычкынып. Аның матур коңгырт-кара күзләреннән нәфрәт очкыннары чәчри башлады. Шулай да ул әллә артык гасабиланудан, әллә башка сәбәп аркасында Рәмзинең кулын бу юлы алып ташламады. Рәмзи аның йөзенә табарак иелде.

— Мин сезне беренче күрүемдә үк яраттым. Ну? Каршы килмәгез. Мин сезне бик, бик яратам. Сездә әз генә дә хис-тойгы юкмыни?

Ниһаять, Әлфия тынычлана төште. Коры гына:

— Алыгыз кулыгызны,— диде.— Утырыгыз үз урыныгызга.— Әлфия хәзер инде Рәмзинең ник килгәненә анык төшенә иде. Аның күңелендә наян бер уй туды. Аныңча, хәзер бу егетнең үзенә мәхәббәт изһар итүен, аның донжуанлыгын белгән хәлдә дә, гашыйк рыцарь булып кылануын тамаша кылып тору бик сәер, мавыктыргыч бер нәрсә иде.

Егет һаман елмайган бер кыяфәттә калды, кулын Әлфиянең биленнән алса да, элекке урынына күчмәде.

— Әгәр дә сезнең мәхәббәт шундый көчле икән, сез инде, акыллым, минем сүзне тыңларга тиеш,— диде Әлфия. Күрәсең, кызның җылырак дәшүе егетнең күңелендә тагы татлы өметләр уятты, ул кискен генә Әлфиягә таба иелде дә аның битеннән үбеп алды.

Кечкенә генә, ләкин шактый каты кулның яңак төбен көйдереп алуы егетнең аңына барып җиткәндә, Әлфия аягүрә баскан, явыз елмаю белән Рәмзигә текәлгән иде.

— Ә анысы, энекәем, бары рөхсәт булса гына эшләнә!

Рәмзинең ачудан күзләре тонып китте. Ул бермәл кызга сугып җибәрергә дә чамалаган иде. Тик ниндидер көч аны тыеп калды.

— Ах, шундый кралямени әле син? — диде ул.

Аныңча, хәзер кыз белән артык конфетланып торуда мәгънә юк иде. Беткән баш бетсен... Күтәреп алырга да караватка илтеп салырга! Ул һаман әле үзенә нәфрәт белән елмаеп карап торган Әлфиянең

башыннан аягынача җәһәт кенә күз йөгертеп чыккач, катгый бер карарга килеп, урыныннан сикереп торды. Кыз инстинктив рәвештә артка чигенде һәм шул вакыт Рәмзине айныткан, ә кызга котылу шатлыгы вәгъдә итеп ишектәге звонок тавышы ишетелде.

Звонок чылтыравы тагы бер кабатланды. Әлфия кискен генә борылды да коридорга чыгып китте. Рәмзи исә, хәлне әле яңа гына искәреп, кызны куып җиту өчен алга ташланды. Ләкин соң иде инде, ишек ачылуга анда Әлфия кул астында эшләүче лаборантка кыз тавышы яңгырады.

— Узып барышлый әле мин. Кәефе дә юк иде Әлфия апаның, мәйтәм, нишләп ята икән...— диде ул.

## 15

Галиәкбәр институтка кергәч, колонналы мәһабәт бу бинаның вестибюлендә беразга тукталып уйланып торды. Аңа югыйсә хәзер кафедрага кереп Эльвира Хәкимовнаны күрергә кирәк иде, ә аннан соң гына инде ректор белән сөйләшергә. Ләкин профессор, үзе дә аңламаган хәлдә, доцент янына башта керергә базмады. Юк, курку түгел иде бу. Үзенең болай да нык теткәләнгән нервларын сакларга теләүдән генә иде.

Ул, һич кирәге булмаса да, приказлар эленә торган витрина янында бераз таптанганнан соң, эшне ректор белән очрашудан башларга булды. Аның телеграммасы буенча килдем бит мин, дип акланды.

Ректор кабинетының алгы бүлмәсендә аны секретарь кыз елмаеп, якты чырай белән каршы алды. Хәтта әле күңел өчен берничә комплимент та әйтте.

— Үзе биредәме — диде Галиәкбәр.

— Биредә, мин хәзер әйтәм.

Гыйниятуллин, әлбәттә, аны күптән көтә иде. Бәлки килмәс дип, хәтта борчыла да башлаган иде. Бу иләмсез зур калку маңгайлы, гадәттә кеше белән төксерәк бер кыяфәттә сөйләшүчән профессорның бүген үзе белән артык дустанә сүз башлау мәгънәсен аңлап җиткермәгән Галиәкбәр, ректор тәкъдим иткән сары күн тышлы йомшак кәнәфигә утырып, ул әйтәчәк гозерне тыңларга әзерләнде. Ләкин ректор алай артык кабаланырга уйламый иде, күрәсең. Ул гәпне пенсионерның хәл-әхвәленнән башлады. Бу тынгысыз картның тынычлап ял итәсе, дөнья рәхәтен чигеп кенә ятасы урында кош фабрикасында тәҗрибәләр оештырып йөрүен ишеткәч, әллә тәнбиһ белән, әллә инде сокланып башын чайкап торды. Ахырда үзе институтта булып узган хәлләр турында сөйләп, бер очракта мактанып, бер очракта зарланып алды. Ниһаять, ул төп мәсьәләне кузгатты. Галиәкбәргә бик мәгънәле генә итеп карап торгач:

— Сез Эльвира Хәкимовнаны күрдегезме әле? — дип сорады.

— Юк, мин туп-туры сезгә кердем.

— Бик елый бит ул...

Галиәкбәр каушый калды.

— Ничек елый?

— Шулай. Сез аны суйгансыз. Хәзер инде мин үземә ышанычымны бөтенләй югалттым, ди ханым.

Галиәкбәр, ни әйтергә дә белмәстән, кулларын җәеп «һе» дип куюдан башка берни дә эшли алмады.

— Ә диссертациясе аның планда,— дип сүзне дәвам иттерде ректор.— Әгәр җимерелсә, ул безгә генә түгел, Мәскәү агайларына да күңелсез сюрприз.

— Соң Мәскәү агайлары нәрсә караган? — дип куйды Галиәкбәр. Ул хәзер ачуының кайнап башына кабу дәрәҗәсенә җиткәнен үзе дә тоя, ректорның мондый мәгънәсез сүзләр әйтү өчен генә үзен эштән аерып чакыртуына күңеле белән рәнҗи иде.

— Мин берни дә аңламыйм,— диде ул пошынып.— Ул үтенде, мин карап чыктым. Кимчелекләр бар, җитди кимчелекләр. Рәхмәт әйтергә дә җиң сызганып эшкә керешергә генә бит инде, югыйсә.

— Ул безнеңчә шулай, Галиәкбәр Хафизович. Хатын-кыз кавеменнән бит доцент! Эмоциягә артык бирелүчән женестән.

— Без андый женес вәкилләрен күрмәгән кеше түгел,— диде Галиәкбәр.

Ректор Галиәкбәргә артык мәгънәле, хәтта серлерәк итеп тагы карап торды. Әгәр бераз күзәтүчәнрәк булсаң, аның әйтергәме, юкмы дип икеләнүен тоеп булыр иде.

— Билгеле, — дип куйды ул, ниһаять,— әгәр Эльвираның иптәше борчылып шалтыратмаган булса, бәлки мин сезгә телеграм сугып та тормас идем.

Галиәкбәр доцентның ире партия өлкә комитетында эшләгәнен белә иде. «Эш менә нәрсәдә икән, — дип куйды ул эчтән генә, —теге борчылып шалтыраткан һәм бу нindидер чаралар эзли башлаган».

— Соң мин нишләргә тиеш булам инде?— диде Галиәкбәр, — хатымны кире алыргамы, мин берни дә белмим, мин диссертация белән таныш түгел дияргәме?

Ректор үпкә аша елмая башлады.

— Ну, што сез? Әз генә сабыр итсәгез, сездән нәрсә үтенүебезне аңларсыз.

— Мин сезне тыңлыйм,— диде Галиәкбәр.

— Менә нәрсә, Галиәкбәр Хафизович,— ректор бераз уйланып торды. Хәзер инде профессорның үзенә буйсынырга тиешле кеше түгеллеге һәм аның белән сүз шактый нәзакәтле мөгамәләдә булырга тиешлеге аның исенә төшә.— Сезгә бик зур үтенеч. Ничектер безгә Эльвираның докторскиен формалаштыруда ярдәм күрсәтергә кирәк. Сез кафедрадан киттегез. Кафедра профессорсыз калды, ә институтта бер дипломлы галим кимеде. Моны бит компенсацияләмичә булмый. Бу инде, минемчә (ректор тагы елмайды), безнең генә түгел, сезнең дә намус эше, дигәндәй. «Профессор китте, үз урынына шәкертен профессор дәрәҗәсенә җиткереп китте». Логично бит. Кыскасы, ярдәм итүегезне сорыйбыз.

— Мин ярдәм итүдән бер вакытны да баш тартканым юк. Эльвира Хәкимовнаның эшен игътибар белән карап чыгу, кимчелекләрен күрсәтү ул, минемчә...

Ректор, аңлата алмавына үкенүдән гаҗиз булгандай, тирән итеп сулады.

— Андый гына ярдәм аңа җитми.

— Нинди ярдәм тагы, әллә мин аның өчен, яңадан эшкә кереп сынаулар уздыра башларга тиешме?

— Әйттем бит инде. Ул сезнең хатны укыганнан соң бөтенләй үзенә булган ышанычны югалткан. Аның өчен эшләргә кирәкми, тик ул үз тәлинкәсенә кереп утырганчы аңа консультантлык ярдәме күрсәтергә генә кирәк.

Галиәкбәр аптырап калды. Ул тегендә, фабрикада, җитди эшкә керешә ләбаса. Шулай тагы планнар җимереләчәкме?

Ул яңадан бу ярдәмнең бөтенләй кирәксез икәнлеген аңлата башлады.

— Сез, минемчә, Эльвира Хәкимовна турында бөтенләй ялгыш караштa,— диде.— Мин аны ун елга якын беләм, ул алай җебеп төшә

торганнардан түгел, көчле, мөстәкыйль хатын. Үзе теләгәнен булдырмый калганы юк...

Ректор аны шунда бүлдерде. Күрәсең, ул профессорның әйткәннәрен үзенчә аңлады.

— Әйдәгез, үткәндәге хәтер калуларны искә төшермик. Сезнең натурага килешми ул.

— Үйлаганым да юк, — диде Галиәкбәр, ректорның мәкерлелегенә тагы хәтере калып. — Ничек инде алай була ала! Сез, зинһар, әллә нинди шик-шөбһәләр белән баш ватмагыз.

— Әлбәттә. Шулай булырга тиеш тә ул. Безнең өчен бит барыннан да мөһимрәге — уртак эш, институт эше.

— Анысы дөрес.

— Менә болай инде, алайса,— диде ректор өстәлгә зур йөнтәс кулын чәпәп.— Сез әле кайткач Эльвира Хәкимовнаны күрмәдегезме?

— Юк, күрмәдем,— диде Галиәкбәр, башта аңа кермәвенә эчтән генә үкенеп.

— Күрергә кирәк булыр. Сорарга, нинди ярдәм кирәк ул сездән.

Галиәкбәр, ректорның артык акыл сатуга тартым тонына эче пошып, йөзен җыерды.

Ректор, нидер аңларга теләгәндәй, профессорны бермәл сынап күзәткәннән соң:

— Беләсезме, Галиәкбәр Хафизович, мин сезне дә аңлыйм. Башта ук кисәтәм, бу эш җәмәгать эше тәртибендә генә булмаячак. Мин сезне пенсиягез саклансын өчен бишенче разряд слесарь-сантехник итеп оформить итәрмен.

Галиәкбәр түзмәде, урыныннан торды һәм ничектер зәгыйфьләнеп киткән тавыш белән:

— Рәхмәт,— диде,— мин сезнең тәкъдим турында уйланырмын. Җавабы үз вакыты белән булыр.

Ул борылды да ректор белән саубуллашмастан кабинеттан чыгып китте. Чөнки ректорга соң дәрәҗәдә рәнҗегән иде. Соңыннан үзенең ни сәбәптән шулай хәтере калуы турында күп уйланды. Юк, ректорның үзен сантехник итеп алырга җыенуы өчен түгел иде, хәтта доцентка ярдәм итәргә кирәк дию өчен дә түгел, ахыр чиктә аның ире шалтыратканлыгы һәм ректорның куштанлануы өчен дә түгел. Ләкин ни өчен? Мөгаен, ректорның изгелек эшләүне административ рельсларга кертергә теләве өчендер, һәм шул тонда сөйләшүе өчендер.

Ректор кабинетыннан чыгып, коридорлар чатлыгында профессор тукталып калырга мәҗбүр булды. Дөресен генә әйткәндә, аның хәзер юри үч итеп Эльвира Хәкимовна янына керәсе килми иде. Шул ук вакытта ул ректорның: «Канатлары тәмам каерылып төшкән ханымның»,— дигән сүзләрен дә исенә төшерми кала алмады. Чыннан да, эш шулай торган чакта, кемгәдер ачудан, үз кул астында эшләгән бер кешене күрмәмешкә салышып, кайтып китәргә картның вөҗданы рөхсәт итми иде.

Шулай икеләнеп торганда ул үзенә кемнеңдер дәшүен ишетте. Аңа таба кафедраның яшь доценты Недзвецкий килә иде. Бу сузан, саргылт йөзле, әле утызны яңа атлап узган кешене Галиәкбәр үзе үстерде дип әйтергә була. Студент чагыннан ук кафедра каршындагы фәнни түгәрәккә йөрде егет. Профессор аның, артык зирәк зиһен иясе булмавына да карамастан, тырышлыгына һәм үҗәтләнеп бирелеп эшли алуына кызыкты. Институт бетергәч, егетне кафедрасында аспирантурага калдырды. Әйбәт гыйльми тема биреп, аны һәр даим дәртләндереп торды. Шулай ул кандидат, аннан доцент булды. Дөрес, Эльвира Хәкимовна коткысына бирелеп ул теге вакыт профессор белән элекке дуслык элемтәләрен бик киметте. Күрәсең, яшьләргә хас булганча, мин үзем дә җитлеккән кеше инде дип уйлагандыр. Мәгәр про-

фессор китеп, кафедраның эше начарлана төшкәч, ул остазын сагына башлады. Моны Галиәкбәр дә сизми түгел иде.

Доцент, профессорны бик хөрмәт итүен йөз чалымнарыннан, кыйланыш-сүзләреннән ачык сиздереп, түбәнчелек белән исәнләште. Аннан үзе утырган бүлмәгә чакырды. Галиәкбәр Эльвира турында сорады. Ул бүген килмәгән икән. Нигә? Анысын Недзвецкий әйтә алмый, чөнки әле телефоннан беркем дә моның турында хәбәр итмәгән. Яшь доцент, профессорга бик мәгънәле текәлеп.— Безнең бүлмәгә керик, шунда барысын да сөйләшербез,— диде.

— Менә эшләр ничеккә китте,— диде ул бүлмәгә кереп утырышкач.— Эльвира Хәкимовна сездән хат алгач, сездәге диссертациясен аның-көеп көтә башлады. Ниһаять, ул килгәч, үзенең диссертациясен безгә, ягъни — ике доцент һәм өч ассистентка бирде. Менә шул хатта язылган әйберләрнең дөреслеген тикшерегез, мин хезмәтемне сезнең хөкемгә тапшырам, диде. Тагы шунысын өстәп әйтте: «Мин үзем бу эш белән шөгыльләнмим, чөнки мине объектив булмауда гаепләүләре бар. Ә сезнең объектив хөкем чыгаруыгызга мин ышанам». Шуннан инде без, барлык эшне ташлап, сезнең тенденциоз булуыгызны исбат итү өчен электрон исәпләү машиналары янына утырып эшкә керештек.

— Һәм нәтиҗә? — дип сорады Галиәкбәр борчыла төшеп.

— Сез хаклы, Галиәкбәр Хафизович!

Галиәкбәр егетнең сөйләгәннәреннән үзенчә нәтиҗә чыгарды. Димәк, Эльвира үзенә шул дәрәҗәдә ышанган ки, үзенең ялгышуы ихтимал дип әз генә дә уйлый алмаган. Бу бик сәер.

— Шуннан ни булып бетте соң? Эльвира Хәкимовна моңа ничек карады?

— Без аның реакциясенә барыбыз да хәйран булдык,— диде доцент.— Күрәсең, үз-үзенә кирәгеннән артык ышанган кешедер ул. Ни булып бетте? Әлбәттә, ул безне коллектив рәвештә үзен юкка чыгарырга теләүчеләр дип атарга базмады. Ләкин шуңа охшаш бер талпыну булды. Аннан эшен университетның исәпләү үзәгенә тапшырган булырга тиеш. Анда да шундый ук нәтиҗә чыккач, бөтенләй аяктан егылды.

— Ни өчен шундый зур ялгышлар киткән аның расчетларында?

— Минемчә,— диде доцент,— электрон исәпләү машинасы утырткан аны.

— Ягъни бозык булганмы? Шулаймы?

— Шулай. Яңа гына алынган машина иде ул. Саташкалый. Ялган саннар чыгарып торган.

— Әйе шул, — дип куйды профессор, — коралны кулыңда тота белсәң генә ул синең ышанычлы ярдәмчең.

Алар бермәл тынып, уйланып утырдылар.

— Аның төшенкелеккә бирелүе тагы шуннан, минемчә, — диде доцент.— Ул булган саннар нигезендә мәкаләләр язып бастырган. Ә хәзер, таблицаларны төзәткәч, бөтенләй бүтән, хәтта баштагысын юкка чыгара торган нәтиҗәләр ясарга кирәк.

— Ничек шулай мөмкин инде?! — диде Галиәкбәр чын күңеленнән ачынып,— җиде кат үлчә, бер кат кис, диләр ич.

Доцент бер сүз дә әйтмәстән, елмаеп кына куйды.

«Эшләр болайга киткәч, минем булдыра алганны эшләмәскә хакым юк,— дип уйланды Галиәкбәр, — бу хәл бит кафедрага гына түгел, бөтен институтның абруена кара тап төшерә ала».

— Мин соңгы елда матбугатны җитәрлек карап бара алмадым,— диде ул Недзвецкийга,— әйтегез әле, кайларда басылды аның мәкаләләре?

Яшь галим санап китте. Профессор исә кесәсеннән блокнотын тиз генә чыгарды да терки барды. Бүген үк китапханәгә кереп ул жур-

налларны карарга булды. Башкача мөмкин түгел. Ничектер эшне ике фронтта дәвам иттерергә кирәк. Ике фронтта: бройлер фабрикасында да, Казанда да. Ләкин барыннан да элек Эльвира Хәкимовнаны күрергә, аның белән сөйләшергә, аны аякка бастырырга. Әлбәттә, ул бөтенләй мәлҗерәп төшмәгән булса.

Галиәкбәр шулай уйланып урыныннан торды һәм гыйльми китапханәнең картотекалар бүлмәсенә юнәлде.

## 16

Ихтыяр көченә шундый бай булып күренгән Эльвира Хәкимовнаның болай изрәп төшүе һич акылга сыймаслык бер хәл иде. Галиәкбәр аның квартирына килеп кергәч тә аңа Эльвираның үз бүлмәсендә авырып ятканлыгын әйттеләр. Ишекне үсмер егет ачты. Галиәкбәр хатынның түшәктә ятуын белгән хәлдә дә, егеткә үзенең хәзер үк доцент белән сөйләшергә тиешлеген аңлатты, һәм, җавапны да көтмәстән, өске киемнәрен салып чөйгә элә башлады. Бераздан үсмер егет әнисе янныннан «керсен» дигән хәбәрне алып чыкты.

Эльвира иркен агач караватта кулларын баш астына куйган килеш түшәмгә карап ята иде. Ул, профессор ишек шакыгач, «керегез» дисә дә, профессорга бөтенләй игътибар итмичә, һаман түшәмгә карап ятуында булды.

— Ни булды сезгә, Эльвира Хәкимовна? — дип сорады карт. Күрәсең, Галиәкбәрнең интонациясе һич хатын көткәнчә түгел, артык борчулы һәм үз итүчән йомшак иде. Кинәт хатынның күзләреннән яшь агып, күз чокырын тутырды.

— Ишетүемчә, сезнең мондый кара кайгыга батуыгызга мин сәбәпче булганмын, имеш. Ләкин мин нишләргә тиеш идем соң? — диде Галиәкбәр һаман шул ук йомшак, үз итүчән тонда. Ниһаять, шактый дәвамлы тынлыктан соң, Эльвира бик тирән итеп сулыш алды, күз яшьләрен йота башлады.

Галиәкбәр, һаман аңа карап, хатынның сүзне ничегрәк башлавын көтте. Ул барысына да әзер иде. Бик ихтимал, хатын елый, профессорны хәкарәтли башлар. Ул чагында Галиәкбәр аңа аңлатырга тиеш. Фәннең артык изге, ташламалар ясап дөреслеккә бернинди дә хыянәт кылмаска тиешлеген хатынга тагы бер тапкыр төшендерергә тиеш. Карт, шулай барына да әзер булган хәлдә, Эльвираның тынычланып сүз башлавын көтте. Бәхеткә каршы, Эльвира артык гасабиланмады, түшәмгә караган килеш, әкрен генә сүзгә кереште.

— Юк, профессор, мин сезне эз генә дә гаепләмим,—диде. — Бөтен гаеп миндә, бары үземнең кешегә артык ышануым аркасында. Мин лаборантларга артык ышанганмын. Ә алар... — Хатынның күзләрен тагы яшь басты, ул тагы тамак төбенә утырган күз яшьләрен йотып, тынып калды.

— Узган эшкә салават,— диде Галиәкбәр. — Хата киткән икән, инде аны төзәтү турында баш ватарга кирәк.

— Бу эш мөмкин түгел,— диде Эльвира, бу юлы күз кырые белән генә булса да Галиәкбәргә карап.

— Ни өчен?

— Өч мәкалә басылды инде шул ялгыш нәтиҗәләр белән.

— Мин аны беләм. Кызганычка каршы, миңа ул мәкаләләр белән бик соң танышырга туры килде. Ләкин ул әле сезгә «барысы да җимерелде, бетте» дияргә рөхсәт бирми.

— Мин, Галиәкбәр Хафизович, бернинди дә чара күрмим. Ничек, яңадан үз-үзеңне фаш итеп, намуссызлыкта гаепләп мәкалә язаргамы? Мондый эшнең булганы бармы соң?

Чыннан да, хәл мөшкел иде. Ләкин шулай да, Галиәкбәрнең ышануынча, бу очракта да башны югалтырга ярамый. Галиәкбәр әле үзе дә ничек буласын анык белмәвенә карамастан, тәвәккәлләп:

— Мин сезгә ярдәм итәчәкмен, — диде.— Күрерсез, барысы да менә дигән булыр.

Хатын ирония белән көлемсерәп куйды.

— Ничек ярдәм итә аласыз сез, олыгайган, үз хәлегез хәл булган карт кеше!

— Ә мин аның рәтен беләм,— диде Галиәкбәр,— тик сез генә үзегезне кулга алыгыз.— Ул урыныннан торды.— Мин хәзер теге якка чыгып торам, сез торыгыз да киенегез. Карагыз аны, озак маташмагыз, миңа да вакыт бик кадерле.

Ул ишекне нык итеп ябып коридорга чыкты. Эльвираның улы зур бүлмәдәге куе яшел бәрхет эскәтер ябылган түгәрәк өстәл янында дәресләрен хәзерләп утыра иде. Ул сорау белән профессорга текәлде.

— Хәзер әниең киенеп чыгар,— диде Галиәкбәр, өстәлдән читтәрәк торган креслога утырып.

Малай тагы китабына иелде. Галиәкбәр исә хатын белән сүзне нәрсәдән башлап китү турында уйлап алды. Ул бөтен күңеле белән бу мул энергияле хатынның абайсызлыгын, моның нигезендә бернинди дә хыянәт ятмавын төшенә иде. Мондый очракта инде үзең белгән, үзеңнең кул астында байтак вакыт тырышып эшләгән кешегә ярдәм кулы сузмау вөҗдансызлыкның иң ямьсез бер чагылышы, аныңча.

Бераздан Эльвира коридор буйлап юыну бүлмәсенә таба узды. Ул зәңгәр ефәк халаттан, чәчләрен тараган иде. Галиәкбәр аны ачык ишектән күргәч, ничектер тынычланып китте. Димәк, көч калган әле хатында, тик Галиәкбәр генә аның өметләрен аклый алсын!

Бераздан Эльвира бөтенләй яңарган бер кыяфәттә профессор утырган бүлмәгә килеп керде. Ул беренче сүз итеп профессордан өйнең җыештырылмаган булуына гафу үтенде, аннан улына икенче бүлмәгә кереп торырга кушты. Ниһаять, алар икәү генә калдылар. Түгәрәк өстәл тирәсенә кара-каршы утырыштылар.

— Сүзне менә нәрсәдән башлыйбыз, Эльвира,— диде Галиәкбәр үзенә сорау белән текәлгән хатынга карап.— Без бүген үк сезнең белән өстәмә экспериментларның методикасын төзәргә тиеш.

Профессор, барысы да тик ул әйткәнчә булырга тиеш икәнлеген сиздерергә теләгәндәй, ике кулын да йодрыклап өстәлгә куйды.

— Юк, минем бернинди экспериментлар белән чуалырга исәбем юк. Мин хәзер гыйльми эш турында түгел, ә яшәргә кирәк микән дигән уйлар белән көн итәм,— диде Эльвира.

Профессор ак мыегы астыннан күренеп киткән ап-ак протез тешләрен ялтыратып ирексездән елмая төште.

— Юкны сөйләмәгез, Эльвира акыллым,— диде ул.— Безгә хәзер сезнең белән бары эш турында гына уйланырга кирәк. Сез авыр чакларда хезмәттән дә көчлерәк табип юк икәнен беләсез бит!

— Бәлки шулайдыр. Ләкин андый прозаик нәрсәләр турында уйланырлык хәлдә түгел әле мин.

— Ә сез мин әйткәнне генә эшләгез, уйланмагыз. Ярдәм — миннән, дидем бит.

Эльвира профессорга ничектер сәерсенеп бераз карап торды да:

— Нигә сез минем өчен шулай борчыласыз? — диде.— Әйтерсең сез нииндидер җинаять ясаган кеше, әйтерсең минем фаҗигамдә сез гаепле. Барысы да үземнән. Шундый зур юләрлек эшләгәнмен икән, җәзасын да үзем күтәрергә тиеш. Кирәкми, борчылмагыз.

Профессор өстәлдә яткан йодрыкларын үзенә таба тартты, аның йөзе җитдиләнеп китте.

— Ә мин, Эльвира Хәкимовна, үземне әз генә дә гаепле санамыйм.

Нәкъ менә киресенчә, мин хезмәтегезне ярдәм йөзеннән тикшердем. Алыгыз әле зинһар кәгазь белән карандаш. Хәер, карандаш үземдә дә бар.

Эльвира сүлпән генә чыгып китте. Ул кәгазь эзләп, ни өчендер, артык озак йөрде. Шул арада Галиәкбәрнең хәтеренә узган көннәрдән бер вакыйга килеп китте. Кырык беренче елны булды бу хәл. Камалышта калган алты кешегә, шул җөмләдән Галиәкбәргә, дошман тарафыннан тар-мар ителгән полкның байрагын алып чыгарга туры килде. Бу төркемдәге алты кешенең икесе медик хатын-кыз иде. Калган дүрт ирнең икесе яралы, ә икесе әле генә пленнан качкан, анда алты тәүлек ач торган солдатлар иде. Гомумән бу төркемдәге кешеләрнең берсе дә үзебезнең якка исән-имин чыгарбыз дип уйламый иде. Юлсыз урыннардан, дошман гаскәрләреннән качып, ярым ялангач һәм ач килеш бару, күп дигәндә, биш көн дәвам итә алыр иде. Тик төркем биш көн дә, ун көн дә барды, һәм инде, өметне өзеп, аяктан калдык дигәндә, безнең разведкага очрап, байракны армия штабына тапшыру бәхетенә иреште. Бу булмастай эшне булдыру дигән сүз иде.

Кешенең мөмкинлекләре чиксез булуына Галиәкбәр шунда ышанды. Бу үз башыннан кичкән хәлләр турында ул соңыннан инде профессор булгач та күп тапкырлар уйланды — шаккатып, хәйран калып уйланды. Монда тәгаен кешеләргә көч-куәт бирүче шул, пуля тишкәләгән, тотып баручысы белән бергә җиргә күп тапкырлар авып төшкән, канга, туфракка буялып беткән кызыл байрак иде. Әйе, ул бер чүпрәк кисәге генә түгел иде, ул ниндидер зуррак, изгерәк символ иде. Солдат өчен намус бәрабәренә лаек бер нәрсә иде. Әгәр ул югалса, полк, бу егетләр-кызлар хезмәт иткән, иптәшләр белән дошманга каршы иңгә-иң торып сугышкан һәм бик күп дуслары шул полк җиңсен өчен сугыш кырында ятып калган полк таркалачак иде, ул яңадан торгызылырга, яңадан сугышларга кереп данлы җиңү юлларына кадәр барырга хокукын югалтачак иде. Әле Эльвира белән сүз барышында карт шул вакыйганы хәтерләп, ирексездән сугыштагы полк байрагы белән доцентның кулына эләккән диплом арасында бәйләнеш күрде. Эльвира бераздан кәгазь-карандашлар алып керде, әйберләрен Галиәкбәр алдына куеп утыргычына чүкте дә, тынып калды.

— Сез язасыз! — диде профессор кәгазь-каләмне аның алдына этеп.— Башта бергәләп уйлашыйк.

Доцентның хәрәкәтсез тик утыруын күргәч, Галиәкбәр:

— Мин сезне аңламыйм,— диде. — Әйтерсең сүз сезнең ниндидер хосуси эшегез турында бара. Алай булмый бит ул, акыллым. Карандаш алыгыз.

Эльвираның йөзендә җиңелчә елмаю чагылды. Ул, буйсынып, әйткәнне эшләде.

— Минемчә, безгә, бернигә дә карамастан, сынауларга керешергә кирәк. Мин карап чыктым, виварийумда[1] буш читлекләр күп. Тик башта бәләкәй генә ремонт һәм дезинфекция уздырасы бар. Карамагансыз, анда тәртип бозылган.

Галиәкбәр уздырылырга тиешле сынау вариантларын аңлатты һәм, минем сүзләремне ничегрәк кабул итте бу дигәндәй сынап, хатынга карап алды. Эльвира исә картның хуҗаларча тәнбиһ ясавына йөзен чытмады, әйткәннәрен тыныч кына тыңлады. Гамьсезлектән идеме, әллә килешү аркасындамы — бу кадәресен Галиәкбәр аңлап бетермәде.

— Я, мин киңәш иткәннәрнең кайсысын уздырырга телисез? — диде ул.

Эльвира, өске иренен тешләп, кара күзләрен бер ноктага төбәде. Ниһаять, аның куе, калын, ләкин ягымлы тавышы ишетелде:

---

[1] Виварийум — тәҗрибәләр уздыру өчен асралган хайваннар абзары.

— Бары сезгә хөрмәт йөзеннән генә,— диде ул. —Бары сезнең, олы башыгызны кече итеп, авыр вакытымда ярдәм кулы сузарга теләвегез өчен...

— Мин анысына да риза,— диде карт.— Мин сезне булдыра алганча киңәшләремнән мәхрүм итмәм. Анысына исәп тота аласыз.

— Рәхмәт.

— Миңа моннан соң үземне өчкә бүләргә туры киләчәк. — Ул кош фабрикасында күптәнге хыялның эшкә ашу мөмкинлеген сөйләде.

Әйе, икенчесе инде — Эльвира эше. Хәзер аны ташлап китү һич тә мөмкин түгел. Ә өченчесе — аның күз нуры, бәләкәй сары песнәге — Лианасы. Ул бичара бабасын сагынып беткәндер инде. Юньсез Сафура аның янына тагы бармагандыр әле. Үзенең онык-кызы янына һаман барып чыга алмавына профессорның йөрәге әрнеп куйды. Иртән самолеттан төшүгә ул өйгә кайтты. Ләкин Сафура өйдә юк иде инде. Шуңа күрә Галиәкбәр Лиана турында берни дә белә алмады. Ә институтка барып кергәч, көндезге ашын кабарга да вакыт артмады. Уку залында, вивариумда, Эльвираларда...

Сүлпәнрәк булса да эш башланды. Эльвира да әкренләп хәсрәт миңрәүлегеннән айный башлагандай булды. Гүя ул Галиәкбәрнең үзен түшәктән торгызуына мохтаҗ иде. Ләкин бер сәгать эшләгәннән соң, Галиәкбәр хәлсезләнә башлавын тойды, аның күз аллары караңгыланды, күңел болгатып башы әйләнергә керешә.

— Бирәр чынаяк чәйме, кофемы әзерли алмассызмы,— диде ул, ниһаять, хәленең артык начарлана башлавын тойгач.

Картның агарып киткән йөзен күрү белән, Эльвира чәчрәп урыныннан торды. Кухняга чыгып, термостагы кайнар суда кофе кайнатып алды, һәм кофейнигын, стаканнарын күтәреп йөгерә-атлый Галиәкбәр утырган зур бүлмәгә керде.

— Зинһар, гафу итегез, Галиәкбәр Хафизович. Тәмам чыгырымнан ычкынганмын икән.

— Зарар юк,— диде карт хәлсез бер елмаю белән,— сез түгел, мин үзем дә үз хәлемне тоймый калганмын. Иртә белән дә, самолетка утырганчы, юньләп ашамаган идем. Ашказаны асты безе дә бераз...

Хатын йөгереп чыгып колбаса, атлан май һәм икмәк алып керде.

— Карагызсана,— диде хәйран калып.— Минем дә бүген авызыма валчык та капканым юк бит.— Ул көлеп җибәрде һәм кухнядан үзенә дә стакан алып чыкты.

Бер үк кичерешләр, хатынның табигый, нормаль хатыннарга хас кайгыртучанлык сыйфатларының Эльвирада сакланганлыгы аларны тагы да якынайтты. Якынайтты һәм башка хәсрәтләрне арткарак чигерде. Алар, ашап-эчкәннән соң, бөтенләй бирелеп, уздырылачак эксперимент планын корырга керештеләр. Галиәкбәр сынаулар методикасын үзе яза барды. Янында ышанычлы, тәҗрибәле кешенең булуын тою Эльвирага талгын бер рәхәтлек сулышы бөрки иде.

Алар экспериментлар турында байтак вакыт сөйләшеп утырдылар. Ниһаять, Галиәкбәргә китәр вакыт җитте. Аның әле бүген Лиана янына барып кайтасы да бар. Аннан өйгә дә соң кайтырга ярамый. Аяк асты тайгак, караңгы төшкәннән соң исерек хулиганнарның да очрау ихтималын белә Галиәкбәр.

Ул Эльвира янынннан әйбәт эш башкарылганлыгыннан туган эчке канәгатьләнү хисләре белән китте. Вокзалга бара торган троллейбуска дәртләнеп утырды, вокзал буфетыннан күчтәнәч сатып алды һәм, поездга өлгереп, Лианасы янына китте. Квартирасына ул тәмам арыганталган бер кыяфәттә кайтып керде.

Ишекне ачу белән бермәл берни дә аңгармыйча коридордагы хәрәкәткә карап торды. Саргылт чәчле ниндидер таза егет мышкылдыймышкылдый коридор идәнен юа иде.

Ул Галиәкбәрне күрү белән аягүрә басты, терсәге белән генә битенә төшеп торган чәчен сыпырып куйды. Ул арада әчке бүлмәдән Сафура да килеп чыкты.

— Әти, таныш булыгыз, бу синең киявең Дмитрий Александрович,— диде ул елмаеп. — Без бүген генә язылышырга үтенеч бирдек.

## 17

Эгоист кеешнең тагы бер үзенчәлеге шуннан гыйбарәт — ул һәрбер уңышсызлыгының сәбәбен тирә-юненнән яки бүтәннәрдән эзли. Аның башына, бәлки мин үзем гаепледер, дигән уй беркайчан да килми. Галиәкбәр ничә ел инде Сафураны күзәтеп, ничәмә тапкыр инде аның менә шушы кагыйдә буенча яшәвен күрде. Фән өлкәсендәге кеше буларак, мөмкин булганча объектив рәвештә һәм салкын канлылык саклап, хәлне тикшерергә ,моңа җавап бирергә тырыша иде ул. Без кешенең җәмгыять законнарына буйсынмыйча, бары үз кәефенә генә карап яшәгәнен күрсәк, еш очракта аның мондый тәрбияне (я тәрбиясезлекне) кайдан һәм кайчан алуы турында уйлана башлыйбыз. Без кешенең барысы да бер дәрәҗәдә акыллы һәм бер үк дәрәҗәдә яхшы сыйфатларны күңеленә сеңдерә ала дигән караштан чыгып хөкем итәбез. Шундый анализга керешкәндә, Галиәкбәр дә күп тапкырлар шушы мәгълүм ысулларны кулланды. Мәгәр ниндидер абсурд нәтиҗәләргә генә китерә иде бу. Чөнки тәрбия нәкъ башкалардагыча. Сафураның әтисе дә, әнисе дә барлык гомерләрен, хезмәттән ямь табып, дәртләнеп, янып яшәделәр. Вак-төяк «тәлинкә-кашык шалтыраудан» башка әйтерлек җәнҗал дип аталган нәрсә бер генә дә булмады. Балалары турында, әз генә дә аермый кайгыртып, икесен дә яратып, җәмгыятькә файдалы кешеләр булып үссеннәр дип тәрбияләделәр һәм, әйтергә кирәк, Сафура бик зирәк, барлык яңалыкны бик тиз тотып алучан булып үсте. Хәер, аны мәктәбендә артыграк мактадылар булса кирәк. Ләкин сәләт — укуга, фәнгә булган сәләт, әхлакый гариплеккә китерергә тиешмени?

Сафураның бәлки үз-үзенә артык ышануы — ни өчен шул кадәр ышанадыр?— озак-озын уйлап тормыйча, тиз генә катгый карар кабул итәргә ашыгуы, һәм шуның аркасында бик еш ялгышуы, ә инде ялгышканнан соң, бу ялгышуында кемнедер гаепләп, үзен судан пакь, сөттән ак итеп калдырырга тырышуы нидән килә соң? Бәлки акылсызлыктыр? Бәлки үз-үзен артык сөюдән киләдер? Ә бәлки кешеләргә артык югарыдан торып карау аркасындадыр? Алай дигәндә, кайдан килгән аңа бу гадәтләр, өйдә, нәсел-нәсептә булмаган эгоизм?

Галиәкбәр уйлап-уйлап та мондый хәлнең очына һич чыга алмый иде. Аптырагач, ул бәлки моңа безнең тормышның социаль шартлары сәбәптер, без бит кешене яшьтән үк горур булыгыз, принципиаль булыгыз, дошманнар белән Олег Кошевой кебек күкрәк киереп, башны югары тотып сөйләшегез, дип өйрәтәбез. Бәлки кайбер акылга зәгыйфьрәк кешеләр бу асылда бик дөрес тәрбияне я үзләренә кирәкле уңай рәвештә, я булмаса ялгыш аңлап эш итәләрдер. Аларның үз-үзен генә күперенке сөю тойгысы, үзен йон уңаена гына сыйпап тормаган һәр кешене җан дошманы итеп күрсәтә торгандыр? Юк! Галиәкбәрнең мондый гоман белән дә килешәсе килми иде. Аның монарчы йөзләгән, хәтта әллә ничә мең студент белән аралашканы булмадымыни! Сафура кебек сансызлар әллә нигә бер генә күренеп китә иде бит.

Ахырда ул, мәктәп һәм гаиләдән гаеп таба алмагач, Сафураның бакчага йөргән чагыннан ук аралашкан тар даирәсеннән гаеп табарга тырышты. Аның күзәтүенчә, кайчагында мәктәп һәм гаиләдән дә күбрәк балага дуслары, ахирәтләре йогынты ясый. Дуслык төшенчәсен

балаларча беркатлы, ялгыш аңлау аркасында, бу ялган дуслык шәрәфенә баланың коточкыч җинаятьләр ясау юлына басу мөмкинлеген, дөреслектән бөтенләй читкә тайпылып китүен Галиәкбәр белми түгел. Сафура рус мәктәбендә укыды. Аның барлык иптәшләре руслар яки руслашкан вак милләт вәкилләре иде. Әйе, руслар арасында да, һәрбер милләт кешесе арасындагыдай, милләтчелек чиреннән котылмаган гаиләләр дә юк түгел әле. Андыйлар башка милләт кешеләренә түбәнсетеп карыйлар. Алар өчен иң кадерлесе һәм иң камил булганы ул — үз милләттәше генә. Кем белә, бәлки Сафурага әнә шундый зарарлы чир йоктырганнардыр? Ләкин мондый хәлнең дә булуы бик шөбһәле иде. Чөнки безнең бөтен юнәлеш һәм тәрбия халыкларның бөек дуслыгын булдыруга юнәлгән бит. Интернационализм безнең яшәешебезнең иң мөһим терәге түгелмени? Шулай булгач, күзе сукыр булмаган һәркем бу бөек могҗизанә кыяны күрми уза алмый.

Галиәкбәр Сафураның кыланышларын күрә, ачына, ләкин, йөрәге сыкрап авыртса да, иң беренче чиратта кызы ясаган авыр күңел яралары аркасында түгел, ә аны, Сафураны, кызганып авырта иде. Нәрсә көтә бу ахмак кызны? Ул бит көннәрдән бер көнне ялгызлыкта калачак. Барлык кеше аннан йөз чөерәчәк. Ул чак бәлки үзенең холкын үзгәртергә дә керешер ул, ләкин инде соң булыр. Шагыйрь әйтмешли, картаеп каткач буыннар эш белү уңайсыз ул!

Кыскасы, Галиәкбәр үзенең анализлары бернинди дә нәтиҗә бирмәвен генә аңлый иде. Кеше табигате ул чеби түгел. Аның психологиясен дә тикшереп белүче юк, бары белеп була, дип уйлаучылар гына бар.

Сафураның әле генә картка мәгълүм булган капылт кияүгә чыгу вакыйгасы, Галиәкбәр фикеренчә, кызының тискәре якларын ахырынача ачып күрсәткән күңелсез бер күренеш. Сафураның бу егет белән әле күптән түгел генә танышуы карт өчен билгеле иде. Инде, ныклап танышмастан, тот та шуңа кияүгә чык, имеш. Бусы нәкъ Сафурача. Кызының этисенә һич югында, киңәш рәвешендә мөрәҗәгать итмәве үзе үк картны санга сукмауның ачык бер үрнәге түгелмени?

Сафура, иренең Галиәкбәр белән исәнләшүен ишетеп коридорга чыккач, һәм этисенә үзләренең кушылуын әйткәч, Галиәкбәр, ни әйтергә дә белмәстән, бер мизгел аптырап торды. Бары йөрәгенең кинәт кысылып авыртуын һәм җанының тоныкк әрнүен генә тойды. Ниһаять, акылын җыеп:

— Ничек шулай уйламаганда-нитмәгәндә, капылт кына? — диде.

Сафура этисенә бу хәбәрне рус телендә әйткән иде. Карт аңардан әле татар телендә сорады. Һәм, күрәсең, бу Сафурага ошап җитмәде, ул этисен шундук кисәтеп куюны кирәк тапты. Ничектер рәнҗеп елмайган хәлдә:

— Эти, онытма, без өчәү хәзер,— диде. Киявең синең рус кешесе, татарча белми. Шуңа күрә, моннан соң аның алдында русча гына сөйләшик.

— Ярый, мин рус телендә дә сөйләшә алам,— диде Галиәкбәр русча итеп.— Шулай да ник алай ашыктыгыз?

— Бу эштә мин гаепле инде,— диде Дмитрий бераз сагаеп, ләкин шулай да елмая төшеп.— Язылышуны мин ашыктырдым.

— Хәерле булсын,— диде Галиәкбәр, өс киемнәрен салып элгәч, үз бүлмәсенә оекчан гына узып. Чөнки аның өй башмакларын кияү киргән иде.

Бүлмә тагы Галиәкбәр киткәндәгечә түгел иде. Күрәсең, кемдер аның ятагыннан файдаланган. Галиәкбәр өстәле янына агач кәнәфигә утырды да маңгаен учына салды. Кәеф китебрәк тора бит. Ахры, артыграк арылгандыр. Профессор, барысын да онытып, бөтен зиһенен бергә җыярга тырышты. Ул да булса — иртәгә эшләнәсе эшләр. Казанга кайтудан файдаланып трестка керергә, андагы начальство белән

кош фабрикасында уздырылырга тиешле сынаулар турында җитди рәвештә сөйләшергә кирәк. Әйткән сүзләреннән кайтмаганнармы, карт ныклап эшкә керешсә, ярдәм нинди булыр?

Ул директор кабинетындагы киңәшмәдә тиешле дәлилләрнең барын да әйтеп өлгермәде, соңыннан гына кешеләрне тәмам ышандырырлык, бик шәп гыйльми фактларның телгә алынмый калганын абайлады. Менә хәзер инде барын да җиткерергә кирәк. Хәзер өстәвенә аның үзе уздырган эксперимент нәтиҗәләре дә кул астында. Ул кинәт дәртләнеп, кәефсезлеген дә тәмам онытып, үз шкафында саклана торган папкаларына чумды. Шактый вакыт казынып кирәкле папканы тапкач, ул ниндидер эчке канәгатьләнү, хәтта куану тойгылары кичерде. Папканы иплап өстәленә салып, аның эчендәге кәгазьләрне, андагы гади графит карандаш белән язылган цифрларны карый, тикшерә башлады. Бу минутта ул үзен, нәкъ элеккечә, институтта янып эшләгән көннәрендәгечә, бәхетле итеп тойды.

Кинәт ишек ачылып китте. Бүлмәгә бер-бер артлы Сафура белән Дмитрий килеп керделәр. Аларның елмайган йөзләренә карап, картның күңеле яңадан бүгенге көнгә әйләнеп кайтты, башына корт иледәй уйлар көтүе кереп тулды, ул кызына, киявенә әйтәсе сүзләрен хәтерләде. Ләкин тәнбиһтән башланган сүзне Сафура үзе әйтеп өлгерде.

— Әти, бәлки син безне тормыш башлавыбыз белән тәбрик итәрсең?

Карт аларга урындыклар күрсәтеп утырырга кушты.

— Чын күңелдән котлыйм, тормышыгыз бәхетле булсын, — диде.

Дмитрий рәхмәт әйтеп баш иде, Сафура исә тирән итеп бөтен тулы күкрәге белән сулап куйды. Ниндидер авыр бер тынлык булып алды. Әйтерсең бу күңелсезлекне Галиәкбәр генә төзәтергә тиеш иде, ул түзмичә сорады:

— Тормышыгызны ничек оештырмакчы буласыз соң? — диде.— Лиана мәсьәләсе турында уйладыгызмы? Мин бүген аның янында булдым, син, Сафура, бармагансың икән. Әйтүләренә караганда, кияү генә булган, ахры, гафу итегез, исемегезне белмим.

— Митя,— дип куйды егет, матур ак тешләрен балкытып. Кияүнең әйткәне картның күңеленә барып җиткәнче үк тагы Сафура сүз башлады.

— Безнең әле, әти, чираттагы эшләр җитәрлек. Лиана һәм синең турыда уйларга өлгермәдек,— диде.

Галиәкбәр буынтыклы ак, зур кулларын җәеп алды.

— Соң, эш нидә?

— Эш шунда, әти, без кечкенә генә булса да туй мәҗлесе уздырырга тиештер бит?

— Әлбәттә. Уздырыгыз.

— О, уздырыгыз! Аңа бит акча кирәк.

Галиәкбәрнең акчасы юк иде. Эшләгән чагында саклык кассасына сала барганы күптән бетте. Аларның иң зур өлешен шул ук Сафураның беренче туена тотты карт, аннан калганы Мәгъмүрә җеназасында төгәлләнде. Хәзер исә профессор айлык пенсиягә генә яши.

— Миндә акча юк бит, кызым,— диде Галиәкбәр. Ул числолыкка карап алды да аның битләрен ертып бүгенге көнгә килеп җитте.

— Әле пенсия дә тиз генә килмәячәк.

Сафура күңелсезләнеп, нәкъ бала чагындагыча, аскы иренен бүлтәйтеп турсая башлады.

— Синең шул булыр инде,— диде татарча,— гомергә мине мактың.— Кинәт ул гасабиланып урыныннан купты, тавышына хуҗа була алмастан, ачу белән: — Нинди ата син, шундый вакытта да ярдәм итә алмагач?!— Ә иренә русча дәште:— Киттек, Дима. Биредә кешечә сөйләшеп буламыни!

Бу дуамаллык билгеле бер максат белән ясалган иде. Галиәкбәр, узган тәҗрибәсеннән чыгып, тиз аңлады. Хәзер әтисе, тукта, кызым, шашма, уйлашыйк, бәлки берәр җаен табарбыз, дип әйтергә тиеш иде. Ләкин карт бу юлы бер сүз дә дәшмәде. Чөнки аның, чыннан да, акчасы юк иде. Ә кемнән булса да бурычка алып торырга ул бөтенләй теләмәде.

Ул яшьләрнең кергәндәгечә бер-бер артлы чыгып китүләрен мөмкин кадәр тыныч булырга тырышып, дәшмичә генә күзәтеп калды. Үзенне кулда тотарга никадәр генә тырышма, Сафураның тотнаксызлыгы карт йөрәккә барыбер кан саудыра иде. Галиәкбәр шактый озак вакыт үзенең язуларына кереп китә алмыйча азапланды. Кинәт аның башы чәнчешеп авырта башлады, ул тагы үзен нәкъ баягыча кәефсез итеп сизде. Дарулар куелган секретер шкафыннан аскофен алып капты, аны өстәлдә торган шактый искергән, тәм кереп бозылган су белән йотты, аннан диван-караватын көч-хәл белән ачып, баш очына колак мендәре салды да сузылып шунда ятты.

«Эшлисе эшләр», — дип куйды ул тавышланып. Тик уйларын туплый алмады, күз алдына Сафураның төксе йөзе килеп басты. Аннан котылыр өчен Галиәкбәр тавышын тагы да күтәрә төшеп: «Эшлисе эшлә-әр!» — дип кабатлады. Күз алдында әле бүген үзен күреп чиксез шатланган Лиана җанланды. Ләкин бу шатлыкны аның әнисе турындагы рәнҗеп әйткән сүзләре тагы юкка чыгардылар. Бала зурларча авыр көрсенеп: «Әнием килми дә килми, ә башкаларның әниләре генә түгел, әтиләре дә килә», — дигән иде. Сабыйның бу сүзләре картның йөрәген шул вакытта ук каты тырнап авырттырган иде. Бу юлы ул тагы да тирәнрәк яра ясады. Әмма Галиәкбәр бирешмәскә тырышты. Тагы иреннәрен җиңелчә хәрәкәтләндереп уй-хисләрне кирәкле юлга юнәлтергә тиешле шул ук сүзләрне кабатлады. Аның күз алдында хәзер Әлфия, аның яшьләнгән күзләре, хәсрәтле йөзе тора. Карт авыр хәрәкәтләнеп креслосына утырды, җыерчыклы зәңгәр кан тамырлары беленеп торган киң маңгаен учы белән каплады.

Юк, болай үз сырхавын тыңлап озак утыра торганнардан түгел иде ул. Ул яңадан башын югары күтәрде, аягүрә баскан килеш хатынының стенадагы портретына текәлде. Мәгъмүрә көлемсерәп, матур кара күзләрен тутырып карт иренә караган иде.

— Я, нишлибез, Мәгъмүрәҗан? — диде Галиәкбәр. Шунда ук куркынып күзләренә яшь тулганын тойды. Ю-ук, болай барып чыкмый. Булмаганны. Юк, юк, инде бирешә үк башладыңмыни, карт солдат? Барып чыкмый, бу сиңа килешми, әфәндем. Син үз гомереңдә хәсрәт елгаларының болайракларын аркыладың, сиңа балавыз сыгып, мәлҗерәп тору гомумән килешми. Ул яшь аша елмаеп яшь һәм гүзәл хатынына текәлде.

— Шулай бит, Мәгъмүрә? Әйт, шулай диген!

Чыннан да, портрет телгә килгәндәй булды. Ул, шулай җаным, шулай бәгырем, шулай кадерле картым, диде кебек.

— Менә шуның белән вәссәләм, без эш турында кайгырта башлыйбыз! — Ул папкасын яңадан ачты, андагы чиксез күп саннар белән чуарланган таблицаларга чумды.

Тиешле материалын барлаганнан соң, Галиәкбәр булачак эшкә рәсми төс бирү өчен трест башлыгына аңлатма-үтенеч язарга дип язу машинасын өстәленә куйды. Ярый, бәхеткә каршы, Сафура аңа кул тидермәгән, бу юлы аның бер җирен дә ватмаган иде.

Эшләре төгәлләнгәндә карт тәмам тынычланган, булачак хезмәт ләззәтен алдан ук тоеп, гадәттәге халәтенә кайткан иде. Ул урын җәеп ятагына сузылды. Кулына үзе өйдә булмаган арада килгән почтаны алды. Ә иртәгесен ул һава сулап кайту өчен, тимер юл буендагы агачлыкка юнәлде. Карт биләмнән әйләнеп кайтканда, яшьләр эшкә киткән

иде инде. Галиәкбәр каты итеп чәй кайнатты да иркенләп кухня өстәле янына утырды. Аннары, эш көне башланырга ярты сәгать кала, трестка китте.

Алай да алданрак барылган иде. Коридорда трест башлыкларын көтеп утырган арада Галиәкбәр ашыга-ашыга баскычтан Фәрит белән кош фабрикасының директоры менгәнен күрде. Ашыгыч рәвештә чакыртылып автомобильдә килгән таныш йөзләрне күрү карт өчен сәер дә, күңелле дә иде.

## 18

Фәрит профессор белән нинди генә киеренке мөнәсәбәттә булмасын, аны трест идарәсендә очратуына шат иде.

Кичә директор кабинетында шактый кайнар бәхәс булып алды. Гатауллин Фәритне, әле яңа гына аңгаргандай булып, узган киңәшмәдәге принципсызлыгы өчен тирги башлады. Директорның әйтүенә караганда, әгәр алар хәзергә һич кирәге булмаган экспериментлар уздыра башласалар, фабрика трест күләмендә бөтенләй артка калачак, план тулмаячак, премияләр бетәчәк, бу исә, үз чиратында, болай да сыйпау, иркәләү аркасында гына фабрикадан китми эшләүчеләрнең гайрәтен чигерәчәк, тагы да начаррак хезмәт итүләренә китерәчәк. Әле белмәссең, бәлки купләрнең китүенә кадәр үк барып җитәр эш. Һәм менә шундый бервакытта баш зоотехник, фабриканың иң көчле терәге саналырга тиешле кеше, аны-моны уйламыйча, профессорга ярарга тырышып производствога күрәләтә аяк чалырга чамалый. Фәрит агарынып китте.

— Ничек инде ул аяк чалырга? Аңламыйм, аңламыйм.

— Син аңламасаң, Фәрит Зарипович, мин бик шәп аңлыйм. Синең профессор кызы белән якын мөнәсәбәттә икәнлегең миңа мәгълүм. Син үзеңнең мәнфәгатең өчен производство интересларын корбан итүгә барасың. Так не пойдет, агайне. Без дә не лыком шиты. Барысы да бик ачык күренеп тора, чөнки ак җеп белән ямалган.

Фәрит тетрәнеп, үзе дә тоймастан, урыныннан купты.

— Бу нинди сүз тагы? Сез бит безнең Әлфия Галиәкберовна белән нинди мөнәсәбәттә икәнлегебезне бөтенләй белмисез. Ә инде...

Ул әйтер сүзен йотып калды, башына яңа бер фикер килеп директорга текәлде.

— Эшләр болайга киткәч, безнең бәхәсне трест кына хәл итә ала. Чөнки сез житди мәсьәләне демагогия белән алыштырмакчы буласыз.

Фәрит фикеренчә, профессор ысулынча уздырылырга тиешле сынауларның кирәклеге бәхәссез иде. Барысы да көн кебек ачык: производстводагы эш технологиясе бер генә минутка да тоткарланып, катып калмаячак. Чөнки торгынлык безнең көннәрдә үлемгә бәрабәр. Фәритнең ачуын китергәне тагы шул булды, әгәр шәхси интересларны күзәтеп эш иткән булса, ул Гатауллин әйткәннәрнең нәкъ киресен эшләр иде бит. Бар икән әле дөньяда акны кара итеп күрүчеләр, җен алгыры!

Ләкин директор бирешергә теләми иде. Ул трест сүзе чыккач кына, җинел сулагандай булды.

— Бик дөрес, — диде. — Нәкъ мин теләгәнчә әйттең. Шулай да теге вакытта профессорга тәлинкә тоту булды.

Ул шул ук минутта селектор төймәләрен басып Казанны сорады.

Телефон көткән арада Фәрит эшне Гатауллинга иплап кенә анлатырга тырышты. Ул булдыра алганча дәлилләп, аның бик мөһим икәнлеген, әгәр уңышка ирешелсә фабриканың даны гына артачагын сөйләде.

— Әйе, шулай ул. Тик бер «мәгәр» бар. Әгәр дә мәгәр уңышлы чыкса! Лаборатория шартларында бик кыю эшләр башкарырга була ул. Ә производствода юк. Уңышсызлык монда бик кыйммәткә төшә. — Га-

тауллин кул кырыен муен тамырына тидереп куйды. — Менә монда төшә ул.

Әлбәттә, ул да үзенчә хаклы иде. Ләкин бу хаклылык, Фәрит фикеренчә, перспективаны, киләчәкне күздә тотмаган хәлдә генә дөрес иде. Аннан профессорның институтта уздырган сынаулары мәгълүм бит. Инде килеп фабрикада уздырылып ята торган сынаулар шулай ук уңай нәтиҗәләр вәгъдә итмимени?!

Фәрит, инандырырга тырышып, тагы шуларны сөйләп китте. Ләкин Гатауллинның күзләре һаман өметсез, хәтта ничектер мыскыллы карыйлар иде. Фәрит, никадәр тырышмасын, бу такыр башлы, тупас йөзле, ләкин үз сүзен уздыру өчен көрәшә белә торган карт төлкене әз генә дә ышандыра алмады. Теге киноларда күрсәтелә торган консерваторның нәкъ үзе инде син, дип өметсезләнеп уйлап куйды Фәрит.

Фәрит, ашыгыч эшләрен хәтерләп, кабинеттан территориягә чыккан иде. Эш көне азагында гына директор аны селектор аша өченче корпустан табып Казанның аларны ашыгыч рәвештә иртәгә иртүк чакырткан- лыгын әйтте. Күрәсең, чакыру әлеге бәхәс буенча гына түгел иде, чөнки директор беренче кварталның производство күрсәткечләрен дә әзерләп, иртәнге бишкә конторага килергә боерды.

Әйе, әле трестка килеп житү белән Фәрит профессорны очратуына бик шат иде. Гатауллин исә моны артык өнәмәде, шулай да сер сынатмады, Галиәкбәр белән якын дусларча исәнләште.

Алар трест башлыгы кабинетына өчәү керделәр. Зур башлы, агара башлаган, ләкин дулкынланып торган куе чәчле баш кеше кунакларны салкын бер тынычлык белән каршы алды. Башта сүз бары производство күрсәткечләре турында гына барды.

— Без барганда, әле материал тупланмаган дип, сез бездән дөресен яшердегез, — диде ул, — ә бит сезнең план катастрофик бер хәлдә.

Ул директорны да, Фәритне дә кулындагы кәгазьләрдәге күрсәткечләргә карап шактый кыздырды. Срок куеп шушы арада ук үзгәреш булырга тиешлеген таләп итте, бер генә дә объектив сәбәпне нигезле дип тапмыйча, мәсьәләне, кем әйтмешли, кабыргасы белән куйды. Ниһаять, сүз әлеге бәхәскә килеп житте.

— Сез нәрсә анда? — диде баш. — Сөйләшенде бит инде, ник юкны бушка әйләндереп вакыт уздырып йөрисез?

Сүзне Гатауллин алды. Ул фабриканың соңгы вакытта авыр көннәр кичерүеннән оста рәвештә файдаланып, инде өстәвенә бу дуамалланып башланачак сынаулар бөтенләй безне артка ташлаячак дигән фикерне алга сөрде. Чыннан да, аның дәлилләре бик ныклы, нигезле яңгырый иде. Логика эксперименталь эшләр алдынгы производствода уздырылырга тиешлеге турында сөйли иде. Глушко икеләнә калды. Ләкин шунда ук профессор сүз алды һәм уздырылачак сынауларның нәкъ менә шундый чакны ярдәм итәчәген исбат итәргә кереште. Ул трест башлыгыннан бер нәрсә генә үтенде, ул да булса сыйфатлы комбиазык һәм тиешле җиһаз-дербия мәсьәләсендә ярдәм күрсәтелсен, ягъни фабрикада бик житди эш барганлыгы һәм бу бер фабрика өчен генә түгел, ә гомумән бөтен трест, хәтта республика өчен бик мөһим нәрсә икәнлеге онытылмасын иде. Бу сүзләр Гатауллинга да ошап китте. Ул үзенең баштагы уйларыннан кайтып, профессорның соңгы таләпләренә ябышты. Ачыктан-ачык, ультиматум рәвешендә, шундый-шундый шартлар тудырылган очракта гына, сынау эшләренә ход бирергә була дип куйды. Галиәкбәргә дә, Фәриткә дә хәзергә шул житкән иде. Аларның трест башлыгына мөрәҗәгать итүләре бушка китмәде.

Глушко каршылык күрсәтмәде, без бирергә уйлашырбыз, ә сез фабрикага кайту белән мөмкинлекләрегездән файдаланып, профессор методлары буенча тәҗрибәләр уздыруга хәзерләнә башлагыз, диде. Бусы инде нәкъ максатча булып чыкты.

Галиәкбәрне кош фабрикасына машинада алып кайтырга булдылар. Әле Гатауллинның Казанда берничә җиргә керәсе бар икән. Юлга чыгуны көндезге сәгать икегә калдырып, таралыштылар.

Фәритнең дә Казанда эшләре юк түгел иде. Ул, вакыт булуыннан файдаланып, мелькомбинат каршындагы комбиазык заводына юл тотты. Аннан — ит комбинатына. Беренчесенә өстәмә комбиазык булмасмы дигән максат илтсә, икенчесенә бройлерлар өчен бик кирәкле һәм, бәхетсезлеккә каршы, һәр вакыт җитешми торган тиенгә техник май алып булмасмы дигән теләк илтте. Тик зоотехникның юлы уңмады, ул нилләр генә вәгъдә итеп карамасын, берни дә майтармады, чөнки Казан тирәсендәге кош фабрикаларыннан берни дә калмый, алар да май, витамин, хәтта пычкы чүбе тоткәзә алмый аптырыйлар икән.

Фәрит Бауман урамындагы татар ашлары йортына кереп бер стопка аракы эчеп, әбәт ашауга сәгать ике дә тулды. Гатауллин машинасы нәкъ икегә профессорны алып шул йорт янына килергә тиеш иде. Әнә ул шунда килеп туктаган да. Фәрит, арткы урында утырган Галиәкбәрне күреп, кайтасы юлның үзе өчен шактый авыр булачагын аңлады. Әлфия мәсьәләсенә генә кагылмасын иде карт дигән теләк аның күңелендә шунда ук урын алды.

Алар озын, ялыктыргыч юлга чыгып киттеләр. Әйтерсең сүз куешканнар, алар юл буена эшкә һәм Әлфиягә бөтенләй бәйләнеше булмаган әйберләр турында гына сөйләштеләр. Бераздан Фәритнең дә күңеле ачылып китте. Ул да сүзгә катышты. Үзе белгән берничә кызык анекдот сөйләп алды. Тик шулай да кызык әйберләрне Гатауллин барысыннан да күбрәк белә иде. Фәрит менә ничә тапкыр инде директорның юлдашы сыйфатында бара. Директор бер генә тапкыр да үзен кабатламас, бер генә тапкыр да кысыр мәзәк сөйләмәс, ни сөйләсә дә тапкырлык тулып ташкан булыр. Була бит шундый кешеләр! Фәрит директорының хәтер байлыгына юл чыккан саен гаҗәпләнә иде. Күрәсең, бу үзенә күрә бер төрле сәләттер инде!

Әйтергә кирәк, Галиәкбәр дә бик күп кызыклы нәрсәләр белә икән. Ләкин аның сөйләгәннәре үзе күргән я ишеткән, һәрхәлдә, булган вакыйгалар. Ә анекдотлары исә аның Гатауллиннныкы кебек түгел, әдәпле, интеллигентныкылар.

Кызыклы әңгәмә барганда, юл артык ялыктырмады. Алар фабрика поселогына килеп кергәндә караңгы төшкән иде инде. Кәкре койрыклар директор машинасы дип тормады, юлчыларны усал һау-һаулап каршы алдылар. Башта директор үзенең аерым коттеджы янында, аннары профессор кызы яшәгән ике катлы өй алдында, селикат кирпечтән салынган шундый ук стандарт өй турысында Фәрит төшеп калды.

Баскычтан менешли үк Фәрит, гадәтенчә, почта әрҗәсен ачып газеталар алды. Кинәт таш идәнгә бер конверт төшеп китте. Хатны кулына алгач, Фәһимәдән икәнен белү белән Фәритнең йөрәген ниндидер салкын елан урап алгандай булды. Ул баскычтан менә алмас хәлдә туктапып торды. Ләкин кызыксыну, син инде үзеңчә яшә дигән сүз булыр бәлки, дип өмет итү, аңа яңадан көч бирде. Ул аулак, шыксыз бүлмәсенә кереп ут кабызды. Өс киемен салудан элек конвертны ертып хатны ачты. Игътибар итте: Фәритнең куллары калтырый иде. Тагы шуңа игътибар итте — хатыны Фәритнең исемен, күрәсең, язарга лаеклы тапмыйчадыр, хатын «син» дип башлаган иде.

«Син, — дип язган ул, — үз рәхәтең өчен балаларыңны минем өскә ташлап, ничәмә ай миннән качып йөрдең. Әгәр эткәй барып сине җинаятең өстендә тотмаган булса, әле дә рәхәтләнеп буйдак егетләрчә йөрер идең. Ләкин көн дә бәйрәм, көн дә туй булмый шул, хыянәтләр өчен бер көн җавап та бирергә туры килә. Озын сүзнең кыскасы шул — балаларымнан котылдым дип уйлама, мин аларның икесен дә уку елы бетү белән сиңа илтеп куям. Аның белән генә чикләнмәячәкмен, мин

эшли торган җирендәге бөтен иптәшләрең һәм дамаларың алдында буранынңы уйнатып сине мәсхәрәгә калдырачакмын. Син әле, егеткәем, ефәк кебек булачаксың, чөнки барлык хокуклар минем якта, закон сине түгел, мине яклаячак. Менә шул. Өстәп шунысын да әйтим, синең пычрак җинаятьчеллегең аркасында хәзер әниең үлем түшәгендә ята. Үлә-нитә калса әтиең хәбәр итәр.

P. S. Акчаны бик аз җибәргәнсең. Алай гына булырга тиеш түгел. Балалар ризыгына кирәсең икән, суд аша алырбыз. Бөтен район халкы минем яклы. Барлык таныш-белеш синең кабахәт кеше икәнлегеңне белде, барысы да аптырый».

19

Истерик тонда язылган дорфа хат Фәритне бөтенләй чыгырыннан чыгарды. Аның өчен хәзер барыннан да авыррагы үзенең хатыны тарафыннан хәкарәтләнүе иде. Ни өчен мещанкалар юллары аерылган ирләрен шулай кан дошманы итеп күрә башлыйлар икән? Димәк, яратмаса яратмасын, тик минем янымнан китмәсен. Димәк, аның өчен барыннан да мөһимрәге үзен яратмаган кешенең бәхетен кисү, аңа үз тиңен эзләргә юл бирмәү. Мине яратмагансың икән, син дә ятратканың белән кавышма! Ни өчен бу гаделсезлек фаш ителми. Монда битярату түгел, кешегә булган гади хөрмәт тә юк.

Фәрит, бүлмә буенча әрле-бирле йөренгәләп, шулай уйланды. Ул бик ачыккан булса да, бернәрсә капмыйча, кая барып сугылырга белмичә, ниһаять, телевизорны кабызды. Ләкин экранда күрсәтелгән нәрсәләр белән мавыгырга никадәр генә теләмәсен, ул аны булдыра алмады, аның уйлары һаман хатынының рәхимсезлегенә кайтып кала иде. Бераздан ул телевизор экраны каршында күзләрен чытырдатып йомган килеш, башын түбән иеп, бернинди хәрәкәтсез утыра башлады. Аның бөтен тирә-юнен караңгы диварлар урап алган кебек иде. Ул Казанда, трест идарәсендә профессор белән үзенең максаты башлыклар тарафыннан хупланганч, барысын да онытып, нинди дер күңел көрлеге кичерә башлаган иде бит. Хәзер исә барысы да җимерелде, хәтта алда торган мавыктыргыч эшләр дә аны кызыксындырмый башлады.

Бераздан аңарда үзенең кайгы-хәсрәтләрен кемгәдер сөйләү теләге көйри башлады. Ләкин андый кеше юк иде. Хәлбуки башта ук Әлфиягә ул чынбарлыкны яшерми сөйләгән булса, бәлки хәзер янында ышанычлы, авыр чакларында кайгысын уртаклашырлык кешесе — гүзәл, акыллы Әлфиясе булыр иде. Һай, һай, һай! Бик зур ялгышлык эшләде, үзен өзелеп сөйгән гөнаһсыз кызны алдап бик нык рәнҗетте шул.

Фәрит һаман әле күзләрен йомган килеш утырды. «Инде нишләргә?» Юк, хәзер өйдә япа-ялгыз калу мөмкин түгел иде. Ул урыныннан торып телевизорны сүндерде. Өйдә хәзер әледән-әле суыткыч гөрләвеннән башка бернинди дә тавыш юк. Фәрит караватянындагы тумбочкада торган кара пластмасса телефон аппараты янына иелде дә телефон номерлары язылган юка дәфтәрчекне актара башлады. Аның исәбе хәзер күңеле яткан берәр кешегә шалтыратып, аңа барып чыгу, әгәр мөмкин булса, шунда үзе теләгән кадәр утырып кайту, үзен тәмам буа башлаган һәм озакламый аяктан егачак хәсрәтләрен җиңеләйтергә, һич югында, аны онытып торырга тырышу иде.

Әбүнә дәфтәрчегенең битләре берәм-берәм ачылды, ләкин эч сереңне ачып, туарылып сөйләшерлек бер генә исем чыкмады. Фәрит дәфтәрне яңа баштан актара башлады. Кешеләрнең кайберсе үзеннән өстен баскычта торучылар, кайберләре аңа буйсынырга тиеш кешеләр. Алар белән мөнәсәбәттә билгеле бер аралык сакланырга тиеш. Ә инде бер үк баскычтагылары исә Фәритнең күңеленә ятмый, я кеше күңеле белән беркайчан да исәпләшмәүчеләр.

Фәрит ирексездән: «Минә кайчан ул чын дус кирәк була икән, — дип уйлап куйды. — Әйе, шатлыкны ялгыз, үзеңә генә дә кичерергә мөмкин, ләкин хәсрәт килгәндә, янында якын кешең булырга тиеш икән».

Әйе, өйдә япа-ялгыз калып булмый иде. Фәрит киенде дә өйдән чыгып фабрикага юнәлде. Белә ул, бу вакытны корпуслар бикләнгән, анда утлар сүндерелгән була, барлык җан иясе рәхәт-тирән йокыда. Ләкин шулай да фабрикада дежур торучылар бар. Алар әледән-әле корпуслар тирәсеннән әйләнәләр, кайберләренә шыпырт кына кереп тә чыккалыйлар. Ә гомумән дежур торучылар беренче корпуста була. Фәрит контроль капка аша узды да туп-туры шунда юнәлде.

Фабрика территориясендә тирән тынлык иде. Ара-тирә күз кысышкалап янган электр фонарьлар һәм теге башта ялкау гына өрә башлаган таныш этләр генә биредә тормыш барлыгын сиздереп куялар. Корпуска якынлашарак Фәрит янына төрле яктан өч эт чабып килде. Аларның исәбе, бәлки бу төнге кунакны йолкып ташлау булгандыр, мәгәр исе бик таныш, үз кеше икәнлеге шунда ук сизелде булса кирәк, җан-фәрманга чабып килделәр дә өчесе бердән Фәрит тирәсендә коерыкларын хәтәр селки-селки сырпалана, баш белгечкә карата булган мәхәббәтләрен изһар итә башладылар. Фәрит этләргә өйдән берәр күчтәнәч алып чыкмавына үкенеп куйды. Берәм-берәм аларның башларыннан сыйпады, җылы сүзләр әйтте. Аннан үзенә өмет белән текәлгән этләрне нәүмизләндереп беренче корпуска кереп китте.

Бүген кемнең дежур торырга тиешлеген Фәрит бөтенләй оныткан иде. Операторлар өчен билгеләнгән бүлектә Рәмзине күргәч, ул бераз аптырап калды.

— Бүген сезнең чиратмыни? — диде ул. — Исәнлекме?

Рәмзи Фәритне күрү белән елмая башлады. Күрәсең, ул Еникеевнең шулай төн уртасында килеп чыгасын күз алдына да китермәгән.

— Ни булды сезгә, рәхәтләнеп йокы симертәсе урында? — диде.

— Я, ничек соң, корпуслар тирәсеннән берәр тапкыр гына булса да әйләндеңме? Барысы да тәртиптәме?

Рәмзи, бу нинди хәл, әллә миңа ышанып бетермиме бу, шуңа күрә тикшереп йөрүеме, дип уйланды.

— Бер тапкыр гынамы соң? Өч тапкыр йөреп чыктым. Тынычлык.— Фәрит өстәл янындагы артсыз утыргычка чүкте, кесәсеннән сигарет чыгарып кабызды.

— Я ничек, КамАЗ бик сагындырмыймы?

Рәмзи сул кашын гына сикертеп куйды.

— Сагынсам, ул әллә кайда түгел ич! Автобус эһ дигәнче илтеп ташлый.

— Син анда бер барып кайттың булса кирәк?

Рәмзи, күңелле бер нәрсәне исенә төшергәндәй, күзләре белән генә үзалдына елмаеп куйды.

— Булды андый хәл, Фәрит Зарипович.

— Ничек соң, бергә эшләгән иптәшләреңне күрә алдыңмы?

— Ну, — диде Рәмзи бөтенләй ачылып. Ул хәзер Фәритнең үзе белән иркенләп сөйләшергә теләвен аңлый иде. — Общежитиедә булдым. Иптәшләр белән утырдым. Бераз сыйладылар.

— Анда синең берәр таныш кызың да калгандыр әле, — диде Фәрит шаяртып.

Рәмзи башта эре ак тешләрен ялтыратып елмайды, аннары Фәриткә сынаулы караш белән текәлеп торганнан соң:

— А как же, — дип куйды. — Миндә дә бит җан бар.

— Ә ул ничек карый соң синең безгә китеп баруыңа?

Рәмзи Сонясын күз алдына китерде, ничегрәк җавап бирергә белмичә уйланып торды. Аннан:

— Ә, — дип кул селтәде. — Андыйлар кайда да табыла ла ул!
Фәрит, җан азыгы эзләгәндәй, һаман гәпне куертырга тырышты.
— Әллә бездә дә берәрсен табып өлгердегезме?
Рәмзи җитдиләнеп кашларын җыерды.
— Бар ул, — диде, — тик сыйфат билгесе куелганнары бик атлыгып тормыйлар хәзергә.
— Нәрсә, үзең ОТКдан уз әле башта, диләрмени?
— Ну!
Фәрит бу теманың артык мантымаганын, егетнең бер дә бу турыда ачылып сөйләшергә теләмәвен аңлагач, сүз куертырлык яңа тема эзли башлады.
— Шулайдыр инде, — дип куйды бераздан. — Син бит әле яңа кеше бездә. Ә бүлмәң ярыймы соң?
— Ну!
Бу соңгы елларда раслау алмашлыгы буларак халык теленә кереп киткән «ну»ны Фәрит яратмый иде. Ул әйтми кала алмады:
— Ну «әйе» дигән сүз буламы инде безнең телгә күчерсәң? — диде.
— Ну! — диде Рәмзи тагы. Фәрит түзә алмады, барлык кайгы-хәсрәтләрен онытып, көлеп җибәрде. Ул Рәмзинең иңбашына кулын салды.
— Рәмзи, беләсеңме нәрсә, яшерен-батырын түгел, син миңа ошадың. Башта, дөресен әйтим, синең бу попныкыдай ялларың да, мыегың да миндә бераз сагаю, ай-һай, моннан рәт чыгар микән дигән шик тудырган иде. Инде ышандым, син җаның-тәнең белән безнең уртак эшкә бирелгәнсең, тырышасың, үз-үзеңне тотышың да ярыйсы. Сиңа минем киңәш шул, ныклап төпләнеп кал инде биредә, заочный институтка кер, гаилә корып җибәр.
Рәмзи хәйләкәр генә елмаеп Фәриткә күз ташлады.
— Шәп бер кәләш табып бирәсезме соң?
— Менә дигәнен табам. Әйт ниндирәк булсын ул? — диде Фәрит.
Рәмзи һаман, елмаюын йөзеннән җуймаган хәлдә, ни әйтергә дә белмәгәндәй, җилкәләрен җыерып куйды.
— Ну, әйтик, менә безнең профессор кызы Әлфия Галиәкбәревна кебегрәк...
Фәритнең йөзендәге елмаю шунда ук сүнде. Ул бер секунд эчендә әллә ниләр уйларга өлгерде. Аныңча, бу егет барысын да белә, һәм юри Фәритне ирештерә иде. Ул артык тыела алмастан утырган урыныннан сикереп торды.
— Беләсеңме, егет, — диде зәһәрләнеп, — саграк кыйлан!
Бу юлы Рәмзи куркуга калды. Аныңча, баш белгеч янәсе теге кичне булып узган вакыйганы ишеткән иде, тәгаен моны начальствога түкмичәчми Әлфия җиткергән. Рәмзи агарынып урыныннан торды. Ул үзен аклау өчен тиешле сүзләр, җөмләләр дә әзерләргә керешә. Ләкин әйтеп өлгермәде, Фәрит, аны тирән аптырашта калдырып, кызу адымнар белән корпустан чыгып, ишекне япты.
Ул үзенең дус эшләрен ияртеп тын корпуслар арасында аяклары талганчы йөрде. Сакчы булуына карамастан, кайчакта аулаграк урынны чамалап, тавык урларга территориягә караклар кергәлиләр иде. Хәзер исә Фәрит керү ихтималы булган шундый берәүне тоту теләге белән янды. Хәлбуки, бөтен территорияне тынлык баскан. Маточниклар корпусы яныннан узганда Фәрит куначада утырган бер тавыкның бары бер тапкыр әллә саташып, әллә болай кыткылдап куюын гына ишетеп калды.
Ниһаять, ул тәмам хәлдән тайды һәм, өенә кайтып, ятагына ауды. Колак очында гына торган будильникның йөрәккә төшеп каты чылтыравына ул байтак вакыт уяна алмый ятты. Баксаң-күрсәң ятуы булган, йокыга киткән, ә хәзер уяныр вакыт та җиткән икән!

Фәрит, гадәттәгечә, юынды, кырынды, әллә кайчан пешерелеп суыткычта кипшенгән борчак боткасын җылытып ашады, чәй эчте. Ләкин болар барысы да механик рәвештә эшләнделәр. Барлык тирәлек, чынбарлык аңа томан аша, дөресрәге, төштәге кебек, тонык зиһен аша күренә иде. Ниһаять, ул шулай ук механик рәвештә сәгатен дөресләп, туфляларын чистартып, аннан кашнесын муенына дөрес чорнарга теләп, көзге алдында бик озак маташты да киенеп урамга чыкты. Эшкә барырга әле иртә булса да, Фәрит эшләнәсе эшләрен һәм алар арасында беренче чиратта башкарылырга тиешлеләрен хәтерләп, фабрикага таба юл тотты.

Ул бар көчен җигеп үзен әзәрлекләгән уйларыннан, хисләреннән качарга теләде. Мөмкин кадәр тизрәк конторага керде, үз өстәле янына утыргач башкарылырга тиешле эшләр турында уйлап тагы баш ватты. Тик эшкә керешү артык авыр иде. Аяз күк йөзен һич сиздермәстән каплап китүчән болытлар кебек борчу әледән-әле аның күңелен биләп ала иде. Шулай да ул контораның парадныена җитәрәк артыннан кемнеңдер ашыга-ашыга килүен шәйләде. Күңеле нидер сизенде. Фәрит аңа борылып карамый булдыра алмады. Күргәч, ирексездән имәнеп тукталып калды. Ашыгып килүче кеше Әлфия иде. Ул, гадәттәгечә, кеш якалы җинел пальтодан, башына ак шәлен бөркәнгән, аксыл чырае, зифа буе белән Фәрит янына килеп басты.

— Исәнмесез, — диде ул күзләрен яшерә төшеп. — Минем сезнең белән сөйләшәсем бар иде.

Фәритнең хәйран калудан кашлары күтәрелеп китте.

— Рәхим итегез. Кайда сөйләшәбез? Мондамы, минем бүлмәгә керепме?

— Сезнең бүлмәдә җайлырак булыр.

Алар авыр ишекне ачып вестибюльгә керделәр, вакыт әрәм итмәскә теләгәндәй, йөгерә-атлый өске катка менделәр. Фәрит ишек өстендә сакланган ачкычны алып бүлмәсен ачты. Бүлмәгә кергәч, икесе дә ниндидер мөһим бер адым ясау алдыннан гына була торган халәттә тынып калдылар.

Фәрит белән Әлфия бер-берсенә караган килеш бүлмә уртасында тукталганнар иде. Фәрит куркынып һәм гаҗәпләнеп Әлфиянең аскы ирене калтыранганын күрде, ул да булмады, кызның якты күзләре яшьләнгән булуын абайлады. Ул, Әлфиягә ярдәм күрсәтергә теләгәндәй, инстинктив рәвештә алга таба атлады, мәгәр колагына кызның нидер әйтә башлавы чалынды, туктап калды.

— Фәрит! Юк, мин артык... — диде Әлфия. — Мин сизәм, тоям, син саф кеше, син бервакытта да кабахәтлек эшли алмый торган кеше. Син аны яратмыйсың. Ә яратмаган кеше белән яшәү мөмкинме соң!

Фәритнең соңгы көннәрдә тәмам суырылып киткән борчулы йөзенә ниндидер яктылык шәүләсе йөгерде, ул Әлфиягә шыпырт кына «бәгырем» дип куюын үзе дә тоймады. Кинәт кыюланып, Әлфияне кочаклап алды.

— Мин шулай булсын дип чын күңелемнән теләгән идем, — диде ул, Әлфиянең кайнар сулышын тоеп. — Тик мин мондый бәхеткә үземне лаек кеше дип санамадым...

Әлфия Фәритнең күкрәгенә сыенып тагы нидер әйтте.

— Син лаек моңа, — дия иде ул, — мин барысы турында да уйландым. Безгә бердәнбер юл — бергә булу. Юкса...

Ул «юкса» дип өстәде, ләкин әйтеп бетермәде, күз яшьләренә буылып тынып калды. Ләкин бу күз яшьләре шатлык, караңгы михнәтләрдән соң ирешелгән якты шатлык күз яшьләре иде.

*Ахыры киләсе санда.*

## Рәдиф Гатауллин

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

### Җавап бир

Табигать! Сорыйм, җавап бир,
Соравым — йөрәгемнән:
— Күчеп китмәдеме җаным
Беренче тирәгеннән?
Җуймадыммы хыялларны,
Омтылыш, теләкләрне?
Саумы җан эзләнүләре,
Тибрәнеш — күкрәктәге?
Җиргә тик гашыйклар кебек
Сокланып карау хисе
Яшиме миндә? Исәнме
Өметнең сихри көче?
Бер шиксез, шашып, яратып
Ашкына белгән сәгать,
Гаҗәпләнә, табына алу,
Рух очышына сәбәп —
Эчкерсез, табигый халәт!
Син миннән китмәдеңме?
... Тәңрем-табигать! Шулар соң
Бер көн ят итсә мине,
Аерылсам иң зур байлыктан —
Хушлашсам мин гамь белән?!
Бүгенге, канатлы яшьлек
Миннән баш тартыр, беләм.
Табигый ихлас нәфрәтен
Ул әйтә калса — хаклы:
Килешүләргә бармый ул,
Бар дөнья яшьлек яклы.
Ышана ул: үзгәрмәс һич,
Ул тугры хакыйкатькә.
Ул хыянәт итмәс мәңге
Зур хискә — Мәхәббәткә,
Иманга, Рухияткә.

... Ул ни әйтер минем хакта,
Җавап бир, Табигать, я?!

●

*Нәкый ага Исәнбәткә, Әмирхан ага Еникигә*

Бәхетле сез,
яшьлегенә
хыянәтсез, тугры кала алганнар! —
Ап-ак канатларны,
алтын алма үскән бакчаларны,
су кызлары көткән кыяларны —
хыялларны
югалтмаганнар!
Тормыш заман
кызуына һаман алып керсен,
туган җирләрегездән ерак кителсен —
җаныгызда, барыбер, яшьлек уты,
мәңге тере гөлләр,
наз, гамь тулы сүзләр...

... Аргамаклар очып үткән юлда
нидән әле күтәрелгән тузан?
Кем яшьлеге бүген юлда узган?
Кемгә дәшә җилләр:
— Мең яшәгез,
яшьлегенә тугры Ирләр!
(Шундыйлар кем?
Янып-янып
сүрелмәгән җаннар
нинди алар?!)
Уйланам да, —
гүя Агыйделгә,
гүя болын, урманнарга, —
юлга чыкмакчы мин... узганнарга.
Үткәннәргә юл — юк. Төшкә генә
керә һаман матур бер манзара:
көмеш инеш башы. Ташлар... Ташлар...
Шул ташлар соң хәзер нинди төстә?
Әүвәлгечә кайнар микән алар?

... Ә сез — бәхетлесез,
җырга лаек бәхетле сез,
яшьлегенә —
үз-үзенә тугры кала алганнар!

●

Ялтадамын. Шаулый диңгез.
Шторм — алты баллы! —
Чайкый причалда корабны,
Ул — «Башкортстан» атлы.

Әй туган җирләр сәламе! —
Килгән күк җылы җиле.
Уйлыйм: «Татарстан»да бит
Бер йөзеп килсә иде.

Аралаша диңгезнең тын
Яки бик ярсу чагы...
«Литва»да, «Грузия» килә,
Һәм «Үзбәкстан» тагы.
Бар чит ил кораблары.

Мин көткән кораб кайда соң?
Ул кайда якорь салган?
Уйландым: гүя еракта,
Көчле давылда калган.
«Очып йөргән голландлы»дай,
Я бер адашкан кораб
Азмыни? Упкыннар йоткан
Атлантидадай тараф?
Причалга килгән кораблар,
Ниләр кичердегез сез?!
Дәшмисез?... Шторм тавышы,
Үкерә һаман диңгез.
... Тауларга карыйм. Алар — тын,
Мәңгегә уйчан, сүзсез.

## Акыл белән сөйләшү

Таный сине шигырем:
Бу — син, Салкын Акыл.
Ыспай киенгән
Шактый зур гәүдәле,
үз-үзеңнән риза —
тыныч, салкын
мәһабәт ир — Акыл!
Сизәм, тормыш кукрәгән
озак имгән Проза син!
Шуңа да бик дус түгелдер
синең белән минем шигырь.
(Әнкә сөтен
үзе аз татыган өчен!)

Шигырем — хис улы,
күктә йөрсә —
Җирне биектән карау өчен генә,
Үз-үзенә ышанычын
һәр көн саен сынап яңарткага
тәкәббер дә күренә.
Бераз алдый...
Әмма «алдау» — бары образ, сурәт.
Гасаби ул бераз, тилерәк, —
тилереп үзенә бирелгәнне
яраткангадыр шигърият!
Һәр адымда ләкин шәрран яра,
һәр януга исем таба,
җыр итә ала
һәр хыялын, уен,
шиген...

... Таный сине, таный;
Салкын Акыл абый,
сиңа иелеп сәлам бирә,
тик һич вакыт буйсыналмый сиңа
йөрәк колы — шигырем!

## Сәяхәттән — мәхәббәт турында

Париж!
Минем өчен булдың бер матур төш...
(Төшем дәвам итә, имеш!)
Әле һаман төштә
күргәннәрем истә:
— Европа! — дип
шаккатмасам да мин, авыз ачып,
матурлыкка булды күңел ачык.
Зур тарихлы,
киләчәге, шиксез, якты француз халкын
мин якыннан таный алдым.

Исем китмәде рекламаларга,
неон белән язган алдауларга,
адаштыргыч төнге утларга да...
Башым идем Эйфель-Манарага.
Гаеп булмас,
гашыйк булдым, дисәм, парижанкаларга.
Ләкин алай димим.

Сәяхәттән кайткач
әйттем ярыма:
— Париж минем өчен бер төш иде,
ә ул төштә, шатлан, сине күрдем:
ун көн дәвам иткән төштә
минем белән бергә идең,
Казан кызы!
Алтын Кояшым минем!

## Якты Бүләккә хат

Бүген тагын сине уйлыйм,
сине сагынам тагын —
сезнең якка карап түгел,
очып ашкынган чагым. —
Сине сагынам тагын.

Телдә кадерле бер авыл
исеме: Якты Бүләк.
Күпме юл үтә каләмем
матур бер сурәт эзләп.
(Сиңа, әй, Якты Бүләк!).

Көзге җил тиеп тирәккә,
шаулаган яфрак сыман,

хатта сагышым тетрәнә —
күзен калтырап торган
алтын, зур яфрак сыман.

Ул төшәр синең кулыңа,
сыенып, җылы эзләр...
Учыңа алырсың аны —
җылынып туңган хисләр. —
Дымланыр синең күзләр.

Очсын бу хатым Бүләккә!

... Ят итмәс туган ягың:
күзге якты көн шикелле
алтын сагышлы чагым.

... Сине сагынам тагын!

## Җаныңда бер тойгы

Нигә кайгы миңа, нигә сагыш?
Алар белән таныш
күпме чәч агармыш!
Бүген
җанда ягымлы бер тавыш:
— Яратасың,
якты синең язмыш!

Нигә сагыш миңа? Нигә кайгы?
Якты уйлар куачак ла аны!
Антлар язам:
— Мин онытмам,
мин югалтмам ярны!

Әйе, еракта ул,
онытырга хаклы:
Аңа
һәрчак әзер җиңел бер юл —
Чигенү атлы.

... Ләкин беләм:
мине юксынырга
җаныңда бар
меңнән бер зур тойгы.
Ә ул — минем яклы!

●

Беләсеңме, бу уйларым ни турында?
... Чынлык белән очраша да Хыял,
матурлыктан әсәрләнеп Рәссам, шагыйрь
күңелендә яңа сурәт тудыра.
Һәм ул сурәт, көйсезләнеп
таләп итә үзен үстерүне,

матур киемгә төрүне;
кирәк аңа зур тәрбия!
Шулай үсә,
ә аннары
күңеленнән аның
кәгазьгә я полотнога сикереп төшә:
үзен тудыручыны
кызык итә,
гүя бала гомерлеккә
ата йортын ташлап китә...

Беләсеңме, һаман уйлыйм шул турыда:
мифта мәшһүр оста Пигмалион да
гашыйк булган Галатеясына —
үзе ясаган таш сынга.
(Зевс кодрәте белән ул сын
әверелгән гүзәл тере кызга!)
Тормышта соң
буламы андый могҗиза?
Ә шулай да,
урынлы бу сорау:
— Үзең тудырган сурәтне
яратырга кушса акыл,
онытырга остасын соң
ул сурәтнең бармы хакы?

Җирдә, юкса, күпме рәссам, күпме шагыйрь...
Һәркөн күпме гүзәл образ туа...

... Нигә шушы уйлар белән утырам әле,
сеңелем, синең туйда?!

## Харрас Әюпов

### Тик без генә

Бәйгеләрдә чапкан аргамактай,
Ялларында давыл уйнатып,
Яшәү дигән зур бер дулкын бара
Вакыт океаны буйлатып.

Безнең турыга килеп җитте менә —
Мәңгелекнең кайнар турына,
Тын алырга кыймый басып торам
Заманыма карап, чорыма:

Киләчәкләр әле уянмаган,
Үткәннәрдә инде тып-тыныч,
Вакыт океаны уртасында
Тик без генә... Хәтта куркыныч!

Бөтенләе белән безгә калган
Җирләр-күкләр, таулар-диңгезләр,
Нишләтерсез икән? — дигән төсле
Күзгә карап тора йолдызлар.

Бәрә дулкын безнең йөрәкләргә —
Яшәү дигән хәтәр чорда без,
Мәңгелектән аваз килә сыман
Бер ышаныч булып:
— Чыдагы-ы-ыз!..

### Тәфтиләү

Кайсыгызның газиз җаны елый,
Бу кемнәрнең йөрәк тавышы?
Кай яклардан алып килә икән
Миңа бу моң сезнең язмышны?

Атка менсәм, сезнең тарафларга
Алып барыр микән бу атым?
Кемгә генә җылы кулым сузыйм,
Кайсыгызны гына юатыйм?

Яу чапканда дошман укларыннан
Егылгандыр бәлки Алыплар,
Яраларын тизрәк бәйлик әле,
Яннарына, атым, алып бар!

Ялларына әллә ут капканмы —
Томырылып чаба тулпарлар!
Янып бетмәсәләр ярар иде,
Каршы чабыйк, бәлки туктарлар...

... Кайдан гына килә икән бу моң,
Кемнәр дәшә миңа ерактан?
Танырлармы — газиз башкайларын
Иңнәремә салып юатсам?..

## Юлда

Бу юллардан инде кемдер узган —
Чорлар аша ярылып эз ята,
Ярасымы әллә Җирнең алар,
Кагылдыңмы — җанны сызлата?

Тавышларын мин ишетәм сыман,
Сулышларын тоям кемнеңдер,
Заманалар янәшәмдә генә...
Гомернең бу нинди көнедер!

Узган юлчы,
Учаклары калган,
Әкиятләр калган, дастаннар.
Бүген шуны сөйләр өчен чорлар
Юл буена чыгып басканнар.

Иңнәремә сарылып көйли җилләр,
Колагыма камыш иелә,
Кабер ташы сөйли,
Чиркәүләрнең
Нигезенә яткан көе дә...

Язмыш, ахры, безнең араларга
Ялгыш кына куйган мең елны,
Ничек кенә яшермәсен тарих —
Мин барыбер таныйм бу юлны!

Учакларны өреп кабызамын...
Бирешмә син, йөрәк, бул чыдам! —
Иң беренче шул сорала бугай
Ерак сәфәр чыккан Юлчыдан...

●

Төркем-төркем кошлар күтәрелде,
Очып узды гомер өсләреннән,
Таралдылар...
Кайдан эзлим инде,
Бу дөньяның кайсы төшләреннән?

Төркем-төркем китеп югалдылар,
Бик аз гына миндә булып бары да.
Бала чакның моңсу торналары!
Тавышыгыз кайсы болытларда?

Безнең өйнең түбә кыегына
Оялаган җитез карлыгачлар!
Сезнең кебек без дә бишәү идек...
Ниләр күрде икән сезнең башлар?

Әллә кайда, ерак-еракларда
Ачыргалаsucceed акчарлаклар —
Тик аларга мәгълүм иде безнең
Мәхәббәттән күккә ашар чаклар.

Тел китергән серле сыерчыклар,
Аккошларым, тургай-былбылларым!
Бармы тагын берәр белүчесе
Ниндилеген безнең бу юлларның?

Төркем-төркем:
Көннәр... айлар... еллар...
Җил дә давыл гомер өсләрендә.
Кошкайларым!
Без кайларда икән,
Шул давылның кайсы төшләрендә?!.

●

Бер күрешү — үзе бер гомер...
*Мәкаль.*

Җаннарыбыз тавыш бирдеме әллә,
Кавышуның бөек мизгеле?!
Вакыт давыллары арасыннан
Ничек эзләп таптың син безне?

Нинди җилләр хәбәр итте икән
Дәвамнарның бездә икәнен,
Сулкылдашып, йөрәк түребездә
Килер чорлар дулап типкәнен?

Бер күрешү — үзе бер гомер шул,
Гомер генә түгел, бер тарих,
Тарихларның башы — кавышуларда,
Күрешүләрдә — яшәү, ышаныч.

Таңнардагы безнең бу кавышу —
Нинди тарих, нинди чор башы?
Нурлы булсын, якты булсын ул чор,
Моңлы булсын — йөрәк, җырлачы!

Гомер саен өләш ул җырны син,
Кавышуның бөек мизгеле,
Чорлар саен! Килер дәверләргә
Моңнар итеп тарат син безне...

## ТАТАРСТАННЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА




**Гомәр Бәширов**

# КАРА ТӨНДӘ НУР ЧӘЧЕП...

хикәя

## I



Басу капкасыннан кергәч, Байтимер беразга туктап як-ягына каранып торды. Авыл читендәге йортлар күбесе салам түбәле, җил капкалы иде. Ул кечкенә чанасын сөйрәп авылның эченәрәк узды. Урыс капкалы, такта түбәле хәллерәк йортлар турысына җиткәч, янә тукталды. Сакал-мыегына сарылган бәсне кулы белән сыпырып төшерде дә тамагын кырып алды, башын күтәрә төшеп көр генә аваз салды:

— Китап сатам, китап! Кемгә китап?!

Бераз көтте дә, капкалар ачылмагач, акрын гына тагын кузгалып китте. Кунып чыккан авылы шәт җиде-сигез чакрымнар булгандыр. Карлы юлдан китап төягән чана сөйрәп килә торгач, Байтимер шактый ук йончыган иде. Ул бияләй аркасы белән маңгаен сөртеп алды, чана тарткан сүс бауны сул иңбашына күчерде. Авыл халкының көндезге ашка утырган чагы булдымы, ничекме, урамда кеше-фәлән күренми иде. Бер-ике тыкрык узгач, туктый төшеп тагын кычкырып карады.

— Китап сатам! Саваплы китаплар, «Ясин»нар, догалыклар! Уку китаплары, бәетләр... Китап сатам, китап!..

Уң яктагы бер өй эченнән яшь бәтиләр кычкырганы ишетелде, ишегалдында бик тилмереп, нәүмизләнеп сыер мөгрәп куйды. Байтимер акрынлый төште. Бозавыннан аерганга шулай тилмереп мөгри ул хайванкай. Аларның да сыеры бозаулар вакыт җитеп калган иде. Бәла-казасыз, исән-сау гына алды микән бозауны Бәдриҗамал? Хатынының йокысы бик каты булуы исенә төшеп, Байтимер пошынып алды. Ярый ла өшетмәгән булса бозауны!

Бара торгач сулдагы тыкрыктан чырык-чырык көлешеп кызлар төркеме килеп чыкты. Алар я аулак өйгә, я өмәгә җыелган булсалар кирәк, өс-башлары бәйрәмчә, битләренә иннек-кершән дә сөрткәннәр, күзләренә сөрмә тартканнар иде. Кызлар авызларын пырчаткәләре белән каплый төшеп, Байтимерне сырып алдылар.

— Исәнлекме, абдый?!

— Нинди китапларың бар?

Байтимер аларны шатланып каршы алды.

— Бар, сеңелкәйләр, төрлесеннән бар!

Яшь-җилкенчәкнең уенчанлыгы, җилбәзәклеге Байтимерне терелтеп җибәрде. Ул бияләен билбавына кыстырып куйды да, кулларын уа-уа, китапларын күрсәтергә кереште.

— Нәрсә генә бирим икән соң сезгә, чибәркәйләргә? «Сак-сок» бәетеме, җыр китабымы, әллә «Суга баткан Гайшә» бәетенме? — дип, капчыгыннан юка гына бер китапчык алды да көйли төшеп бәетен дә әйтеп күрсәтте:

Чәршәмбе көн кер чайкарга
Ник җибәрдең, әнкәем?
«Барма, кызым», дигән булсаң,
Бармас идем, әнкәем...

Кызлар әсәрләнеп беравык тыңлап тордылар. Әмма аларның берсе кулын селтәде:

— Әем, кирәкмәй, бик тә кызганыч! Безгә күңел ачардайрак китап булсын!

Китапчыга шул гына кирәк иде. Ул мыегын сыпыргалап чанасы янында бии-бии теленә салынырга тотынды.

— Менә күптән шулай диләр аны! Бар андый китаплар, бар! «Кемне куандырыйм икән болар белән?» дип өйдән чыкканнан бирле саклап килдем. Ходаның рәхмәте, сезгә насыйп икән! Менә сезгә «Мәхәббәт корбаны», менә аннан да шәбрәге «Хат язмак нәмүнәсе».— Сер сөйләгәндәй шыпырт тавыш белән аңлатып та бирде:— Егетләргә хат язу үрнәге була инде бу!

Кызлар бер-берсенә карашып чыркылдашып алдылар.

— Сөючеләре булса, эш хатка гына терәлмәс әле!— диде берсе.

— Һи, сездәй чибәрләрне дә сөймәгәч! Бер битегез ай, берсе кояш, күзләрегез нур чәчә.

— Ай-ай, абдый, тел үзеңдә! Бу килештән син китабыңны гына түгел, бедпең үдебедне дә сатып ебәрмәгәең!— диештеләр.

Кызларның берсе:

— Әллә Фал китабың да бармы? — диде.

Байтимер кулын-кулга бәреп алды.

— Бар гынамы әле! Ике төрле! Берсе пичәтни, берсе кулдан язган шикелле.

Тун итәге белән тузанын сөртеп сөйләнә-сөйләнә китапны әлеге кызга сузды.

— Өр-яңа! Әле кара исе дә очып бетмәгән.

— Ни бәя?

— Зерә дә юнь. Нибары унбиш тиен генә.

Кызый телен чартлатып куйды.

— Сиңа юнь дә миңа кыйбат шул, абдый. Бәләкәй генә төш инде!

Тулган ай төсле ачык йөзле, уймак авызлы бу чибәр Байтимергә бик тә ошады. Аңа якын итеп «кызым» дип дәшәсе килә иде. Ләкин болай дисә, үзен бик картайтып җибәрер шикелле тоелды. Кырыктан узган булса да, яшьләр янында яшьрәк буласы килә иде әле.

— Юк, сеңлем, төшә алмыйм, чамага килми. И, сеңелкәем, мин бит сиңа беләсеңме нинди китап калдырам? Дөнья бәясе!

— Булса да...

— Әллә фал ачып күрсәтимме? Ә?!

Кызый икеләнеп торды да башын чайкады.

— Бәй, анысын үдебед инде, өйгә кайткач...

Әмма Байтимернең бу китапны бик тә сатасы килә иде, җитмәсә, нәкъ менә шушы кызга.

— Алайса, укып кына күрсәтимче, ярыймы? — диде. Кулына өргәләп китапны урта бер җиреннән ачты. — Менә, бөтен шартларын китереп ачканнан соң шушы фал чыкса, ачучыны нилэр көтә? «Синең күңелеңдә, дигән, изге бер ниятең бар, дигән. Әмма ләкин син шул гамәлне кылыргамы, кылмаскамы диебрәк, икеләнебрәк йөрисең, дигән. Дошманнарың исә, дигән, хөсетләнеп, сине ул уеңнан, дигән, биздерергә чамалыйлар, дигән. И адәм баласы! Әгәр дошман коткысына бирелмичә, тәвәккәллекне үзеңә юлдаш итсәң, синең алдыңда бәхет капкалары ачылыр, кулыңа чук-чук мал керер, хак тәгалә сиңа бер кыз углан тудырырга насыйп итәр...»

Теге кыз кулын селтәп:

— Җитте, җитте, абдыкай, мактадың-кызыктырдың, болайга киткәч алмаенча булмай! — диде. Әмма учындагы акчасын санап караганнан соң көрсенеп китапны хуҗасына сузды.

— Ай, ялгышканмын, булмай икән, акчам унике тиен генә, — диде.

Байтимер уйланып торды да китапны кире бирде.

— Әйдә, ярар, сиңа насыйп икән, игелеген күр. Атаң матур кияүгә бирсен, бәхетле бул! — диде.

Кызый башын ия-ия рәхмәтләрен әйтеп, иптәшләре белән өенә таба юнәлде.

Салмак кына атлап тагын кузгалып китте Байтимер. Берике йорт кына узган иде, аңа тагын дәштеләр.

— Абзый, абзый, тукта әле!

Борылып караса, уңдагы капка төбеннән бер егет дәшә икән. Башында кырпулы бүрек, аягына чуар кукмара итеге, өстенә шәһәрчә пальто сымак нәрсә кигән.

— Исәнлекме, абзый?

— Шөкер әле, энем, шөкер генә!

— Кая, «Йосыф китабы» бармы синдә?

— Һи, нигә булмасын икән? Шундый чибәр егеткә кирәк булгач табабыз инде аны!

Байтимер капчыгыннан шактый ук калын зәңгәр катыргы тышлы китап алып бирде.

— Тагын нәрсә бирим? Уникенче елга календарь бар. Менә тагы «Мең дә бер кичә».

— Кыйбатмы?

— Берсе-берсе иллешәр тиен.

— Тозлы икән. Бишесе бер сарык бәясе.

— Һи, егет кешегә малмыни ул?

Егет көлемсерәп китапларның барысын да күздән кичерде, капчыкка үрелеп карады. Аңа тагын нидер кирәк, әмма ул аны теле белән әйтергә базмый кебек иде. Китапчы аңа сыныйрак карап ал-

ды. Читтә акча эшләп кайткан көяз егеткә охшаган иде бу. Байтимер бераз икеләнеп торды да тунының эчке кесәсендә йөрткән берничә юка китап чыгарды.

— Менә болар ничек булыр икән? — диде.

Егет китапларның исеменә күз йөртеп чыкты.

— Әһә! «Ачлык патшасы», «Кем үз көче белән тора?», «Яшь гомер». Һем, кызык. Мондыйлар да булгалый икән?

— Сирәк кенә. Кешесенә күрә генә.

— Укып карыйк.

Егет саубуллашып өенә кереп китте.

Авылның уртасына җитәрәк Байтимер мәчет түбәсенә күз салды. Манараның күләгәсе мәчетнең кыегына менеп бара иде. Хәзер мәдрәсәдә шәкертләр көндезге тәнәфескә тукталырга тиешле. Ул кызурак атлый башлады.

Китапчының мәдрәсә баскычы төбенә барып җитүе булды, ишек кинәт ачылып та китте, эчке бүлмәдән куе пар белән бергә эчелеккә[1] шау-шу килеп, берсен-берсе төрткәләп, эреле-ваклы укучы малайлар бәреп чыкты. Алар букчаларын айкап барысы берьюлы кычкырырга, Байтимер янында сикергәләргә тотындылар.

— Китапчы абзый килгән! Китап сатучы!

Байтимергә төрле яктан сораулар яудырдылар.

— Кая китапларың, абдый, кая, ниндәйләр?

— Дәреслекләр дә алып килдеңме?

— Мин «Күңел җәүһәрләре» дигәнием?

Байтимер үпкәләгән кыяфәт белән:

— Их, их, их! — дип башын селекте. — Шәкертләр дип йөрисез инде үзегезне, янәсе, әйеме? Ә «исәнме, саумы» кая?

Шәкертләр кыенсынып беравык тынып тордылар. Аннары көзге әтәчләрнекедәй җитлекмәгән яшелле-зәңгәрле, калынлы-нечкәле тавышлары белән һәммәсе берьюлы шаулап, сикергәли-сикергәли исәнләшеп алдылар.

— Әссәләмегаләйкүм, абдый!

— Исән-сау гына килеп җиттеңме?

— Әйбәт кенә йөрәйсеңме?

Байтимер, бөтен йөзе белән балкып, уңга да, сулга да баш игәләде.

— Аллага шөкер, оланнар. Бик шөкер. Менә шулай! Менә монысы чын шәкертләрчә, ичмасам, тәрбияле балаларча! Менә сезне сагынып килдем.

— Бик озак килми тордың бит, абдый.

— Шулай, озак инде күрешмәгәнгә.

— Былтырдан бирле.

— Әйе шул!

Чапаны күз ачып йомганчы җилтерәтеп эчелеккә алып керделәр. Малайлар, китапчыны уртада калдырып, борыннарын тарта-тарта түземсезлек белән капчык авызы ачылганын көтә башладылар.

Китапчы юри ашыкмады. Зур эшкә тотынгандай, тамагын кыргалаган булды, алмаш-тилмәш уч төбенә төкергәндәй итте.

— Кая әле, кем, мин сиңайтим! Нәрсәләр бар икән капчыкта! Нинди шәп китаплар?

Тик шунда нидер исенә төшкәндәй шапылдатып тезенә сугып алды.

— Соң, кара әле! Ярамый бит болай! Дусларча булмый. Бәйрәм ашы — кара каршы! Шигырь әйтеп күрсәтмисезмени? Ә?!

---

[1] Эчелек — мәдрәсәләрдә аяк киемнәре салып калдыра торган тышкы салкын бүлмә.

Шәкертләр кыенсынып бер-берсенә карашып алдылар да китапчының каршысына килеп тезелделәр. Арадан берсе:

— «Туган тел»не әйтикме? —диде. Икенчесе:

— Юк, «Татар кызы» дигәнне әйтик,— диде.

— Мин аларны күрше авылда ишеткәнием шул. Бүтәне юкмы соң?

Балалар берсен-берсе бүлдереп:

— Бар, бар!— диештеләр— Алайсам, «Сабагыңны бел, балам»-ны әйтәек!

— Бик хуп! Я әле!

Шәкертләр беравык таптанып тордылар да бөтен бүлмәне яңгыратып көйләп тә җибәрделәр:

Гыйлем эстәү һәркемгә,
Ирләргә һәм кызларга
Фарыздыр барчамызга,
Сабагыңны бел, балам.
Атаңны бик олугла,
Анаңны бик кадерлә,
Туганыңны хөрмәтлә,
Сабагыңны бел, балам.
Аларның сүзен ишет,
Вакытында мәктәпкә кит,
Укырга бик җәһәт ит,
Сабагыңны бел, балам...

Беренче көйләүләре түгел иде, күрәсең, шигырьне яттан беләләр икән, балаларча ихлас күңелдән бирелеп әйттеләр. Байтимер түгәрәк коңгырт сакалын сыйпаштырып елмаеп тыңлады.

— Афәрин, оланнар! Ай рәхмәт, ай үскәннәр. Зерә дә күңелле булып китте! Менә хәзер инде минем чират! Каяле!

Ул китапларын сөйләнә-сөйләнә чанадагы чыпта өстенә тезә башлады.

— Инде дә бәхет басты сезнең! Күрәсезме нинди яңа, нинди матур китаплар алып килдем мин сезгә!

Ачык ал, кызыл, яшел, күк төсле китап тышлары, күз явын алырдай булып, бүлмәне нурландырып җибәрделәр. Бер малай иснәнеп:

— Кара, китап исе чыкты!— диде.

Байтимернең үзеннән-үзе авызы ерылып китте.

— Һе, чыкмыйча, чыгар шул! Китап машинадан төшүгә, табадан төшкән коймак шикелле, кайнар килеш төя дә чап сезнең янга!

Малайлр көлешеп алдылар. Алар китапларны үзләре тотып карарга ашыгалар, ә китапчы абыйның берәмләп күрсәтәсе килә иде.

— Менә сезгә «Кыйраәт»[1]. Кем сорады әле «Күңелле сәхифәләрне?» Аннары менә Габдулла Тукай абыегызның «Күңел җимешләре», «Тургайлар» бар, «Су анасы» бар. Бер-ике генә «Алтын әтәч»тә[2] калган икән сезнең бәхеткә!

Хәзер инде Байтимергә ике тезенә таянып утырырга гына калды. Бу юеш борыннарның әнә шулай кысылышып, бер-берсен этеп, бөтен дөньяларын оныткан хәлдә китап актарулары аңа бик ошый, боларның шатлыкларын күреп тору үзе бер рәхәт. Ул шушы беркатлы, гөнаһсыз сабыйлар арасында үзе кичергән юл кыенлыкларын да, туңуларын, ачлы-туклы йөргән чакларын да оныта, ул балалар шатлыгына куанып яши иде. Балаларның күбесе ак чырайлы, ябык, өсбашлары да ярлы гына. Арада камзул кигәннәре булса да, кайберләре бер кат киндер күлмәктән генә килгән, тула оеклары да ямаулы иде.

---

[1] Кыйраәт — уку китабы.
[2] А. С. Пушкин әкиятенең тәрҗемәсе.

Ләкин аларның моңа һич исләре китми, чәйгә кайтасыларын да оныты, китап белән мәш киләләр: актаралар, рәсемнәрен карыйлар, битләрен саныйлар, бәясен сорыйлар, шунда ук укырга да керешәләр иде.

Шулай куанып утыра торгач, нидер исенә төшеп, Байтимер кулын-кулга сугып куйды.

— Их-ма! Оланнар! Карагыз әле: оныта язганмын лабаса! Менә сантый! Ә! Ни әйтте мөхәррире укып күрсәтерсең дип!— Ул сөйләнә-сөйләнә актарына торгач, капчыгыннан юкарак кына бер журнал алды, аңа өргәләде. — Менә, тыңлагыз әле! Күзеннән шактый ерак куеп укырга ук керешге: «Сөекле туганкайларым! дигән.— Менә, алланың әмере белән, дигән, сез туганкайларым өчен «Ак юл» журналы да чыгара башладык, дигән. Бу көнгә чаклы, дигән, сезнең өчен китаплар гына язалар иде, дигән. Инде журналыгыз да булды. Сезнең шатлыгыгызны да, күңелсезләнүегезне дә уртаклашучыгыз булды, «Ак юл»ыгыз булды»... дигән. Менә бит нинди яңалык! Я, кемнең ел буе журнал укыйсы килә?

Юньлерәк киенгән берничә бала, акча алып килергә дип өйләренә чыгып йөгерделәр. Башкалары күзләрен мөлдерәтеп карап кына тора иде. Байтимер аларның хәлен аңлады. Ул балалар боегуын үзенеке кебек үк авыр кичерә иде, авыр сулап куйды. Кулыннан килгәнчә бу юлы да юатырга тырышты.

— Кайгырмагыз, оланнар! Шәрикләрегездән бер-икесе язылса, шул һәммәгезгә дә җитәр. Өй борынча йөртеп укырсыз, — диде.

Бервакыт күрә, чыпта өстендә китап калмаган диярлек, ә акча түләүче юк. Байтимер утырган урынында арлы-бирле килгәләп көлеп җибәрде.

— Менә сиңа, мә!— Ул бармак очларын берсенә-берсен ышкып күрсәтте.— Ә кети-мети кая? Китапның хакын кем түли, ә?! Болайга китсә сез бит, юеш борыннар, мине ыштансыз калдырасыз, ә?!

Акча табарга өмете булмаганнары китапларны теләр-теләмәс кенә кире китереп куйды. Байтимерне беренче күрүләре генә түгел, китапчы агайның юри генә ачулануын беләләр иде. Китапчыны төрлесе-төрлечә юмаларга кереште.

— Өйләдән соң алып килерием, ярыймы, абдыкай?

— Безнең тавыклар күкәй сала башлады. Йомырка белән алмыйсыңмы, Байтимер абзый?..

Байтимер боларның берсенә дә кире җавап бирә алмады.

Зуррак бер малай китапны күкрәгенә кыскан килеш чана алдында таптана иде.

— Я, синең эшләр ни чама?— диде Байтимер.

Әлеге яшүсмер аңа турысын ярып салды.

— Акчам юк та юк. Әтинең дә бирүенә ышанмыйм. Тик менә укыйсым бик тә килә, абдыкай!

— Нишләрбез икән соң?

— Көтәсеңә биреп торсана, Байтимер абзый!

— Кызыл кар яугач түләргәме?

Яшүсмер аның ышанмавына җәберләнеп иреннәрен турсайтты.

— Ышанмыйсыңмы? Валлаһи түлим, абдыкай, билләһи түлим! Икенче килүеңдә түләмәсәм, баскан урынымда җир йотсын.

— Ярар, ярар, карганма!

— Ничек ышандырыйм соң?

— Ярар, ышандым! Фартавай егеткә охшыйсың. Унике тиенгә җаныңны сатмассың! Әйеме?

— Дөрес!

Үсмер егет шатлыгыннан нишләргә белмичә атылып-сугылып өенә йөгерде.

Шәкертләрнең яннарында акчалары булмавын ул электән үк белә иде.

— Бакырларыгызны әзерләп куегыз. Урамнан узганда чыгарып бирерсез,— диде.

Мөгаллимдә чәй эчеп чыкканнан соң Байтимер авылның башка урамнарын да әйләнергә булды.

Алты почмаклы бер таза йорт каршысыннан узганда өй эченнән «зың-зың» иткән таныш аваз ишетелде. Байтимер туктап аягындагы чабатасына күз салды. Аның кәсепкә чыгып китүенә ун көннән артып бара иде инде. Чабатасының астына, тиз ашалмасын өчен, сүс кушып үргән булса да «мыеклары» тырпая башлаган икән ләбаса! Әгәр юлы уң булса, бу чыгуында арзангарак төшереп киез итек юнәтеп булмасмы дигән уе да бар иде.

Байтимер чанасын баскыч төбендә калдырып, шул өйгә керде. Ул ялгышмаган. Өй стенасына беркетелгән йон теткечнең чәнти бармак юанлыгы керешен тартып йон тетүдән чыга иде бу зыңлаган аваз.

— Әссәләмәгаләйкүм! Алла куәт бирсен!

Йон тетүче, эшен туктатып, ишеккә борылды. Күлмәк җиңе белән маңгаен сөртеп алды.

— Вәгаләйкүмәссәләм, купис. Яхшы сүзеңә рәхмәт.

Байтимер көлеп җибәрде.

— Әйтмәсәң дә! Куписның да нинди әле!— Ишек яңагына сөяләп аягын күрсәтте.— «Купис»ның чабатасы «чәчәк ата» башлады бит.

Итекче сыек кына сакалына, салынкы кашларына кунган онтаны[1] уч төбе белән сыпырып, «аңлыйм» дигәндәй башын игәләде, мич башына сузылып, аннан ап-ак киез итек алып бирде.

— Менә! Сине генә көткән икән! Итек түгел, кимерчәк бу! Рәхәтлән! Җылы тәнеңдә тузсын!

— Шулай булсын иде дә бит...

Байтимер итекнең йөзенә бармаклары белән басты, кунычын урталай бөкте, эченә кулларын тыгып алды, тыштан гына аякларына чамалаган булды. Итек көзге йоннан бик тыгыз итеп басылган, аңа ошый иде.

— Бәяме?

Итекче аның каршысына килеп биленә таянды.

— Иң әүвәл син шуны чамала, купис: ошыймы пима, аягыңа мач киләме?

— Үзе ошый да бит, хакы нишләр...

— Әрбир ошадымы, егет кеше акчадан гына тормый инде ул. Китер кулыңны, әнә, рәхәтлән! Сук та ал, ике сум илле тиеннән!

Байтимер күңелдән генә янчыктагы акчасын чамалап карады. Китап хуҗалары белән исәпне өзгәннән соң имана түләргә алып кайтасы бар. Бәдриҗамалны да онытырга ярамый. Ай-һай... Ул итекне кире хуҗасына сузды.

— Юк, булмый икән.

— Я, күпме бирәсең, күпме? Егерме тиен төшәм!

Китапчы бүреген киеп ишек токтасына ук ябышты.

— Бигайбә, абзый кеше, чамага туры килми икән...

Итекче һаман да өметен өзми иде, күрәсең.

— Тукта әле, син дә Казан арты түгелме соң?— диде.

— Шулайрак: Арча тирәсе.

Итекче тирләгән кулын киндер алъяпкычына сөртеп күрешергә сузды.

[1] Онта — он тузаны.

— Иһи! Исәнме, якташ! Таза-сау гына йөрисеңме?! Мин дә шул яктан бит, Кукмара Көеге.

— Алаймы? Кара, гупчи дә якын лабаса! Мөгаен, безнең әниләр икесе бер кояшта киндер киптергәндер...

Берсенә берсе карашып көлеп алдылар. Итекче тагын кулын сузды.

— Әйдә, миннән булсын яхшылык. Якташ итеп утыз тиен төшәм. Мәгәрич тә миннән булыр.

— Юк, әлегә булмый. Байый төшкәч инде.

Итекченең Байтимерне һич җибәрәсе килми иде. Ул итеген аның борын төбендә айкап мактарга тотынды.

— Соң, аллаң бар иткере! Кукмара эше бит бу! Син мондыйны бүтән җирдә җылап эзләсәң дә таба алмыйсың. Моны алмасаң, гомергә итек чырае күрмәссең!

— Әйтәм бит, чамага килми.

Итекче сулагай кулын селтәп ачуланып калды.

— Әй, юма телләремне әрәм иткән мин юләр. Йөрисең шунда эш бүлдереп!

Ишек ябылуга өй эчендә яңадан зың-зың килә башлады.

## II

Әлеге авылда сатасын сатып, берәүдә кунганнан соң, Байтимер яңадан юлга чыкты. Кыш урталары узып язга таба авышкан, көннәр озая, кояш көләч карап көннәрнең күңелен йомшата башлаган чак иде. Һава ярыйсы ук салкын булуга карамастан, кояш әйбәт кыздыра, китапчы туны аша күкрәгенә кояш җылысы үтеп керүен сизә иде. Ул кырпулы бүреген кашларына ук басып төшерде. Чөнки әллә кайларга кадәр пыяладай ялтырап, «күгәреп» яткан чана табаны эзләре күзне камаштыра иде. Картлар кышның бу вакытын юкка гына «күк табан»[1] димәгәннәр. Байтимер менә шушы табан бетеп «б... табан» башлангач кайтырга тиеш. Ә аңарчы йөре дә йөре... Хәер, ул инде юл йөрергә өйрәнгән, бу як юлларын күп таптаган, һич кыенсынмыйча җиңел атлый иде. Табанына тимер салган кечкенә чананы юньләп тартасы да юк диярлек, ул йомшак кына тавыш чыгарып, җырлый-җырлый арттан уйнап кына бара. Тагын бер җиде-сигез чакрым узып, ул Уразгилдедә кунып чыгарга тиеш. Аннан инде Минзәләгә дә ерак калмый. Минзәләдә исә аны китап сәүдәгәрләре Кәримовлар җибәргән тагын бер чана «тавар» көтеп ята.

Бу якларда авыллар, Казан артындагы шикелле, берсенә икенчесе орынып утырмый, аралары ерак. Чана юлы тип-тигез ап-ак кар өстеннән соры пута булып борыла-борыла офыкларга кадәр сузыла. Юл әллә нидә бер генә ялгыз агач янынннан уза, я инеш буена төшеп әрәмәлектән әйләнеп менә. Аннары якын-тирәң тагын шул ук тигез кыр, шул ук ялтыраган чана эзе.

Башка авыллар арасында арттан берәр атлы куып җитә дә алдагы авылга тикле утыртып бара торган иде. Бүген анысы да юк.

Байтимер, озак атлый торгач, әлеге бертөрлелектән ирегеп-ялыгып я шигырь, я мөнәҗәт көйләп җибәрә иде.

Колан кактан җиргәнсә,
Как тапмый чүлдә үләр.
Үзенең башын зур тоткан,

[1] Борынгылар кыш һәм яз фасылын көн озынлыгына, табигать торышына карап берничәгә бүлеп йөрткәннәр. Унбердә (ягъни көн озынлыгы унбер сәгать чагында) күк табан, уникедә — б. табан (юлга ат тизәкләре чыга), унөчтә — су табан (юлларга су чыга башлый) диелгән.

Агаенын башын хур тоткан
Карындаш тапмый ятта үләр.

Тауда булыр таргыл таш,
Тарыкса күздән чыгар яшь.
Тар култыктан ук тисә,
Тартып алыр карындаш.
Карындашың булмаса,
Далада калыр ялгыз баш.

Бер атлы да очрамауга гаҗәпләнеп бара торгач, бүген җомга көн булуы исенә төште. Менә нидән юлга чыкмый икән халык! Коймак, кабартма, күзикмәк пешереп сыйлана торган, ял итә торган бәйрәм көн. Юлга чыгасы көнне Бәдриҗамал да аны коймак пешереп сыйлаган иде. Хатынының шул чактагы борчулы чырае күз алдына килде. Байтимер сәке өстендә аягын бөкләп юл чәенә утырган иде. Бәдриҗамал аның алдына бер тәлинкә кайнар коймак китереп куйды да тын гына самавар артына елышты.

Юлга чыгар алдыннан хатынының болай күңелсезләнеп утыруы Байтимергә ошамый иде. Ул тәлинкәне аңа табарак этеп:

— Коймагың бик тәмле булган. Әйдә, үзең дә җитеш,— диде.

Бәдриҗамал, күтәрелеп карамыйча гына:

— Әй, ашыйсы да килми шунда...— диде, әйтәсе сүзе бар шикелле иренә карап-карап алды.

Балалары үзләренчә көн күрә башлап, йортта икәү генә калгач, алар бер-берсенә бик якынайганнар иде. Бәдриҗамал ирен хәтта кич белән эштән кайтканда да сагынып өлгерә, ире теле белән берни әйтмәсә дә, Байтимернең дә үзен шулай яратуын сизә иде. Бәдриҗамалның балаларына булган мәхәббәте дә хәзер иренә күчте. Иң тәмле ризыкларын Бәдриҗамал ул рәхәтләнеп ашасын дип пешерә, аңа күңелле булсын дип өен, бары белән, курчак өе төсле матур, җыйнак итеп җыештырып тота. Бу — яшь вакыттагы, коры саламдай, дөрләп кабынучан ялкынлы мәхәббәт түгел. Юк, бу көл астында көйрәп яткан утлы күмер кебек кайнар, саллы, бик тә кадерле һәм гомерлек тирән тойгы иде.

Ул-кыз җитештереп әби-бабай булырга торганда андыйны тел белән әйтүе оят лабаса. Үзе киткәч, Бәдриҗамалга бик күңелсез булачагын ир булган кеше әйтмичә дә сизәргә тиеш иде. Бу турыда ул тешен агартмагач, Бәдриҗамал үзе сүз кузгатты.

— Әле кайтуыңа да күп түгел дә бит, югыйсә. Әзрәк өйдә торсаң да зыян итмәс иде кана. Юк. Ай бирде, кояш алды. Ташлыйсың да китәсең...

Байтимер уңайсызланып тамагын кырып алды. Бәдриҗамалның үпкәсен тирәнгә җибәрәсе килми иде. Хатыны белән алар яратышып, тату гомер иттеләр, чибәр генә бала-чагалар үстерделәр. Ике кызлары кияүдә, әнә уллары да быел башка чыкты. Байтимернең кыш буе диярлек югалып торуы балалар барында әллә ни сизелми иде. Хәзер менә Бәдриҗамалга бөтенләй ялгыз калырга туры килә шул инде. Моның кыенлыгын белсә дә, башка чарасы булмагач Байтимер шаяртуга борып карады.

— И әнисе! Тузаннарымны коеп бер җиллэп кайтыйм инде. Аннары ни бит әле, кыш буе өйдә ятсам, туйдырып бетермәгәем дип тә шикләнәм!

Иренең шаяртуын колак яныннан гына уздырып, Бәдриҗамал икенче яктан суктырып карады.

— Әнә анда абзар түбәсе тишелгән. Беркөн дә төлке кереп тавыкларны кырып чыга язды. Ярый әле, рәхмәт төшкере, ата каз каңгылдап уятты.

Байтимер аңа буш чынаягын сузып:

— Малайга әйт, ямап китсен,—диде.

Иренең болай бик ансат «котылуы» Бәдриҗамалга ошамады.

— Әй, китап дигәндә синең күзеңә ак-кара күренми инде. Гомерлек чир булды лабаса. Рәхәтләндереп акчасы төшсә икән, ичмаса. Ни аллага, ни муллага дигәндәй. Бер тиенлек куян, ике тиенлек зыян!

Ни әйтәсең, үзенчә хаклы иде хатыны. Байтимер мәдрәсәдә үк китап укырга бик һәвәс, язу-сызуга да бик маһир шәкертләрнең берсе иде. Кызлар хатын, ихтимал, аннан да остарак язучы булмагандыр. Яшьрәк чагында бәетләр, мөнәҗәтләр язу белән дә мавыкты. Шагыйрьләр белән әдипләр аның каршында зур ихтирамга лаеклы бөек затлар иде. Аның әдәбиятка мәхәббәте мәдрәсә тәмамлаганнан соң да сүрелмәде, тик башка бер юл алды. Байтимер, кайбер авылдашларыннан күрмәкче, Казан байларына яллanып, кышларын Кама, Чирмешән, Ык буйларында китап сатарга йөри башлады. Егет чагында башланган бу кәсепне өйләнеп бала-чагалары булгач та ташламады.

Бәдриҗамал иренең сәфәр чыгу ниятеннән кире кайтмаячагын белә иде инде. Утыра торгач, авыр сулап куйды. Иренә кара күзләрен сирпеп шаянрак сүз әйтеп ташлады.

— Хатыныңны ялгыз өйдә бичуралар куркытыр дип тә кызганмыйсың, ичмасам,— диде.

Мондый чакта иң ансаты телеңә салыну иде. Байтимер тастымалы белән мыек читләрен сөрткәләгән булып көлеп җибәрде.

— Нигә? Әгәр дә миннән яшьрәк, миннән чибәррәк бичура туры килә икән, мин сүз әйтмәм,— диде. Һәм арттырып та җибәрүен шунда гына абайлап алды. Бәдриҗамал коты чыгып сикереп торды. Үпкәләп, җәберләнеп усалланган күзләрен иренә текәде:

— Тефү, тефү, әстәгъфирулла диген, җүнсез! Авызыңнан җил алсын! Ничек шундыйга телең бара!?— дип, күзләрен сөрткәләп кече якка кереп китте.

Җәмәгатен үпкәләтә язуына уңайсызланып, Байтимер юмаларга ашыкты.

— И, җүләр! Әллә чынга алды инде?! Юк ла, син тагын! Шаяртып кына әйтүем! Бер әйттем, биш кайттым.

Почмак яктан хатынының үпкәле тавышы ишетелде:

— Андый белән шаярмыйлар! Хатының тамчы да җәл түгел сиңа, шуңа авызыңны җырып утырасың!

Хатынын рәнҗетеп калдырса, Байтимергә сәфәрдән әйләнеп кайтканчы күңел җәрәхәте булачак иде. Аңа пошаман төште. Ул моның шаярту гына икәнлегенә ышандыру өчен әлләниләр эшләргә дә риза иде.

— И, әнисе, авырга алмасаңчы! Яратып кына шаяртуым бит! Беләсең ич инде: синнән дә якын бер кемем дә юк лабаса!

Хатыны да зурга җибәрергә теләмәде, күрәсең. Ул борыннарын тарткалап яңы белән генә булса да яңадан табынга килеп утырды. Яңгырдан соң килеп чыккан кояш төсле ягымлы гына күз сирпеп, иренә чәй ясап бирде.

— Хатыныңа рәхмәт әйтергә кирәк сиңа! Ярый әле, сабыр холыклы булып чыкты,— диде.

— Бик рәхмәт, Бәдриҗамал, мең рәхмәт!

— Берәү булса, «чыгармыйм булгач, чыгармыйм!» дип итәгеңә ябышыр иде.

— Кәсепкә чыгармыйлар димени? Син алай арттырып җибәрмә!

— Нинди кәсеп бит! Берәүләр умыртып акча эшли, ә син ни юллар үтеп, ни михнәтләр чигеп такыр кесә белән кайтасың, җитмәсә әле үзеңне өтермәнгә ябып куярлар!

Бәдриҗамал иң авырткан урынга килеп бәрелде. Былтыр утыртып куйган үрәтник Байтимернең күз алдында әле һаман кара багана булып сераеп тора иде. Әмма хатынына моны алай куркыныч итеп күрсәтергә һич тә ярамый. Юк! Байтимер бер дә исе китмәгәндәй кыланды.

— Һи, әллә нидә бер кара мәче аркылы чыккан икән, аңа минем, ичмасам, мыегым да селкенми, — дигән булды.

Ә Бәдриҗамал алай уйламый икән. Ул иренә күзләрен мөлдерәтеп карап, күңелендәге шик-шөбһәсен яшермичә әйтте:

— Ай, алай бик егетләнмә! Үрәтник исемә төшкән саен, эчләрем «жу» итеп китә. Җитмәсә, әллә нинди куркыныч төшләр керә. Син кайтканчы, йокылар юк инде миңа. «Тагын тотып япмадылар микән? Нихәлләр генә булды икән?» дип кан йотам инде мин.

Иң борчыганы сәфәрнең алай ук хәвефле түгел икәнлегенә Бәдриҗамалны ышандыру, аны тынычландырып калдыру иде. Китап белән йөрүнең куркынычы гына түгел, җанны рәхәтләндерә торган куанычлы яклары да барлыгын аңа ничек төшендерергә? Әллә кайдагы ерак авылларда сине кадерле кеше итеп каршы алуларын beләмени ул? Мәктәп балаларының яңа китапны кулына алганда күзләренең ничек очкынлануын, йөзләренең ничек яктырып китүен күрәмени ул? Син алып барган китаплар никадәр кешене бәхетле итә, караңгы авылларга нинди якты нур чәчә! Шуларны нинди сүзләр белән аңлатырга?

Байтимер тегеләй дә, болай да уйлап карады. Әмма хатынын тынычландырырлык көчле сүзләр таба алмады.

— Син инде, әнисе, куркыныч уйлар белән үзеңне азаплама. Күр дә тор, берни булмас. Бисмилланы әйтеп ишегеңне биклә дә тик утыр китап укып. Менә шул! Төн кунарга кыз-кыркын, карчык-коры чакырырсың,— диде.

Бәдриҗамал, күзем туя күреп калыймчы, дигәндәй, аннан күзен алмастан, башын иеп кенә тагын әйтеп куйды:

— Күңелемә шик төшкәч нишләтим соң?!.

— Начар итеп уйлама! Андыйны башыңнан куып чыгар! Менә шул!

Ишек янындагы бүкәнгә утырып аягын киенгәндә Байтимер хатынының борчулы карашын сизеп тагын күтәрелеп карады. Чыннан да... Ни булды моңа?! Почмак як белән ике арадагы ишек янагына сөялгән килеш, Бәдриҗамал, күзен мөлдерәтеп, һаман аңа карап тора иде. Бу караштa чиксез кызгануны, ниндидер куркыныч барын сизүме, нәрсәме, шундый бер шом бар кебек тоелды. Ләкин Байтимер ул шомны күрмәгәнгә сабышты, торып хатынының иңбашын сыйпап алды.

— Сиздем инде, сиздем! «Озак йөрмә, миңа күңелсез!» ди күзләрең. Ярар, тизрәк әйләнү ягын карармын. Киңәштекме шулай?

Хатыны, башын игәләп, аның ак йон шарфын алып бирде.

— Ярабби, фәрештәләрнең амин дигән вакытына туры килсенче, шулай булсынчы!— диде.

Байтимер чанасын тартып авылыннан чыгып киткәндә таң беленеп кенә килә, бөтен авыл өстендә моңлы әтәч тавышы эленеп тора иде. Басу капкасын чыккач, Бәдриҗамал, яшь чагындагы кебек, аның муенына сарылды. Борыны белән иренең тамак астына елышып соңгы сүзләрен пышылдады:

— Кара аны: үрәтникле авылга керәсе булма, буранлы юлга чыкма! Ярыймы, ярыймы,— диде.

Шул аерылышу минутлары күз алдына килде дә, Байтимер, күңеле нечкәрүен үзеннән-үзе яшерү өчен, тамагын кырып алды. Бәдриҗамалын гүя аның көмештәй ялтырап яткан шушы киң басуда

берүзе җил-җил чана тартып баруын күреп торган сымандай итеп күз алдына китерде дә аңа иseme белән дәште.

— Борчылма, Бәдриҗамал, нәкъ син әйткәнчә бара эшләр. Урәтниклардән читтәрәк йөрим. Көннәр дә аяз тора! — диде.

Хатынының аны һаман да яшь вакыттагыча чын күңелдән яратуы аны куандыра, дәртләндереп тора иде. Үзенә дә ягымлырак булырга кирәклеге турында уйлап алды. Моннан соң калган гомерне, бер-береңнең кадерен белеп, тагын да матуррак, татлырак итеп уздырырга кирәклеген күңеленә беркетте. Бу юлы Бәдриҗамалга күлмәклек алып кайтып сөендерергә дә ниятләп куйды.

Алда шактый ук калын урман чыгасы бар иде. Байтимер, урманның җил үтеп кермәстәй ышык урынына барып җитте дә, агач төбендә чанасына утырды. Кояшның ягымлы җылысы битне иркәли, аяклар рәхәт кенә чымыр-чымыр килә, агач башларының салмак кына шаулап торуы йокыны китерә иде.

Юлчы шушы рәхәткә оеп кузен үк йомган иде инде, кинәт ул килгән яктан кыңгырау тавышы ишетелде. Байтимер борчыла башлады. Бу вакытта кыңгыраулы атларда йөрүче я станавай, я судебный, я урәтник кенә булырга тиеш иде. Байтимер сикереп торып якягына каранды. Тирә-якта тирән кар, юл бер генә. Ул тозакка эләккән җанвар сыман камалуда калган иде.

Ул да түгел, борылыштан мичәүле кара атлар җиккән кара чана килеп чыкты. Байтимер чанасын бата-чума кар эченә сөйрәп кенә өлгерде, кузлада утырган сакаллы кучерның маңгаенда җиз калай ялтырап китте. Ул гайрәтле тавыш белән:

— Шапку долой! — дип кычкырды.

Байтимернең тешләре кысылды, үзеннән-үзе йодрыклары йомарланды. Бөтен тәне, бөтен нервылары шундый бер көч белән куырылып, тартышып килде ки, хәтта ул үзе теләсә дә бүрек салырга кулын күтәрә алмаган булыр иде.

Кинәт кучерның катлы-катлы итеп сүгенүе ишетелде. Аның кулындагы озын кара чыбыркы сызгырып килде дә Байтимернең аяклары янында очы белән шартлап кар тузаннары күтәрде. Шул арада кара шинельле юан кеше утырган кара чана узып та киткән, чана яныннан еландай койрыгын болгый-болгый әлеге озын чыбыркы сузылып бара иде.

Байтимергә әллә ни булды. Юл уртасына сикереп чыкты да, бөеренә таянып, бии-бии такмак әйтергә тотынды:

Бас, кызым, Әпипә,
Син басмасаң, мин басам.
Бас, бас, бас, бас!..

Аяк астындагы кар шатор-шотыр итте, күктә кояш, җирдә урман чайкалып арлы-бирле килде. Ул хәзер үзен дию пәриләрен ахмакка калдырып хур иткән әкият батырлары кебегрәк хис итә иде. Аның бүреген салдырырга ыстанавайның кулы кыска булды, кодрәте җитмәде! Әй, һәй, һәй, һәй!..

Акылына килгәч, ул чанасына утырды да рәхәтләнеп бер көлде. Үзен-үзе «юләр син, юләр, шыр тиле!» дип үртәде. Шулай да ул үзеннән бик канәгать иде. Моннан соң аны нинди кыенлыклар көтәдер, анысын алла белсен, әмма шул кара козгыннар алдында башын иеп үзен-үзе кимсетмәвенә ул чын күңелдән куана иде.

Чың-чың иткән кыңгырау тавышы күптән тынган, тегеләр күздән үк югалган иде инде. Байтимернең ул якка барырга аягы тартмый башлады. Кара чана кояшның җылысын, урманның тынлыгын, бөтен тирә-якның ямен сүндереп бара, аның артыннан гел шомлы

салкын җил генә исә кебек тоела иде. Нишләргә? Кире борылыргамы? Алар артыннан барса, үз аягы белән килеп капмасмы?

Уйлана торгач кына исенә төште: әгәр хәтере ялгышмаса, урманны чыккач юл икегә аерылырга тиеш иде. Чыннан да, шулай булып чыкты. Кара чана урман авызында Уразгилде юлына түгел, уңга борылган иде. Байтимер сулга кереп китте.

Урманның аргы ягында җил салкын яктан исә башлаган икән. Безелдәгән тавыш чыгарып каршыга җәяүле буран себертә, салкын җил тун итәкләрен ачып тез башларына ябыша, бит алмаларын кыздыра иде. Байтимер китап капчыгын кар үтмәстәй итеп чыпта белән төрде, җилгә яны беләнрәк борылып кызурак атлады.

Бераздан маяклы юл башланды. Бу инде авылның якынлыгын белдерә, җылы өйне, кайнар чәйне күз алдына китерә иде. Маяклы юлда үзеңне ул кадәр үк ялгыз итеп тә сизмисең. Җем-җем иткән ап-ак кар өстенә кеше кулы белән утыртылган бу учмалар салкын җилләр сызгырып торган менә шушындый шәп-шәрә шыксыз кырда да сине кемдер кайгыртуын искәртеп, күңелләрне күтәреп җибәрә иде.

Атлый торгач, Уразгилде үзе дә күренә башлады. Ул инеш буена сузылып утырган бер мәчетле уртача гына авыл иде. Зәңгәр түбәле мәчет янында тәбәнәк кенә мәдрәсә бинасы да күренә. Мондый авылларга урәтник-мазар бик сирәк килеп чыга, ыстанавай-фәләннәр, берәр зур эш кузгалмаса, бөтенләй сәлам дә бирмичә читләтеп кенә уза торган иде. Байтимер авылга тыныч күңел белән килеп керде.

## III

Кырыйдагы ике урамны йөреп әйләнгәннән соң китапчы мәчет янындагы тәбәнәк кенә таш кибет янына килеп чыкты. Кибет ишеге төбендә торган чибәр генә яшь кеше (приказчик булса кирәк) аны кибеткә дәшеп кертте.

— Әйдә, аягыңа ял булыр. Бәлки синең календарең да бардыр әле? — диде.

Ул туры якалы кара бишмәт өстеннән ап-ак алъяпкыч япкан, болай да бик пөхтә кеше күренә иде. Байтимер аны беренче күрүдә үк ошатып:

— Кешесенә күрә табылыр, — диде.

Аягындагы карны каккалаганнан соң муенындагы шарфын да сүтә башлаган иде, әлеге егет Байтимергә бик үк «таралып төшмәскә» киңәш итте.

— Кибетебез салкын, таракан катырырлык, хуҗа утын җәлли,— диде.

Байтимер һавага өреп карады. Авыздан пар чыга иде.

— Карасана, нәкъ миндәге «Ялт-йолт»та язганча икән! — диде, яттан шигырь укып күрсәтте:

> Рус мәүлүде[1] үтеп китте, көннәр суык,
> Мондый көндә борыннарда өреләэ куык;
> Мичсез салкын кибетләрдә сатучылар
> Малын сата бии-бии кулын уып...

Сатучы егет бот чабып көлеп алды.

— Карале, минем турыда бит бу! Шәп суктырган, шәп! Хуҗага укып күрсәтәм әле мин аны!

Ачык чырайлы кеше белән гәпләшүе дә күңелле иде. Байтимер бераз мактана төшеп, тасма телләнеп алды.

— Таварым күңелле тавар минем. Арада шундый чеметеп ала торганнары да юк түгел,— диде.

[1] Рус мәүлүде — христиан динендәге рождество бәйрәме.

— Алай икән бит!
— Гыйбрәтле китапларым да җитәрлек! Ал гына, укы гына!
Ул арада кибеткә бер-ике хатын-кыз килеп керде. Алар бу ят кешегә яннары беләнрәк басып чәйдер, шикәрдер кебек кирәк-яракны алдылар. Акча түли башлагач, Байтимер дә телгә килде:
— Түтекәйләр, абыстайлар! Акчагызны яулык почмагына төйнәп куйганчы минем таварыма да күз салыгызчы! — диде.
Хатыннар, авызларын каплый төшеп, моңа борылдылар.
— Бәй, күргебез дә юк. Бирегә тагын бер сатучы бар икән ләбаса! — дигән булды берсе.
— Бар гынамы әле! Сатучының да ниндие!
Байтимер аллы-кызыллы, зәңгәрле-яшелле китапчыкларын чана өстенә тезеп салды.
— Менә, түтекәйләр! Бу энекәш тән азыгы сатса, мин җан азыгы сатам, саваплы азык!
Берсе китаплар өстенә иелеп күз йөртеп чыкты.
— Савабы да кирәктер инде аның, абдый. Тик аның белән генә җан асрап булмай шул. Тән адыгына ач булмасак, шунысына да бик шөкрана кылабыз инде,— диде.
Икенче хатын да телгә килде:
— Бик тә кыршылган чакка туры килдең шул, абдыкай! Ыстарысталар кичә генә бөтен авылны кырып-себереп имана акчасы җыеп чыктылар.
Хатыннарның сөйләшергә һәвәслеген шәйләп алу белән китапчы сүз янчыгын тагын да киңрәк ачып җибәрде.
— Сездәй язу таныган кешегә китапсыз да ярамый бит, түтекәйләр. «Китапсыз өй — канатсыз кош, китапсыз өйдән фәрештәләр качкай, китаплы өйгә бәракәт иңгәй» дип әйтеп калдырган бабайлар.
Хатыннар үзара пышылдашып нидер киңәшеп алдылар. Теге телчәне яулык почмагын ук чишәргә кереште:
— Кая соң? Олы кеше бик мактагач, әллә берәр китап караекмы соң?— диде.
Байтимер аягүрә басып чанасы өстендә кайнашты.
— Карагыз, кара, түтекәйләр. Китапларның көлле яктан сихәтләре бар. Сау чакта куанычың, сырхау чакта юанычың ул яхшы китап!
Ул берәм-берәм китапларын күрсәтә башлады.
— Ниндәләен сайлыйк? Кызыгыз булса, менә «Әдәпле кыз бала» дигән китап бар.
Әлеге хатын авызын каплап елмаеп куйды.
— Минем кызыма әдәпне «мыеклы китап» өйрәтә шул инде...
— Алайса, үзеңә табыйк! Нинди китап яратасың? Кабаң янында җеп эрләп утырган көенчә дөньялар гизеп, диңгезләр, янар таулар кичәсең киләме? Менә сиңа «Мең дә бер кичә».
— Ай, алай бик еракка сикермәек әле, йөрәгем җитми! Картымның да талканы бик коры, үз яныннан әллә кайларга җибәрмәс. Үз тирәбез турында язылган берәр нәрсә юкмы соң?
— Дисеңме? Алай булгачыннан менә сиңа үзебезнең тормыштан бәетләр, мөнәҗәтләр бар. Кайсын сайлыйсың?!
Шулай кыстап, тәмле телләнә торгач, ике хатынның икесенә дә берәр китап тоттырып, китапчы аларның артларыннан рәхмәт әйтеп калды.
Кемдер тамак кырганга күтәрелеп караса, кибеткә кечерәк кенә гәүдәле бер карт кереп килә икән. Сатучы аңа башы белән ымлап:
— Баһаветдин абзый бу, авылның мәчет карты,— диде.
— Ә, шулаймыни?— Байтимер аңа баш иде.— Исәнлекме, абзый кеше?

Карт теләр-теләмәс кенә иреннәрен кыймылдатып:

— Саулыкмы...— диде.— Ул үзе китаплар караштыра, үзе өзлексез иреннәрен кыймылдатып нинидер дога укый иде.— Саваплы китапларың да бармы?.. Илаһи раббым...

Байтимер аңа күтәрелеп карады да көлемсерәде.

— Һәммәсе дә саваплы безнең китаплар, абзый.

— Карап караек, алайсам... Лә хәүлә вә лә куәтә... Бармы соң синдә «Әптияк», «Ясин», догалыклар?

Байтимер түбән карап кына елмаеп куйды.

— «Һәфтияк»ме? Хәзер абзый кеше, хәзер!

Кеше никадәр наданрак булса, аның белән эш итү шул кадәр мәгънәсезрәк килеп чыга иде. Ул кибетче егеткә шаян караш ташлап, капчыгыннан юка гына бер китап чыгарды.

— Тагын догалыклар диденме? Менә ул догалык!— Ул тефү, тефү ди-ди бармакларына төкергәләп китап битен ачты.— Әйт кенә, кай төшләрең сызлый, кай төшләреңә нинди чирләр ябышкан? Хәзер табып бирәм догасын!

Карт шикләнебрәк кенә китапка үзе сузылды. Ләкин ул догалыкны киреле-башлы тота иде. Байтимер китапны үзенә алды.

— Бисмилласын әзлисеңме?

— Соң...

— Бар инде, бар! Менә, башында ук! Син аның догасын тыңла: «Әгәр дә бер бәндә сихер зәхмәтенә дучар булса, ошбу доганы укыгай: «Кыл-кыл җиһан башы, кыл-кыл җиһан уртасы, кыл-кыл җиһан азагы. Җиһан диде, җиһан җитмеш җиде, җиһан җиде йөз дә җиде! Барчасын зекер кылдым[1], көлле[2] сихерне тузан иттем! Тефү, тефү, тефү!»

Карт, иреннәрен кыймылдатып, Байтимер әйткәннәрне кабатлый иде. Бу вакытта кибеткә берән-сәрән тагын берничә кеше кергән иде инде. Байтимер шуларга ымлап алды да тагын әйтеп куйды.

— Ишеттеңме, картлач! Шуннан соң син күр дә, мин күр, «сихер кул белән сыпырып төшергәндәй юкка чыккай» дип әйткән китап!

Баһау карт күзен челт-челт йомып тыңлый иде. Әмма кибеттәге халык «пырх-пырх» көлешә башлагач, ул кинәт кабынып китте:

— Нәмәрсәкәй син догаи шәрифкә урам сүзләре кыстырасың?! Дога икән, син миңа корьән сүзе укы, хәдис укы!

Китапчы аңа сынийрак карап алды. Карт ияген шәп-шәрә итеп кырып алган да сакалын ияк астында гына калдырган, мыегы да тигәрҗеп юанлыгы гына иде. Мондыйлар гадәттә берәр ишанга мөритлеккә кул биргән бәндә булалар, чеп-чи надан башлары белән күп белгән булып кыланалар иде.

Билгеле, Байтимернең шушы кадәр халык алдында бу надан картка бирешәсе килмәде. Ул тагын да дәртләнебрәк бәхәсләшергә тотынды.

— Соң бит, рәхмәт төшкере! Гарәпчә әйтүдән ни файда мәгънәсен аңламагач?!

— Аңламасаң да савап! Барыбер савап!

— Әнә шул савап ди-ди балалар надан кала да инде безнең. Ишеткәнең юкмыни?

Күп яттык без мәдрәсәдә,<br>Белмәдек без бер нәрсә дә...

— дип зарлана бер шәкерт.

---

[1] Зекер кылу — әйтеп узу, телгә алу.

[2] Көлле — һәммә, барлык.

— Намазсызлар зарлана, имансызлар!

— Менә мин кайчаннан бирле китап сатам, нинди мәдрәсәләрдә генә булмыйм! Үз телебездән зарланмый бит шәкерт. Йөрәккә сары май булып кына ята,— ди.

Байтимер кулына календарь алып аның бер битен укып күрсәтте:

Китап дигән дәрья бар,
Дәрья төбендә мәрҗән бар;
Белгәннәр чумып алыр,
Белмәгәннәр коры калыр...

— Я, әйтче абзый! Ошбу халык сүзенең корьән аятеннән кай төше ким? Нигә балалар укымаска тиеш аны?

Кибет эче сагайды, тынып калды. Карт арлы-бирле селкенде, якягына борылгалап кычкырып җибәрде:

— Әһә! Ишеттегезме, җәмәгать?! Әллә ниткән урам такмагын аллаһ тәгалә сүзенә тиңли! Әстәгъфирулла, тәүбә диген!

Байтимер башын чайкады.

— Юк, әйтмим, тәүбәлек эш юк монда. Корьәнгә кагылмыйм, ул үз урынында. Дөньялыкта яшәр өчен әүвәл башта үз телеңне белергә кирәк дип кенә әйтәм. Ул бит ана сөте белән кергән, канымызга сеңгән.

Баһаветдин картның иреннәре дерелди башлады, күзләре елтырап китте.

— Әйтәләр бит сиңа тиңләмә дип, тиңләмә! Гөнаһ, гөнаһ, телең корыр!— диде ул.— Корьән сүзе — изге сүз, ул аллаһ тәгалә сүзе! Ул пәйгамбәр галиһиссәламгә күктән вәхи булып иңгән. Ә син әйткән такмак нәмәрсәкәй?! Ә?! Аны бит ыштансыз малай да, имансыз мөртәт тә әйтә ала. Әйеме? Сабакмыни ул? Аңа үләт тә тиясе юк!

Кибеткә җыелган халыкның үзе яклы булуын сизеп, Байтимер тагын да канатланыбрак китте, ул чанасы аша Баһауның каршысына ук чыгып басты.

— Ай-һай, бик тә хаталанасың, карт. Ашаган табагыңа төкергәндәй, үз телеңнән үзең көләсең. Әйе, көләсең! Уйлап кара, нихәтле яман атын сатсаң да менә барыбер үз телеңдә сөйләшәсең ләбаса! Изге тел дип никадәр һушың китсә дә, карчыгыңа самавыр куярга гарәпчә әйтмисең бит! Әйе бит?! «Я, әййөһәл, карчык! Куйчы әле әссамаварый, әчик әле әччаи вә бишшикәри бил хөбзи»[1] димисең! Юк бит?!

Китапчы абзый моны корьән укыгандагы кебек бормалый биреп, шундый мәзәк итеп көйләде, кибеттәге халык гөр килеп көлешергә тотынды.

Баһау карт нишләргә белмичә таягын тукылдатты.

— Тагын шул? Кемдә нәрсә, иблистә эскрипкә кайгысы, ди мулла. Беләсеңме син ходай нәрсәгә дип яраткан гарәп телен? Ә? Әдәм баласын корьән шәриф сүзләрен укысын да аллаһ тәгалә турында, ахирәт турында гына уйласын дип! Әлхәмдрилла, аны гына беләбез!

— Ә дөнья тормышын кем кайгырта, аның турында кем уйлый? Мәндн анасымы?

Кибеттәге халык беравык гөрләп алды. Баһау карт авылдашларына шәбәеп карап торды да тагын да тирә-юньгә чәчәргә тотынды.

— Сүләп мәтәштерә бит әле! Дөнья, дөнья! Эт ашасын дөньясын! Дөнья малы — дуңгыз каны!

Мондый туңбашны нәрсәгә булса да ышандыру — булмастай эш, мәгънәсез сүз боткасы куерту иде. Байтимер, бу картка түгел, җыелган халыкка карап сүз йөртте:

[1] Бил хөбзи — икмәк белән.

— Соң, Баһаветдин абзый, синең шикелле бөтен гомерне намазлык өстендә генә уздырып булмый лабаса! Тормыш итәсе, тамак туйдырасы, бала-чага үстерәсе бар ич!

Баһауның җавабы әзер иде.

— Ходай җан биргәнгә юнь бирә! — диде.

— Ходайга ышан, тик үзең дә кайгырт, дигән бабайлар. Яшьләр солдатка китә, завод эшенә керә, шахтада күмер казый. Дөнья гыйльмен белмәсә, язу-сызу өйрәнмәсә, ул ничек кеше арасына керсен, ничек дөнья кусын!? Шулай итеп шул, безнең яшьләр үзебезчә дә, тегенеңчә дә, моныңча да белергә тиешле!

Бу килмешәккә җавап таба алмыйча аптырап калуы, авылдашларының шул денсез яклы булып тешләрен ыржайтып торулары картны тәмам чыгырыннан чыгарды. Ул Байтимергә кинәт арты белән борылып төкеренә башлады.

— Тефү, тефү, телеңә тилчә! Синдәй имансызлар белән әрепләшеп гөнаһлы буласым юк әле! — диде.

Байтимер каты кычкырмас өчен бөтен түземлеген җыеп картның каршысына барып басты.

— Бүтәне бүтән, абзый кеше, әмма дә ләкин иманга тел тидерештән булмасын! Ишеттеңме? Юк, кагылмыйк иманга! — диде.

Карт авылдашларының әле берсенә, әле икенчесенә борылып куанычыннан кычкырып җибәрде:

— Әһә! Ишеттегезме? Җан җиренә китереп суктыргач ничек үрсәләнә! Һа!

Картның очынуына һич тә ис китмичә, Байтимер аңа бөеренә таянып кына җавап бирде:

— Юк, абзый кеше, юкка кәперенмә! Без андый изелеп аккан нардан түгел! — Ул картның күзенә карап шигырь әйтеп салды.

Кем дисең бу фетнәле эшләр башы?
Кайда бу хаксызга тәфтишләр башы?
Кем җигә безгә тәдәнни [1] арбасы?
Кемгә ләгънәт әйтәсе һәм каргасы!
Бәдбәхет, мәлгунь кеше кем, дусларым?
Бер авылның чалмалы карт марҗасы! [2]

— Я, әйтеп карасана, абзый кеше, кем турында икән бу шигырь?

Көтелмәгән бу хәлдән карт «ә» дияргә дә, «я» дияргә дә белмичә телсез калды. Кибеттәге халык дәррәү күтәрелеп көләргә тотынды.

— Әһә! Каптырдымы? Каптырды! Шап иттерде!

— Ай-ай, мач китердең, абзый, малатчина!

— Менә, ишеттеңме ишетмәгәнеңне! Безнең арада бик батыр да бит, менә хәзер аста ятыр! Һа-һа-һа!

Баһаветдин карт ачуыннан күгәренеп төкеренә-төкеренә ишеккә китте.

— Җыен намазсыз, җыен... Әстәгъфирулла... Тефү!

Аның артыннан шаулашып көлешеп алдылар.

— Бәй, үзебез дә җик күргән инде аның быжгуыннан. Бигрәк тә мөгаллимнәр, — диде берсе.

— Шулай, — дип кушылып китте икенчесе. — Тик бөкрене кабер генә төзәтә диләрме? Аңа тел тидереп, ник дәштем көненә төшәсең инде.

---

[1] Тәдәнни — мәдәниятнең кире ягы, мәдәниятсезлек.

[2] Габдулла Тукайның «Кайда, кем?» дигән шигыре. Бу шигырендә ул Балтач районы Түнтәр авылының мулласы, патша охранкасының агенты, заманында татар яшьләре арасындагы яңа карашларга каршы торып, әләк язу белән шөгыльләнгән Ишмөхәммәт ишанны фаш итә.

Кибеттэгелэр нидер эйтеп бетермилэр иде кебек. Байтимер куркаклардан булмаса да, аның күңеленэ шик төште.

— Тел төбегездэ нидер бар,— диде ул.

Кибетче егет моңарчы сүзгэ кушылмаган иде. Ул Байтимергэ карап-карап алды да турысын эйтергэ булды.

— Белэсеңме, абзый, шулай да иң хэерлесе — бу тирэдэн тизрэк таю булыр,— диде.

— Нигэ? Берэр явызлык кылыр дисеңме?

Кибетче егет кашларын сикертте, кулларын җэеп җибэрде.

— Шайтан белсен анықын! Дин юлында изгелек эшлим дип, савaплы булам дип... урэтниккэ тишмэгэе.

Тагын берэү киңэш бирде:

— Эллэ, мин эйтэм, тэртэңне башкорт ягына борасыңмы? Ни эйтсэң дэ башкорт ягы иркенрэк сулый. Анда, бездэге шикелле, адым саен каравыл, авыл саен элэк түгел.

Үрэтник кулына элэгүнең нэрсэ икэнен Байтимер белэ иде инде. Эмма ул никадэр телэсэ дэ хэзер башкорт ягына чыгып китэ алмый иде. Ник дигэндэ, Минзэлэгэ кереп чанасын тутырып чыкмыйча берничек тэ мөмкин түгел иде.

## IV

Иртэгесен юлны үзгэртергэ туры килде. Байтимерне кундырып чыгарган элеге кибетче егет аңа Минзэлэгэ эйлэнгеч юлдан барырга киңэш бирде.

— Баһаветдин карт урэтниккэ җиткерэ калса, ул сине олы юл буеннан эзлэр,— диде.

Байтимер Уразгилдедэн караңгылы-яктылыда ук чыгып китте дэ басу капкасын узуга урынтын юлга борылды. Ун-унбиш чакырым эйлэнсэ эйлэнер, аның каруы күңеле тыныч булыр. Минзэлэнең үзендэ дэ сак булырга, кеше күзенэ чалынмаска, китап төяп чыкканнан соң да волостьлы авылларга кермэскэ булды. Анда күз күрер. Шыпырт юлга төшеп, Сөн аша Бөрҗэн ягына чыгып китэр дэ... эзлэ син аннары даладагы җилне!

Уразгилденең аргы ягыннан, офыкны зэңгэрсу-ал төскэ бизэп, таң беленеп килэ иде. Менэ шундый матур таң вакытларында үзенең шундый изге эшлэр белэн йөрүе, менэ хэзергедэй акыл белэн эш кылуы Байтимернең күңелен күтэреп җибэрде. Ул салмак кына атлап барган көйгэ, гадэтенчэ шигырь көйлэп алды.

> Сабыр берлэ эшлэгел ошбу эшне,
> Сабыр берлэ эшлэнер эшлэр башы,
> Морадына тиз җитэр сабыр кеше,
> Бу эштэ дэ күрекле сабыр кылгыл имди... [1]

Лэкин яхшы кешелэрнең Баһау карт турында искэртүлэре яңадан исенэ килеп төште. Шундый тискэре бэндэлэр узган ел да аның канына тоз сипкэннэр иде. Шундыйларның элэге нэтиҗэсендэ Иске Масраның Эсфэндияр белэн алар Сарапул ягында урэтниккэ элэгеп, өч атна каталашкада утырып чыктылар. Ни өчен диген? Дөньяви китаплар сатып йөргэн өчен! Ярый эле акыллары җитеп чеп-чи наданга сабыштылар. Янэсе, алар ни урысча, ни татарча лэм-мим бер нэрсэ белмилэр. Алардан сөт тэ юк, йон да юк. Байлар ни төяп чыгарсалар, шуны саталар да йөрилэр...

---

[1] «Йосыф-Зөлэйха» поэмасыннан. Йосыфның Зөлэйхага биргэн киңэше.

Үрәтник белән «минеке малы-малы гына кәләкәйт» дип, урысчаны ватып-җимереп сөйләшүе исенә төште дә Байтимер үзалдына елмаеп куйды. Тик капкан саен калҗа эләкми. Итәгеңне, җиңеңне җыебрак йөрү хәерле...

Шулай да бу бәйләнүләр аны гел бимазалап тора иде. Кара инде син, ә?! Үз телеңдә китап укыганга эт урынына ябышалар. Дөньяда булмаган хәл! Үз телеңдә укырга ярамасын, имеш. Анда бүтәннәрнең ни эше бар? Тора-бара сөйләшергә ярамый, аннары җырларга да ярамый башласа нишләрсең? Байтимер аңлавынча, кычкырып торган гаделсезлек иде бу. Ул хакта уйлаган саен аның ачуы кабара иде. Баһауларга ачу итеп быел Байтимер тагын да озаграк йөриячәк! Юк, алай гына туктата алмыйсың әле Байтимерләрне!

Ул җилгә аркасы белән борылып, шарфын тамак астына тартып, бүреген басыбрак киде, бияләйләрен бер-берсенә шапылдатып бәреп алар эченә җыела бшлаган суыкны куып чыгарды. Кояш чыкканда табигать һәркайчан бермәл шулай салкын сулышын өреп, кырысланып ала инде ул.

Юлны кыскарту өчен ул я берәр бәет, я шигырь әйтә, кайчакларда җырлап та җибәрә торган иде. Барачак авылы күренмәгәч, уйланып барды-барды да авыз эченнән җыр сузды.

Оят түгел микән көй көйләргәй,
Безнеңдәйгенәй солтанат ирләргәй?
Җырлау гына түгел, ай, такмакларсың,
Газиз башым ерак илләрдәй...

Төнге буран юлга кар өйгән, эзсез юлдан чана тартып барулар җиңел түгел иде. Юл өстендәге беренче авыл Чиялегә китапчы өйлә җиткәндә генә килеп керде. Бер әбигә кереп чәйләп чыкты, акрын гына урамнарны йөреп әйләнде. Мөгаллимнән шәкертләр янында кунып чыгарга рөхсәт алды да узып барышлый каравыл өенә кереп чыгарга булды.

Бу якларда ел саен диярлек бер әйләнеп чыкканлыктан, бу тирә авылларының гореф-гадәтен Байтимер яхшы белә иде. Мал-туар тирәсендә кичке эшләр башланганчы авылның ир-аты, яшь җилбәзәге төштән соң беразга каравыл өенә килеп чыгучан. Йортларда тәмәке исе чыгарырга ярамаганлыктан, өлкәннәрдән, хатын-кыздан яшеренеп, авылның җиде-сигез тәмәке тартучысы да гадәттә каравыл өенә килеп тәмәке пыскыта. Мондыйлар арасында җыр китаплары, бәетләр, төрле хикәятләр яхшы үтә иде.

Ишекне ачуга Байтимернең борынына сасы тәмәке исе килеп бәрелде. Күңеле нидер сизенеп ул кинәт кире тартылды. Узган ел аларны тотып япкан үрәтниктән дә нәкъ шушындый тәмәке исе килә иде бит! Әмма чигенергә соң, аны күреп алганнар иде инде. Байтимер керсә дә керде, кермәсә дә керде. Үрәтник әзли чыкса, иң элек каравыл өенә сугылачак бит! Их-ма...

Каравылчы мич яккан җиреннән кызарган йөзе белән борылып моның сәламен алды.

— Әйдүк, әйдүк, мактап йөрисең икән. Менә хәзер мичкә бәрәңге тәгәрәтәм,— диде.

— Әйдәргә исәп...

Ян сәкеләрдә тагын берничә ир-ат утыра иде. Кысылышып китапчыга да урын бирделәр. Ул бияләйләрен салды, тунын чишеп җибәрде, болардан хәл-әхвәл сорашып алды. Каравылчы мичен болгатып дөрләтеп җибәрде дә моның чанасына күз салды.

— Казан артыннандыр инде,— дип куйды.

— Шулайрак...

— Сезнең яклар күренгәли бездә. Я тегүче килеп чыга, я итек басучы, я бүтән берәр оста.

Ишек янында тәмәке пыскытып утыручы сары каеры тун кигән бер агай да сүзгә кушылды.

— Шундый һөнәрле, таза тормышлы, игелекле яктыр инде ул, күрәсең,— диде.

Араларында аягына кара киез итек, өстенә хәтфә якалы кара бишмәт кигән кара тут йөзле бер чибәр егет тә бар иде. Ул да берничә сүз әйтеп куйды.

— Бәй, Габдулла Тукай язган ич әнә: «Җил дә вакытында исеп, яңгыр да вакытында ява» дигән. «Урманында кып-кызыл кура җиләк тә җир җиләк, күз ачып йомганчы, һичшиксез, җыярсың бер чиләк» дип тә әйткән.

Байтимер исә үз ягын кыенсынып исенә төшерә иде. Казан өязенең бер-берсе янына тыгылышып утырган салам түбәле, ярлы авыллары, көз җитүгә зимагурлыкка чыгып китүче меңнәрчә ярлылары күз алдына килде. Хәле авыр булмаганда игенче җылы өен, бала-чагасын ташлап чит-ят җирләрдә каңгырып йөрер идемени? Бу якларның күбесе киез итек кигәндә ул үзенең чабаталы булуына да хурлана иде. Ләкин болар шулай үзенә күрә бер затлы, кадерле як итеп ихтирам белән сөйләгәндә Казан артының яман атын сатып дәрәҗәсен төшерергә теле бармады. Киресенчә, анда горурлык хисе уянды.

— Шөкер, бик игелекле безнең ягыбыз, яманлар хәлем юк,— диде.

Әлеге чибәр егет аеруча кызыксына, аның тагынниләрдер беләсе килә иде булса кирәк.

— Шулай да нииндирәк ул Казан үзе, Казан арты дигәннәре?— дип сорады.

— Ниндирәк дип, һәр җәһәттән данлыклы инде ул яклар. Китаплар да шунда чыга, һөнәрчелек тә бик көчле. Көмешчеме анда, бүтән һөнәрме. Тукай да безнең яктан чыккан. Бер Казан үзе ни тора! Университеты гөрләп эшли, укыган кешеләре бик күп. «И Казан, нурлы Казан!» дип тикмәгә генә әйтмәгән Тукай.

Чибәр егет Байтимернең янына ук килеп утырды.

— Университеты турында берәр китап-мазар юкмы?

Каеры тунлы кеше, тәмәкесенә өргәләп:

— Нивирсит дидеңме? Анысы нәмәкәй була тагын? — дип сорап куйды.

Байтимер белән Заһит бер-берсенә карашып елмаешып алдылар:

— Безнеңчә баш мәдрәсә диярга ярый. Дуктырлар, төрле зур укыган кешеләр әзерләп чыгара. Аның турында китап дигәннән...

Байтимер җавап биреп өлгергәнче ишек ачылып китте. Аннан кара шинель кигән, кылыч таккан, зур гәүдәле, мыеклы кеше килеп керде. Байтимернең аркасыннан салкын йөгерде. Менә ул баягы ялгышның «әҗере!» Уйлаганы алдына ук килеп басты. Аһ, егетләр! Ничек болай таксыз кыланды, нигә үз аягы белән килеп капты соң әле ул?! Нигә тагын да еракkарак тайпылмады?..

Урәтник идән уртасына туктап бүрек өстеннән кигән сары башлыгын аркасына чөйде, бер ишек янындагы чанага, бер Байтимергә күз ташлап куанычыннан гөрелдәп куйды.

— Әһә! Так, так! Гәпләшәбезме? Монда да өлгердек, әйе?! Җитез, бик тиз, әйтерең дә юк!— диде.

Урәтник кулларын угалап түргә барып утырды. Аның артыннан кергән староста белән дисәтник, бүрекләрен култык астына кыстырып, ишек янына бастылар. Урәтник китапчыга сүзсез генә кулын

сузды. Кулъяулыгын сүтеп губернатор кәгазен биргәндә бармаклары дерелдәп китүен күреп, Байтимер тешләрен кысты, эченнән «бирешмәскә, нык торырга!» дип кабатлады.

— Язуым дөрес, ваш былгаруди, кул да куйган, пичәте дә бар. Хуҗа үзе алып бирде. Безнең язусыз чыгылмый, ваш былгаруди. Шунсыз ярамый, закон, беләбез...— дип сөйләнде.

Үрәтник кәгазьдән күз йөгертеп кенә чыкты да, бүксәсен киерә төшеп, аны эчке кесәсенә салып куйды. Байтимер эсселе-суыклы булып китте. Шомлы тынлык эчендә кечкенә чанага башы белән ымлап, үрәтник:

— Ну-ка, князь, күрсәт нәрсә сатасың!— диде.

Бу мыскыллау сүзен Байтимер кемнән генә ишетсә дә тыныч кына сеңдерә алмый иде. Бияләйләрен арлы-бирле китергәләп башын чайкады.

— Ялгышасыз, ваш былгаруди. Кенәзләр мондый салкыннарда кар ерып өч тиенлек китап сатып йөрми, үзенең Питербурдагы җылы сараенда кәефләнеп утыра, — диде.

Үрәтник калын тавыш белән көлеп алды.

— Ха-ха-ха! Кара, кара, ошамады тагын үзенә! Ну, ярар, күп сөйләнмә, күрсәт товарыңны!

Чанасына иелгәндә Байтимер эченнән генә сүгенеп: «Тот капчыгыңны, албасты! Монда сине куандырырлык пычагым да калмады!»— дип уйлап алды. Чөнки ул «Ачлык патша», «Төрле милләтләрне җәберләү кемгә кирәк» кебегрәк китапларны Казаннан чыккач та озатып бетергән иде. Ул капчыгында актарына торгач, берничә дини китап тартып чыгарды.

— Менә, изгеләр турында. Безнеңчә, «Кыйссасыләнбия» дип йөртелә. Бусы урысча «Отходная» [1] дип әйтелә бугай, шундыйрак малитва, үләр алдыннан укый торган.

Ул үрәтникнең дөньяви китаплар саткан өчен утыртып кую ихтималын белә иде инде. Андыйларны астарак калдырып диниләрен генә күрсәтергә булды. Капчык төбендә калган тагын бер китапны актарып чыгарды.

— Менә, бусы да малитвенник, «Һәфтияк» дибез.

Ләкин үрәтник нидер сизенде булса кирәк, ул Байтимергә бармак янады.

— Шалишь! Алай булмый!— диде, старостага капчыкны бөтенләй бушатырга кушты.

Ян сәкегә капчык төбеннән яшел, зәңгәр, кызыл тышлы юка китапчыклар коелды. Үрәтник шуларны берән-берән алып исемнәрен сорарга тотынды. Байтимер эшне тирәнгә җибәрмичә котылуны өмет итеп, китапларның бисмиллалыларын гына күрсәтергә булды. Үрәтник аңа ышанмыйча старостаны чакырып алды.

— Укы!— дип боерды.

Старостаның куллары дерелди, күзләре әлҗе-мөлҗе килә, ул китапчыкларны бер якынайта, бер ераккарак куеп карый иде.

— Монысы ту... тургай турында...— дип башлаган иде, үрәтник аны тыңлап бетермәде.

— Нинди тургай? Какой-такой тургай булырга может дин китабында? Значит, молитвенник түгел! Долой! — Ул китапчыкны ян сәкегә ташлады. — Тагы?

Староста Габдулла Тукайның «Күңел җәүһәрләрен» русча әйтә алмыйча кара тиргә батты. Башын кашыды, сакалын учлап карады, «Син булдың минем башыма бәла!» дигәндәй, янында торган Байти-

---

[1] Отходная — ясин дигәне.

мергә күзен акайтып алды. Урәтник исә һаман ашыктыра иде. Старостаның нидер мыгырдавын ошатмыйча:

— Ну, ну! Нәрсә син бозаулый алмаган сыер шикелле мөгерисең? — диде.

Ниһаять, озак азапланганнан соң, староста тотлыга-тотлыга тагын бер сүз әйтеп куйды:

— Нәрсә, нәрсә?

— Юк, сиртсә түгел, душа, душаның нәмәкәйләре...— диде, шул «нәмәкәйләрен» капшап күрсәтергә теләгәндәй бармак очларын уарга тотынды.

— Нинди душа? Какой-такой душа? Кемнеке ул душа?

Староста беравык күзләрен челт-челт йомгалап урәтникнең тәмәке төтене саргайткан калын мыегына карап торды. Аның яңагыннан тамчы-тамчы тир тәгәри, ул, хәле бетеп, менә хәзер аяк астына авар кебек күренә иде.

— Стал быт... стал быт, мирныкы, ягъни халыкныкылар инде.

Урәтник үзе өчен ниндидер яңалык ачып шуңа куангандай билләренә таянып елмаеп куйды.

— Аһа! Душа! Мирныкы! Әнә нәрсә турында икән синең капчык төбенә яшергән китапларың! Аңлашылды! — Ул китапчыкны староста кулыннан алып сәкегә ыргытты.—Все! Бетте! Бүтән сатмыйсың!

Староста белән дисәтниккә Байтимерне күрсәтеп башы белән ымлакты. Тегеләр китапчының икесе ике ягына килеп бастылар. Каравыл өендәге бүтән кешеләр, башларын иеп, бер читкәрәк елыштылар.

Байтимер башта үз колагына үзе ышанмыйча катып калды. Аннары аның бөтен гәүдәсе кайнарланып китте. Ул маңгаен сыйпаштырып:

— Аңлашылмый, ваш былгаруди, ни өчен? Язуым бар бит! — диде.

Урәтник папкасын алдына куеп нидер яза башлаган иде. Башын күтәреп гамьсез, битараф күзләре белән Байтимернең йөзенә текәлде.

— Сиңа бит язу мондый китаплар сатарга түгел, молитвенниклар сатарга гына бирелгән. Кая монда Коран и тагын шуның ише магометанская религия китаплары? Ә?

Байтимер күңелендә кузгалган өермәне басып, ягымлы тел белән аңлатып карады:

— Гел шундыйларны саттым да мин. Ә болары болай гына, аз гына. Халыкка андыйлары да кирәк бит, ваш былгаруди. Календарь анда, әйтик, шигырьләр, акыллы киңәшләр, дөнья турында...

Урәтник язуыннан бүленеп Байтимергә күзе белән тишеп алырдай итеп чекерәеп карады.

— Беләсеңме, князь, синең телеңне кыскартасы бар! Понятномы? Сезгә нәрсә укырга кирәген его величество патша хәзрәтләре сездән яхшырак белә! Понятномы? Әнә Коран укыгыз, маңгайларыгыз шешеп чыкканчы намаз укыгыз. Сезгә шул җитмәгәнмени?

Китапчы һаман да өметен өзми иде әле. Ул үзенең юма теле белән тегенең күңелен йомшартырга тырышып карады.

— Шулай да тормыш булгач, дөнья гыйлеме дә кирәк була бит, ваш былгаруди...

Ләкин ул урәтникнең ачуын гына чыгарды.

— Менә шуның өчен кирәгеңне аласың да инде син! Шундый китаплар саткан өчен 1018 статья сиңа? Понятномы?

Байтимер җилтерәп урәтникнең каршысына килеп басты.

— Нахак бу! Дөрес түгел! Андый закон юк! Була да алмый!

Урәтник тешләрен кысып кына:

— Җитте, өйрәтмә мине! — диде.

— Дөрес түгел! Мин бит хезмәтче генә! Ни бирсәләр шуны гына сатам. Болар бит хуҗаныкы! Әнә аларны судка бирегез, мине түгел! Мин боларны...— дип китапларына үрелә башлаган иде, үрәтник, тавышын үзгәртмичә генә:

— Кагылма! — диде.

Байтимер кулын сузган килеш тораташ булып катты. Гүя башына күсәк белән органдай телсез калды. Хәтта «крамола» дигән куркыныч сүз дә бу кадәр сынын катырмаган, төрмәгә элгү куркынычы да болай каушатмаган иде. Дисәтник аның кыр чәчәкләредәй төрле төстәге хуш исле китапчыкларын дәү, пычрак бияләе белән сыпырып ала башлагач, Байтимер җаны әрнүдән кычкырып җибәрә язды. Ул китапларыннан мәңгегә аерылгандай өметен өзеп, хәле бетеп ян сәкегә барып утырды.

Үрәтник папиросын суыргалый биреп Байтимергә күз салды. Нидер уйлагандай беравык тын утырды да язган кәгазен яңадан бер укып чыкты. Китап капчыгына күз төшерде дә кәгазьне Байтимергә сузды.

— Мин чыгарган закон түгел. Әнә үз картларыгыз бик күп белә. Магометаниннарга школада дин китаплары гына укытылырга тиеш. Бүтән китаплар уку язык, бик каты тыела. Патша законы да шулай куша. Понятномы!?

Бу бәндә белән бәхәсләшүнең мәгънәсе юк иде. Байтимер дәшмәде.

Үрәтник кулы белән ишарәләп кәгазьгә кул куярга кирәклеген аңлатты. Байтимер башын селкеп:

— Куймыйм,— диде.

— Нишләп?

— Дөрес түгел. Миндә гаепләрлек китап табылмады.

Үрәтник, берни әйтмәстән, кәгазьне староста белән дисәтниккә таба этәрде.

## V

Китапчының кулга алынуы бөтен авылны борчуга салды. Каравыл өе янына төркем-төркем булып халык җыела башлады. Таза-таза ирләр, егетләр, яшүсмерләр каравыл өенә керәләр дә Байтимергә карап үзара пышын-пышын нидер сөйләшәләр. Алары чыга, бүтәннәре керә. Байтимер үзен кызгануларын аңлый, ара-тирә «приговор» дигән сүз дә ишетелгәләп кала иде.

Өйләдән соңгы сабакка барышлый каравыл өенә эреле-ваклы мәдрәсә шәкертләре кереп тулды. Алар кызарган борыннарын тарткалап ишек янында таптаналар, Байтимердән күзләрен алмыйлар, аны чын күңелдән кызганалар иде. Китапчы абзый бүген алар янына килергә, кичен китап сатарга, әкият сөйләргә тиеш иде бит. Авыл халкының аның яклы булуын, аны кайгыртуын сизеп тору Байтимергә үзенә күрә бер юаныч булды, аның балаларга берәр ягымлы сүз әйтәсе килде.

— Эшләр менә шулайрак булып тора бит әле, оланнар. Сез инде изге теләктә торыгыз. Иншалла, эш зурга китмәс. Яңа китаплар алып мин сезгә тагын...—дия башлаган иде, үрәтник аңа әйтеп бетерергә ирек бирмәде. Каравыл өе тирәсенә күпләп халык җыелу да, килгән берсенең аңа күзенең агы белән чәнчеп каравы да үрәтникнең эчен пошыра, күңеленә шом сала иде. Үз телләрендә кәлә-мәлә нәрсә киңәшәләрдер бит, шайтан беләмени аларны!? Байтимерне халык күзеннән югалту өчен, шул тирәдәге мунчага илтеп яптырды.

Колгадай озын буйлы каравылчы Әүхәди карт аңа иске толып калдыгы сузды, үзенчә юатып та чыккан булды:

— Хәзерге сәгатьтә ристан чутында исәпләнсәң дә үзебезнең кеше ләбаса. Мунча җылы, ят та йокла, пешерми ашамаслар, — диде.

Ишекне тыштан бикләп алды да шыгыр-шыгыр килеп мунча тирәсендә йөрергә тотынды.

Каравылчы үзе дә абайламастан Байтимернең иң авырткан урынына бәрелде. «Ристан!..» «Ристан чутында...» Җитмәсә, мыскыл иткәндәй, мунчага китереп тыктылар. Моңарчы Байтимерне һәркайда укымышлы кешеләр белән тиң күрәләр, ул гомер буе китапчылар, мөгаллимнәр, муллалар белән аралашып яши, мәҗлесләрдә иң хөрмәтле урыннарда утыра торган иде. Бу гаделсезлеккә аның ачуы кайный, бөтен җаны-тәне тузына, бу адәм хурлыгына ул түзеп ятачак түгел иде. Ләкин нишләргә икән соң аңа, нишләргә?!

Бая аңа күзләрен мөлдерәтеп караган мәдрәсә шәкертләре, аны шатланып каршы алучы йөзләрчә бүтән балалар күз алдына килде. Әнә ул гөнаһсыз сабыйлар да, бөтен авыл халкы да аны болай мыскыллауларына рәнҗиләр, алар да Байтимер яклы, аннан нидер көтәләр кебек тоелды.

Гәрчә аны тотып утыртучы урәтник булса да, Байтимер аңа ул кадәр ачу тотмый иде. Кайсы яктан гына уйлап караса да бу афәтнең җеп очы һаман да шул кичәге Уразгилде картына барып тоташа, шул мөртәт исенә төшкән саен Байтимернең тешләре кысыла, үзеннән-үзе йодрыклары йомарланып килә иде.

Каравылчының түземлеге озакка җитмәде. Әйләнә-тирәдә бер-авык килеп сарып йөрде дә мунчага кереп кулларын угаларга тотынды. Байтимер алдында яхшатлы булыр өчен генә микән, урәтниккә төрттереп алды.

— Әй, йөри шунда кеше азаплап! — диде.

Байтимернең зиһене чуалган, аның хәтта үзен-үзе күрәсе килми, киеменнән тәмәке сасысы аңкып торганлыктан, Әүхәди керүен дә өнәп бетерми иде. Ул ләүкәгә сузылып яткан килеш селкенеп тә карамады.

Әүхәди «уф-уф» дигәләп ишек төбенә чүгәләде, тамагын кыргалады да, Байтимернең дәшмәвенә эче пошып, тагын сөйләнеп алды.

— Син алай бик артык нитмә... хафаланма, башыңа бәрмәгәе...— диде.

Әүхәди үзенең ни җитте бәндә түгел, укымышлы кеше икәнлеген сиздерү өчен, кайчандыр мәдрәсәдә башына кереп калган китап сүзләрен кыстырырга ярата иде.

— Син фәһемле бәндә, шаять беләсеңдер, адәми зат әлмисактан[1] бирле берсен-берсе талап яши. Мәдрәсәдә чакта укыдым, хан заманында булган хәлләр. Бүтәннәрдән акыллырак, сәләтлерәк кеше килеп чыга икән, аңа элек-электән көн күрсәтмәгәннәр. «Син адәм нәселеннән түгелдерсең, фәрештә затыннан булсаң кирәк. Бәс, шулай булгач, сиңа үз асылыңа кайту лазим булыр» дип, акыл ияләрен асып куя торган булганнар. Әйтәм бит, борынгыдан ук шулай килә.

Байтимер каравылчыга берникадәр гаҗәпләнгәндәй игътибар беләнрәк карап куйды. Карасана, юкка гына китап сүзләрен кыстырмый икән. Мәдрәсәдә укуы бушка китмәгән икән ләбаса! Куян бүрек астыннан күңел түренә салырдай акыллы гына сүзләр чыга бит! Аның Әүхәди сүзенә ышанасы килсә дә, үз халкы турында начар уй йөртергә күңеле рәнҗи иде. Ләкин тормыш тәҗрибәсе шул кабахәт гадәтне раслый түгелме соң? Бер-береңнән көнләшү, көнләшү, әләкләү гомер буе аның теңкәсенә тиеп килгән иң явыз чир ләбаса! Аның гынамы тагын?! Каһәр төшкән кара әләк менә аны икенче мәртәбә төрмәгә утырта бит инде!

---

[1] Әлмисактан бирле — бик борынгыдан бирле.

Әүхәди исә үзеннән-үзе бик канәгать иде. Шул арада ул бик һәйбәтләп җылынып алды. Хикмәтле сүзләр сөйләп «ристанның» күңелен күтәрде... Чыгарга дип таягын кулына алгач Байтимергә карап беравык икеләнеп торды. Байтимер башын калкытып:

— Нәрсә? — дип сорады.

— Чәйләп килергәе дә исәп... Син ничек?.. Иншалла дигәндәй... ул-бу дигәндәй... булмас ла?!

Байтимер ләүкәдән төшеп Әүхәдинең каршысына килеп басты.

— Хәзергә исәп юк. Әйтимме кайчан «ул-бу буласын?!» Мунчада йоклатсагыз!

Каравылчы шаккатып сүзләрен әйтә алмыйча торды.

— Тефү, тефү! Авызыңнан җил алсын! Син бит мине Себер җибәрттерәсең! Үз дин кардәшеңне!

— Әгәр дә мәгәр Себер китәсең килмәсә, мине бу сасыда йоклатмыйсың. Алай кардәшкә дә санагач!..

Каравылчы мескенләнеп кулларын җәеп җибәрде:

— Ай аллам! Соң мин нишли алам? Түрәләр фәрманы бит!

— Бар да әйт түрәләреңә: мунчага ябарга берәүнең дә хакы юк! Монда йокларга мин мунча пәрие түгел, мин — кеше! Кеше!

Әүхәди арлы-бирле борылгалый торгач, ишек тоткасына үрелде;

— Мәйлең. Әйтеп карыйм алай булгачыннан. Тульке син зинһар...— диде.

— Бар, бар! Кайгырт!

## VI

Каравылчының аяк тавышы тынуга тәрәзә кинәт караңгыланып китте. Байтимер борылып караса, бая каравыл өендә Казан яклары турында сорашып утырган теге чибәр егет икән. Ул тәрәзәнең бер өлгесендәге кырындыкны алды да эчке якка кечерәк кенә төргәк сузды.

— Абзый, менә инәй сиңа ризык җибәрде,— диде.

Җанга якын бу ягымлы сүзләрдән, әллә кайдагы чит-ят кешеләрнең туганнарча кайгыртуыннан Байтимернең бөтен барлыгы куаныч белән тулды. Ул тәрәзә өлгесенә иелде.

— Ай, егет, мең рәхмәт сезгә! Үзеңә дә, әниеңә дә. Исемеңне дә белмим бит әле!

— Заһит мин, мөгаллим улы. Безнең эти күрше авылда укыта.

— Мин сине каравыл өендә үк ошаттым. Күрәм, батыр егет икәнсең.

— Бәй, моңа әллә ни батырлык кирәкми. Менә, зерә дә күңелсез килеп чыкты бит әле. Кайда япканнар? Чиялеләдә япканнар... Бөтен авылга хурлык!

— Нишлисең бит, анысы сездән түгел.

Бераз ак-ягына каранып алганнан соң Заһит тагын тишек тәрәзә өлгесенә иелде.

— Абзый, мин ишетеп тордым: урәтник сине Минзәләгә җибәрттермәкче, чын өтерменгә.

Байтимер монысын ук көтмәгән иде. Ул «әһ» дип ыңгырашып куйды.

— Чәнчелеп кенә киткән икән! Үзе әйттеме?

— Үзе. Стражниклар килеп алыр, — диде.

— Кайчан?

— Анысын әйтмәде.

Аһ, егетләр! Байтимер моңарчы эшнең алай зурга китәчәгенә бик

үк ышанып та бетми, урәтник былтырдагы шикелле шулай бераз өркетер дә җибәрер дибрәк уйлый иде. Ә хәзер?.. Коточкыч булып ристан тормышы күз алдына килеп басты. Аның ярты башын кырып алалар да, ристан чикмәне кидереп, аягына-кулына богау салып караңгы җир астына ташлыйлар. Аның колагына хәтта чылтыр-чылтыр иткән богау тавышы да ишетелгәндәй булды. Авылыннан да аералар, китапларыннан да, Бәдриҗамалыннан да!.. Ул беравык зиһене чуалып башын учлап утырды. Ни өчен? Коточкыч гаделсезлек иде бу. Нахак, нахак!

Теге егет тә шуңа борчыла. Ул нидер әйтергә кыенсынып торды да тагын тәрәзәгә иелде.

— Байтимер абзый, әллә ниме... тәвәккәлләйсеңме? Чын өтермәнгә барып капканчы дим?

— Ничек?.. Нәрсәгә тәвәккәлләргә?

— Нәрсәгә дип... чыгасың да таясың. Тәрәз алына.

Байтимер беравыкка тынып калды. Аның ялкынлы уйлары кайнап-кайнап сулыш эчендә бер ноктага бәреп чыктылар. Тәрәзә өлгесе бушлыгында Заһитка аның түгәрәк сакалы күренде.

— Булмый, туганкай, булмый. Мин угры түгел, юл да басмадым... Мине утырткан кеше үзе чыгарсын, законный итеп.

— Ай-һай, абзыкай, ай-һай!..

Бу абзыкайның холкы бер ягы белән Заһитның атасы холкына да охшаган иде. Аның менә шулай кышкы бураннарда чана тартып китап сатып йөрүендә фидакарьлык, изге җанлылык, батырлык бар. Заһит атасы шикелле үк бу да акча өчен йөрми. Аның китапка, гыйлемгә шундый тирән мәхәббәте Байтимергә зур ихтирам тудыра иде. Заһит башын чайкады.

— Белмим, белмим, урәтник чыгарыр микән? Теге Уразгилде карты бик яман пычраткан бит! Патшага каршы уй йөртә, опасный сүзләр тарата дип әләкләгән.

— Шундый сүз йөримени?

— Урәтник старостага тишкән.

Байтимер көрсенеп куйды.

— Шулайдыр, әләк ашый булыр минем башны. Өрми торса, этнең башы авырта ди бит.

— Нәкъ инде, нәкъ!

— Юк, шулай да аңа тыңлап этне хурларга ярамый. Эт андый бәндәдән юньлерәк. Ул беркайчан да үзенең тамагын туйдырган кешегә тими. Котырган эт бу! Үз халкына ташлана!

Тәрәзә өлгесенә килеп Заһит тагын пышылдап алды.

— Төнлә мин сине Сөннең аргы ягына чыгарып куярмын. Эти әйтә, анда урәтникләр азрак, ди. Башкорт даласы киң.

— Ә аннан ары нишләргә?

— Арытабатын шахта ягына чыгып китәрсең. Җәмәгатеңне шунда алдырырсың...

Әмма Байтимернең мондый кырын эшкә һич аягы тартмый, ул гаделлек белән ерып чыгарга өметләнә иде. Ничек итеп? Менә анысын ул үзе дә анык кына белми, уйлана гына иде әле.

— Юк, энекәш, бигайбә. Минем авылым, йортым-җирем, яхшы исемем бар. Үземне-үзем пычратасым килми,— диде.

Шулай бер-берсенә карашып уйлашып торганда тыкрыктан узган юлчыларның атлары пошкырганы, чаналары чыжылдаганы ишетелде. Байтимер кинәт кенә, башына нидер килеп тилпенеп куйды.

— Карале, Заһит! Баядан бирле бертуктаусыз юлчылар узып тора. Кая бара шулар?

Заһит:

— Минзәлә ярминкәсенә! — дип пышылдады.

— Алар Уразгилде аркылы узалармы?
— Әйе, Минзәләгә шуннан барышлы.

Байтимер тыкрыкка караган килеш озак кына уйланып утырды. Теге кире беткән әләкче картның кабәхәтлеге берәзлексез җанын кыйный иде. Аны хәзер хәтта үз язмышы да ул кадәр борчымый башлады. Ни булса шул! Әмма ул каһәр төшкән бәндәнең халыкка шул кадәр зарар салып та һичбер җәзасыз калырга тиешлеге берничек тә башына сыймый иде. Бу нинди коточкыч гаделсезлек! Күпме кешенең тормышын агулаган, моннан соң күпме яшь укытучының башына җитәчәк! Юк! Ярамый болай, ярамый! Томаларга авызын, томаларга! Сабак булсын! Нишләргә кирәген ул бая ук уйлап куйган иде инде. Шул фикерен ныгыткандай үзалдына кискен генә:

— Шулай! — диде дә Заһитка сузылып үтенечен әйтте:

— Син, энекәш, миңа ап-ак чаршау, я булмаса, бик зур җәймә алып килә алмассыңмы, ә?

Егет ни әйтергә белмичәрәк аптырап калды. Байтимер тәрәзә тишеге аша аның беләген кысты.

— Син миңа ышан, энекәш, ышан! Ярыймы? Бик кирәк, изге эшкә кирәк!

Заһит ул әйбер аңа качар өчен кирәктер дигән фикергә килеп баш какты:

— Ярый, булды гына! — диде дә китеп тә барды. Бераздан ук әйләнеп тә килде. Тәрәзәне алып Байтимергә зур гына бер төргәк сузды.

— Уйлап бетердең инде, әйеме? — диде.

Байтимер үзалдына көлеп алды. Хәйләкәр елмаеп сакалын сыйпаштыргалады:

— Уйладым. Тик синеңчә барып чыкмый бит, энекәш. Үз аягым белән зимагурлыкка чыгасым килми,— диде.

Заһит моны китапчының тәвәккәлләргә йөрәге җитмәүдән дип аңлый иде.

— Әйтсәм әйтим, Байтимер абзый, муенчак салганда баш иеп тору да егетлек түгел бит! — диде.

Байтимер көлеп җибәрде. Аның «Их, сине! Минем баштаниләр барын белмисең бит син!» дип әйтәсе, күңелендәгесен ачып бирәсе килде. Ләкин ярамый иде.

— Качып китү батырлыкмы? — диде.

Егет пошынып торды да янә бер җанланып алды.

— Алайсам, эти кайткач, приговор җыябыз! Бөтен халык сине коткаруны үтенеп кул куячак!

Ул приговор дигәннән берәр мәгънә чыгармы, юкмы, анысын алла белсен. Әмма бу егетнең менә шулай ихлас күңелдән кайгыртып йөрүе үзе генә дә зур юаныч иде. Байтимер бөтен кайгыларын онытып Заһитның кулын кысты.

— Мәңге онытмам, энекәш, балаларыма сөйләп калдырырмын. Егетнең асылы икәнсең,— диде.

Заһит саубуллашып китеп барды.

Бая башына килгән уе Байтимерне шулкадәр мавыктырды, ул хәзер чыгып киткәнче каравылчының килеп җитмәвен генә тели иде.

Заһит китүгә Байтимер җәһәт кенә аягын киенеп алды, чаршауны туны эченнән биленә бәйләде, билбавын кысыбрак урады. Тиз генә тыштагы яктылыкка күз салды. Кояш бер ягына борылып, икенде-ахшам вакыты җитеп килә икән. Аңа озак маташырга ярамый, тагын да тоткарланса, Уразгилденең ясту намазына соңга калачак иде.

Инде чыгып китәм дип тәрәзәгә үрелгәндә, каравылчы килеп кермәсенме? Нишләргә? Байтимер эченнән сүгенеп арлы-бирле йөренергә тотынды. Ул каравылчыны:

— Я, ничек? — дип каршы алды.

Әүхәди таягын сөяп кулларына өрергә керешә.

— Староста әйтә, «бер кичкә — кер мичкә», бер төнгә генә түзсен инде, ди.

Байтимер кинәт усалланып, кулларын бутый-бутый Әүхәдине кысырыкларга тотынды.

— Юк, әйтмә дә, тыңламыйм да, монда кунмыйм да! Незаконный бу! Бар әйт: булсын миңа җылы өй, булсын чиста урын-җир, ашау-эчү! Хәзер үк, шушы сәгатьтә үк!

Каравылчы нидер әйтергә теләгән иде, Байтимер аның аркасыннан этеп чыгарып җибәрде.

— Бар, бар, бар! Әнә анда кич булып килә. Кырыкка ярылсыннар, илла мәгәр тапсыннар!

Әүхәдинең чыгып йөгермичә хәле булмады. Байтимергә исә шул гына кирәк тә иде. Ул юлга чыгар алдыннан сәкегә утырып кулларын күтәрде. Ләкин мунчада корьән сүзен әйтергә ярамавы исенә төшкәч, үз-үзенә хәерле юлны күңеленнән генә теләде.

Тәрәзәнең кадакларын йолкып алу бер минутлык эш иде. Тышка чыккач, тәрәзәне яңадан үз урынына утыртты. Мунчага ышыкланып як-ягына каранды. Әңгер-меңгер вакыт иде, урамда беркем дә күренмәде. Ярминкәгә баручыларның берсе Байтимерне авыл чыкканчы ук чанасына утыртты.

## VII

Башмак бүлмәсендә чабатасын салып оекчан гына баскычтан менеп барганда Байтимер мәчет эченә колак салды. Фарыз бүлмәсендә [1] ачы, нечкә тавышлы шәкертнең корьән укыганы ишетелде. Байтимер үзенең бик вакытлы килеп җитүе турында уйлап алды. Корьәнне бит намазның ахырында гына укыйлар.

Байтимер намаз укучыларның иң арттагы сафына килеп тезләнде. Моның бик соң килүенә күршеләре гаҗәпләнебрәк карап алдылар. Әмма Байтимернең моңа әллә ни исе китмәде. Чөнки өс-башларына караганда, болар берсе дә бу авыл кешеләре түгел, ярминкәгә барышлый кунарга тукталган сәүдәгәрләргә охшаганнар иде.

Михрабның ике ягында берәр утырмалы лампа гына яна, мәчет эче ярым караңгы иде. Шулай да Байтимер, күзләрен уйната торгач, Баһаветдинне тиз тапты. Ул иң беренче сафта, нәкъ мулла артында утыра иде. Карт башына ап-ак чалма ураган. Күрәсең, ул бүген мәзин вазыйфасын үти торгандыр, чөнки шәкерт корьән укып бетергәннән соң мулла вәгазь әйтү өчен мөнбәргә күтәрелгәндә аңа таягын Баһаветдин алып бирде.

Вәгазь Байтимернең бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты. Ул күңеленнән план корып утырды. Мәзин урынына калгач, Баһау картка утларны сүндереп, иң арттан мәчетне бикләп чыгарга туры киләчәк бит! Байтимергә исә нәкъ шул гына кирәк тә.

Менә вәгазь дә әйтелде, мулла белән корьән укучыга сәдака биреп битләрен дә сыпырдылар. Шуннан соң намазчылар акрын гына, вәкарь белән генә ишеккә таба кузгалдылар. Баһаветдин күзенә чалынмас өчен, Байтимер башмак бүлмәсенә алдан ук төште дә караңгы почмакта чабата киндерәсен бәйләгән булып матаушты. Картлар, үзара мыдыр-мыдыр сөйләшеп, мәчеттән шактый озак чыктылар. Байтимер, шул арада, лампага арты белән борылып, чаршауны чишеп алды, җыерылган урыннарын сыпырды. Аннары борын тишекләренә

[1] Фарыз бүлмәсе — мәчетнең михраблы, мөнбәрле иң эчкәрге зур бүлмәсе.

мамык-тыкты, бияләйләрен кесәсенә яшерде. Аның тамагы кибә, аз гына куллары калтыранып куя иде. Ни әйтсәң дә хәтәр эшкә тәвәккәлләде ул! Чит-ят җирләр, ә ул берүзе. Андый-мондый әләгеп куйса, аңа исән-имин котылулар, ай-һай!.. Әмма Байтимер ул фикерне кире кагып үзенә-үзе башын селекте. Юк, ул гаделлек белән бара, аның кылачак гамәле дөрес булачак. Тик картлач йөрәге ярылып ычкынып кына куймасын! Ә аңа картның арт сабагын укытмыйча ярамый. Әйе! Күз — куркак, тел — батыр, тел үзенекен эшләр.

Ниһаять, картлар чыгып бетте. Баһауның өстәге бүлмәләрдә утлар сүндереп йөрүе ишетелде. Менә ул, мәчет җеннәрен качырыр өчен, әдәпле генә тамак кыргалап кыштыр-мыштыр башмак бүлмәсенә төште. Менә, бисмилласын әйтә-әйтә, алдына карап кына киез катасын киде, стенага эленгән бердәнбер лампаны сүндерде. Инде чыгам гына дигәндә, ишек янына пәһлуандай зур гәүдәле бер ап-ак нәрсә килеп басмасынмы!

Баһаветдин тыны кысылып баскан урынында тораташ булып катты. Аның башына коточкыч уй килде: «Җен! Мәчет җене!..» Куркуыннан аның йөрәге тасырдый, тезләре калтырый башлады. Күзләре акайды. Коты чыгып, сүз әйтә алмыйча, тотлыга-тотлыга «э-э-э!..» ди-ди кырын-кырын ишеккә таба атлады. Ләкин ак шәүлә канатын җәеп аңа аркылы төште. Баһаветдиннең бисмилла әйтеп таяк белән орырга ниятләве булды, таягы шалтырап караңгыга очты. Ул да түгел, әлеге зат кул урынына ак канатларын күккә күтәреп, морҗадан чыккандай калын тавыш белән тыңкышлап моны гарәпчә кяфер, хинзыр, фасыйк дип каргарга тотынды. Баһаветдин салкын тиргә батты. Мөселман җене корьән телендә чучка, имансыз, бозык җан дип сүгә икән, харап эш! Кая инде ул рәхим-шәфкать, кая инде ул теге дөньяда җәннәтләр! Өске катлауларда Баһаветдиннең бәясе ничегрәк йөрүен белмичә килгәнмени ул!..

Ләкин йа мәүла, йа Мөхәммәт! Бу нинди тамаша! Әлеге җен татарча да белә икән ләбаса! Канаты белән ишарә итеп Баһаветдингә:

— Сәҗдәгә егыл! — дип үкереп җибәрмәсенме! — Әҗәлең якаңнан тотты! Тәүбә кыл!

Баһаветдин ни үле, ни тере идәнгә ауды. Тик шунда аның башына яңа уй килде. Җен түгел бу, фәрештә! Газраиль фәрештә! Җен булса, тәүбә иттереп маташыр идемени? Баһаветдин яткан җирендә үлә язып ашыга-ашыга:

— Илаһым, гөнаһларымны ярлыка! Тәүбә, тәүбә, тәүбә! — дип ыңгырашты.

Ләкин Газраиль моңа гына канәгать булмыйча, ачулы тавыш белән гарәпчә нидер укынды да бөтен мәчетне гөрелдәтеп янә аваз салды:

— Гөнаһларыңны атап әйт!

Баһаветдингә бөтен мәчет фәрештәләр белән тулган кебек тоелды. Өстәге бүлмәләрдә, баскычларда фәрештәләр «Газраиль» әйткәнне кабатлыйлар, шуңарга күрә аның авазы шулай яңгырап ишетелә, алар Баһаветдиннең җанын алып китәргә көтеп торалар. Баһаветдин бу дөньядан тәмам өметен өзде. Теге дөньяга барлык гөнаһларыннан арынып, сабый балалардай гөнаһсыз килеш китеп барырга ниятләде. Маңгаен идәнгә орып чын күңелдән гөнаһларын әйтергә тотынды.

— Языкларым бихисап... йа, хода! Тәүбә, тәүбә! Минзәлә базарында кысыр сыерны буаз дип алдап кыйммәт бәягә саттым. Ярлыка, ходаем!

— Тагын?

Бөтен мәчет эче «Газраиль» артыннан:

— Тагын!.. Тагын! — дип кабатлады.

Baһавeтдин мескен тавыш белән, ишетелер-ишетелмәс кенә ялваруын дәвам итте.

— Тәһарәтсез намаз укыдым, әллә ничә тапкыр... Мәчеткә килгәндә таеп егылам да тәһарәтем сына... Тәүбә, тәүбә, ярлыка ходаем!

Газраиль ягыннан мәче пырхылдагандай сәер тавыш ишетелеп китте. Ләкин ул тәһарәтнең ничек сынуы белән артык кызыксынмады. Баһавeтдиннең иң авырткан җиренә килеп кагылды:

— Әләкләреңнән тәүбә ит, хаин!

Баһавeтдин сыкранып: «Аһ, аллам! Әле анысын да беләләр икән» — диде, үзен-үзе кызганудан елап җибәрде.

— Тәүбә,тәүбә! Телемне тыя алмадым шул, каһәр суккан телемне...

«Газраиль» тагын да дәһшәтлерәк итеп:

— Әйт, кемнәргә яктың ифтира! [1] — диде.

— Мөгаллимнәргә... Намаз өйрәтәсе урынга шигырь җырлаталар дип...

— Тагын?!

Баһавeтдин китап сатып йөрүчене күрше авылда тотып ябулары турында ишеткән иде. Ул торган саен тирәнгәрәк бата баруын аңлап, котылудан бөтенләй өметен өзде.

— Гөнаһлы, гөнаһлы! Китапчыны әләкләдем... Урәтниккә.

— Аһ, явыз! Мәлгунь! Нәрсә дип?!

— Патшага тел озайта дип, хәтәр китаплар сатып йөри, дип.

Фәрештәнең рәнҗүдән уһылдап куюы, хәтта иДәннәр шыгырдавы ишетелде.

— Иманың кая? Намусың кая? Үз туганнарыңның башына җиткәнсең бит! Гөнаһсын кая куярсың?!

Баһавeтдин-мөрит тетрәнеп куйды. Аның күңелендә үзе кул биргән ишанга рәнҗү тойгысы кузгалды. Һәммәсенә ул гаепле, ул, аның кәсафәте! Үз кадерен үзе белеп ил агасы булып түрдә генә утырасы урында, ишан сүзенә мөкиббән китте Баһавeтдин, башы җитмәгән нәмәкәйләргә килеп кысылды, шуның белән хур булды. Ишан үзе хәзер яшь кәләше белән чүкердәшеп ясту чәе эчеп утырадыр, ә менә аның тугрылыклы мөрите монда «Газраиль» каршысында кан калтырап идәндә ауный! Бик кодрәтле икәнсең, күрсәт менә могҗизаңны!.. Коткар менә хәзер!..

«Фәрештә» түземсезләнеп тагын үкереп куйды:

— Сиңа әйтәләр!

Мөрит идәнгә тагын да ныграк елышып:

— Тәүбә, тәүбә! Әввәлгесе, ахырысы...— диде.

Газраиль кем беләндер киңәшкәндәй авыз эченнән нидер сөйләнде, нидер укынды да кырыс кына тагын дәште:

— Син, алланың гөнаһлы колы, торгыл! — диде.

Көч-хәл белән дерелдәгән аякларына басканда Баһау «Газраиль»гә күтәрелеп карарга коты чыгып торды. Бу күтәрелүгә чалгысын айкап җибәрсә, шуның белән җан тәслим кылачак бу мөрит. Баһау иманын әйтә башлады. Ләкин «Газраиль» фәрештәнең чалгы-мазары күренмәде, селтәнмәде дә. Баһавeтдиннең бәләкәй җаны куанычыннан шашарга җитешеп үрле-кырлы сикерә иде. «Җанымны алмый икән? Әлегә исән калам икән!»

«Газраиль» канатларын хәтәр айкап янә телгә килде:

---

[1] Ифтира — нахак яла ягу.

— Йа, бозык җан! Әҗәлең көтә! Хода тәгалә хозурына барырга хәзер бул! Өч көн, өч төн өеңнән чыкмыйча намаз укып гөнаһларыңнан тәүбә ит! Әләкләреңнән ваз кич! Ярлыкаса, шунда гына ярлыкар сине бер хода.

Баһаветдин котылу шатлыгыннан яңадан «Газраиль»нең аягына егылды.

— Кичәм, ваз кичәм! Белмәдем, күрмәдем, гөнаһсын өстенә алыр хәлем юк диярмен...

Ул кызып китеп «знайт-низнай!» дип тә ярып салмакчы иде дә, фәрештә урысча әллә белә, әллә юк дип икеләнде дә, анысын әйтми калдырды.

Идәннән торса, йа алла! Бу нихәл, ишек янында беркем юк! Якягына борылгалап карады — юк! Бисмилласын, ләхәүлесен әйтеп уңга, сулга тәкеренде — юк!

Баһаветдин үз күзләренә үзе ышанмыйча, кырын-кырын барып тышка атлады. Әмма бусагадан чыгуга абынып егылды. Кабаланып торды да, яңадан капмагаем дигәндәй, артына карый-карый өенә таба йөгерде.

Бу вакытта Байтимер ак чаршауны төреп маташа, тәкъва мөритнең терсәкләрен тырпайтып чатыйк-чотыйк йөгерүен көлә-көлә сөннәт булмасеннән карап тора иде.

## VIII

Авыл йокларга хәстәрләнә иде. Кайбер йортлар утларын сүндереп караңгыга күмелгән, башкаларның кучкарларындагы лампалары тычкан уты кебек кенә елтырый. Урамнар бушап калган. Авыл тыптын, хәтта этләр дә өрми. Мәчеттән чыгып басуга таба юнәлгән җәяүлене беркем дә күрмәде.

Авылдан чыккан шәпкә Байтимер ярыйсы ук кызу кайтты. Бераз талчыкканлык сизелсә дә аның күңеле күтәренке иде. Кулларын селти-селти җәһәт атлап ул үзенә-үзе көлеп җибәрде. Мәче әйтә: «мыяу» дип, күсе әйтә: «мин синнән дә уяу!» дип. Кирәгеңне алдың инде, Баһаветдин. Шул кирәк сиңа, карт ишәк! Йөрмәссең кеше әләкләп, кан бозып!..»

Шулай да ул берәр чакрым киткәннән соң туктап авыл ягына колак салды. Тавыш-тын юк, берни дә ишетелми иде. Хәер, нигә шикләнергә? Баһаветдин алпан-тилпән өенә кайтып җиткәнче Байтимер ярты юлны үтәчәк! Аннары инде Чияле утлары да күренә башлар. Теге ягы да ап-ачык, шоп-шома! Кем күргән? Шайтаным да күрмәгән! Картның башы ике түгел, ул әләгән кире алырга тиеш, дөрес булмаган дип.

Ул әле һаман да тынычланып җитми, теге кире беткәнне ничек акылга утыртуын көлә-көлә исенә төшерә иде. Бәлки аның бу эше бүтәннәргә дә сабак булыр әле. Моннан соң шәкертләр дә, яшь мөгалимнәр дә иза чикмәс, ә ул, Байтимер, үзенең яраткан эшен дәвам иттерер...

Кайта торгач, Байтимер тәмам тынычланып адымын акрынайта төште. Тирә-ягында төн караңгысы белән өретелгән кар басуы, аяк астында кар шыгырдый, күк йөзе йолдыз белән тулган. Аның баш түбәсендәге киек каз юлында йолдызлар, аны күрер өчен үзара кысылышып, бер-берсенә урын бирәләр. Байтимернең әлеге изге эшен белгәнгә шулай күңелле җемелдәшәләр кебек иде. Байтимер бу хыялына үзе үк елмаеп куйды. Мондый чакта башка ниләр килмәс? Әмма аның күңеле шулкадәр хуш, ул үзенең бу гамәленнән шулкадәр канәгать,

аның кем белән булса да шатлыгын уртаклашасы килә иде. Ниһаять, ул иртәгә хатынына язачак хатын күңеленнән әйтергә керешә.

«Сезки гыйззәтлү вә хөрмәтлү хәләл җефетемез Бәдриҗамалга безки чит җирләрдә сәргәрдан булып[1] йөргүче хәләл җефетегез Байтимердән күктәге йолдызлар санынча чук сәлам. Шуның бәгъдендә[2] сүзләргә күчсәк, үзебез саг-сәламәт, әшебез һәм уңайга тәгәрәп торадыр.»

Ул аяк астында кар шыгырдаганны тыңлап бераз уйланып торды. Аның әлеге хәлне читләтеп кенә, киная белән генә булса да хатынына да белдерәсе килә иде. Тик шунда Чиялегә кайтып андагы хәлләрне белмичә алай язарга кулы бармады. Уйланып барды-барды да хатын шулай очлап куярга булды: «Ходай сәламәтлек биреп, бәла-казалардан имин кылса, эшләребезне уң әйләсә, тагын ике-өч атнадан, хут ае кергәч газиз туган ил якларына әйләнергә ниятләнеп торабыз...»

Ул да түгел, Байтимер барган якта күктә ниндидер ут күренә башлады. «Нинди ут? Нәрсә булыр бу?» дип гаҗәпләнеп кайтканда, юлда ат пошкырганы ишетелде, караңгыдан ниндидер карамчык килеп чыкты. Ул зурайганнан зурайды, ниһаять, чанага җигелгән ат булып, Байтимер каршысына килеп туктады. Заһит икән. Чанасыннан сикереп төште дә Байтимернең җиңенә килеп ябышты.

— Абзый, стражниклар килде!

Байтимернең моңа әллә ни исе китмәде. Аңа гаеп ташлаучының авызын томалаганнан соң, ул патша зобаныйлары аны элекке кебек үк өркетми башлаганнар иде инде.

— Килмәгәйләре! Нәплевәйт! Минем итәгем-җиңем җыелган. Күрше авылда кодача бикәмә кереп чыктым әле! — диде, хәле беткәндәй чана эченә ауды. Заһит аның өстенә толып япты. Эштән чыгып арганлыгын Байтимер шунда гына сизде. Күптән татып каралмаган бу рәхәтлек минуты белән аның бөтен барлыгын биләп алды. Йомшак печәнгә сузылган аякларына тамырлары буйлап җылы дулкыннар йөгерде, бөтен әгъзалары йомшап, изрәп төште. Шушы рәхәткә бирелеп ул күзләрен йомды да салмак кына йокы бишегендә тирбәлә башлады. Ара-тирә атның пошкыруы колагына керә, «герт-герт» иттереп тигез генә юыртуы ишетелгәп куя, чалуга төшкәндә чананың юл кырыена бәрелүе генә сизелгәли иде.

Бераздан чана кинәт кырынаеп китте. Заһит бияләйләрен бер-берсенә кагып тавышланып алды.

— Әһә! Менә ул Чуракай юлы! Аннан инде Сөн аша башкорт ягына! Ф-и-и-ть!

Байтимер һаман да йокымсырый иде әле. Заһит исә җилгә аркасын куеп Байтимер ягына сузылып ятты да, аңа котылырга ярдәм итүе белән кәефләнеп, сөйләнергә тотынды:

— Минемчә, абзыкай, Камбаркага чыгарга да Донбасс ягына таярга кирәк сиңа. Анда инде, эшкә урнашкач, җиңгәйне дә алдырырга булыр.

Байтимер кинәт нидер исенә төшкәндәй күзен ачты. Алар Чиялегә кайтып җитәргә тиеш түгелме соң инде? Ат исә шәп кенә түбәнгә таба юырта, җиңелчә генә чана табаннары чыжылдый иде. Байтимер кинәт торып утырды.

---

[1] Сәргәрдан булып — аптырауда калып, йөдәп.
[2] Бәгъдендә — соңында.

— Туктале! Син мине Чиялегә алып кайтмыйсыңмыни?

— Юк, башкортка таба киттек бит...

— Нишләп? Мин бит алай димәгән идем!

— Әти шулай кушты, минемчә, акыллы киңәш! Анда кайттың, беттең!

Байтимер бөтен тәне берьюлы сызлый башлагандай йөзен чытып бөгелеп төште. Аннары кинәт тураеп Заһитка текәлде:

— Стражниклар килде, диденме әле?

— Әйе, икәү. Әзмәвердәй ике күсәк.

— Ә старостаны нишләттеләр?

— Качыргансың диләр, яныйлар, таптыралар.

Байтимер Заһитны ике иңбашыннан тотып селки башлады.

— Соң, шулай булгач? Ни җаным белән качыйм ди мин?.. Әүхәди ничек?

Заһит бераз дәшмичәрәк барды.

— Ничек дип... тотып алдылар.

Байтимер ыңгырашып куйды. Аның күз алдына ямаулы киез итеге, куян бүреге белән озын буйлы, ябык чырайлы Әүхәди килеп басты.

— Их, туган! Ялгыш юлга кердек без. Ярамый болай. Әйдә, бор атыңны!

Егет атын туктатыр-туктатмас бара биреп Байтимергә ялынырга тотынды.

— Соң бит, абзыкай, пычагым да булмый картка! Бераз өркетерләр дә чыгарырлар. Аның каруы син котыласың!

Бу сүз Байтимергә мыскыллаган сыманрак ишетелде. Ул үзенә үзе рәнҗеп:

— Котыласың, имеш! Качыпмы? Үз урыныңа картны яптырыпмы? Юк, булмый алай! Тукта!

Ат тукталды. Ләкин егет һаман да суза иде әле.

— Алайса монысын да әйтим: бу әти киңәше генә түгел, бөтен авыл картлары әйтеп җибәрде: «Бала булмасын, үз аягы белән аждаһа авызына кайтып кермәсен»,— диделәр.

Байтимер гомере буе караңгы авылларга китап ташыды, халыкка гыйлем нуры чәчте. Инде хәзер шул изгелеген үзе үк аяк астына салып таптасынмы? Ул сикереп торып дилбегәгә ябышты.

— Ярар, энекәш, кайгыртуларыңа бик рәхмәт. Тик булмый болай! Кайттык авылга!

Заһит кулын селтәп:

— Их, абзый, тыңламыйсың бит, үз аягың белән бит... — дип сукранды.

Болар кайтып кергәндә, бөтен авыл аякка баскан иде. Мәчет манарасына фонарь менгереп асканнар (Байтимергә кырда шул ут күренгән икән.), урамнар, капка төпләре тулы халык. Заһит атын каравыл өе янына килеп туктатуга, бөтенесе шым булдылар. Халык арасында чыш-пыш килеп: «Тотканнар, алып кайтканнар!» — дия башлаганнар иде, Заһит бер сүз белән авызларын томалады.

— Юк, Байтимер абзый качмаган, йомыш белән генә чыккан! — диде.

Каравыл өенең ишеген ачуга, колакларына ачыргаланып кычкырган ямьсез тавыш ишетелде. Кызарынып бүртенгән стражник,

җиңнәрен сызганып, Әүхәдинең ялангач аркасына «чаж» да «чож» чыбык белән суга иде.

Байтимер бер-ике атлауда стражник белән Әүхәди арасына килеп басты.

— Сукмагыз! Ул гаепле түгел! — дип кычкырды.

Стражник, аның артында гына торган староста, шундагы барлык халык кötелмәгән бу хәлдән кинәт тын калды. Стражник бу качкынны үзе эзләргә җибәргән Заһит тотып алып кайтты дип уйлый иде. Ул исерек күзләрен Байтимергә акайтып, аяк тибеп кычкырды.

— Аһа, каптыңмы, разбойник!? Ят әнә шуның урынына!

Байтимер башын селекте.

— Ятмыйм! — дип карышты.— Сугарга хакыгыз юк! Мин качкын түгел, һава алырга гына чыктым.

— Ха! Нинди кадерле җан!

— Кадерлеме, түгелме, мунчада асрарга мин хайван түгел! Хакыгыз юк!

Стражник ачуыннан төкереп куйды.

— Әле җитмәсә акыл сата! Син, такыр баш, не смей его величества государь-императорның честный солдатына каршы әйтергә! Молчать!

Стражник зәһәрләнеп килеп Байтимернең кулларына богау салды.

— Менә сиңа!

Инде кызыл түшләр дә килде, бакчада эшләкиләр[1] дә сайрый башлады. Өй түбәсеннән көнозын тып та тып тамчылар тама. Бүтән елларны Байтимер нәкъ шушы вакытта кайта торган иде.

Бәдриҗамал ире кайтышка аңа аршины ун тиенлек һәйбәт ситсыдан яңа күлмәк тегеп куйды. Йомырка саткан акчасына Арчадан кара хәтфә кәләпүш алдырды. Ире кайткач ягарга дип мунчасына коры утын кертеп салды. Иренең ерак юлдан исән-имин кайтуы шатлыгыннан аш мәҗлесе уздырырга ниятләп, кибеттән дөге ярмасы, йөзем җимеше, куй мае, бөртекле чәй алып кайтты. Сөенче алучыга бирергә дигән күчтәнәч конфетлары да әзер иде.

Иртәнге эшләрен бетергәннән соң Бәдриҗамал һәр көнне чәчен тарап үрә дә яңа күлмәген киеп ирен көтә башлый. Кыз чагында ук алган көмеш беләзеген, көмеш балдагын кия, Байтимере бүләк иткән фирәзә кашлы алкасын тага да, тәрәзәгә еш-еш күз салгалап, капка келәсе чылтыраганны көтә.

Төшенә дә бик әйбәт керде. Агартырга дип болынга озын-озын итеп киндер җәйде Бәдриҗамал. Иренең ак юлы шулай кергәндер инде. Тып иттереп менә кайтып төшәр, боерган булса...

1978.

≈≈≈≈≈≈

[1] Эшләки — песнәкнең язгы кушаматы. Халыкта аның яз башында сайравына охшатып: «эшләки, эшләки, эшләмәсәң, хаста ки!» дигән такмазасы да бар.

## Шәмси Хамматов,

тарих фәннәре кандидаты.

# СУГЫШТА СЫНАЛГАН ӘДӘБИЯТ

Мин рядовой солдат бу сугышта,
Тик бер нәрсәм белән аерылам:
Рядовойлар төнен йоклаганда,
Мин йокламыйм. Шатлык, кайгылар
Бер минут та башка тынгы бирми,
Окоп почмагында утырам,
Аламын да куен дәфтәремне
Яныл җыр язарга тотынам...

ФАТИХ КӘРИМ.

Шагыйрь Фатих Кәримнең Бөек Ватан сугышының иң кызган чорында — 1942 елның октябрь аенда Хәрәкәттәге армиядән язган бу ялкынлы шигъри юллары беренче мәртәбә «Совет әдәбияты» журналының шул ук елгы 11—12 саннарында басыла. Сугыш кыенлыклары аркасында кайбер республикаларда әдәби журналларны чыгару вакытлыча туктатылып торган чакта да партия Үзәк Комитеты һәм ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты безнең журналыбызга үз эшен дәвам иттерергә булыштылар: татарча басылган бердәнбер бу журнал нигездә совет халкының изге көрәшенә багышланган әсәрләр белән тупланып чыга. Башта өч мең, аннары ун мең данәдә таралган «Совет әдәбияты», Гази Кашшаф әйткәнчә, «сугыш елларында халыкның юлдашы, сердәше, юанычы һәм куанычы булды. Ул аларны фидакарь хезмәткә, дошманга каршы кыю, әрсез сугышырга рухландырды, илһамландырды» [1].

Әйе, язучының, шагыйрьнең матбугатта әйтелгән ялкынлы публицистик сүзе фронтта һәм тылда фидакарь көрәшүче совет халкында җиңүгә ышаныч тудырды. «Кече җир» китабында Л. И. Брежнев матбугатның, язучылар һәм журналистларның шундый эшчәнлегенә югары бәя бирде: «...Солдатлар өчен үз араларындагы шагыйрь тарафыннан әйтелгән туры сүзнең яки гади генә сугышчан листоктагы рәсемнең никадәр әһәмиятле булуы турында да әйтергә телим. Чөнки бу сүз, бу рәсем турыдан-туры аларга төбәлгән» [2].

Сугыш елларында совет әдәбиятының, әдипләрнең, публицистларның халык алдында авторитеты тагын да үсте, аларның күп милләтле укучылар даирәсе белән элемтәсе ныгыды. Бу мәкалә укучылар игътибарына әдәби журналыбызның авыр сы-

---

[1] «Казан утлары», 3 сан, 1972 ел, 156 бит.
[2] Л. И. Брежнев. Кече җир. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1978 ел, 34 бит.

нау елларында каләм осталары иҗаты белән дошманны җиңүгә керткән өлешен барлау максатында бер тәҗрибә буларак тәкъдим ителә.

**1941 ел.** Бөек Ватан сугышы башлангач, «Совет әдәбияты» әдәбият, сәнгать һәм иҗтимагый-политик журнал буларак, үзенең тематикасын бик нык үзгәртә. Моңарчы язучылар тыныч тормыш, оборона мәсьәләләрен яктырткан әсәрләр иҗат итү белән бергә, Мәскәүдә уздырыласы Татар сәнгате һәм әдәбияты декадасына әзерлек алып баралар. Декаданың бай репертуарын булдыру, татар поэзиясе антологиясен төзү, аны рус телендә чыгару, гомумән, ирешкән уңышларны бөтен СССР халыкларына күрсәтү, әдәбиятыбызның бай тарихи мирасын өйрәнү һәм башка бик күп иҗат планнарын тормышка ашыру көн тәртибендә була. Ләкин сугыш, әлеге эшләрне туктатып һәм кичектереп, бөтен көчне Ватанны саклауга юнәлтүне таләп итә.

Язучылар союзы каршындагы иҗат секцияләре урынына Ш. Маннур, Р. Ишморат, К. Нәҗми, Л. Җәләй, Г. Кутуй, Т. Гыйззәт иптәшләр составында агитация-пропаганда бүлеге төзелә. Идеология эшенең иң куәтле учагы булган «Кызыл Татарстан» газетасында һәм радиокомитетта язучылар көче туплана.

Журналның Дәүләт оборона комитеты Председателе И. В. Сталинның радио буенча ясаган чыгышы басылган июль саны тышлыгына «Ватан өчен!» исемле плакат төшерелгән. Аның астында В. Маяковский сүзләре:

> **Җир шарында**
> **эшчеләрнең лозунгысы**
> **Бөтен җирдә**
> **болай булсын:**
> **Фашистларга сөйлә**
> **янгын теле белән,**
> **Пуля сүзе,**
> **штык үткенлеге белән!**

Шул ук санда Ш. Камалның «Без җиңәчәкбез!» дигән публицистик мәкаләсе, М. Җәлил, Ә. Исхак, Г. Кутуй шигырьләре урын алган. Аларга кыскалык, сугышчан үткерлек хас. Илнең барлык иҗади көчләре дошманны җиңүгә тупланган булуын белдереп, Шәриф Камал болай яза: «Фән эшчеләре, инженер-техника көчләре, язучы һәм сәнгать эшчеләре үзләренең иҗат һәм хезмәт көчләрен шуңар юнәлдерәчәкләр... Без үзебезнең эшебез хак икәнлеккә нык ышанабыз. Бездә гаделлек, бездә хаклык... Дошманны тар-мар китереп, җир йөзеннән юк итү өчен бездә бөтен шартлар җитеш. Әлбәттә, без җиңәрбез!»[1]

М. Җәлилнең «Дошманга каршы» шигырендә гитлерчыларга үч-нәфрәт, җиңүгә ышаныч уты дөрли:

> **Юк бу илдә урын илбасарга,**
> **Үз башына төшәр хәсрәте!**
> **Туплар булып ява явызларга**
> **Халкыбызның ачы нәфрәте**[2].

Бераз соңрак Шәйхи Маннурның «Туган ил өчен»[3] дигән шигыре инде очучы татар егете Исмәгыйльнең һавада дошманга каршы аяусыз көрәшүе һәм бер сугышта батырларча һәлак булуы турында сөйли. Нур Баянның «Үч бөркет»[4], Әхмәт Фәйзинең «Бүре» походы»[5], Әхмәт Исхакның «Ике сугышчы»[6] шигырьләрендә, Салих Батталның «Әкият һәм тормыш турында баллада»сында совет солдатының сыгылмас характеры ачыла. Муса Җәлил шигъриятендә дә шундый үзгәреш кичерә. Журналның 11 нче санында аның октябрьда язылган өч шигыре («Окоптан хат», «Госпитальдән», «Каска»[7]) бирелә.

---

1 «Совет әдәбияты», 7 сан, 10 бит.
2 Шунда ук, 11 бит.
3 Шунда ук, 8 сан, 6 бит.
4 Шунда ук, 7 бит.
5 Шунда ук, 9 сан, 12 бит.
6 Шунда ук, 13 бит.
7 Шунда ук, 12 сан, 10—12 битләр.

**Ил!**
**Алдыңда синең мин ант итәм,**
**Шаһит булсын кулым ярасы.**
**Гитлер явын тар-мар итми торып,**
**Якты күрмәс күзем карасы,**

— дип яза шагыйрь. Һәм, билгеле булганча, ул шушы антына ахырынача турылыклы булып кала.

Сугыш көннән-көн кызып, революция бишеге — Ленинград куркыныч астында калгач, шагыйрьләр яңа әсәрләрен Ленинградка багышлыйлар.

**Анда безнең кайнар каннарыбыз**
**Кояш нуры өчен түгелгән.**
**Анда безнең титан кулларыбыз**
**Зур заводлар, йортлар төзегән,—**
**Бирмәбез без Ленин каласын!**

— ди, мәсәлән, Ш. Маннур («Бирмәбез!»).

Г. Бәширов, К. Нәҗми, Г. Кутуй, М. Әмир, Г. Әпсәләмов һәм башка әдипләрнең язмаларында ил тормышын сугыш хәленә күчерү проблемалары сурәтләнә. А. Алиш август аенда хәрби частьтан «Дошманга каршы» (ашыгыч сызмалар) исемле әсәрен яза. «Без,— ди ул,— туган илебезне ерткыч дошманнардан сакларга дип килдек. Бу изге бурыч. Бу бурычны намус белән үтәү өчен без бердәм күтәрелдек» [1]. Моны А. Алишның татар матбугатында чыккан соңгы әсәре дияргә мөмкин.

Яңа шартлар һәм яңа тема художество чараларының да яңаларын таләп итә. Һәм бу чорда, мәсәлән, патетик проза, ягъни шигъри проза — нәсер жанры тагын да зуррак үсеш ала. Мәгълүм ки, жанр буларак, нәсер татар әдәбиятында Октябрь революциясенә чаклы ук формалаша. Утлы көннәрдә язучылардан Ш. Мөдәррис, Г. Кутуй, Г. Бәширов, М. Максуд, Ә. Еники, И. Туктар һәм башкалар үз нәсерләре белән матбугатта актив катнаша башлыйлар. Нәсер элементлары башка язучыларның очерк, хикәяләрендә дә ачык күренә. Менә Мирсәй Әмирнең «Тагын да зуррак бәйрәмгә кадәр»[2] дигән хикәясе. Анда колхоз шоферы Фатихның яратып йөргән кызы Тәнзилә белән никахлашырга әзерләнүе турында сөйләнә. Әмма яшьләрнең өмете тормышка ашмый кала — сугыш башлана, туйны дошманны җиңгәнгә кадәр кичектереп торырга туры килә. Хикәянең пафосы бөтен совет халкының уртак омтылышын чагылдыра.

1941 елгы хикәяләрдә бер үзенчәлек игътибарны үзенә җәлеп итә. Ул — тынычлык һәм сугышны капма-каршы куеп күрсәтү. М. Әмирнең әлеге телгә алынган хикәясе, Г. Бәшировның «Сержант Хәйруллин», Г. Кутуйның «Яшен», Г. Галиевнең «Сугыш вакытында», Р. Ильяснең «Минем авылдашым» әсәрләре гадәттә тыныч, бәхетле тормыш күренешләре белән башланып китә дә, аннары дәһшәтле сугыш көннәрен сурәтләү алгы планга чыга.

«Совет әдәбияты»нда драма әсәрләре дә басыла. Алар нигездә сугыш темасына багышланганнар. Бу яктан Таҗи Гыйззәтнең «Серле казна» (яки «Ил агасы!»)[3], «Таймасовлар»[4], Риза Ишморатның «Дошман лагеренда»[5], Мирсәй Әмирнең «Йөрәк уты»[6] пьесаларын шактый уңышлы сәхнә әсәрләре дип атарга мөмкин булыр иде.

**1942 ел.** Журнал укучыларына кыенлыклар алдында баш имәгән, социалистик җәмгыятьнең өстенлегенә ышанган, совет Ватанына җаны-тәне белән бирелгән совет кешесе образы гәүдәләндерелгән күп кенә яңа әсәрләр тәкъдим итә.

[1] «Совет әдәбияты», 10 сан, 24 бит.
[2] Шунда ук, 7 сан, 13 бит.
[3] Шунда ук, 8 һәм 9 саннар, 28—36, 63—76 битләр.
[4] Шунда ук, 10 сан, 32 бит.
[5] Шунда ук, 8 сан, 37—42 битләр.
[6] Шунда ук, 9 сан, 46—58 битләр.

Ибраһим Газиның «Кышкы кичтә»[1] һәм «Ана»[2] хикәяләрен алыйк. Алар дошманга нәфрәт тудырырлык итеп язылган. Образлар укучы күңеленә тирән үтеп керә. Уңай һәм тискәре типларның әдәби эшләнеше гаять төгәл. Беренчесендә, мәсәлән, фашист ефрейторы — кабахәт, ерткыч — хәтта бишектә яткан сабый баланы, мич башыннан да төшә алмыйча яткан карчыкны үтерүдән үзенә «тәм, күңел рәхәтлеге» таба.

Шагыйрьләр дә киң полотнолы лирикага күчә — поэмалар, балладалар, ягъни эпик әсәрләр дә шулай ук фронтта, ут эчендә языла.

Хәертдин Мөҗәй — Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтта командир. Аның алгы сызыктан җибәргән шигырьләре әледән-әле журнал битләрендә урын ала. Сурәтләре туплар гөрселдәве астында сызылган конкрет вакыйга һәм кешеләр аша ул үз тойгыларын белдерә:

**Әй, шагыйрь, бел, син сөйгән ил — изге җир ул,**
**Кара тап төшмәс аңар, ул каралмас, ул азат,**
**фәкать азат.**
**Тамды яшем туфрагыңа, синең өскә, туган ил!**
**Антым ул синең исемеңә, бөтенләй**
**синеке мин**[3].

Шактый гына материалларның азагына «Хәрәкәттәге армия» дип куелган. Әхмәт Ерикәйнең фронтка барып шундый адресат белән язган ике очеркы игътибарга лаек. («Уңышлы разведка» һәм «Геннадий Гобәйдуллин», 11—12 саннар.) Советлар Союзы Геройлары Салават Кәримов белән Гыйният Гобәйдуллин батырлыгына багышланалар алар. Журналда гитлерчыларга каршы аяусыз көрәшүче батырларның фоторәсемнәре белән басылалар.

Габдрахман Әпсәләмов та «Көндәлек дәфтәремнән» дигән язмаларында сугыш вакыйгаларының җитез агышын, аның кайнар сулышын укучыга тәэсирле итеп җиткерә.

А. М. Горький төрле милләт культуралары казанышларын алмашуда тәрҗемәгә һәр вакыт җитди игътибар биреп килгән иде. «Әдәбият мәсьәләләренә килгәндә мин шулай уйлыйм, — ди ул 1928 елда, — безгә иҗади казанышларны алмашу эшен җайга салырга кирәк. Грузин язучылары үз кульязмаларының тәрҗемәләрен Мәскәүдә рус телендә бастырырга тиешләр. Әрмәннәр дә, татарлар да шулай эшләсеннәр. Рус язучылары да кульязмаларын Тифлистә, Харьковта, Казанда һ. б. милли телләрдә бастырырга тиешләр. Шулай үзара тәҗрибә алмашу, һичсүзсез, берберең белән һәрьяклап якынаюга һәм ныграк танышуга булышыр»[4]. Шул хакыйкатьне истә тотып, Татарстанның матбугат органнары СССРдагы төрле милләт халыкларының рухи казанышларын пропагандалауга зур әһәмият бирәләр. «Совет әдәбияты» журналы да бу яктан үзенең пропагандистлык, арадашчылык ролен эшлекле үти. Сугыш елларында журнал битләрендә «Ватан сугышы эпизодлары» дигән рубрика белән күп кенә рус һәм чит ил язучыларының сугыш каһарманнары турындагы тирән эчтәлекле очерк, хикәя, публицистик язмалары һәм мәкаләләре бирелә. Аларга документальлек, оперативлык хас. Мәсәлән, Н. Вирта «Партизаннар», Ф. Сетин «Батырлык», В. Иванов «Политрук И. Веремей», К. Смирнов «Большевик», Э. Виленский «Политрук Кемал Касумов» дигән язмалары белән чыгыш ясыйлар. В. Вишневский, А. Сурков, В. Кожевников, Т. Тэсс, Б. Полевой, Н. Тихонов, Жиованни Жерманетто, Проспер Мериме, Эрнест Хемингуэй кебек әдипләрнең чыгышлары журналның дәрәҗәсен аеруча нык күтәрә. Илья Эренбургның «Кеше ашаучылар «фәлсәфәсе» дигән публицистик мәкаләсен, «Фашизм юк ителергә тиеш» дигән рубрика астында Эптон Синклер, Теодор Драйзер, Жан-Ришар Блок язмаларын[5] укып, сугыш чорында аларның нинди иҗат планнары белән яшәвен, фашизмга каршы ничек көрәшүләрен белергә мөмкин. Гитлерчыларның ерткычлыгын фаш иткән әсәрләр арасында Жан-Ришар Блокның «Фриц Мюллерның карьерасы», Бальдер Ольденың «Ерткычлар», А. Исбахның «Партизан улы» дигән очерклары, И. Эрен-

[1] «Совет әдәбияты», 4 сан, 17 бит.
[2] Шунда ук, 5 сан, 19 бит.
[3] Шунда ук, 1—2 саннар, 18 бит.
[4] В. Имедадзе. «Горький Грузиядә», Тбилиси, 1958, 108—109 битләр.
[5] «Совет әдәбияты», 8 сан, 1941 ел, 43—60 битләр.

бургның «Нәфрәт» исемле публицистик мәкаләсе аерым урын алып тора. Автор фикеренчә, совет халкын җиңәргә мөмкин түгел. Шуңа да мәкаләдәге «Безнең тормышка мәхәббәтебез ничаклы зур булса, нәфрәтебез шул чаклы көчлерәк», дигән сүзләр укучыда теләктәшлек хисе уята.

**Сөйләр сүзләр бик күп алар**
**Иренмичә сөйләсәң.**
**Озын сүзнең кыскасы шул,**
**Күп яшәргә теләсәң:**
**Үлем турында уйлама,**
**Илең турында уйла.**
**Илең турында уйласаң,**
**Гомерең озын була**[1].

Әсәрләрнең әнә шулай көн таләбе югарылыгында булырга тиешлегенә журнал битләрендә әледән-әле басым ясала. Рецензияләрдә, әдәбият мәсьәләләренә багышланган мәкаләләрдә исә әсәрләрдәге кимчелекләр күрсәтелә, аларны бетерергә, кабатламаска кирәклеге әйтелә. Л. Җәләй («Ватан сугышы чорында татар совет әдәбияты»[2]), Ф. Хөсни («Сугыш лирикасы»[3]), Хәсән Хәйри (Х. Хәсән, Х. Уральский псевдонимы белән), («Патриот анты», «Ашыгыч язылган әсәрләр»[4]), Г. Иделле (К. Нәҗминең «Атакага» дигән шигырьләр җыентыгына рецензия[5]) әдәби хәрәкәт үсешенә кагылышлы мәсьәләләр белән чыгыш ясыйлар. Шулай итеп, әдипләрнең актив катнашы белән журналның «Тәнкыйть-библиография» бүлеге дә бу чорда шактый җанлана төшә.

**1943 ел.** Совет — Германия фронтында сугышлар барышында Германия империалистларының Советлар Союзы халыкларын кол итүгә исәпләнгән авантюристик планнары тулысынча җимерелде. Совет халкы җиңүгә ышанып яшәде, сугыш кырында тарихта тиңдәше булмаган батырлыклар күрсәтте. Болар һәммәсе журналда чагылыш табып килә.

Прозаны алыйк. Г. Бәширов, Ф. Хөсни, И. Гази, Г. Кашшаф, Х. Госман, Р. Ишморат, А. Расих һәм башка әдипләр борын-борыннан курку белмәс халкыбызга мәдхия җырлаганнар. 1943 ел әсәрләрендә тагын данлы Рус җирен немец-фашист илбасарлардан тазарта бару шатлыгы, гасыр афәтенә каршы шул Рус иленең бар халкы бердәм күтәрелүе калку итеп күрсәтелә.

Менә М. Әмирнең март аенда язган «Юлбашчы кушканча»[6] дигән очеркы. Кызыл Армия — иң кешелекле, халыкчан армия. Ул — халыкларга бәла-каза, афәт түгел, бәлки азатлык алып килүче, халыкны яклаучы гаскәр. Оккупацияләнгән авылшәһәрләрне фашистлардан коткару өчен күп милләтле ил сакчылары тиңдәшсез батырлык үрнәкләре күрсәтәләр. Автор илебезне «азат итүдә зур батырлыклар күрсәткән сугышчылар, Ивановлар, Галимбаевлар, Солтанбаевлар, Әминевләр, Хөсәеновлар, Бойченколар... руслар, үзбәкләр, казакълар, чувашлар, грузиннар, татарлар, башкортлар, украинлылар — бөек илнең туганлык семьясында аерылмас дусларга әверелгән батыр Ватан уллары» турында сокланып, рухланып яза.

М. Максудның Советлар Союзы Герое Ф. Фәтхуллин турында «Фәриднең хатлары»[7] дигән очеркында гади очучыдан полк командирына кадәр күтәрелгән батырның уй-фикерләре аның кардәшләренә язган хатлары аша бирелә.

Ил өстенә килгән бәла-казаны Ватанның һәр халкы үз җилкәсендә күтәрде. Күп милләтле илебезнең батыр уллары, бер булып, дошманны кыйный-кыйный Көнбатышка барды. А. Әхмәтнең «Өч егет»[8] очеркында шул агымның бер мизгеле тотып алынган. Татар егете Гыйниятуллин, рус Лебедев һәм үзбәк Нуруллаев бер сәгать буе барган тигезсез көрәштә дошманның 60 солдатын һәм офицерын юк

[1] «Совет әдәбияты», 8 сан, 24 бит.
[2] Шунда ук, 9—10 саннар, 95—106 битләр.
[3] Шунда ук, 4 сан, 76—79 битләр.
[4] Шунда ук, 7 сан, 61—62, 66—67 битләр.
[5] Шунда ук, 63—65 битләр.
[6] Шунда ук, 2—3 саннар, 86—89 битләр.
[7] Шунда ук, 5 сан, 62—65 битләр.
[8] Шунда ук, 7 сан, 47 бит.

итә. Дошманга чиксез нәфрәт хисе, халыклар дуслыгының какшамас ныклыгы әнә шундый җиңүләр китерә. Очерк авторы шул хакыйкатьне раслый.

С. Урайский «Татар халкының батыр улы Зиннәт Шәрәфетдинов»[1], Х. Госман «Яуда танылган егетләр»[2], Ә. Ерикәй «Советлар Союзы Герое Салихов»[3], Г. Әпсәләмов «Наратлар шаулыйлар»[4], Ш. Маннур «Татар офицеры»[5], А. Шамов «Снайпер сүзе», «Җыр тавышы», «Нәфрәт көче»[6] дигән очеркларында Бөек Ватан сугышының утлы сулышын укучы күңеленә оста җиткезә алганнар. Әлеге авторлар алгы сызыктан әдәби очерклар язу белән беррәттән, хикәя жанрын да дошманга каршы көрәш коралы итеп файдаланалар. Аларда тыл һәм фронтның, Кызыл Армия белән халыкның бер бөтен булуы ассызыклап күрсәтелә.

И. Гази, М. Әмир, Г. Иделле, Г. Кашшаф, А. Расих, Г. Әпсәләмов, Х. Госман, К. Нәҗми, А. Әхмәт иҗат иткән проза әсәрләре Бөек Ватан сугышы геройларын популярлаштыруда җитди өлеш була ала. Аларның хикәяләре халкыбызның уллары һәм кызлары батырлыгына онытылмас һәйкәл.

Сугыш еллары поэзиясендә актив шагыйрьләрнең берсе — Әхмәт Ерикәй. Аның шигърияте яшьлек дәрте, яшәү яме белән сугарылган.

Журналның июль санында тәнкыйтьче Хәсән Хәйринең «Ялкынлы сугышчы һәм шагыйрь» дигән мәкалә-рецензиясе басыла. Ул М. Җәлилнең «Тупчы анты» дигән китабы турында. «Сугыш башланганнан бирле,— ди Х. Хәйри,— Муса Җәлилнең күп кенә шигырьләре басылып чыкты, аларның күпчелеген окоптан, сугыш кырларыннан язып җибәрде. Аларны без зур канәгатьләнү белән яратып укыдык һәм укыйбыз»[7]. Шунда Җәлилнең «Әйдә, җырым!» дигән ялкынлы шигыре китерелә:

**Аргамагым, әйдә, канатлан да,**
**Җил булып оч сугыш кырына.**
**Җырым утын корыч сөңге итеп**
**Мин күтәрдем хәзер кулыма.**
**Каләмемне салдым юл сумкама,**
**Автоматым тактым аркама,**
**Фашистларга каршы пуля һәм җыр**
**Бил каешымда бергә саклана**[8].

С. Баттал, Ә. Исхак, С. Хәким, Н. Арсланов, Ф. Кәрим, Д. Фәтхи, Ш. Мөдәррис, Г. Хуҗи, М. Ногман, Ә. Юныс һәм башка авторларның шигырь, поэмалары да җиңүгә өндәүче көч булып яңгырый.

**1944 ел.** «Хәзер инде Кызыл Армиябездә гәүдәләнгән чын тормыш һәм яшәү көче һөҗүм итеп алга бара,— дип язды Газиз Иделле үзенең бер очеркында.— Бүгенге көннәр — безнең тантанабыз көннәре, безнең урамдагы бәйрәм көннәре»[9]. Шушындый героик күтәрелеш совет кешесенең монументаль образын тудыруда төп эчтәлеккә әверелде.

Соңгы сулышына кадәр сугышның алгы сызыгында торып иҗат иткән шагыйрь Гадел Кутуй «Без — сталинградчылар» дигән атаклы нәсерендә болай дип язган иде: «Сине саклап калу өчен утка-суга кергән совет баһадирларының исемнәрен кешеләр, изге исемнәргә хисаплап, мактап телгә алырлар. Алар турында, үзләрен һәм үз коралларын данга бизәгән батырлар турында җырлар, дастаннар төзерләр»[10]. Бу юлларда Бөек Ватан сугышының «мәңгелек тема» булуын да, киләчәктәге иҗат юнәлешен күзаллауны да ачык күрергә мөмкин.

Бөек Ватан сугышының баштагы елларында поэзия нигездә «көн кадагына суга торган» декларация-лозунг поэзиясе булып яңгырады. Халыкны көрәшкә туплауда ул нәкъ менә шушы сыйфаты белән реаль көчкә ия була алды да. Әмма сугыш-

---

[1] «Совет әдәбияты», 7 сан, 50 бит.
[2] Шунда ук, 51 бит.
[3] Шунда ук, 9—10 саннар, 40 бит.
[4] Шунда ук, 111 бит.
[5] Шунда ук, 119 бит.
[6] Шунда ук, 123 бит.
[7] Шунда ук, 6 сан, 76 бит.
[8] Шунда ук, 74 бит.
[9] «Совет әдәбияты», 2—3 саннар, 1944 ел, 18 бит.
[10] Шунда ук, 1 сан, 29 бит.

ның җиңүле барышы әдәби хәрәкәттә дә чагылмыйча кала алмады: татар поэзиясендә совет кешесе бөтен бөеклеге белән күрсәтелә башлады, әсәрләренең эпик колачы киңәйде. Әхмәт Фәйзинең «Туу сулышы» дигән патетик поэмасы, Кави Нәҗминең «Фәридә» исемле драматик поэмасы, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким, Мәхмүт Максуд, Зәки Нури һәм башкаларның 1944 елда даими басылып барган шигырьләре татар совет поэзиясенең яңа сыйфатларга баюы һәм төрлеләнүе турында сөйлиләр.

ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты секретаре Ғ. Шәфиков журналда «Татар совет язучыларының бүгенге бурычлары» дигән мәкалә белән чыгыш ясый. Ул сугыш елларында татар поэзиясе үсешенә дә киң туктала. «Фронтовик шагыйрь Фатих Кәримнең «Мәхәббәт һәм нәфрәт» исемле шигырьләр җыентыгы, — дип яза ул, — татар совет батырларының эчке дөньясын, аның тирән патриотизмын һәм дошманга каршы юнәлгән утлы нәфрәтен чагылдыра. Яшь шагыйрь-фронтовик Шәрәф Мөдәррис үзенең шигырь һәм поэмаларында совет сугышчысының батыр образын җанландыра. Аның «Тупчы Ваһап» исемле поэмасы татар халкының сугышчан улында тупланган батырлык сыйфатларын эпик төстә гәүдәләндерүгә омтылуы белән әһәмиятле»[1].

Мәкаләдә шигырь җыентыклары мисалында сугышчан поэзияне, үткен сатираның, көрәшкә дәртләндерә торган агитацион шигырьләрнең сыйфаты уңышлы үсә баруы күрсәтелә; шагыйрьләрнең Ватан сугышы геройларын күләмле поэма, балладаларда яктырта башлаулары әйтелә; Г. Кутуй, С. Хәким, С. Баттал, Н. Баян, Ә. Исхак, Г. Хуҗи, Ә. Юныс һ. б. шагыйрьләрнең сугышчан лириканы баету өлкәсендә нәтиҗәле эшләүләре уңай бәяләнә.

Сугыш ахырына таба татар прозасында чын мәгънәсендә яңару сизелә башлый. Әдипләр сугышның чын асылын, кешеләр арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләрне, аларның рухи дөньясын җанлы итеп гәүдәләндерүдә уңышлы адымнар ясыйлар. Совет кешесенең олы образын тудыруны, шуның аша халкыбызның күркәм сыйфатларын ачып бирүне язучылар төп принцип итеп алалар. Һәм, ниһаять, чынбарлыкны тирәнтен өйрәнеп язылган зур полотнолы әсәрләр күренә башлый. Гомәр Бәшировның соңгарак татар совет әдәбияты классикасына керәсе «Намус»ыннан өзек[2], Гадел Кутуйның «Рөстәм маҗаралары»[3] исемле хыялый романы, Мирсәй Әмирнең «Миңлекамал»[4] драмасы, Әмирхан Еникинең «Бер генә сәгатькә...»[5] дигән хикәясе һәм башка әсәрләр басыла.

«Миңлекамал» драмасы, — дип язды Гази Кашшаф «Патриотизм көче» дигән мәкаләсендә,— сугыш чорындагы колхозчылар массасын объектив гәүдәләндергән художество әсәре һәм ул татар совет әдәбиятының бүгенге юнәлешен характерлавы белән дә әһәмиятле»[6]. Әдәбият белгече әлеге драмада публицистик ялкын яшәвен һәм бу нәрсә әсәрнең политик әһәмиятен көчәйтүен ассызыклап күрсәтте.

Татар культурасының бу елдагы үсешен күзаллаганда тагын бер күңелле җанлануны читләтеп үтү мөмкин түгел: журналда әдәбият мәсьәләләренә кагылышлы бәхәс һәм фикер алышулар да башланып китә. Аны «А. Расихның бер хикәясе турында» исемле мәкаләсе белән Л. Җәләй «кабызып» җибәрә[7]. Фикер алышуга Фатих Хөсни кушыла.

Сүз дә юк, сугыш чоры әдәби хәрәкәтендә иң үтемле формаларның берсе булган очерк жанры 1944 елда тагын да көчлерәк публицистик яңгыраш ала. Фронтовик язучылар Габдрахман Әпсәләмов, Атилла Расих, Гали Хуҗиев, Абдулла Әхмәт, Газиз Иделле һәм башка әдипләр публицистика трибунасыннан аеруча еш чыгыш ясыйлар.

Совет кешеләре җиңүгә якынлашкан чакта совет әдәбиятының яңа баскычка күтәрелүендә ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм Татарстан өлкә партия оешмасының аталарча кайгыртучанлыгы җитди роль уйный. Алар, язучылар иҗатына гомуми бәя бирү белән беррәттән, каләм ияләре алдында торган бурычларны да ачык билге-

---

[1] «Совет әдәбияты», 2—3 саннар, 11 бит.
[2] Шунда ук, 5 сан.
[3] Шунда ук, 6, 7, 8, 9 саннар.
[4] Шунда ук, 7, 8, 9 саннар.
[5] Шунда ук, 6 сан.
[6] Шунда ук, 5 сан, 67—69 битләр
[7] Шунда ук, 9 сан.

ләп торалар. Мәсәлән, ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты бюросы 1943 елның 17 декабрендә «Татарстан совет Язучылары союзы правлениесенең эше турында» карар кабул итә. Анда «Татарстан язучылары хезмәт иляәрен совет патриотизмы, социалистик Ватанга мәхәббәт һәм бирелгәнлек рухында тәрбияли торган әсәрләр иҗат иттеләр. Ул әсәрләр татар халкының милли горурлыгын һәм явыз дошманга — немец-фашист ерткычларына каршы көрәштә батырлыгын чагылдыралар, татар халкы улларының сугыш кырындагы фидакарьлеген сурәтлиләр (Муса Җәлил, Фатих Кәрим, Г. Разин, К. Нәҗми, А. Шамов, М. Әмир, Ф. Хөсни, Х. Госман һ. б. әсәрләре)»[1],— дип билгеләп үтелә. Аннары карарда «аерым татар язучылары (Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, А. Әхмәт) агитация шигыре һәм сатира буенча яхшы әсәрләр бирделәр һәм Ватан сугышы геройларын күрсәтә торган эпик әсәрләр тудыру өстендә эшли башладылар (Ф. Кәримнең «Идел егете», Ш. Мөдәрриснең «Тупчы Ваһап» поэмасы, Г. Разинның «Татар егете»), диелә. Бу әсәрләрнең шактый өлеше Ватан сугышының беренче көннәреннән үк фронтларда көрәшү белән бергә, иҗат эшләрен дә дәвам иттерүче фронтовик-язучыларның әсәрләреннән торалар. Фронтовиклар арасыннан яшь язучылар күтәрелеп чыкты (Ш. Мөдәррис, А. Расих, Н. Арсланов һ. б.)»[2],— дип күрсәтелә.

Шуның белән бергә ВКП(б) өлкә комитеты бюросы бу чордагы татар әдәбиятының җитешсезлекләре барлыгын, татар язучыларының тыл героикасын, республикабыз промышленносте эшчеләре, колхозчылары һәм интеллигенциясе тормышын әле йомшак чагылдыруларын күрсәтә; укучыларны совет патриотизмы, милли горурлык, бөек рус халкы һәм Советлар Союзының башка халыклары белән туганлык һәм сугышчан дуслык, социалистик Ватанга мәхәббәт һәм дошманга нәфрәт рухында тәрбияли торган, художество ягыннан югары сыйфатлы әсәрләр иҗат итүне Татарстан совет язучылары алдына төп бурыч итеп куярга кирәк дип таба[3].

**1945 ел.** Журналның январь санында галим-тәнкыйтьче Г. Халитның «Сугыш һәм шагыйрь» (Шәрәф Мөдәррис иҗаты турында) дигән мәкаләсе урнаштырыла. «Ватан һәм татар халкы өстенә килгән куркынычның никадәр зур һәм коточкыч икәнлеген безнең әдәбият Сталинград һәм Идел өчен булган рәхимсез көннәрдә, безнең җиңүебезнең, ә немецның һәлакәте башлануы булган көннәрдә аеруча тирән хис итте дисәк ялгыш булмас. ... Татар халкы да һәм аның әдәбияты да ул көннәрдә дә бердәм ышаныч — җиңү ышанычы белән яши алды»[4],— дип яза автор.

Совет солдаты илебез калаларын, шул ук вакытта Европа илләрен азат итеп, көннән-көн алга бара. Ул кайларда гына булмасын, үзенең туган җире турында уйлый.

**Венгрия...**
**Синең киң кырларың,**
**Урманнарың бар да танышлар,**
**Чәчәк ата синдә көнбагышлар...**
**Ләкин миндә һаман сагыш бар...**
**Тик шулай да бодай кырларыңны,**
**Татарстан, артык сагындым;**
**Мин сагындым эшчән кызларыңны,**
**Чия бакчаларын авылымның**[5]**.**

— ди Нур Баян «Илем, сиңа!» дигән шигырендә.

Ватан сугышы елларында фронттагы яшь көчләр арасыннан поэтик дәрт, илһам белән әдәбиятка күркәм өлеш кертүчеләрнең берсе — Шәрәф Мөдәррис. Ватанга мәхәббәт һәм фашизмга нәфрәт кебек бөек идеяне байрак иткән хәлдә, бу яшь шагыйрь әдәбиятыбыз каршына куелган иң әһәмиятле проблеманы — татар халкының Бөек Ватан сугышында күрсәткән героизмын чагылдыруны максат итә.

Халкыбызның патриотик тойгыларын чагылдыру Ф. Кәрим поэзиясендә дә көчле. Бөек Ватан сугышы — безнең илебез ягыннан гадел сугыш, азатлыкны яклау су-

[1] «Совет әдәбияты», 2—3 саннар, 8 бит.
[2] Шунда ук, 8 бит.
[3] Шунда ук, 8—9 битләр.
[4] «Совет әдәбияты», 1 сан, 1945 ел, 56—57 битләр.
[5] Шунда ук, 37 бит.

гышы. Шуны тоеп күрәшү үзе алга әйди, дошманга нәфрәтне көчәйтә. Патриот-шагыйрь Ф. Кәрим Җиңү таңында сугышчыларның рухын үстерерлек шигъри юллар иҗат итә.

Фатих Кәрим талантының гөрләп чәчәк аткан чагы Бөек Ватан сугышы елларына туры килә. Шагыйрьнең лирик герое совет сугышчыларының типик образы булып гәүдәләнә, аңарда совет солдатының үлемсез баһадирлыгы чагыла. Әнә шуңа күрә дә сугыш кырында батырларча һәлак булган патриот-шагыйрь «Ф. Кәрим рухына» багышланган шигырендә Әхмәт Фәйзи:

**Минем исемем кайтыр синең янга**
**Җиңү көне белән бер көнне,**
**Кабынып сүнгән ерак яшеннән соң,**
**Соңлап килгән күкрәү шикелле** [1],

— дип яза «Ач тәрәзәң...» исемле шигырендә.

Туган туфрак, туган җир! Ул һәрчак шагыйрьләр, язучылар, композиторлар, художниклар, журналистларның илһам чыганагы, рухландыру көче булып тора. Бу Гали Хуҗиевның фронттан җибәргән шигырьләрендә бигрәк тә ачык чагыла.

**Бер йотым су — безнең язмышның**
**Тормыш булып җиргә килеше.**
**Бер уч туфрак — безнең тормышның**
**Аерылгысыз изге өлеше** [2],

— дип язды ул «Чишмә» шигырендә. Бу чорда язылган шигырьләрендә Гали Хуҗиев та, Ф. Кәрим кебек үк, гражданин, солдат, шагыйрь буларак күз алдына килә.

Сугыш елларында актив язган шагыйрьләрнең берсе — Салих Баттал. Ул журналның 3—4 саннарында «Тын диңгез ярларында» дигән поэмасы белән катнаша. Анда автор совет очучыларының батырлыгын тасвирлый, «мең фашистны дөмектергән өчен коммунист йөрәге»нә дан җырлый.

Утлы еллар поэзиясен оптимистик рухтагы әсәрләр белән баетучылардан М. Садри, Н. Арсланов, Гиз-Эль-Габид һәм башка исемнәрне атарга мөмкин.

Журнал сугыш елларында актив яза башлаган яшь авторларның шигъри әсәрләренә дә шактый урын бирә. З. Нури, С. Шакир, М. Хөсәен, М. Гаяз кебек шагыйрьләрнең әсәрләре, мәсәлән, әледән-әле басыла. Зәки Нури дошман тылындагы белорус партизаннары отрядыннан еш язып тора. «Шәһәрне алгач» дигән шигырендә ул, үз тойгысын белдереп, болай ди:

**Тәүлек узды менә. Кайнар тәүлек!**
**Аның мактанырлык даны бар.**
**Мең йөрәкләр теләгән үтәрлек**
**Җиңү алып килгән таңы бар.**

Прозаиклардан Гариф Галиев үзенең «Олы юл язмышы»нда совет сугышчыларының Польшага аяк басулары, полякларның азатлык алып килүче дусларын шатланып каршылаулары турында сөйли.

Г. Әпсәләмовның «Хәнҗәр» [3] дигән очеркында артиллерист Тәхау Дәүләтшинның, үз-үзен аямыйча, командир гомерен саклап калуы тасвирлана. «Зәңгәр иртә» [4] хикәясендә исә төрле милләт сугышчыларының дуслыгы, шул бердәмлеккә нигезләнгән ныклык ачык күрсәтелә.

Ф. Хөсни хикәяләре тылдагы тормышны, «Фронт өчен!» дип янып-көеп яшәүче колхозчыларны үзәккә алуы белән характерлы. Аның «Хатыннар» [5] дигән хикәясендә татар хатын-кызларының тылдагы фидакарь хезмәте колхозчы Фәсихәт образы аша күрсәтелә.

Батыр сугышчылар турындагы очерк һәм язмалары белән танылган Газиз Иделленең «Минзәлә егете» дигән язмасы кыю разведчик турында. Автор үз героен тыныч тормышта да, кан койгыч сугышта да тасвирлый.

---

[1] «Совет әдәбияты», 3—4 саннар, 54 бит.
[2] Шунда ук, 13 бит.
[3] Шунда ук, 71—72 битләр.
[4] Шунда ук, 30—33 битләр.
[5] Шунда ук, 2 сан, 8—14 битләр.

Журналның 1945 елгы 3—4 нче саннарында Г. Бәшировның тылдагы героизмны тасвирлаган «Намус» романыннан «Җилкенү» дигән өзек басылып чыга. Нәкый Исәнбәтнең «Нур Заһид» дигән драмасы революционер Мулланур Вахитовка багышлана. Биш пәрдәлек драманың беренче пәрдәсе «Совет әдәбияты» журналының 1 санында бирелә. Үткәннәргә борылып карау (драмада 1918 елгы вакыйгалар тасвирлана) бүгенгенең кыйммәтен аңларга, бүгенге казанышларны саклап калырга, данлы традицияләрне үстерергә этәрә.

«Гади итеп кенә түгел, уртача итеп кенә дә түгел, яхшы итеп, дәртле итеп, героик пафосны әдәби чаралар аркылы сеңдереп язарга, Ватан сугышында күренгән геройларга тиң итеп язарга кирәк»[1],— ди Ф. Хөсни «Новелла турында» дигән шактый күләмле мәкаләсендә.

Сугыш шартларында фронтта иҗат ителгән әсәрләр укучыга бик нык тәэсир итә. Шуны раслап, «Совет әдәбияты» журналы аларга шактый төгәл бәя бирә. Ибраһим Газиның «Алар өчәү иде» дигән җыентыгына карата «Гафи» псевдонимы белән язылган Ф. Хөсни мәкаләсендә мондый юллар бар:

«Китапка кергән хикәяләрнең беришесе 1942 елда, ягъни язучының тылда торып фронт турында хыялланган көннәрендә, икенчеләре, хыял чынга әверелгәч, ягъни язучы үзе фронтка барып чыккач язылганнар. Боларның беренчесендә таркаулык, абстракт аң, абстракт төшенчәләр үзләрен бик нык сиздерәләр, икенче төркемдәгеләрдә инде конкретлык, вакыйгаларның һәм хисләрнең җыйнаклыгы сизелерлек дәрәҗәдә көчәя һәм хикәяләрнең ышандыру көче дә бик нык арта»[2]. Бу сүзләрне сугыш елларында журналда басылган бүтән әсәрләргә карата да әйтелгән дип уйларга кирәк.

«Без тыныч төзелеш чорына аяк бастык. Безнең бурычлар тагын да катлауландылар. Батырлыгы белән дөньяны таң калдырган халык язучылардан катлаулы әсәрләр, аның көрәшенә тиң булырлык полотнолар көтә... Бөек идеяләрне тормышка ашыру өчен фронтта һәм тылда гаять зур көрәш алып барган халык шул көрәшнең дөрес чагылышын яктыртуны сорый»[3]. Тәнкыйтьче Гази Кашшаф язган әлеге юлларда бөек Җиңүдән соң ук бөтен кискенлеге һәм җитдилеге белән актуальләшкән заман таләбе аеруча кискен гәүдәләнә.

Әдәбият белгече Гали Халит сүзләре белән әйткәндә, 1945 елның май көннәре сугыш кырларында туп тавышларының тынуын һәм Кызыл Армиянең үзенең бөек тарихи миссиясен уңыш белән үтәп чыгуын хәбәр итте. Кешелек тарихында яңа сәхифә ачылды. Җиңүче халкыбызның барлык материаль һәм рухи көчләренең чәчәк атуындагы яңа, тыныч төзелеш дәвере башланды. Хәзер инде, дүрт ел буена барган искиткеч сугыш вакыйгалары үзләренең бөтен тирәнлекләре белән ачылгач, һәрбер язучы каршында безнең җиңүләребезнең тарихи законлылыгын, батыр халыкларыбызның политик-мораль көчен тирәнрәк һәм тулырак аңлату һәм сурәтләү мөмкинлекләре туа[4].

Сүз дә юк, сугыш елларында язучы каләме штыкка тиң булып көрәште һәм татар әдәбияты, һичшиксез, көчле адымнар белән алга атлады. Бу җәһәттән Гали Халит «Азатлык, дуслык һәм батырлык көзгесе» дигән мәкаләсендә болай дип язган иде: «Бөек Ватан сугышы елларындагы әдәбиятыбыз да илебез халыкларын искиткеч батырлыкларга илһамландырган җиңүгә ышану идеясенең реаль сиземләнүен, кешеләребезнең фронттагы һәм тылдагы эшен, хисси-фикри чынбарлыгын, идея һәм мораль көчебезне чагылдыручы ачык көзге булып торды... Фашизм алып килгән кара үлем куркынычы белән йөзгә-йөз очрашу сугышында... иҗади илһамның нинди бөек эшләргә сәләтле икәнлеген, кыска гына вакыт эчендә, тагын да тулы һәм ачык сиздек»[5].

Героизм — кешеләрнең Ватанга булган мәхәббәтенең иң югары чагылышы. Табигый ки, совет сугышчыларының яу кырында күрсәткән батырлыкларын чагылдыру, олы образлар тудыру әдәби хәрәкәтнең иң олы максатына әверелә. «Халыкларның чит илбасарларга каршы, капиталистик изүгә каршы бергәләп көрәшүләрен

[1] «Совет әдәбияты», 3—4 саннар, 62 бит.
[2] Шунда ук, 83 бит.
[3] Шунда ук, 6 сан, 72—73 битләр.
[4] Шунда ук, 72 бит.
[5] Шунда ук, 65 бит.

бөтен тулылыгы һәм җанлылыгы белән язарга тиешбез, — дип язды Кави Нәҗми. — Бу әсәрләрдә без Бөек Ватан сугышы геройларын, республикабыздагы эшчеләр, колхозчылар һәм интеллигенциябезнең хезмәт батырлыкларын күрсәтергә тиешбез»[1].

Сугыш елларындагы татар әдәбиятында фронт чынбарлыгы тематикасының уңышлы әсәрләре шактый күп. Әмма аларның күбесе, ни генә дисәң дә, фронтовик язучылар тарафыннан «сугыш тынып торган арада» язылганнар, һәм бу әсәрләрдә кешенең эчке дөньясын күрсәтү, эпик тирәнлек җитенкерәми. Бу уңайдан Гали Халит болай дип язган иде: «Татар халкының Бөек Ватан сугышы чорындагы тарихи чынлыгын художестволы итеп гәүдәләндереп калдыруда беренче ашыгыч яки кисәкчә уңышлы тәҗрибәләр эшләнсә дә, ләкин хәзергә әле монументаль характерга күтәрелеп бирелгән совет солдаты, татар солдаты образы юк»[2]. Җиңү салютыннан соң ук көн тәртибенә куелган бу проблеманың аеруча әһәмиятлелеге Кави Нәҗми, Хәсни Кәрим, Фатих Хөсни[3] мәкаләләрендә дә ассызыклап әйтелде.

Яңа шартларда туган яңа бурычларны үтәүгә, җиңүче халыкка лаек образлар иҗат итүгә утларда сыналган татар совет әдәбияты көчләре җиң сызганып керешә. Совет кешеләре тормышындагы бөек үзгәрешне бөтен киңлеге, тулылыгы һәм тирәнлеге белән ачарга омтылуда партия һәм хөкүмәтебез кайгыртучанлыгы язучылар өчен нык таяныч булды.

«Совет әдәбияты» журналы фронтта татар сугышчылары яратып укый торган басмаларның берсе була.

«Бөек Ватан сугышы елларында,— дип яза Афзал Шамов,— без, фронттагы язучылар, «Совет әдәбияты» журналының һәр санын бик сагынып, зарыгып көтеп ала идек. Безнең өчен бик кадерле кунак иде ул. Аның яңа саны килгән саен көннәр күңелле бер бәйрәмгә әверелә иде дисәм дә, арттыру булмас»[4]. Афзал ага Шамов бер лейтенантның журнал турында әйткән сүзләрен китереп болай дип дәвам итә: «Сугышчылар аны бик кызыксынып, яратып укыганнар, хәтта ул татар сугышчылары арасында хәрби-политик тәрбия алып бару өчен кулланма булып та хезмәт иткән. Сугышчылар аны тылдан, туганнарыннан, әти-әниләреннән килгән хат кебек итеп укыганнар»[5].

«Партия органнарының «Совет әдәбияты» журналын сугыш чорында да саклап калу турындагы карарының, — дип яза ул еллардагы журналның редакторларыннан берсе Гази Кашшаф, — әйтеп бетергесез зирәк акыл белән эшләнгәнлеген тормыш раслады. Аның һәрбер саны,— ди ул аннары,— кимчелекләре булуга да карамастан, теткәләнеп беткәнче укыла, кулдан-кулга күчә, тылдан бик кадерле бүләк төсендә фронтка юнәлә. Хәрби частьлардан махсус соратып алалар, кичектерми, фәлән-фәлән саннарын җибәрегез дип таләп итәләр, әгәр алар сораган саннар барып җитмәсә, шактый каты шелтәле сүзләр белән хат җибәрәләр»[6].

Бөек Ватан сугышының авыр елларында чыккан «Совет әдәбияты» журналы, барлык совет матбугаты кебек, күп милләтле совет кешеләрен Ватанга бирелгәнлек хисендә, социалистик патриотизм рухында тәрбияләүдә Коммунистлар партиясенә зур ярдәм итте.

[1] «Совет әдәбияты», 6 сан, 74 бит.
[2] Шунда ук, 67 бит.
[3] Шунда ук, 73—76, 98—104 битләр.
[4] «Казан утлары», 1972 ел, 5 сан, 129 бит.
[5] Шунда ук, 130 бит.
[6] Шунда ук, 3 сан, 156 бит.

*Журналыбызның бу рубрикасы аша без хөрмәтле укучыларыбызга яңа бер сәхифә — кырым-татар совет шагыйрьләре иҗатыннан үрнәкләр тәкъдим итәбез. Бай фольклор белән сугарылган, зур тарихлы әдәбият вәкилләре үзләренең үзенчәлекле шигырьләрендә Совет Ватанын, социализм тудырган халыклар дуслыгы идеяләрен, безнең бөек чынбарлыкны дәртләнеп җырлыйлар.*

## Черкез-Али

### Мин Октябрь баласы

Ышанырга мөмкин түгел, ышанмыйм,
Син картайдың инде, дустым, дисеннәр.
Елдан-елга күңлем үсә, куанам —
Дуслар мине яшь егет дип белсеннәр!

Чөнки минем йөрәгемдә кайнаган,
Октябрьда яратылган ал кан бар.
Ленинизм рухы белән рухланган,
Җиңүләргә алып барган илһам бар.

Һәр көн җиңү, һәр көн бәйрәм, олы туй —
Картлык ни ул? Китсен таулар артына.
«Мин Октябрь баласымын!» — ди бүген
Карты-яше куанып зур бәхтенә.

Октябрьдан башлап типкән йөрәгем,
Чәчәк аттың олы Ватан хакына.
Һәр бәйрәмдә керәм әле уенга,
Йөрәгем яшь, чал төшсә дә башыма.

### Тыңла, гүзәл

Күзләреңдәй күзләр бар,
Сүзләреңдәй сүзләр бар.
Сөйдем дисәм йөзеңне —
Сиңа охшаш йөзләр бар.

Аптырашка калдым мин,
Алданыпмы алдым мин?
Сөйдемме соң күзеңне?
Әллә татлы сүзеңне?

Тыңла, гүзәл, сүзем хак —
Кашыңа да, күзеңә дә,
Һәм дә татлы сүзеңә дә
Алданмаган идем мин.
Әмма бәллүр кебек чиста
Йөрәгеңне сөйдем мин.

ГӘРӘЙ РӘХИМ тәрҗемәләре

## Әшрәф Шәми-Задә

### Бер тамчы су

«Бер тамчы су нәрсә ул?» — дип
Кимсетеп ялгышмагыз,
Шул бер тамчы — елгаларның,
Диңгезләрнең башыдыр.
Диңгезләрне, дәүләтләрне,
Йөрәкләрне кузгаткан —
Бер тамчы су, бер тамчы кан,
Бер тамчы күз яшедер...

### Сагыш

Ай яктысын таң дип белеп,
Сискәнеп, яр, уяндым.
Баш астымда мендәремне
Син дип уйладым.
Ничә айлар, ничә еллар
Сагышларга камалдым,
Инде сабырым калмады, яр,
Кабындым, яндым.
Гел уемда, гел телемдә,
Күзең зәңгәр, Җәүһәриям!
Үзең төштә, үзең өндә,
Үзең җәүһәр, Җәүһәриям!
Яшь вакытлар ике килми —
Ул бер татлы төш кенә,
Якты күзең, шат йөзеңне
Күрим, гүзәлем!
Гомер язы үтеп киткәч,
Озакламый кыш килә...
Бергә үтсен дип, язларым
Телим, гүзәлем!
Гел уемда, гел телемдә,
Күзең зәңгәр, Җәүһәриям!
Үзең төштә, үзең өндә,
Үзең җәүһәр, Җәүһәриям!

НУРИ АРСЛАНОВ тәрҗемәләре

## Риза Фазыл

### Низамига

Исәнме, Низами, шигърият маһире!
Баш иеп килдем мин мәгарәң янына.
Син гафу ит мине, гашыйклар шагыйре,
Нигәдер, йөрәгем дулкындай кагына.
Кагына, гаҗәеп аһәңле сазыңның
Рухи бер яктысы нурына тулганга;
«Ләйлә вә Мәҗнүн»нәр — без торган гасырның
Тирән, саф мәхәббәт мирасы булганга.
Дастаннар тудырып, кердең син гүрләргә,
Дастандай гел җиңеп яшисең телләрдә.
Тылсымлы җырыңны укыйлар йотылып
Иң бөек, иң ерак илләрдә.
Галәмдә атыңа сүрелмәс дан алып,
Мәңгелек үлемсез җырга син охшыйсың.
Күзләрдә нурланып, йөрәктә урнашып,
Минем халкымның күңелендә яшисең.
Шуңарга яныңда утырам мин менә,
Бу газиз күрешү һич чыкмас исемнән.
Бакчамнан каберең чәчәкләр утырттым,
Баш иям алдыңда үз халкым исменнән.

## Сеитүмер Әмин

### Җивана

Поездлар китерде мине бу җиргә,
Күрдем мин сыныңны монда, Җивана!
Ут салдың, сөеклем, яралы җанга,
Йөрим мин юлларда тик яна-яна.
Бакчамда гөлләрем чәчәк атканнар,
Чүлләрем, су эчегез кана-кана[1].
Исертте дә мине, әсир дә итте
Шомырттай күзләрең, гүзәл Җивана!
Бекабад[2] чүлендә niләр күрмәдем!
Йөземне ялкынлы коры җил өтә...
Син туган туфракта мин бер узгынчы, —
Мин юлчы... Мине зур юллар көтә.

Поездлар китерде мине бу җиргә...
Ялкыннар кабыздың миңа, Җивана!
Йөземне көйдергеч эссе җил өтә,
Узгынчы мин, мине киңлекләр көтә.

---

[1] Кана-кана — сусын кандырып, туйганчы.
[2] Бекабад — Үзбәкстан чүлләрендә төзелгән яңа промышленность үзәге.

## Билал Мамбет

### Ана һәм Ватан

Бетмәгән шикелле кояшның яктысы,
Аналар җылысы йөрәктә төгәнмәс.
Һич кипмәс аналар җанының чишмәсе,
Аналар данына берни дә тиңләнмәс!

Анага җылылык чишмәсе — Тик Ватан!
Ватансыз ананы күрдем мин кинода...
Мескен ул, хәлсез ул, йөзендә беткән кан,
Җаны көл-күмерле, җылысы калмаган,
Әйтерсең янгыннан корыган бер тирәк...
Ананы бәхетле итәргә — ни кирәк?
Уйладым: Туган җир учагы — иң кирәк!

ӘДХӘТ СИНУГЫЛ тәрҗемәләре

## Юныс Тимеркыя

### Вәгъдәсе бар икән...

Ак мәрмәр ташларга уелган
Саф чишмә агадыр чылтырап.
Төбенә чүлмәкләр куелган.
Өстендә ай тора ялтырап.
Чүлмәкләр су белән тулуны
Кыз көтә, бик сылу ул үзе!
Зәйтүннән карадыр толымы,
Ай төсле балкыйдыр ак йөзе.
Ул миңа дөньядан кадерле!
Чү, нинди сагышың бар, иркәм?

Сулары яшь булып түгелде,
Кемгәдер вәгъдәсе бар икән!..[1]

Ә. ГАДЕЛ тәрҗемәсе

[1] Кырым татарларында чүлмәктән су түгү — вәгъдәле кыз булуны аңлата.

Тәүфикъ Әйди

# АТОМНЫ ЙӨГӘНЛӘҮЧЕ

Егерменче гасыр башы. Макс Планк табигатьтә кинәттән сикерешләр ясалу мөмкин түгел дигән мең еллар дәвамында тамыр җәйгән ышанычны тетрәтә. Альберт Эйнштейн әлегә кадәр какшамаслык төсле тоелган пространство һәм вакыт төшенчәләренең чагыштырмача гына төшенчә булуларын исбатлый, материяне «катып калган» энергия итеп таныта. Ирле-хатынлы Кюриләр, Эрнест Резерфорд һәм Нильс Борлар бүленмәс дип кабул ителгән нәрсәнең бүленергә мөмкинлеген, каты җисемнең тотрыклы булмавын, бәлки даими үзгәреш кичерүен ачалар. Күнегелгән чынбарлыкны танып белүдә революция ясала...

Бөек галимнәр һәм аларның гүзәл ачышлары замандашы булган Казан арты крестьяны Шиһабетдин исә дөньяны күзаллауда ниндидер үзгәрешләр булырга мөмкинлеген башына да китерми. Коркачык авылында элек тә күпчелеккә җир җитмәгән, хәзер дә кытлык. Биектау белән Коркачык арасы элек тә егерме бер чакрым булган, хәзер дә. Казанга килеп Иске бистәдә приказчиклыкка яллангач та тирә-якта шаккатырырлык үзгәрешләр күрми ул. Көне байга эшләп уза. Кичләрен егет-җиләп җыйналышса, аулакта «Караурман»ны сузып, туган авылларын искә төшереп, яңа бишмәт яисә тай-фәлән юнәтерлек мая туплау хакында хыяллана.

Эрнест Резерфорд, альфа-кисәкчекләр белән бомбага тотып, азот атомнарын тарката. Коркачык егете Шиһабетдин, Эбрә авылы кызына өйләнеп, башлы-күзле була. Нильс Бор микродөнья законнарын ача, Шиһабетдин исә үзе белгән иң нәни зат — яңа туган баласын тамаша итә. Татар агай-энеләргә бу чорда микродөнья күзәтер өчен махсус приборлар кирәкми — табигать бүләге күз дә бик җитеп тора, шушы ук оптик корал макродөньяга да канәгатьләнерлек тәрәзә ача. Үзе камил, үзе универсаль!

Егерменче еллар. Германиянең Геттинген университеты атом физикасы үзәгенә әйләнә. Гамбург аксөягенең улы Джемс Франк, Бреслау биологының малае Макс Борн кебек дөньяның төрле кыйтгаларыннан җыйналган интеллектуаль балалары атом серләренә сукмак эзлиләр.

Шул көннәрдә Казанның «Транзит» артиле ямчысы Шиһабетдин гаиләсендә өченче бала булып Шәүкәт Ибраһимов дөньяга килә. Аның көннәрдән бер көнне күренекле атомчы галимнәр сафына басачагын бу вакытта берәү дә фараз итә алмый, билгеле.

Тере, хәрәкәтчән, йөгерек карашлы, түгәрәк йөзле малай әле ни бары биш яшьтә генә булса да, кәгазь-карандаш ярата. «Сасу сасасым килә, сабак укыйсым килә», дип ялына торгач, апасы аны үзе белән мәктәпкә алып бара. Шәүкәткә монда бик ошый һәм ул апасына тагын, тагын иярә.

Яз, газиз углым, кара тактаны сыз акбур белән!
Һәм кара күңлеңне ялт иттер ак нур белән!..

Габдулла Тукайның бу шигъри юллары шундый мәһабәт, серле, мавыктыргыч яңгырый ки, биш яшьлек сабый тылсымлы сүзләрнең сихеренә бирелеп, дәфтәр битләрен чуарлый башлый. Менә шулай ул Казанның Ногман мәктәбе дип даны чыккан уку йортына яшьтәшләреннән шактый элегрәк юл салырга өлгерә.

1932 ел. Англиядәге Кембридж университеты галиме Джемс Чэдвик атомы таркату ачкычы булган нәни кисәкчә-нейтронны ача. Тугыз яшьлек Казан малае Шәүкәт исә завод урамындагы иптәшләре белән бергә ике бистә арасындагы алабута урманында өйдән чәлдереп чыккан самавыр морҗасыннан «туп» атып йөри.

1934 ел. Римда итальян физигы Энрико Ферми уран атомын нейтрон белән бомбалап, чылбыр реакциясен ача. Ә дүртенче класс укучысы Шәүкәт Ибраһимов бу вакытта Бакалтай болынында футбол тубы артыннан чаба. Аннары биш җанны туйдыруны ялгызы гына кайгыртkan атасын да аптырашка калдырып, күгәрчен үрчетүче бер көтү дусларын җыеп кайта да табак тулы пәрәмәчне ялт иттерә. Киң күңелле Шиһабетдин абзыйга билбавын кысыбрак буып, улының юмартлыгына сокланырга гына кала!

Казандагы уникенче татар мәктәбендә туган тел укытучы Шакир Нигъмәтуллин Шәүкәтнең апасы Асияне күрә дә:

— Әтиеңә әйт әле, безнең яңа укучыбыз — синең энең бик шаян. Дәрестә астыртын гына шукланып, башкаларны көлдереп утыра,—ди.

Математика укытучысы Кәрим Хәмитов:

— Гаҗәп сәләтле, мин чишә алмаган мәсьәләләргә дә зиһене җитә, — дип шатлана. Аннары ул да: — Тик наянлыгы артыграк менә,— дип өсти.

Үзгәреш сигезенче класска җиткәч башлана. Элек яхшы укуы белән генә күзгә бәрелсә, хәзер инде ул башка яклардан да мактап телгә алына. Комсомолга керә, ВЛКСМ бюросы эшендә актив катнаша башлый, мәктәп стена газетасы редакторы итеп сайлана. Проектлар ясый, Нәриман урамындагы прокат базасыннан тар тасмалы фильмнар алып кайтып, укучы иптәшләренә кино күрсәтә һәм шулай аның киномеханик даны тарала. Бер үк вакытта Кәрим Хәмитов оештырган математика, педагогия институты укытучысы доцент Галиев алып барган физика түгәрәкләренә дә һәвәсләнеп йөри, укытучысына ияреп пединститутка да бара, андагы лаборатория белән таныша. Мәктәптә исә физика буенча тәҗрибәләр уздыруда Галиевнең алыштыргысыз ярдәмчесенә әйләнә. Шул арада артист Сәлих Әхтәмов җитәкчелек иткән үзешчән сәнгать түгәрәгендә биергә өйрәнә һәм, шәһәр ярышларында җиңеп чыккач, осталыгын күрсәтергә Мәскәүгә сәфәр чыгарга әзерләнә.

Совет физигы академик Капица унөч ел буе Кембридж университетында дөньяның иң күренекле галимнәре белән бергәләп тикшеренүләр алып бара. Бу вакытта бистә малае Шәүкәт өйләрендә иң аулак урын саналган лапаста инглиз телен үзлегеннән өйрәнә генә башлый

эле. Атом физикасы исә ургылып алга атлый, төрле ил, төрле милләт вәкилләре казанышлары белән вакытында танышыр өчен телләр белү аеруча кирәкле шартка әйләнә.

Унынчы класс бик яхшы билгеләре белән тәмамлана. Алда — кызыктыргыч юллар. Әмма көтмәгәндә — сугыш афәте. Шәүкәт солдат шинелен кия һәм Оренбург артиллерия училищесендә укый башлый. Тик монда аны тиф бәреп ега. Савыга башлагач, сәламәтлеге ныгыганчы дип, егетне туган шәһәренә кайтарып җибәрәләр.

Дөньяда сугыш уты дөрли. Әле кайчан гына институт аудиторияләрендә, академик лабораторияләр һәм тын кабинетларда гына телгә алынган атом физикасы дәүләт эшлеклеләрен һәм хәрбиләрне кызыксындыра башлый. Атомчы галимнәрне «аулау» башлана. Фашистлар оккупацияләгәч, ватаны Данияне калдырып, Швециягә качкан мәшһүр Нильс Борны, самолетның бомба бүлегенә утыртып, инглизләр Бөекбританиягә алып китәләр. Уе югары материяләр тирәсендә әйләнгән галим, очучының кислород битлеген кияргә кушуын ишетми кала һәм, самолет болытлардан югары ашкач, тончыга башлый. Фашист истребительләре юлны бүлә калса, пилот төшерү төймәсенә басу белән ул үзенең «стратегик кыйммәтле башы» Төньяк диңгезенә олактырылачагын һәм акулаларга азык булачагын, әлбәттә, белми!..



*Рәсемдә: Роальд Сәгъдиев. Шәүкәт Ибраһимов (уңда)*

Язмыш Шәүкәтне нәкъ менә шушы драматик чорда атом физикасы өлкәсенә алып керә.

Сугыш башлангач, СССР Фәннәр академиясенең кайбер институтлары Татарстан башкаласына эвакуацияләнә. Шәүкәт, савыкканчы эшләп торырга дип, әнә шул институтларның берсе шефлык иткән заводка урнаша. Монда урта белемле зирәк слесарь-лаборантка белорус академигы Николай Сирота игътибар итә һәм егеткә үзе дә укыта башлаган Казан авиация институтына керергә киңәш бирә.

1943 елда Мәскәүдә Атом энергиясе институты оештырып, Курчатов, Флеров, Капица һ. б. совет галимнәре төш физикасы өлкәсендәге тикшеренүләрне киңәйткәндә Ш. Ибраһимов КАИда техник фәннәр нигезен үзләштерергә керешә. Чор кырыс, егет үзе дә «алма пеш, авызыма төш» дип ятучылардан түгел. Салкын аудиторияләрдән чыккач, Шәүкәт вагоннардан йөк бушатыр өчен станциягә йөгерә, анда җылынып кайткач, күмер тузаннарын юып төшерә дә кулына дәреслекләрен ала. Шулай итеп югары белем алган егет 1948 елда завод үзәк лабораториясенә эшкә җибәрелә. Лаборатория башлыгы В. А. Воскре-

сенский үз хезмәтенә бирелгән кеше була, озакламый ул кандидатлык диссертациясе яклый һәм Шәүкәтне дә металлар, каты җисемнәр буенча фәнни эш алып барырга дәртләндерә. Бераздан матбугатта Ибраһимовның гыйльми мәкаләләре дөнья күрә. Уңыш белән канатланган Шәүкәт хәзер инде белемен арттыру турында уйлый башлый, 1952 елда Мәскәү корыч һәм эретмәләр институты аспирантурасына керергә карар бирә. Бер урынга биш кеше конкурс тоткан имтиханнарда Казан егете яхшы теоретик әзерлекле икәнен күрсәткәнлектән, имтихан алучы профессор — СССР дәүләт премиясе лауреаты Борис Григорьевич Лифшиц:

— Бик перспективалы егет, — дип белдерә.

Аспирантурага чакыру килү белән сөенче тышка бәреп чыккан Шәүкәт, заводы белән арасы өзелеп бетүгә, нәни чемоданына бер-ике пар эчке кием сала да Казан белән саубуллаша.

Мәскәү. Яшь аспирант монда илебезнең күренекле галимнәре белән йөзгә-йөз очраша, мавыгып Финкельштейн, Уманский, Гуцов лекцияләрен тыңлый һәм төш физикасы өлкәсендәге проблемалар белән якыннан таныша. Ибраһимовның аспирантурада укыган дәвере атом энергиясен файдалануга бәйле төрле сенсацияләргә бай заман була. Ул Мәскәүгә килгән 1952 елны АКШ водород бомбасының атасы Эдвард Теллер өчен Ливермор шәһәрендә беренче класслы термотөш лабораториясе салына. 1953 елны Совет хөкүмәте дөнья җәмәгатьчелегенә үз водород бомбасының барлыкка килүен белдерә. 1954 елда АКШ атом бомбасының атасы саналган Роберт Оппенгеймер водород коралы җитештерүгә каршы хәрәкәт иткән өчен хөкем ителә һәм дәүләт аппаратындагы барлык рәсми вазифаларыннан берьюлы читләтелә. Шәүкәтнең остазлары исә 1955 елда атом энергиясен тыныч максатларда файдалану буенча галимнәрнең Женева халыкара конференциясен оештыруда актив катнашалар. Могҗизалы көчкә ия атом төшен һәлакәт чыганагыннан иминлек терәгенә, бәхет хәзинәсенә әйләндерү хәрәкәте көчәя. Профессор Лифшицка беренче күрүдә үк ошаган Казан егете аның җитәкчелегендә шушы юнәлештә тикшеренүләр алып бара һәм аспирантура чоры тәгәлләнгәнче үк кандидатлык диссертациясен тәмамлый. Гыйльми совет членнары диссертация яклаучы Шәүкәт Ибраһимовның, мавыгып китеп, су буе формулаларны, такта тулгач, стенага яза башлавына ни әйтергә белми аптырап калалар, аннары егетнең кайнар дәрте, әзлекле исбатларына хуплау белдерәләр. Яшь галим 1955 елдан башлап атом энергиясен файдалану буенча Дәүләт комитетының физика-энергетика фәнни-тикшеренү институтында эшләргә тотына. Монда аның инициативалы галим, радиация шартларында тәвәккәл, кыю тикшеренүче сыйфатлары ачыла һәм ул тиздән өлкән фәнни хезмәткәрлектән әле нигез ташлары да салынмаган лабораториянең башлыгы итеп билгеләнә. Союзда шушы типтагы беренче эре тикшеренү үзәген барлыкка китергәндә һәм аның эшчәнлеген җайга салганда, әле фәнни яктан да хәл ителмәгән бик күп проблемалар калкып чыга. Шәүкәт Ибраһимов үз җитәкчелегендәге галимнәр, инженерлар белән берлектә байтак кыен мәсьәләләрне эш барышында ук уңышлы чишеп, нурландырылган радиоактив материалларның үзлеген һәм структурасын тикшерү өчен хәтсез генә прибор, еракта торып идарә итә торган механизмнар иҗат итә.

Халык хуҗалыгының барлык тармакларын үстерү өчен энергия белән коралланy хәлиткеч роль уйный. Менә шуңа күрә безнең илдә электр станцияләре төзүгә даими игътибар бирелә. Нәтиҗәдә 1975 елда электр станцияләребезнең егәрлеге 1940 ел белән чагыштырганда егерме мәртәбә арта.

Әмма электр энергиясенең 85—90 проценты әле һаман казылма органик ягулыкны яндыру хисабына эшләп чыгарыла. Без, электр энергиясен куллану үскән саен, нефть, ташкүмер һәм табигый газ чыгаруны да күбәйтергә тиеш. Ә бит бу продуктлар халык хуҗалыгының бүтән мөһим тармаклары өчен дә бик кирәк. Кызганычка каршы, җирнең органик ягулык хәзинәсе иксез-чиксез түгел, сакчыл тотмасак, ул инде якын киләчәктә үк сарыф ителеп бетәргә мөмкин. Галимнәр моны алдан ук чамалап, энергиянең яңа чыганакларын эзли башлаганнар. Авыр атом төше бүленү, соңрак җиңел элементларның термотөш синтезы процессында гаять зур күләмдә энергия бүленүе ачылгач, кешелек дөньясы җиңел сулап куя. Чөнки, Ибраһимов язганча, «халык хуҗалыгында ягулык буларак водород изотоплары дейтерий, тритий хезмәт иткән термотөш реакторлы электр станцияләрен файдалану дөнья энергетикасы проблемаларын берничә миллион елга хәл итә». СССРда бу юнәлештәге хәрәкәт Шәүкәт килеп урнашкан Обнинск шәһәрендә Җир шарындагы беренче атом электр станциясен 1964 елда эшкә җибәрүдән башлана. Әмма атом энергиясен кулланырга омтылу галимнәр алдына бик күп фәнни-техник табышмаклар китереп куя. Кыйммәткә төшкән кечкенә егәрлекле Обнинск тәҗрибә станциясеннән арзанлы электр энергиясе бирерлек корылмалар салуга күчкәнче, теоретик һәм практик тикшеренүләрнең тулы бер тезмәсен башкарырга кирәк була. Ибраһимов реактор белән циклотронда төш нурланышына дучар ителгән материалларны өйрәнергә карар бирә һәм фараз итү, исәпләү, тәҗрибәләр ясауга баштанаяк кереп чума.

Термотөш электр станциясен эшләтер өчен төп үлчәмнәр — температура, тыгызлык һәм плазманы тоту вакытын идарә ителә торган термотөш реакциясе барырлык дәрәҗәгә җиткерү кирәк. Моның нинди кыен бурыч икәнлегенә ышаныр өчен бер генә үлчәмне атыйк: дейтерий+тритий реакциясе барсын өчен плазма температурасы кимендә йөз миллион градуска хәтле күтәрелергә тиеш. Дейтерий+дейтерий реакциясе өчен исә дүрт йөз миллион градус җылылык таләп ителә!

Менә шундый температуралар булдырыла торган атом казанын кайсы материалдан ясарга? Без белә торган чуен казаннар җылылык мең ярымнан узса эри, өч мең градуста исә кайнап парга әйләнә башлый бит!

Гадәттән тыш кызулык, радиация шартларында материаллар химик, физик яктан нинди үзгәрешләр кичерә? Уңай үзгәрешләрне көчәйтү, тискәреләрен тоткарлау мөмкинлеге бармы?

Шәүкәт Ибраһимов Обнинскида ундүрт ел буе менә шундый мәсьәләләр буенча бу өлкәдә нигез ташы салуга китерә торган эзләнүләр алып бара. Фән дөньясында төш нурланышы белән җисемнәрнең үзара тәэсир итешүләрен, шул чакта җисемнәрнең атом структуралары үзгәрүен өйрәнүче пионер булып танылa һәм 1965 елда бу тармакта беренче докторлык диссертациясен яза. Аның гыйльми хезмәтләре каты җисемнәр физикасы һәм төш физикасы арасында яңа фән барлыкка килүен хәбәр итә.

Ибраһимовның бу чордагы кызыклы һәм әһәмиятле ачышлары эссе лабораториянең эшчәнлеге белән бәйле. Бу лаборатория дүрт бүлектән гыйбарәт булып, анда төрле җисемнәр җөмләсеннән тылсымлы энергияне үзенә туплаган җылылык чыгару элементы да тикшерелә, чөнки аның яну, төрле үзгәрешләр кичерү дәрәҗәсен белү фән өчен дә, практика өчен дә үтә мөһим була. Галимнәрне нурланган чагында җылылык чыгару элементының формасы үзгәрүе, тышчасы уалуы, бүленүче компонентларының хәле, изотоплары составы, трансуран элементларының туплануы һ. б. кызыксындыра.

Эссе лабораториядә тикшеренүләр күп төрле юнәлештә үткәрелә, чөнки ул реакторлар төзүнең тәҗрибә базасына әйләнә. Лабораториягә төрле республика һәм илләрдән белгечләр агыла. Алар монда фикер ишетә, киңәш ала. Ш. Ибраһимов табигатьтә әзер килеш очрамаган, әмма атом техникасы мохтаҗ булган материалны барлыкка китерү юлларын эзли. Медиклар җәнлекләргә чир йоктырып тәҗрибә ясаган шикелле, Шәүкәт тә лабораториядә материалга төрлечә тәэсир итеп карый: басым ясый, нейтрон белән бомбалый, төрле тирәлеккә батыра, пар һәм башка матдәләр белән эшкәртә. Материал чыдамлырак булсын өчен аны чыныктыру чаралары, дәвалау өчен тылсымлы «дару» эзләп, яңадан-яңа сынаулар уздыра. Көннәр, айлар, еллар агышы галимне вакытның кадерен тагын да ныграк белергә, бөтен көчен һәм сәләтен бер юнәлешкә тупларга әйди.

Әмма галим, серле күренешләрне тикшерүгә муеннан кереп чумуга карамастан, якташлары һәм яшьлек дусларына төрлечә булышырга да вакыт таба. Казан егетләре Нәҗип Якупов, Ярулла Сөнгатуллиннарны фән дөньясына кыюрак атлап керергә рухландыра. Аспирант Ярулланың матди хәлләре «мөшкел»леген күреп, үзе диссертация яклагач ук:

— Хәзер мин эшли башлыйм инде, тагын алырмын әле, — дип аңа заманы өчен кадерле мал саналган сәгатен бүләк итә. Иптәшләрен атом өлкәсендәге ачышлар белән таныштырып, гыйльми эшкә һәвәсләндерә.

Ибраһимов фәнни докладларын аның белән бергә эшләүче институт галимнәре генә түгел, күренекле академиклар да кызыксынып тыңлый һәм хуплау белдерә. Төрле гыйльми басмаларда радиацион материалчылыкның актуаль мәсьәләләрен яктырткан, шул тармакта нинди дә булса яңалык ачкан хезмәтләре белән аның исеме ватаныбызда гына түгел, чит илләрдә дә танылу таба.

Эшләнгән эшләре байтак. Әмма аларны кунакка килгән атасы Шиһабетдингә һәм, үзе сырхау булуга карамастан, улының хәлен белешергә юлга чыккан анасына ничек күрсәтергә соң?

— Плазма дигән нәрсә чамасыз кайнар булганлыктан, атом казаны бик тиз туза, — дип аңлата Шәүкәт,—аның эчке ягы тутыга. Аннары радиацион нурлар тәэсирендә уала, яргалана башлый. Нейтрон дигән кисәкчекләр килеп бәрелү аркасында кристаллик төзелеше үзгәрә. Реактор дип атала торган әнә шул казанны чыдамлырак итү юлларын эзлим мин.

«Транзит» әртиле олаучысы Шиһабетдин абзый плазма, нейтрон, радиация дигән сүзләрне бер дә ишетмәгән төсле:

— Егерме ел укып, шул гомердән бирле әле һаман бер юньле казан ясый алмадыңмы? — дип шелтәле сорау ташлый.

Шәүкәт көлемсери, атомнар турында сөйләп, сиксән яшендәге картның башын әйләндерәсе килмәгәнлектән, кулына аккордеонын ала да ата-анасының яраткан җыры «Караурман»ны сузып җибәрә. Шиһабетдин абзый кайчандыр үзенең «шул малайның доңгырдатып утыруларыннан туйдым инде», дип сукрануларын, улының мондый зарлануларыннан соң аккордеонын тотып, лапаска төшеп китүләрен инде күптән оныткан. Ул хәзер рәхәтләнеп Шәүкәтнең җырлавын тыңлый, «Каз канаты», «Башмагым»нарны җиренә җиткереп сыздыруына куана. Юньле казан әмәлли алмаса да, бик үк төшеп калган егет түгелдер әле бу, дип уйлый. Югыйсә, җир кырыендагы әллә нинди Беркли лабораторияләренә кадәр сәфәр чыгармаслар иде!

Илебезнең экономикасы ныгый барган саен, кыйммәткәрәк төшүенә карамастан, яңа атом электр станцияләре төзү елдан-ел үсә.

Атом энергиясен файдалану заманыбызның иң актуаль бурычына әйләнеп баруын бөтендөнья күрсәткечләре дә раслый.

Шәүкәт Ибраһимов та системалы рәвештә катлаулы процессларны өйрәнә һәм, фәндә беренче булып, кристалларның радиацион җимерелү теориясен барлыкка китерүдә әһәмиятле роль уйный торган күренеш һәм закончалыкларны ача. Аның Обнинск, И. В. Курчатов исемендәге Белояр атом станцияләре реакторлары, тиз нейтроннар реакторының җылылык чыгару элементларын тикшерүе атом энергетикасы һәм төш техникасы үсешенә кертелгән җитди өлеш булып тора.

1964 елның декабре. «Москоу Ньюс» газетасы совет галиме Шәүкәт Ибраһимов белән АКШ тикшеренүчесе Джон Вейт арасында барган дискуссия хакында хәбәр итеп, бәхәсләшүчеләрнең фотосын басып чыгара.

1969 ел. Илебезнең радиацион физика өлкәсендәге иң күренекле галимнәреннән берсе булган Шәүкәт Ибраһимов Казагыстанда эшли башлый. 1970 елда ул Казагыстан Төш физикасы институтының директоры итеп билгеләнә һәм республика Фәннәр академиясе академигы итеп сайлана. Аның җитәкчелегендә институт коллективы төш энергетикасында кулланыла торган байтак әһәмиятле материалларның радиактив нурланыш вакытындагы диффузиясе үзенчәлекләрен, нурланышның корычтагы фаза үзгәрешләренә йогынтысын, алюминий эремәләре таркалу тизлеге һәм дәрәҗәсенә тәэсирен һ. б. бик күп проблемаларны тикшерә башлый. Кыска гына вакыт эчендә институтның шактый күрсәткечләре яхшыртыла, радиацион физиканың яңа юнәлешләре буенча эзләнүләргә нигез салына. Шуның нәтиҗәсендә металлик кристаллардагы радиацион бозыклыкларны өйрәнү буенча Бөтенсоюз киңәшмәсе 1977 елда Алма-Атада уздырыла. Термотөш синтезы реакторлары өчен материаллар табу һәм тикшерүгә багышланган 1978 елгы Бөтенсоюз конференциясендә исә Ш. Ибраһимов җитәкләгән институт галимнәре унбер доклад укый. Шунысы да игътибарга лаек, бу гыйльми хезмәтләрнең һәрберсендә якташыбызның фәндәге шәхси табышлары да күркәм өлеш буларак чагылыш тапкан, бу докладлар турыдан-туры аның катнашында язылган иде.

Киеренке фәнни-тикшеренү эшләрен Шәүкәт Ибраһимов оештыру, яшь белгечләр әзерләү белән бергә алып бара. Аның шәкертләре арасында Г. Ганиев, Г. Ибраһимов, К. Фәрхетдинов кебек безнең якташларыбыз да бар, аларның соңгысы кандидатлык диссертациясен якларга да өлгергән инде.

1975 ел, Казан. Туган шәһәрен сагынып кайткан Ибраһимов бала чак дусты Василларга килеп керә. Араларыннан данлыклы галим чыгуына горурланып йөргән йорт хуҗасы, академикның үзен күргәч, аптырап кала: шундый дәрәҗәле зат гади бер эшченең ишеген шакыймы? Бераздан инде ул Шәүкәтнең элеккечә үк шаян, кече күңелле кеше булып калуын күргәч, өстәл тирәсендә мәш килә. Мондый асыл кунак көн дә килми!

— Икенче кайтканда шул завод урамындагы бергә үскән малайлар белән җыелып утырасы иде, — ди Шәүкәт Асия апасына. — Василлар мине, коймаклар пешереп, бик каты кунак иттеләр, сөйләшеп рәхәтләндек. Искиткеч эчкерсез, әйбәт кешеләр.

Ибраһимов кешеләрнең әнә шулай матур якларын күрә белә, шуңа күрә дә аңа иптәшләре һәм танышлары бик тиз ияләшә. Казагыстан Фәннәр академиясе президенты Аскар Кунаев Казан егете белән аралаша башлагач, Татарстан башкаласына ял итәргә дә килә. Бергәләп татар җырларын җырлыйлар, Кабан буйларын гизәләр.

Аннары сүз тагын төш физикасына кагыла. Шәүкәт Ибраһимов җитәкчелек иткән институтка СССР ФА президенты А. П. Александров, Атом энергиясен файдалану буенча СССР дәүләт комитеты председателе А. М. Петросянцлар килү, тикшеренүләрнең яңа программалары хакында киңәшүләр телгә алына.

1979 ел. АКШ эшчесе Эвинс Джефф, Франция фермеры Раймон Пайар нейтрон бомбасын тыю кирәклеге турында үз хөкүмәтләренә мөрәҗәгать итәләр. Казагыстан Фәннәр акдемиясе вице-президенты Шәүкәт Ибраһимов исә төш энергиясен тыныч максатларда файдалану буенча эзләнүләр алып бара. Ул инде бу вакытта матбугатта фәннең өч юнәлеше буенча 150 ләп гыйльми хезмәт бастыруы һәм шуның өчен Хезмәт Кызыл Байрагы ордены, медальләр, Казагыстанның Дәүләт премиясе белән бүләкләнүе, халык депутаты һәм җәмәгать эшлеклесе буларак, илебез сәясәтен билгеләүдә катнашуы белән яхшы мәгълүм шәхескә әверелгән. «Транзит» әртиле олаучысы бөтерелгән кеч-кенә мәйданнан фәннең кыя тавына ургылып менгән академик, зур бер республиканың меңнәрчә галимнәре эшчәнлегенә җитәкчелек итүче фикер иясе — менә кем ул Шәүкәт Шиһабетдин улы Ибраһимов. Бөек Октябрь барлыкка китергән уңай мөмкинлекләр, кайнар омтылыш һәм тырыш хезмәт татар халкының бер улын кыска гына вакыт эчендә әнә шулай сукыр билгесезлектән бөтен дөнья укымышлылары күзенә ташланырлык биеклеккә күтәрде. Ак якалы Европа, көяз галстуклы Америка фәнни-техник революция очкыннары кабынган гасырыбыз башында ниндидер Коркачык крестьяны нәселеннән үзе игътибар белән күзәтәчәк зат чыгар һәм, Чехословакия, Германия, Англия кебек илләрнең менбәренә күтәрелеп, чорыбызның үзәк гыйльми проблемалары хакында төпле сүз алып барыр дип башына да китермәгәндер.

«Шәүкәт Шиһабетдинович Ибраһимовның фәнни эшчәнлеге миңа егерме ел чамасы таныш инде, — дип яза СССР Фәннәр академиясе член-корреспонденты А. С. Займовский. — Бу чор эчендә ул радиацион материалчылык өлкәсендә СССРда юл ярып баручы галимнәрнең берсенә әверелде, гыйльми хезмәтләре чит илләрдә дә киң танылды. Ибраһимовның фәнни тикшеренүләре теоретик яктан гына түгел, практик һәм техник яктан да атом энергетикасы белән төш техникасы өчен ифрат зур кыйммәткә ия».

«Ш. Ш. Ибраһимов җитәкчелегендә үткәрелгән тикшеренүләр атом материалчылыгын өйрәнүгә кертелгән зур өлеш булып тора, — ди икенче бер күренекле совет галиме, СССР ФА член -корреспонденты С. Т. Конобеевский. — Бу тикшеренүләр бер үк вакытта каты җисемнәр физикасы өчен дә җитди әһәмияткә ия, чөнки бу өлкәдә дә нурланыш күләменә карап тимер һәм вольфрам челтәре параметрларының монотон булмаган үзгәрешләре, феррит-перлит корычларының нейтрон белән нурландырылганда микроструктурасы үзгәрү кебек күп кенә факт һәм күренешләр беренче тапкыр ачылды. Тулаем алганда Ш. Ш. Ибраһимовны металлчылык, металл физикасы өлкәсендәге күп кенә гыйльми мәсьәләләрне уңышлы чишкән олы галимнәрнең берсе, оста оештыручы һәм фәнни тикшеренүчеләр коллективы җитәкчесе итеп санарга кирәк».

Якташыбыз Шәүкәт Ибраһимов бүген әнә шул үзе күтәрелгән югары мәйданнан зур дәрт белән яңа үрләргә таба атлый. Аның иң татлы хыялы һәм бердәнбер зур максаты — кешелек дөньясын кояш хәзинәсе шикелле миллионнарча елга җитәрлек куәтле энергия чыганагы белән кораллаңдыру. Прометей хупларлык һәм үз рухи омтылышларына лаек санарлык теләк!

**Фатих Хөсни**

# ОРЛЫКЛАР КАЯ ТӨШӘ...

*Этюдлар*

## Шәһәр чите, кешеләр...

Жәяү йөрергә яратуым белән бер мактандым кебек инде. Мәгәр машиналы кешеләргә тамчы да үпкәм юк, йөри бирсеннәр. Әмма тормыш ваклыкларын күзәтү, әтәчне тавыктан аеру, кибәргә элгән керләрнең ни дәрәҗә чиста юылган булуларына карап хуҗабикәләренең уңганлыкларын беркадәр чамалау өчен, әлбәттә, күбрәк җәяү йөрү, ашыкмыйча йөрү, күренешләргә күңел күзе беләнрәк карый йөрү файдалырак. Машинада выжылдап кына узганда күп нечкәлекләрне аеру мөмкин түгел. Һәм тагы бер шарт: күбесенчә шәһәр читендә йөрергә кирәк. Шәһәрнең үзәге ыгы-зыгылы, анда кешеләр кабаланыбрак чабалар, чапмаганнары зур-зур өйләргә, таш «тартмалар»га яшеренгәннәр, күренсәләр дә бизәнебрәк күренергә яраталар. Ә шәһәр читендә, бигрәк тә элеккедән калган кечкенә-кечкенә агач өйләрдә яшәүчеләрнең нужасы, өмете уч төбендә...

Моннан егерме еллар чамасы элек минем «Шәһәр читендә» дигән хикәям дөнья күрде. Аннары русчага да тәрҗемә ителеп, «Огонек» журналында да басылды. Хикәя зур түгел һәм ах итәрдәй әллә ни вакыйгасы да, алдынгы дип санарлык кешеләре дә юк. Гап-гади кешеләр, гап-гади шәһәр чите. Хикмәт: үзем аеруча яратам шушы гап-гади хикәяне. Яратам, ләкин очрашуларда, күп кешеле аудиторияләрдә укый алмыйм. Чөнки ул настроение хикәясе, язылышы, эчке моңы ягыннан күп кеше алдында уку өчен түгел, бер генә кеше, сеңдереп кенә уку өчен язылган.

Чү, нишләп әле мин үз хикәямне үзем күккә чөя башладым. Максатым: аның «орлыгы» ничек төшүе, ничек аның «шытып», тишелеп чыгуы турында сөйләү иде ич.

...Әйе, бу болай булды. Үтеп барам шулай бер көнне Подлужный урамыннан. Якшәмбе көнне. Әлбәттә, җәяү. Күрәм: урамның бер ягында керосин цистернасы туктаган, аның тирәсен төрлесе төрле савыт тоткан кешеләр чорнаган, күбесе хатын-кыз. (Әле ул елларны газ дигәне шәһәр читендәге искедән калган кечкенә-

---

Ахыры. Башы журналның 5 нче санында.

кечкенә йортларга хәтле үк барып җитмәгән иде). Әйткәнемчә, күбесе хатын-кызлардан торган шул керосин чиратында, уртада, сузгә кысылмыйча гына, озын буйлы бер ир кеше басып тора. Озын, какча гәүдәле, кара тутлы кеше. Күренеп тора: ашык-пошык кына җыенып чыккан. Аягында өйдә генә өстерәргә ярый торган, җәмшәеп беткән чүәк, башында, аның да нәкъ түбәсендә, әлегер-әләкмәс кенә ремесленный малайлары кия торган фуражка, «РУ» билгеләре. Янындагы хатын-кызлардан ике башка югары калкып күренгән бу «РУ» абзый шунда ук минем игътибарымны җәлеп итте. Читтәрәк кенә туктап, мин бу абзыйга бер мәл карап тордым: гади күренә бу кеше, ләкин гадәти түгел. Шунда ук күңелдә фараз кылулар башланды. Әлбәттә, бу нинди дә булса бер тол ир булса кирәк. Юкса керосин чиратына болай кабаланып үзе чапмас, ничек итсә итәр, хатынын җибәрер иде. Әлбәттә, баш чүмеченә генә чәпәгән әлеге «РУ»лы кепка аның үзенеке түгел, һөнәр мәктәбендә укучы малае бар булса кирәк. Әле берәү генә дә булмавы мөмкин. Әгәр, әйтик, телеграф баганасы кебек шөкәтсез озын шушы адәм ялгыз баштан берничә бала үстереп азапланса? Чыгынкы яңак сөякләре, өсте-башының бик алай «байларча» булмавы, бигрәк тә башындагы «РУ» минем игътибарымны нык кына биләде; юк, гадәти «телеграмм» баганасы түгел бу, ватылган-сугылган, ләкин әлеге дөнья куудан туктамаган нужалы ир булса кирәк... Подлужный урамыннан, керосин цистернасы янынннан алып киткән беренче тәэсирем менә шул булды. Бу әле, әлбәттә, хикәя түгел, ләкин күңелемнең кайсыдыр бер яшертен почмагында урын алды: моннан хикәя чыгуы бик тә мөмкин.

Һәм, ниһаять, минем фантазиям эшкә кушылды, башланды әкренләп төенләнергә. Әйтик, ул ялгызбаш дөнья көтүче урамның бу башында яши, ди. Ник әле ул урамның аргы башындарак шундый ук мәшәкать белән тормыш алып баручы, балалар үстерүче,— икенче берәү, ялгыз тол хатын, әйтик, Хәдичә дигән хатын булмаска тиеш монда?

Хәдичә һәм Котбый («Телеграмм» баганасының исеме шулай) бер-берсен якынтын беләләр, көнкүреш нужасы аларның икесен дә бер якка таба сыккан. Шунлыктан аларда бер-берсенә карата күңел җылылыгы, шәфкать һәм ихтирам хисе бик нык саклана! Ләкин шуннан да ары китәргә күңелләре «рөхсәт» итми, чөнки белеп торалар: вакытлары инде узган, инде икесе дә төс салганнар, ояны ташламаска, балаларны үстерергә булганнар. Ләкин шулай да тоялар: аларга шушы керосин чиратында булса да очрашкалап тору тел белән әйтеп булмаслык ниндидер эчке рәхәтлек бирә. Берсе икенчесенең керосинга кайчан киләчәгенә хәтле үк: бу турыда үзара сүз булмаган сурәттә дә, әллә кайдан белеп торалар. Керосин кирәк булса да, булмаса да, Хәдичә киләсе көнне Котбый килә, киресенчә, Котбый киләсе көнне Хәдичә алдан ук чиратка килеп баскан була.

— Минем бүген үк бугазга килеп терәлмәгән — ди Хәдичә Котбыйга якынлаша төшеп. Аннары кызара төшеп болай дип тә өсти,— тәҗел генә барасы җирем дә бар, басыгыз, Котбый абый, минем урынга. Һәм үзенең чираттагы урынын Котбыйга калдырып китеп бара.

Шулай үтә айлар, шулай үтә еллар... Һәм бер көнне, искәрмәстән генә Котбыйның инде бөтенесе белеп бетергән, бөтен Подлужныйга мәгълүм керосин савытын күтәреп, әлегәчә берәүгә дә таныш булмаган, күрер күзгә үк чая күренгән бер хатын килә. Чиратсыз-нисез ырып-ерып үтә, савытын керосин җибәрүченең борын төбенә китереп төртә.

— Торасы килгән кеше тора бирсен, минем вакытым юк! — ди ул китешли, әдәп саклап үз чиратын көтүче хатыннардан мыскыллы көләп.

— Ай-яй-яй! Кергән Котбый абзыйның комганы кулга! — дип шаяртып әйтеп куя чиратта торучы яшьрәкләрдән берсе. Барысы да кычкырып көләләр бу сүздән. Тик арада бер хатын гына — тик Хәдичә генә көлми. Хәдичәне бу минутта икенче гамь биләп алган. Хикәяне мин болай очлыйм: «...Хәдичәне аптыратып калдырган нәрсә бәтенләй икенче: ничек торыр мескен Котбый ул усал хатын белән? Котбый үзе торсын да, балалары ничек торыр? Һәм бу минутта Хәдичәнең инде төс сала башлаган йөзенә, теге вакыттагы кебек, матур гына булып алсулык йөгерде. Ни

өчен шулай? Әйтә алмыйм. Бәлки, Котбыйны кызганудандыр? Бәлки, аның балаларын кызганудандыр? Бәлки, үзен кызганудандыр? Белмим, белмим! Хәер, дөньяда без белеп җиткермәгән хәлләр азмыни!»

Әйе, шулай. Дөньяда әлегә без белеп җиткермәгән хәлләр дә юк түгел. Ләкин бу очракта хикәяне шулай очлау бөтен нәрсәне укучының авызына чәйнәп салырга теләмәүдән. Укучы башсыз түгел, әйтеп бетермәгәнне ул үз фантазиясе белән тутыра. Бигрәк тә алынган вакыйга физик шәкеле белән үтәдән-үтә ярылып ятмаган, күбесенчә ымлауларга, психологик коллизияләргә корылган хикәядә язучыдан этрафлы тәфсиллелекне, барысын да чәйнәп салуны таләп итү дөрес булмас иде. Әлбәттә, бу очракта мин «Шәһәр читендә» дигән хикәяне тәмам камилләшкән бер әсәр дип әйтүдән ерак торам. Аның кимчелекләре бардыр, ләкин шулай да, узып барышлый Подлужный урамыннан тапкан «деталь» бер-берсе турында чын ихластан кайгыртучы кешелекле кешеләр турында уйландырырлык җылы гына хикәя булып чыкты, дияргә кыюлыгым җитә.

Әмирхан Еникинең «Йөрәк сере» повестенда Зөһрә ханымның чын йөрәктән һәм авторга зур ышану белән сөйләгән матур һәм катлаулы хикәясе, язучының үз исеменнән түгәрәкләп әйтелгән, түбәндәге лирик юллар белән тәмамлана: «...Мин аны оныта алмыйм, мин аның үзен дә, тавышын да оныта алмыйм. Күптән сагынып көткән көй булып очрады ул миңа... Очрады, шушы тын юлларны минем белән бергә таптады, көлде-җырлады, гыйбрәтле үткәнен сөйләде, аннары вакыты җиткәч, ак, кызыл чәчәкләр бәйләмен күкрәгенә кысып, миңа кулын изәп китте дә барды. Үз дөньясына, үз тормышына, үз бәхетенә! Гомергә, мәңгегә! Инде юк ул минем өчен... Әмма, әйтегезче, дуслар, йөрәккә төшкән көйне тиз генә, ансат кына онытып буламы соң?»

Җырга тиң бу юллардан соң, Зөһрә ханымның моннан соңгы «үз дөньясы, үз бәхете» ничек ялганып китте икән? Яки язучы күңелендә тирән эз калдырган ул моңлы «көйне» ничек алай онытмый саклый алды икән? Бер караганда, андый сораулар да урын бар кебек. Мондый сорауларны куючыларны да ахмаклар димәс идем мин. Димәк ки, аларга хикәяләнгән язмыш, ул язмышта катнашучылар үтә дә ошаган булса кирәк. Шунлыктан алар кызыксыналар. Ләкин андый сорауларны куючылар бер хакыйкатьне төшенеп җитмиләр: бер әсәрдә дә — гәрчә ул бик талантлы язылган әсәр булса да — кочакка сыймастайны кочаклап булмый. Ә дөнья, андагы кешеләр язмышы бер вакытта да кочакка гына сыеп бетми. Бәлки аның иң гүзәл сәхифәсе нәкъ менә без әйтеп бетермәгән өлешендә кала торгандыр. Шулай да булсын, аларын җырларга икенче җырчылар килер.

## Әгәр шагыйрь теләсә,
## Күкләр белән сөйләшә...

Сәнгатьнең, поэзиянең үз законы бар. Әлбәттә, алар тормыш закончалыкларына нигезләнеп тудырылалар, әмма, югарыда әйткәнебезчә, художник белән тормышның үзара мөнәсәбәтендә башкалар өчен, хәтта художникларның үзләре өчен дә сер булып яткан закончалыклар да юк түгел. Талант — шуның өчен дә талант ул, тормыш һәм табигать аның алдында башкалар өчен ачмаган «серләрен» ача.

«Поэзия — езда в незнаемое»,— ди В. Маяковский. Шагыйрьләр сандугач белән дә, хайваннар белән дә, дәрья сулары һәм яшеннәр белән дә сөйләшә алалар. Ләкин бу сөйләшү табигать законнарына каршы килеп түгел, киресенчә, аның башкалар өчен ачылмаган закончалыкларын ачып сөйләшү булсын.

Гомумән алганда, лирик шагыйрь Илдар Юзеев лириканың икенче «котыбы» булган героик-эпик поэмалар да бирде һәм бер көнне килеп, адәм ышанмаслык хәл, тотты да Тынлык белән сөйләшергә ниятләде һәм сөйләште дә. Мин бу очракта шагыйрьнең «Тынлык белән сөйләшү» исемле поэмасын күздә тотам. Җир-ана, сугыш кырында башларын салган миллионнарча корбаннар, Хиросима һәм Нагасаки

фаҗигаләре, тынлык, бер минутлык тынлык һәм гамьсез тынлык арасындагы диалоглардан торган, асылда аллегорик сурәтләүгә нигезләнгән, арада шәрә публицистика рәвешендә сугыш корбаннарының гомуми статистикасы да кысылган бу поэманы мин Илдар Юзеев иҗаты өчен характерлы әсәр димәс идем. Тоташ символлардан торган бу әсәрдә шагыйрьнең әйтергә теләгәне ачык һәм кырыс реализм. Шагыйрь әле күптән түгел генә булып үткән сугыш дәһшәтләрен күңеле аша үткәреп күз алдыбызга бастыра, шагыйрь сугышта балаларын югалткан аналарның кайгыларын уртаклаша, шагыйрь гамьсезлеккә каршы көрәшкә чакыра, ниһаять, шагыйрь кисәтә: юк әле, бетте дә тынычландык түгел, кайдадыр икенче бөркәнчек астына яшеренеп икенче гитлерлар баш калкытырга, сугыш кисәвен яңадан тергезергә маташалар, аек булыгыз, баш калкытырга ирек бирмәгез, үз вакытында кулларына сугыгыз, ди.

Мин бу очракта поэманы тулысынча анализларга керешмәдем. Ләкин шулай да сугыш корбаннарының онытылмавы, онытылырга тиеш түгеллеге, аларның һәр даим дөнья хәтерендә кисәтү булып яңгыраячагы турында бик матур һәм төгәл әйтелгән берничә диалог китермичә дә үтә алмыйм.

**Җ и р-а н а:**
**Улларым, балаларым...**
**Тик үзем генә беләм мин**
**Күпме улларым барын...**
**Б а л а:**
**Җыр тавышы килә сыман**
**тирәннән-җир түреннән...**
**Җ и р-а н а:**
**Алар һаман җырлап уза**
**аналар күңеленнән...**
**Б а л а л а р җ ы р ы:**
**Әй, аналар, карагыз,**
**Кайтып килә балагыз,**
**Тик өйләргә керәлмибез,**
**Узып кына барабыз.**
**Җир-ананы сакладык,**
**Җанны биреп якладык,**
**Бер минутка гына кайттык,**
**Бөтенләйгә кайтмадык.**

Күрәсез, монда бөтенесе шартлы, бөтенесе символика. Ләкин нык платформада торып, кирәкле идеягә хезмәт иттерә белсәң, символикадан да файдаланырга мөмкин икән. Шагыйрь дигән кешенең үлгәннәрне терелтергә дә көч-кодрәте җитә икән!

Поэмага болай озак тукталуымның сере тагын шунда, беренче карашка гел шартлылыктан гына торган кебек күренсә дә, бу әсәрнең шагыйрь-художник күңеленә әүвәл мәртәбә төшкән беренче «орлыгы» гаять реаль, күздән яшь китерер дәрәҗәдә реаль булган.

...Кайсыдыр урта мәктәпләрнең берсендә, өлкән яшьләрдәге бер педагогның акыллы киңәше белән, гыйбрәтле бер очрашу үткәрергә булалар. Әйтик, мең тугыз йөз кырык беренче елның язгы чыгарылышында мәктәпне тәмамлаган кешеләрне җыеп, утыз елдан соң шушы ук мәктәпне бетереп чыгачак бүгенге яшьләр белән очраштырырга. Янәсе, сөйләшсеннәр, олылар яшьләргә гыйбрәтле сүз әйтсеннәр, кирәк икән — чабуларыннан тартсыннар. Бер сүз белән әйткәндә, эстафета тапшыру тантанасы. Китә адресларны барлау, сорашу, эзләнү... Ничек кенә кыен булмасын, башлаган эшләреннән кире кайтмыйлар, җитә билгеләнгән көн...

Мондый кызыклы һәм гыйбрәтле «мероприятие»дән шагыйрь дә читтә калмасын, диптер инде, Илдар Юзине дә чакыралар. Бара Илдар, күрә Илдар: бөтен җирдә олы тантана өне. Яшьләр киенешкәннәр-ясанганнар, укытучыларның әллә кайчан пенсиягә киткәннәрен дә чакырганнар, кыскасы, көтәләр болар.

Кәтәләр, дулкынлану һәм тирән эчке кичереш белән көтәләр. Ләкин шулай да очрашу күз алдына китергәнчә килеп чыкмый. Олыгаеп, үзләре балалар анасы булган берничә хатын-кыз килә. Соңыннан, тәфсилләбрәк сораша торгач, мондый аянычлы хакыйкать ачыклана: 1941 нче елгы чыгарылышның малайлары, күбесе, Ватан сугышында геройларча үлеп калганнар. Туган җир, укыган мәктәпләре, йөргән сукмаклары, белем биргән укытучылары өчен башларын салганнар. Бөтенесе, бөтенебез өчен. Әлбәттә, монда аерым-аерым биографияләргә ябышып, кайчандыр исән булган — кайткан, шаярган, уйланган һәм гомер итү турында хыялланган, ләкин сугыш мәхшәре тарафыннан бөтен планнары фаҗигале рәвештә пыран-заран китерелгән персонажларны да күтәрергә мөмкин булыр иде. Ләкин ул чагында әсәр, бәлки, мондый гомумиләштерү, тәенләп-тәенләп күз алдына бастыру көченә, экспрессив көчкә ия була алмаган булыр иде.

— Ни әйтергә? Ничек әйтергә?

Бу ике сорау, әлбәттә, һәр художник алдында һәм һәр вакыт торган. Хәзер дә шул кискенлеге белән кала бирә. «Ни әйтергә?» дигән сорауга җавабында без художникны билгеле бер дәрәҗәдә регламентламыйча кала алмыйбыз. Укучы яки тамашачы өчен, әдәбият һәм заман өчен, шул җөмләдән художникның үзе өчен дә, әлбәттә, нәрсә эләксә — шуңа ташлану ярамас. Аның әһәмиятле тормыш материалы күтәрүе, халык төркемнәрен тирәнтенрәк кызыксындыра, кузгата торган теманы күтәрә белүе һәм моны вакытында күтәрә белүе зарур.

Ләкин «Ничек әйтергә?» соравына җавабында художник ни кылса да ирекле. Без аңарга акыллы киңәшләр бирә алабыз, бәлки без аңа кайбер конкрет ишарәләр дә ясый алабыздыр, художник боларны тыңлый, синең белән ризалашкан кебек баш селкеп, «Мәрхәба! Я хуш!» дип утыруы да мөмкин, ләкин иҗатка керешкәч аның алласы — аның үз күңеле. Менә шунда инде чын иҗат кешесенең хөрлеге дә. Һәм бәлки иҗаттан килә торган шатлык чыганагы да шушы хөрлектән башлана торгандыр.

Монда да искә алмый үтү мөмкин булмаган бер «ләкин» бар. Ул үзе уйлана, үзе баш вата һәм үзенчә баш вата, «Ничек әйтергә?»не үзенчә хәл итә. Әмма ул эчтәлеккә тәңгәл туры килә торган, эчтәлекне түкмичә-чәчмичә укучыга бөтен тулылыгында җиткезә алырлык форма кысасы сайлый белергә тиеш. Һәр яктан төгәл әсәр генә даһи әсәр була ала дигән кебегрәк бер фикер әйтә Леонардо да Винчи. Моңа ни дә булса өстәү мөмкин түгел, ләкин шәрехләбрәк бирәм дигән атлы булып, сыекларга мөмкин. Бу чаклысын инде әдәбият эше белән көн вә төн шөгыльләнүче әдәбият, сәнгать белгечләренә, тәнкыйтьчеләргә калдырыйк. Күз тимәсен, бу чаклысында инде алар остарып беткәннәр. Кемнең башын ничек әйләндерергә икәнлекне күршедән сорап тормыйлар.

## Ньютон алмасы шулай да җиргә төшә....

Шагыйрьләргә һәм гомумән художник җанлы кешеләргә күкләрдә, йомшак болытлар арасында йолдызлар белән сөйләшеп йөрергә нихәтле генә «рөхсәт ителмәсен», иртәме, соңмы алар барыбер җиргә төшмичә булдыра алмыйлар.

Без моны әледән-әле космонавтларны космоска озатып һәм космостан каршы алып торганда күреп торабыз. Югыйсә анда, космоста, җирнең тарту көче дә юк инде, иллюминатордан карап җирнең кай төшендә нәрсә булганлыгын гына күреп йөрисе, тамаша да тамаша... Җитмәсә космик аппарат сәгатенә меңнәрчә километр тизлек белән әйләнә, төшмә җиргә, тирбәл дә тирбәл шул «ахыр заман» бишегендә. Юк, төшәләр, сагынып төшәләр җирне. Мин аларның киткәндәге чырайларына (әлбәттә, телевизор аша), кайткандагы күләч йөзләренә игътибар итәм. Киткәндә аларның чырайлары җитди, йөкләнгән җаваплылык хисен сизүдән чак кына кырыс булыр, кайтканда исә бөтенләй башкача. Авыз ерык ук булмаса да, йөзләрендә мөлаем нур уйнар. Бу, әлбәттә, йөкләнгән бурычны уңышлы үтәүдән дә килә

торгандыр, ләкин, минемчә, бу — барыннан да элек — Җир белән исән-имин кавышудан. Ай, Җир-җаный, олуг син, илаһи син үзеңнең балаларың өчен!

Мин яшьрәк-тилерәк чагымда, иҗатымның башлангыч елларында, шартлы реализмга бирелеп, сөяктән сарайлар салып карадым. «Кара шәһәрнең һәлакәте» дигән бер повесть та яздым, «Бүреләр», «Аккош күле» дигән парчалар иҗат иттем. Хәтерем ялгышмаса, «Бүреләр»е кайдадыр басылып та чыкты кебек. Хәзер, кырыкилле ел узганнан соң күз алдыма китерәм: бөтенесе шартлы, бөтенесе томан эчендә, бөтенесе баштан уйлап чыгарылган һәм, өлешчә, рус әдәбиятындагы шундый саташуларга ияреп эшләнгән маташулар булган болар. «Кара шәһәр...» анысы капитализм. Мин шуны ниндидер башваткыч «әфсен»нәр белән кыска гына вакыт эчендә зир-зәбәр китерәм. Бүреләре дә — берсе дә — төнен бакча артлатып качапоса шуышып, крестьян агаеның рәтләп каралмаган лапас түбәсеннән абзарга үтеп, сарыгын сыртына салып алып китүче ерткыч бүре түгел. Алар унлабы бергә киләләр, кара төндә авылга җитәр-җитмәс туктыйлар һәм парлашып уларга тотыналар. Янәсе, кара көчләр. «Кара шәһәр...»не, тора тартып редакциягә яки нәшриятка күтәреп барырга кыймыйча, Ибраһим Газига күрсәттем. Иренмичә укыды һәм күзгә карап әйтте:

— Синең эш түгел бу, Пәтыйк. Гомумән дә эш түгел бу, саташу. Син моны больше күтәреп йөрмә, бүтән берәүгә дә күрсәтмә,— диде.

Авыр туфрагы җиңел булсын мәрхүмнең, әйтсә, туры әйтә торган әйбәт гадәте бар иде. Бәлки мин Ибраһимны, барыннан да элек, әнә шул турылыгы, вакытында кисәтә белгәнлеге өчен дә сагынамдыр.

Бар бармактан суырып язу. Бар тормышны фантазия белән кушып, чак кына «күтәрә төшеп» язу. Бар тормышны һич бизәмичә, барлык каршылыкларында, яраҗәрәхәтләре белән ачып язу. Беренче төрлесенә карата халыкта бик тә төгәл һәм бик тә усал әйтем дә бар — «артыннан чыгарды» ди. Икенче төркемгә, барыннан да әүвәл, бөек инглиз фантасты Герберт Уэллсны кертер идем. Өченче төркемгә Л. Толстойдан, Ф. Достоевскийдан башлап дөньяның барлык бөек реалист художниклары керәләр.

Сүз уңаеннан әйтү: тормышны фәнни фантазия белән кушып, беркадәр «күтәрә төшеп» язучылар кайвакыт уйлап, эшнең асылына төшенеп җитмичәрәк язу нәтиҗәсендә, тормышны күтәрәсе урында «төшереп» тә куя алалар. Моңа мисал итеп шул ук бөек инглиз фантасты Герберт Уэллсны алырга мөмкин. Мәгълүм булганча, 1920 нче елда Уэллс Россиягә килә. Сугыш арты еллары, Россия өстеннән революцион тетрәүләр, дәһшәтле ачлык үткән. Әлбәттә, бу илдә бары да ал да гөл түгел. Ләкин шул җимерекләкләр, бөлгенлекләр, ачлы-туклы барган көнкүреш ыгы-зыгы арасыннан сәламәт башлангыч та күренә бит. Кешеләр иртәнге көнгә ышаныч белән яшиләр. Әмма бөек фантаст, асылда яхшы ният — Россиядәге хәлләрне үз күзләре белән күрү нияте белән килгән мәшһүр язучы әнә шул сәламәт башлангычны күреп җиткермичә, үз иленә кайткач «Россия караңгылыкта» дигән китап язып чыга. Бу турыда инде күп язылган. Әмма Ольга Берггольцның «Көндезге йолдызлар» дигән автобиографик повестеннән бөек фантастның бу сәяхәтенә карата үтә дә төгәл әйтелгән юлларны китермичә үтә алмыйм: «...Инде күп еллар үткәннән соң мин шуны белдем: шул елларда, шул көннәрдә үк диярлек минем туган илемә мәгълүм инглиз язучысы — фантаст Герберт Уэллс килә. Һәм мин соңыннан аның бу сәяхәте турында язып чыгарган китабын укыдым.

Ул без кайткан тимер юлдан ук килгән, ул безнең кебек үк хатын-кызларны, ирләрне һәм балаларны күргән, ул безне күргән. Аерма тик шунда: **без яшәгәнбез, ә ул бары тик күргән генә.**» Бик тә мәгънәле, хәтта уйландыра торган сүзләр. Күрү — бер нәрсә. Үзең яшәп карау — **бөтенләй икенче.**

Бу уңайдан минем «иҗат командировкалары» буенча ашыгыч рәвештә теге яки бу төзелешкә, теге яки бу «объект»ка барып кайтканнан соң шундый ук ашыгычлык белән кәгазьгә төшкән озын-озын очерклар, повестьлар, романнар турында берничә сүз әйтәсем килә. Бер караганда, барысы да бар, барысы да үз урынында кебек күренә ул әсәрләрдә. Фамилияләр санала, нинди дә булса конфликт та табылган, проблемалар да бар, язучының язу стиле дә каһәрләрлек түгел. Ләкин бик әһә-

миятле бер нәрсә — **яшәү җылылыгы** сизелми. Чөнки алар, Ольга Берггольц әйткәнчә, күреп яки сөйләгәнне тыңлап кына язылганнар, яшәп түгел.

Моннан, әлбәттә, язучы бары тик үзе яшәп күргән мохитны гына яза ала икән, дигән берьяклы нәтиҗә чыгарырга ярамый. Үзе еллар буена заводта кайнаган, эшләгән, күргән, тир түккән кешенең дә, әйтик, шул үзе эшләгән заводы турында бер юньле нәрсә дә яза алмавы мөмкин. Эшне, әлбәттә, беренче чиратта талант хәл итә. Ләкин талант янына намуслылык, ярата белү, бары тик шул үзең яраткан нәрсәләр, үзең яратырга өлгергән кешеләр турында гына яза белү дә кирәк.

Ай, бик тә нечкә, үтә дә четерекле мәсьәлә бу! Монда язучыдан, гражданин булуы өстенә, шәхес була белүе сорала. Без аның язганы аша, тормышның бер кисәген күрү белән генә канәгатьләнмик, художник буларак, язучының үзен дә, аның симпатиясен, антипатиясен дә күрик, аның күңел җылылыгын, иманын тойыйк. Шунсыз ул башкалар күңеленә йогынты ясый алмаячак. Күңелдән чыккан гына күңелгә керә, ди халык.

Әйе, Ньютон алмасы, әлбәттә, җиргә төшмичә кала алмый. Әмма шуны да онытырга ярамый: художникның үз күңелендә пешә торган үз алмасы да була бит. Үз аңы, үз күңеле, үз чаралары белән пешерә ала торганы. Читтән китереп тагыла торган теләсә нинди теманы — гәрчә ул бик әһәмиятле тема булса да — аның «пешерә» алмавы да мөмкин. Һәм без аны көчләмик. Юкса, әдәбиятны макулатура басачак.

## Башлый белү — шулай ук осталык сорый

Югарыда без әсәрне үз вакытында һәм үз урынында туктата белү, нәкъ кирәкле төштә нокта кую турында сүз алып бардык. Үз урынында һәм үз вакытында куелган ноктадан да көчлерәк тәэсир иткән нәрсә дөньяда юк, дияр дәрәҗәгә җитеп әйттек моны. Бетерүдән элек башлап китәргә кирәк бит әле. Әсәрне башлап китә белү, беренче аккордны табу шулай ук ансат эш түгел. Ахыр чиктә, шул бит инде укучыда рухи халәт уятачак, әсәргә алып кереп китәчәк. Тора торгач табигать тасвирыннан башлап китү һәм моны үлчәүсез сузу, үз тасвирың белән үзең мавыгып китеп, нәрсә турында язачагыңны, ни әйтергә уйлаганлыгыңны онытып җибәрү ихтималлары да бар. Бу — бик хәтәр адым. Укучының шунда ук синнән суынуы мөмкин. Кайчандыр, хәтта классикада да, битләп-битләп табигать тасвиры бирү практикасы булган, әмма эш һәм хәрәкәт заманы — безнең заман укучысы мондый «юмартлык»ны кабул итә алмый, аны син шунда ук мавыктыргыч вакыйгага алып кер. Бу, әлбәттә, табигать тасвиры безгә ят нәрсә икән дигән сүз түгел. Ул кирәк. Ләкин тиешле микъдарда һәм тасвирлана торган вакыйгаңа ничектер бәйләнешле булсын, синең үз алдыңа куйган фикри-эстетик максатыңны ныграк ачарга хезмәт итсен.

Бу яктан Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ы классик үрнәк була ала.

«Фәхрине үтереп ташладылар» — беренче аккорд менә шул. Өч сүздән торган шушы кыска җөмлә әсәрдә сурәтләнәчәк атмосферага шунда ук алып керә. Димәк, уен эш бармаячак монда. Ниндидер яшертен куллар бар, дошманнар бар, ятьмәләргә төренгән көрәш бар. Шул өч сүз укучының игътибарын дәррәү биләп ала.

Яки Һади Такташның «Мокамай» поэмасын алыйк. Нигездә лирик чигенеш рәвешендә, дус малаеның фаҗигале язмышын әрнү һәм моңлану белән тереп сурәтләгән бу әсәрен Такташ, әлбәттә, алай кискен нотадан башлый алмый. Аңарга әле узганга кире әйләнеп кайтырга, үзенә ияртеп укучыны да алып китәргә кирәк. Йомшак итеп һәм бик тә тирбәтеп алып китә ул безне.

**Белмим,**
**Әллә күпкә,**
**Әллә бик озакка,**
**Ахры, мәңге оныта алмамын,**
**Тамбов урманнары уртасында**
**Усак яфраклары шаулавын...**

Соңыннан, әсәрнең эченә керәрәк, шагыйрь Тамбов урманнарында имәннәр булганлыгын да искә төшерә, «ике штансыз малай» каен башларына да әледән-әле үрмәли торган булганнар. Ләкин беренче строфада, кереш аккорд урынына китерелгән юлларда нишләптер усакны китереп куя ул. Бәлки шагыйрь моны аңлы рәвештә эшләмәгәндер, ә менә «аң»нан эчкәрәк яшеренгән рухи интуициясе аны усакка китереп төртә.

Бу башлангычта нәкъ менә усак урынлы да. Усак яфракларының башкаларга караганда күбрәк шаулаганы өчен түгел (бәлки шагыйрь беренче нәүбәттә шул якны күздә тоткандыр), ә бәлки усакның, йомшак һәм чәрексез агач буларак, Мокамай-Мөхәммәтҗанның, арба тәгәрмәче урлауда гаепләнеп, авыл җыенында кыйналганнан соң, идән астына ябылуы һәм, ахыр чиктә, шул гарьлекне күтәрә алмыйча үз-үзенә пычак салу түбәнлегенә тәгәрәрлек йомшак җанлы кеше булып чыгуы белән ниндидер уртаклыгы булганлыктандыр. Иҗат психологиясенең искәрмәстән генә художникка ясаган «диктаты» нәкъ әнә шундый нечкә мәсьәләләрдә үзен сиздерә дә инде.

Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» хикәясе, мәсәлән, мондый җөмләләр белән башлана: «Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә». Башлана, дидек. Ләкин асылда бу башлану гына түгел, бу — хикәя кылынычак вакыйгаларның ачкычы, камертоны. Халыкта кылганны әбиләр чәче дип йөртү дә бар икән. Бу яктан да кылган хикәядә гәүдәләнәчәк ак әби язмышы белән тәңгәл туры килә. Әмма иң нык туры килгән эчке моңны әйтеп бетереп булмый һәм аны әйтеп бирергә тырышуның кирәге дә юктыр...

Әллә кайчан, сугышка хәтле үк, әле өйрәнчек чакта дип әйтерлек язылган бер хикәям искә төшә. «Ана хикәясе» дип аталган бу хикәя революцион буталыш елларындагы авылны, дөресрәге, авылдагы төнге бер эпизодны сурәтли. Хикәянең эчтәлеген сөйләп торуның урыны бу түгел, әмма, минем уйлавымча, шул чорның атмосферасына алып керүдә азмы-күпме азык бирүче бизәкләрне китерү кирәктер:

«Күкнең җир белән тоташкандай күренә торган чите туп тавышыннан гөрселди. Күгәрченнәр, юаш тынлык эзләп, каядыр еракка очалар. Әкрен генә исеп куйган кичке җил белән шәһәр ягыннан дары исе, лазаретлар исе, янган дворецлар исе килә».

Ныклабрак селки калсаң, бу җөмләләрдән дә төгәл булмаган урыннарның коелуы ихтимал, ләкин тулаем алганда ышанып әйтергә була: бу башлангыч укучыны битараф калдырмаячак.

Ә менә «Ак перчатка» дигән хикәядә, сөйләнә торган төп вакыйгага керешкәнче, колхоз җитәкчеләре белән машинага утырып басулар карап йөрү, блокнотка тәрткеләр, саннар, исемнәр яудыра бару — болар бөтенесе журналистикадан. Мин бу хакыйкатьне бигрәк тә соңыннан, әдәби атналыклар уздырып йөргәндә, очрашулар вакытында әлеге хикәяне халыкка укып карый башлагач, сиздем. Халык хикәянең ул башлангыч өлешен, гәрчә фактлар бик тормыштагыча төгәл теркәлгән булса да, кабул итми. Чөнки андый фактлар аларның үзләрендә дә җитәрлек, алар фактлар белән очрашырга дип килмәгән, алар сәнгать белән очрашырга дип килгәннәр. Мин бу артыклыкны «корбан» итеп, ниһаять, хикәянең кереш өлешен төшереп калдырып укый башладым.

«Монда безнең хикәягә, өченче тизлек белән диярлек чаптырып, шофер Мостафа килеп керә» — шулай башлап китәм мин хикәяне. Һәм тыңлаучының шундук колагы тора. Кем ул Мостафа шофер? Нилектән әле болай чаптырып килеп керә хикәягә? Аның ак перчаткалы кызга ни мөнәсәбәте бар? Берьюлы әнә нихәтле сорау һәм кызыксыну уяна тыңлаучыда. Шуннан соң инде ул исемнәре телгә менгән персонажларга күз алдыннан югалырга ирек бирми, алар артыннан үзе дә ияреп китә. Ә чынлап караганда, сәнгать әсәренең төп бурычы — ияртеп алып китү бит. Кайсы якка алып китә? Анысы икенче мәсьәлә. Ул хәтлесе художникның позициясенә бәйләнгән. Ләкин ияртеп алып китә алу кодрәте — сәнгатьчәлекнең асыл күрсәткече.

Һәр очрактагы кебек, бу очракта да, ахыр чиктә, мәсьәлә художникның акыл һәм осталык көченә килеп терәлә. Әсәрне, анда катнашучы геройларны, аларның үзара мөнәсәбәтен, аларның гамәлен, гадәтләрен төп сызыкларында гына булса да

алдан үз күңелеңдә күрмичә торып, дөрес һәм төгәл башлап китеп булмый. Ә башлап китүнең төгәл бизәкләрен күрү өчен, бер үк вакытта, әсәрдән чыгу юлын да алдан күрә белергә кирәк. Халыкта, керүдән элек чыгуың турында уйла, дигән сүз йөри. Бик мәгънәле сүз.

Төрле язучылар була. Мин бер драматургны беләм. Ул, һич тә яшермичә, ачыктан-ачык әйтә. «Мин башы яки азагы турында алдан баш ватып тормыйм. Мин хәзергесе минутта җанланып күз алдыма килеп баскан эпизодны язам. Аннары икенче эпизодны. Аннары өченчесен. Аннары аларны үзара «монтажлау» турында кайгырта башлыйм», ди. Һәр юләр үзенчә акылдан яза, диләр. Бәлки, әлеге драматург үзенчә хаклыдыр. Белмим, белмим! Ләкин мин үзем ишек ачып керткән геройларымны үзем үк ишек ачып озатып калмыйча тынгы таба алмыйм.

Миннән хәер-фатиха аларга! Укучылар күңеленә исән-имин барып җитсеннәр. Укучыларны үзләренең яшәешләренә ышандырсыннар, гыйбрәт бирсеннәр. Ләкин бер вакытта да кергән ишекләреннән, ничек кергән булсалар — шулай чыгып китмәсеннәр. Чак кына булса да үссеннәр, акыл җыйсыннар, кыйналсыннар, ләкин кеше буларак кыйналсыннар.

Шуның өстенә, шуларның бөтенесе өстенә үзләре белән кешеләргә чак кына булса да яңа сөенеч тә алып килсеннәр.

## Дерсу Узала

Соңгы елларда экранга чыгарылган күп санлы картиналар арасыннан минем үземдә, нишләптер, «Дерсу Узала» картинасы аеруча якты тәэсир калдырды. Мин аны ике мәртәбә — беренче тапкыр Пермьдә, кызыбызда кунакта чакта оныкларым белән җыйнаулашып, икенче тапкыр Казан экраннарының берсендә карадым. Шунысы игътибарга лаек, картинаны балалар да, олы яшьтәгеләр дә бердәй кызыксыну белә карый. Юкса, әллә нәрсәсе дә юк, кыландырмыш сюжет борылмалары да, героик яки романтик вакыйгалар да башыңны әйләндерми. Ерып йөргесез куе Уссури тайгасы, урман, урман, анда-санда ерткыч хайваннар күзгә чалынып кала. Алары да тешләрен ыржайтып, өскә ташланырга тормыйлар, кыскасы, бернинди мажара да юк. Шул ерып йөргесез тайга урманнары арасыннан язучы, географ, картограф Владимир Арсеньев экспедициясе бара. Берсен-берсе ярты сүздән, хәтта ишарәдән үк аңлый торган дус кешеләр, арыгач башны башка куеп, урман туфрагында ятып йоклыйлар, ашарга пешерергә кирәк булса, учак ягып, ут тирәсенә сүзсез генә җыелышалар, берсенең авызыннан да зарлану яки гаҗәпләнү сүзе чыкмый. Әйтерсең шушы урманда туганнар, шунда ук үләчәкләренә дә ышанганнар... Баралар, көн баралар, төн баралар, искә алырдай, киләчәк трассаларны сызганда ориентир булырдай калкулыкларны, елга-чокырларны Арсеньев альбомына терки бара. Шунда, шул хәрәкәтчән сәяхәтчеләр арасында, алар нәрсә ашаса — шуны үк ашап, алар кайда баш куеп йокласа — шунда баш куеп, артыкны һич дәгъва итмичә, кәкре аяклы, төп шикелле юан, башкалар ишетмәгәнне алдан ишетә белә торган сак һәм саф җанлы Дерсу Узала, шул тайга урманнарының чын хуҗасы Дерсу Узала бара. Ерткыч хайваннар аны таныйлар, ул аларны әллә кайдан, ерактан, ничектер исләреннән үк диярлек абайлый, экспедиция кешеләрен алдан үк кисәтә — нишләргә ярый, нишләргә ярамый?

Мине чын ихластан тетрәткәне, миңа бер очракта да, бер уңай белән дә татырга туры килмәгән яңа шатлык китергәне картина үзе, бигрәк тә аның баш ролендәге Дерсу Узала булды.

Уйландым, әле хәзер дә кайта-кайта уйланам, бигрәк тә, менә бу хезмәтне башлагач уйланырга туры килде: кайда, нәрсәдә соң бу кәкре аяклы килбәтсезнең йогынты көче?

Мин үзем моның өч серен таптым шикелле. Беренчесе шунда: Дерсу Узала — дөньяның фани зиннәтләреннән өстен тора торган кеше. Кыска гына бер диалог искә төшә:

— Кайда соң синең өең? Кайда, кем белән яшисең? — дип сорыйлар экспедициячеләр.

— Тайга минем өем, сопкалар... — ди Дерсу кыска гына итеп. Бу кыскалыкта мактану яки гаҗәпләндерергә тырышуның әсәре дә юк. Әле ул әйтеп кенә бетерми, аның урынында бүтән берәү булса, «Кем белән яшисең?» дигән сорауга «Арсланнар, юлбарыслар, ак аюлар белән аралашып яшим» дип тә өстәр һәм бу һич тә шапырыну булып яңгырамас иде. Чөнки Дерсу Узала, җаны һәм эчке инстинкты белән, чын-чынлап арсланнар токымыннан диярлек. Аңарга дөнья зиннәте, дөнья шау-шуы кирәк түгел, аңарга барыннан да элек карурман серлелеге кирәк.

Психологик нәтиҗә шул: язучы, әлбәттә, Дерсу Узала түгел. Дөнья шау-шуының үзәгендә, халык тормышының кызып кайнаган урынында булырга тиешлеге ягыннан, язучы Дерсу Узаладан бөтенләй үзгә. Шулай да, дөньяның үзгынчы зиннәтләренә кызыкмау ягыннан, без Дерсу Узалага якынрак торсак, ай-һай ла, бер дә зарар итмәс иде. Күреп, ишетеп, белеп торабыз лабаса, әлеге шул фани мавыгулар — данга, акчага, шәрә мәхәббәткә кызыгулар нәтиҗәсендә әледән-әле талантлар күзгә күренеп ваклана, җимерелә килә ич.

Дерсу Узаланы сөйкемле иткән икенче ягы: аның эчкерсезлеге, кешеләргә бирелеп хезмәт күрсәтергә әзер торуы. Арсеньевның бер сүз катуы җитә. «Күпме бирерсез?» дип сорау юк, бернинди шарт куяю юк, ул экспедициягә юл күрсәтүче булып ияреп китә. Йөри, мәшәкать чигә, зур тәвәккәллекләргә бара, ләкин әйткән сүзеннән кайтмый. Сукыраюы сәбәпле, ничектер бер адашып калганнан соң, мең мәшәкатьләр аша, экспедиция кешеләрен яңадан эзләп таба, элек ничек хезмәт күрсәткән, яңадан шулай бирелеп хезмәт итүен белә. Кешеләргә ярдәм күрсәтү, ярдәм күрсәтә алганлыгын тоюы — менә аның яшәү чыганагы. Әйтәсе дә юк, безгә дә шундый муллык белән килсәче кешеләргә шулай гадел хезмәт итә белү!

Дерсу Узаланы күңелдә дус итеп калдыра торган өченче сыйфаты: аның табигатькә якынлыгы. Җилдән-яңгырлардан курыкмый, ерткыч хайваннар тешенә эләгүдән шулай ук курыкмый, салкын җирдә йоклап ревматизм алармын дип уйлап та бирми — андый хәвеф-хәтәрлекләрне күңеленә дә китермичә, үзенең серле һәм хәвефле тайгасында яшәпме яши ул. Бер эпизод күз алдында калган:ниндидер сәбәпләр аркасында экспедиция бүлгәләнә. Арсеньев белән Дерсу икәве генә калалар. Борын төбендә озын һәм буранлы төн. Алай гына булса икән, Дерсу сизенә: төнлә бик яман «пәри туе» булачак.

— Бөтен башка эшләрне куеп торырга, әзерләнергә кирәк, — дип Арсеньевка киңәш бирә Дерсу. Һәм шунда ук әзерләнә дә башлый. Әзерләнүе нәрсә? Тотына чыбык-чабык, кура-камыш ташырга. Моны күреп, Арсеньев та тик кала алмый, әлбәттә. Уссури тайгасын миңа караганда күбрәк күргән кеше, белә торгандыр, дип ышана Дерсуга. Ә бу ышаныч хәйлә белмәс Дерсуга яңа дәрт, көч-куәт бирә: «Командир миңа каршы төшмәде, командир үзе дә тотынды, син хаклы, Дерсу!» дигәндәй була ул үз-үзенә. Бергәләп тау чаклы чыбык-чабык: кура, коры-сары җыялар. Ләкин шунда ук ут төртергә ашыкмый Дерсу. Чөнки белә: әле бу тайга буранының башы гына, аның чын-чынлап котырынуы алдарак булачак. Һәм бу хәтәрне сизенүдә ул, Дерсу Узала — ике аяклы «Барометр», күп укыган Владимир Арсеньевка караганда, чагыштыргысыз өстен булып чыга. Төннең һәм буранның иң хәтәр бер вакытында, тайга «пәрие» бөтен богауларыннан ычкынып, бу ике шашкан адәм баласын очырып алып китәргә җыенганда, кичтән үзләре өйгән «тау»-га ут төртеп җибәрә Дерсу. Тайганың котырынган стихиясенә каршы бу икәүнең аңлы рәвештә алдан әзерләнгән үз «стихиясе» торып баса. Һәм шул ут ышыгында алар сакланып калалар.

Кемнең җаны тетрәнмәс Дерсуның бу кадәр алдан күрүчәнлегенә. Беренче чиратта, әлбәттә, Арсеньев «эри» бу утта. Бик якын дусты итеп күңеленә урнаштырган Дерсуны, бер вакыт табып, үзенең Хабаровскидагы резиденциясенә алып китә ул. Янәсе, кунак итәргә. Шәһәр, әлбәттә, цивилизация, комфорт. Зур-зур бүлмәләр. Йомшак караватларда гына йоклыйсы. Бер көн үтә шулай, ике көн үтә шулай, өчкә киткәч көчкә китә Дерсу Узала өчен.

— Гел шулай, шушы таш тартмалар эчендә кысылып яшисезме? — дип аптырап сорау куя Дерсу бер көнне. Күрә Арсеньев: монда шул Дерсу стихиясе түгел. Һәм ике көпшәле «цивилизованный» мылтыгын бүләк итеп, кунагын үз стихиясенә озатырга мәҗбүр.

...Үлем кайда да, кемгә дә бер килмичә калмый. Шул җөмләдән Арсеньевка да бер көнне шомлы хәбәр килеп төшә. Аның җан дустын, аның юл күрсәтүчесен, аның хәр күңелле зирәк иптәшен, белмим, әлеге шул ике көпшәле «цивилизованный» мылтыгы өчен, белмим, башка бер коткы аркасында, тайга урманында үтереп киткәннәр.

Үлем кайда да үлем, үлем кайда да матур нәрсә түгел. Ләкин тайга уртасында, яңа гына күмелгән кабер янында, үзенең олы кайгысы белән ялгыздан-ялгыз басып калган Арсеньев бу үлемне, ничектер, матурлый белгән. Күрәсең, олуг дуслыкның, кешегә бирелеп хезмәт итә белүнең, шул ук вакытта хөрлекне ахыргы сулышына чаклы саклый алуның баш ирешмәслек кодрәте үлемнең шыксызлыгын да җиңә алган булса кирәк.

Бу китерелгән кыйсса турыдан-туры без куйган темага карамый, ләкин мондый кыйссаларны, мондый Дерсу Узалаларны белеп тору иҗат кешесе өчен бер дә артык йөк түгел.

## Габбас мулла — трагик образ

Алдан ук сизеп торам, бәхәсләр булырдыр бу турыда. Бер караганда, бәхәсләшергә урын да бар кебек. Үзе мулла, үзе, имеш, трагик дәрәҗәгә күтәрелгән, пьедесталга бастырылган. Муллаларның барысын да бер очтан кара реакционерлар итеп күрергә күнеккән һәм бары тик каһәрләнергә тиеш дип кенә табучы бер яклы караштагы кешеләр бездә әле дә булса бетеп җитмәгән. Әлбәттә, муллаларның күбесе реакциягә, дин чапаны астында патша самодержавиесенә, өстен сыйныфларга хезмәт итүче «соры кортлар» булганнар. Шул ук вакытта муллалар арасыннан халыкка дөнья гыйлеме йоктырырга, халыкны агартырга тырышучы күп кенә прогрессив кешеләр — укытучылар, галимнәр, шагыйрьләр дә чыккан.

Гариф Ахуновның «Идел кызы» романындагы баш геройларның берсе Габбас мулланы мин югарыда китерелгән төркемнәрнең берсенә дә кертмәс идем. Чынын гына әйткәндә, аның муллалыгы да ташка үлчим генә. Ә кеше буларак, ул бик катлаулы, каршылыклы. Аның тормыш-көнкүреше гаять четерекле борылмалар аша үтә. Шул четерекле хәл-әхвәлләр, заман китереп тудырган каршылыклар арасында буталудан тәмам аптырау-йөдәү хәленә килгәч, ул үзенә-үзе кул салырга мәҗбүр. Димәк, ул трагик язмышлы кеше.

Бу бахырның тормыш борылмаларына, бөтенесенә булмаса, кайберләренә күз салып үтик.

Иң элек ул мужиктан чыккан мулла, аның указлы мулла икәнлеге турында романда хәтта ишарә дә ясалмый. Элекке бай мулла хаҗ сәфәрендә үлеп калгач, аның кырык яшьлек тол хатынына «Алып-сатар Габделхәлим» сәүдәгәрнең кыставы аркасында яшь башыннан йортка кергән, димәк ки, иң элек үзенең яшьлеген урынсыз корбан иткән кеше ул Габбас. Хәйләкәр сәүдәгәр Габделхәлим куштанлыгы да, әлбәттә, булмаган түгелдер, ләкин эш монда гына түгел. «Хәерче Җамалетдинның үндүртенче баласы» булган артык кашык Габбас, һичшиксез, Шәмсениса абыстайның байлыгына да кызыккан булырга тиеш. Әйтеп карагыз, элек мужикның кайсысы гына байлыкка кызыкмаган да, кем генә тиз арада мал-мөлкәтле булырга хыялланмады икән! Менә шушы байлыкка кызыгуы аркасында яшь башын кырык яшьлек тол остабикә муенчагына тыгуы белән Габбас фаҗигагә беренче мәртәбә аяк атлады.

Нинди фаҗига? Монда без эшнең торышыннан үзеннән-үзе логик рәвештә килеп туа торган, туарга тиешле хәлләрне күздә тотабыз. Берсенең өлкән яшьләрдә, икенчесенең яшь булуы әллә шома гына узгандыр дисезме? Икенчедән, тыштан ничек кенә шома күренмәсен, элекке бай һәм дәрәҗәле мулла хатыны Шәмсениса, сиздерәме ул моны, сиздермәскә тырышамы, үзен ничек тә өстенрәк, хуҗа кеше итебрәк тота. Моны Габбас, ир кеше буларак, әлбәттә, эчтән кичергән булырга тиеш. Шул ук мәкерле Шәмсенисаның, Габбасны ничек кулда тотарга тырышып, үзенә читен булса да, хурланса да, үзе йөреп ирен яшь кыз Хәнифәгә өйләндерүе, димәк

ки, Габбасны ике ут арасында калдыруы мужиктан азган бу беркатлы мулла өчен ансат булгандыр дисезме?

Икенче хәтәр җил өйнең тышында. Зартугай авылының икенче мәхәлләсендә бай һәм яхшы ук тәкәббер Сөләйман мулла утыра. Ул астыртын кеше — чак кына көнчелектән, чак кына тәкәбберлектән булса кирәк — төрлечә мыскыл итеп, Габбас мулланы кимсетергә, түбәнәйтеп күрсәтергә тырышып — әле аның мәхәллә кешеләренә, әле Габбасның турыдан-туры үзенә оскы уты үрләтеп тора. Габбас бахыр моны да эченә йотарга, конфликтка кермәскә тырышырга мәҗбүр. Әлбәттә, бу да аның җанын кыршымыйча узмагандыр.

Шулай да Габбас чыдый. Булдыра алганча мәхәлләгә хезмәт күрсәтә. Яхшы һәм кешелекле булырга, кайгы-хәсрәт килгәндә сабырлык белән күтәрергә өйрәтә. Олыгаеп барган Шәмсенисадан кыз бала — Нурия дөньяга килү факты Габбасны бу тынгысыз йортка, ниһаять, башы-аягы белән кадаклый. Ул бала өчен җанын фида кылырдай булып шатлана, кыз баланы һәр җәһәттән абруйлы, әти-әнисенә карата миһербанлы, дөнья мәшәкатьләре алдында түземле, барыннан да элек, укымышлы, кешелек өчен файда китерердәй кыз булып үсүен теләп, кулыннан килгән бөтен эшне авырыксынмыйча башкара. Нурия үсә төшкәч, «тукта, бозылып китүе бар, мәхәллә кешеләре ни әйтер» дип икеләнеп тормыйча, кызны русча укырга һәм дөнья гыйлемнәренә өйрәнергә дип Алабугага илтеп укырга бирә. Алай гына да түгел, Габбас, ул вакыттагы материаль тормышның җиңел түгеллеген истә тотып, кызына әледән-әле азык-төлек ташый, кызының хәлен белеп тора.

Әлбәттә, ул яхшылыкка җавап итеп яхшылык көтә һәм моңа аның хакы да бар кебек. Ләкин ай-һай ла!

Дөнья кинәт Габбас мулла аңламаганча, ул бөтенләй көтмәгән якка таба үзгәреп китә — Рәчәй җиреннән барлык катлауларны тетрәтеп, атышлары һәм митинглары, Марсельезалары һәм бу тетрәүне өнәмәүче өстен катлауларның ачудан ярсып күтәрелүләре белән Революция давылы уза. Габбас бу хәлләрне ничектер колак яныннан үткәрмәкче, аның революцияне котлап кул чапканы да ишетелми, каһәрләп тә сүз әйтми. «Гел болай булмас, урынына бер утырыр» дигән кебегрәк позициядә кала Габбас.

Ләкин дөнья бик алай тиз утырмый. Китә якалашулар. Зартугайдан Шәяхмәт Айдаровлар, Солтаннар күтәрелеп, революция дулкынына кушылып китәләр. Колчак калдыклары совет яклы мөгаллимнәрне ат койрыгына тагып, җәзалап үтерәләр... Габбас мулланың сөекле Нуриясе дә Алабугада гына сыеп калмый, Казанга китә. Андагы белешләре ярдәме белән, әлбәттә, мулла кызы икәнлеген шәрран ярып кычкырмыйча, элек татрабфакка, аннан медицина факультетына укырга керә.

Еллар үтә. Габбас мулла башына ява... ул көтмәгән бозлы яңгырлар. Аның үз туганнарыннан берсе милиционер Уразаева, аягына кирза итек киеп, биленә каеш буып, наган тагып алган Уразаева, яшьтән үк ирдәүкәләнеп, тәмәке тарта, аракы эчә башлаган Уразаева, бөтен Алабуга өязендәге муллаларны, попларны җыеп, урман кистерү эшенә мобилизацияли. Шул җөмләдән, Габбас мулла да кисә урманны. Габбас бу эшкә һич каршы түгел, ул гомумән кече яшьтән эш эшләп, нужа күреп үскән кеше. Шулай кирәк икән, димәк, кирәк. Кисәләр. Ләкин Габбас бер нәрсәгә бик рәнҗи. Шул туганы Уразаева бу олы яшьтәге кешеләрне — муллаларны һәм попларны юри мыскыл иткәндәй, иртәләрен зарядка ясатып, басу буйлатып чаптырып йөдәтә.

— Әйдәгез, буржуй калдыклары, тәмен татыгыз хөрриятнең, җитәрлек халыкның канын эчеп яттыгыз.

«Менә монысы нигә? Ник чаптырып азаплый ул олы яшьтәге абзыйсын?» дип, аптырап, үзенә-үзе сорау бирә Габбас. Моны ул ачыктан-ачык мыскыл дип саный һәм бу мыскылга аның намуслы җаны протест белдермичә кала алмый.

Хәлбуки, күрәселәре моның белән генә бетми, чын күрәселәре алда булган икән әле. Якынлаша колхозлашу еллары, кулакларны сыйныф булу ягыннан бетерү башлана. Эшнең алар файдасына бармаганлыгын сизеп, хәйләкәр Шәмсениса, ышыклану почмагы эзләп, Казанга — укымышлы кызы янына кача. Монда, болганчык Зартугайда, пожарда янган элекке хаҗи өенең күмерле-кисәүле нигезендә, актык туннарын сатып, җир тырнашып салган яңа нигездә Габбас белән Хәнифә икәве

гена калалар. һәм чынлап та элекке кебек челтәрле-чарлаклы булмаса да, көч-хәл белән тергезгән бу яңа өйдә үз тиңе Хәнифә белән генә калган Габбас тынычланган да кебек була: «Юк, безгә тимәсләр, икебез тиң «хәерчедән чыккан» алла бәндәләре ич без...»

Юк шул, тынычланырга ашыккан икән безнең Габбас картыбыз. Тияләр. Рас тебе-тамыры белән йолкып ташларга икән һәр төрле «сыйнфый соры кортлар»ны, ничек инде Габбас мулла гына бер читтә торып калсын. Хәнифә белән икесен мунчага куып чыгаралар да, мең газап белән үзләре салып кергән йортларын колхоз файдасына — икенче урынга күчерәләр.

Бик авыр кичерә Габбас бу соңгы куылуны, чын күңеленнән гаделсезлек дип таба. Сүзсезгә әйләнә, кара көя, хәтта бердәнбер таянычы булып калган Хәнифәсенә дә сүз катмый. Шулай да ул әле бөтенләй үк өметсез калмый. Казанда бит аның укымышлы кызы бар, авыр чакларында үзләреннән арттырып, онын-ярмасын илтеп, укытып үстергән Нуриясе бар. Хәлбуки, иң авыры, бәгырьне иң өзә торганы Казанда көтеп торган икән.

— Әти, син бу тирәдә күренеп йөрмә,— дип бусагасыннан куа аны укымышлы Нуриясе.

...Бөтенләй бетеп, мораль һәм физик яктан тәмам бөрешеп кайта Габбас шәһәрдәге кызы яныннан. һәм кем белән дә аралашмыйча, беркемгә бер зарлану сүзе ишеттермичә, иңке-миңке килеп, атна-ун көн йөреп карый да, йокысыз үткәргән бер төннең иртәгесен чыгып китә һәм өйгә бүтән әйләнеп кайтмый. Аны каен ботагына асылынып үлгән җирендә зираттан табалар. Тере кешеләргә өмете беткән Габбас, әйтерсең өмет эзләп мәетләр хозурына барган.

Шул чорның рәхимсезлегеме бу? Чорныкы түгел. Аерым кешеләрнең, акны карадан аера белмәүче таш бәгырьле кешеләрнең, куркак кешеләрнең рәхимсезлеге. Шул ук вакытта әйтми узып булмый, революция ясаганда урынлы-урынсыз артык кызып китеп, кирәк-кирәкмәгәндә «йомычка очыру» белән мавыгу галәмәте дә чагыла монда.

Габбас мулланың иң зур фаҗигасе шунда: ул боларның вакытлы күренеш кенә, зур эш кузгатканда әйләнгән баштан килеп чыккан сикеренүләр һәм җикеренүләр генә икәнлеген аңламый.

Тизрәк «яңача күренергә» тырышып ясалган мондый «сикеренүләр», әлбәттә, махсус эшләнгән эш түгел иде, ләкин ничек кенә димик, андый хәлләр булды. Әсәрдә үзенчә бик тә колоритлы фигура булып күренеп калган шул Уразаева үзе генә дә ни тора!

Аның Алабугада мөгаллимә түтәенең шыр өендә уналты-унҗиде яшьлек гөнаһсыз Нурия белән беренче очрашу картинасын искә төшерик.

— Тәмәке тартасыңмы? — Нуриягә биргән беренче соравы бу аның. Колакка сыймас бу сүздән аптырап калган Нурияне — бу «буржуй калдыгы чукынчыкны» күреп, тагы да мыскыллый төшү нияте белән, Уразаеваның шунда ук икенче тәкъдиме дә әзер:

— Әйдә, алайса, аракы эчәбез.

Ышанып әйтергә мөмкин: ул минутта аның бернинди аракысы да юк, чак-чак кына паекка тиенеп торган ул авыр көннәрдә аракы булуы мөмкин дә түгел. Ләкин ул ике дә уйламый, әйтә, аның бердән бу «буржуй калдыгы» туганын мыскыл итәсе килә. Икенчедән, шулай зәһәр сөйләшкәч һәм, ирләрчә, итек кунычына камчы сабы белән суккалап йөргәч, яңача — революционерларча чыккандай күренә.

Соңга табарак, Уразаеваның «революционерлыгы» Габбас мулла Казаннан кайткач, Габбасның хатыны Хәнифәне, икенче төрле әйтсәк, үзенең җиңгәсен чакыртып, аңардан сорау алу картинасында күренә. Монда инде ул бөтенләй кешеләрчә сөйләшә белү сәләтен үк югалткан, анда тик каеш-каткан кәҗүнни сүзләр генә торып калган.

Я, тасвирлап торган булабыз. Галстук тагып йөрүне мещанлыкка санап каһәрләү, кызларыбызның, чәч толымнарын кистереп ташлап, шакмаклы кепка киеп йөрү өлгеләре булмадымыни?!

Авторның батырлыгы: ул дөньяның шул чордагы хәлләрен тик уң яктан күрү

һәм күрсәтү белән генә чикләнмәгән, аның тискәре яклары булганлыгын да әйткән һәм гүяки безне алдагы эшләребез өчен кисәткән.

Аңлы рәвештә табылган детальдер дип әйтә алмыйм, ихтимал, әлеге шул безне эчтән этәрә торган иҗат интуициясенең этәрүе аркасында килеп чыккан могҗизадыр. Габбас мулланың зират эчендәге ак каен ботагына асылынуы да күңелне эзсез калдырмый. Юкса, бу күңелсез финал өчен Габбас бүтән берәр караңгырак почмакны да тапкан булыр иде. Юк, ул нәкъ ак каенны тапкан. Кечкенә генә деталь бу, хәтта шул да бу фаҗигале үлемгә тонык кына булса да бер нур сирпи.

## Әйтер сүзең бармы? Үз сүзең?

**Ни әйтергә?**

Бу бәйләнчек сорау язучының башыннан бер вакытта да, куып караганда да китми. Әлбәттә, йокы сәгатьләрен искә алмаганда. Йокы дигәннән, язучының йокысын әйтер идем — бу яктан алла иң каһәрләгән җан ияләренең берсе язучы. Мин үзем, менә егерме ел инде, гел йокы даруы кулланам. Әле алай да өч-дүрт сәгать ничек кирәк алай йоклаганнан соң башлана: төшләр, саташулар, әллә кайчан булып узган мәхәббәт романнарының кире әйләнеп кайтуы. Кайвакытта камил бер сюжетка корылган төшләр дә күрәсең. Торып утыр да яз. Яшермим, минем төшләрдән төенләнеп киткән хикәяләрем бар. Әлбәттә, уянгач аны өнгә туры китереп, тормыш соравы белән яраштырып яңадан «эшләп чыгарасың».

Кыскасы, ансат түгел язучының эше, ай-һай ла, бер дә ансат түгел! Бик аптыраганнан булса кирәк, чын булса әгәр, Лев Толстой еш кына әйтә торган булган, имеш:

— Иблис уйлап чыгарган безнең бу газаплы эшне. Юкса, кеше чәчү чәчәргә, болында печән чабарга, сәхра-урманнарда сунарга йөрергә генә яратылган булган. Иблис — шуның өчен дә Иблис ич — күрә моны: адәмнең эше тоташ бәйрәм. Саф һавада җаны теләгәнне генә эшләп йөри. Көнчелегенә көч килә Иблиснең, адәм белән кайчандыр юк кына сәбәптән бәйләнешеп тә киткән булганнар икән болар, аның өчен дә кесәсендә таш саклап йөрткән булса кирәк, шикаять белән алла хозурына киткән бу.

Иблис булса да аны да алла үзе яраткан бит, тыңлый алла Иблиснең шикаятен, дөрес дип таба бу очракта. Сорый тегеннән:

— Соң нишләтим моның өчен адәмне? Дәгъваң урынлы, чара күрмичә калдырып булмый,— ди.

Иблис — шуның өчен дә Иблис бит, каһәр — тиз генә әйтергә ашыкмый. Тора алла каршында җилкәсен кашып, күңеленнән усаллык уйлап. Һәм озак уйлап торганнан соң, ниһаять, әйтә:

— Синең кушуың буенча, адәм хәзергә киң яланда чәчү чәчә, урак ура, печән чаба. Җиләс су буенда балык тота, урман-кырларда җәнлек атып йөри — шәп эшләр болар барысы да. Мондый җиңел кәсептән бер дә бер көнне синең ул адәмнәреңнең азынып китүләре дә мөмкин.

Уйга калдырды бит Иблис алланы, янә сорый алла Иблистән:

— Соң, синеңчә, тагы нишләтим мин ул адәм балаларын?

— Ә син аларга акыл эше дә җибәр,— ди Иблис явыз тантана белән,— кырдаяланда саф һава иснәп кенә йөрмәсен, өендә, өстәле артында акыл эше белән дә чиләнсен.

Әнә шуннан бирле адәм балалары акыл эше белән дә баш ватарга мәҗбүрләр, имеш.

«Ясная Поляна» утарында, Толстойның яшәү-эшләү шартларын сөйләгәндә, безне гыйбрәтле бер факт белән таныштырдылар. Толстой яшьрәк чагында, димәк, нервлары ныграк булганда өске катта, гаилә членнарыннан аерым бүлмә белән генә аерылып, эшли торган булган. Олыгаеп, нервлары какшый төшкәннән соң, ул югары өйләрдә бала-чага, кунак-төшем ыгы-зыгысы белән сыешып эшли алмый, астагы тимер ишекле, калын таш стеналы, чак кына караңгы, чак кына дымлы һавалы кладовкаларның берсен кабинеты итеп җайлатырга мәҗбүр була. Калганын

үзегез уйлагыз: граф һәм исеме дөньяга мәгълүм әдип Толстой — әллә ул бу көченүне язу эше уен булганлыктан эшләгәндерме?

Шулай да мавыгып киттем бугай мин. Бу очракта бит язучының кешеләргә — укучыларына әйтер сүзе, үз сүзе булырга тиешлеге турында тукталмакчы идем. Моны, әлбәттә, дөрес аңларга кирәк. «Үз сүзе» дигән сүз — бу заманнан, кешеләрдән, кешеләрнең зур ихтыяҗларыннан аерылу дигән сүз түгелме? Алай уйлау яки алай әйтү өчен фил сөягеннән корылган манарада, кайдадыр болытлар арасында, дөньядан аерылган шәп-шәрә эстет булырга кирәк. Ул манараны да әле космоска чыгышлый бәрәр җир ниярчененең бәрелеп, чәлпәрәмә китереп узуы мөмкин. Заманнан аерылган кешенең үз сүзе булуы мөмкин дә түгел. Бу яктан, Михаил Шолоховның чит ил журналистлары белән очрашканда әйткән үткен һәм төгәл сүзләре искә төшә: «Без йөрәгебездә булганны әйтәбез,— ди ул,— ләкин безнең йөрәкләребез тулысынча партиягә, халыкка бирелгән».

Моны шулай ук дөрес аңларга кирәк: художник партия карарларын, халык әйткәннәрне, җыелышларда сөйләнә торган дөрес сүзләрне иллюстрацияләп утыручы гына түгел. Художник боларның барысына да игътибар белән колак сала, аларга таяна, шул әйтелгәннәргә үз өлешен дә кертеп, халыкка хезмәт итү хисе белән яна, ләкин бу бурычларга якын килүдә, боларны ничек тә үтемлерәк итеп әйтә-җиткерә белүдә аның «үз сукмагы» бар, ул партия һәм халык әйткәнне, художник-гражданин буларак, үз җаны аша үткәреп, үз кайнарлыгын да кушып сурәтли. Шунсыз чын сәнгать әсәренең тууы мөмкин түгел.

Кызганычка каршы, еш кына болай да була. Әсәр бик тә актуаль темага язылган. Әсәрдә, тышкы яктан караганда, әдәби иншалауның барлык атрибутлары үз урынында. Тел ягы да яманларлык түгел. Шушы өстә күренеп яткан тышкы күрсәткечләренә карап, кайбер вак балык аулаучы «тәнкыйтьчеләр»нең бу әсәрне тиз генә мактап ташлаулары да мөмкин. Ләкин укыганда әсәр күңелне җылытмый. Аны укысаң да күз белән генә укыйсың, күңел белән түгел. Чөнки аңарга язучының үз күңеле, үз «иманы» салынмаган. Ул — күпмегә алган, шул бәягә үк сата.

Аннары безне соңгы вакытларда бердәй талантлы, бердәй шома, бердәй күпшы шигырьләр ташкыны баса башлады. Боларда мин шагыйрьнең үз фикере юк дип әйтмәс идем. Киресенчә, боларда бөтенесендә шагыйрь тик үзе генә, үзенең «мин»е, үзенең үткәне, үзенең сагышлары, үзенең табышлары... Боларда социаль тормыш, аның кешеләре, көрәшләре һәм җиңү шатлыклары җитми.

Кул астында гына булганлыктан, менә мин «Казан утлары» журналының 1977 елгы 4 нче санын ачып, анда басылган шигырьләрне күзәтеп утырам. Роберт Әхмәтҗанов, Фаил Шәфигуллин, Мөдәррис Әгъләмов, Шамил Маннаповларның бәйләм-бәйләм шигырьләре басылган. Начар шигырьләр түгел. Арада кеше күңеленең нечкә кылларын тибрәтә алырдайлары да бар. Ләкин бөтенесе өчен дә уртак характерлы бер кимчелек: һ. Такташның «Тун трагедиясе» җитми бу шигырьләргә. Искә төшерегез әле: нинди шаян-шук, уен-көлкеле Такташ анда.

**һәрбер минут, һәрбер секунд өчен**
**Көрәш бара совет илендә**
**Ә мин**
**һәр көн утырып сезнең тунны ямыйм,**
**Өч-дүрт сәгать уза кимендә...**

— дип, тиешле сыйфат күрсәткечләрен җиткермичә сатуга товар чыгарган меховой кешеләренә чын ихластан үпкә белдерә шагыйрь. Әллә бездә үпкә белдерерлек яклар юкмы? Унынчы бишьеллыкны нигездә сыйфат бишьеллыгы дип атыйбыз. Ни өчен без үзебезнең нечкә уйлый, кичерә, сагышлана белүебез белән мактануны булдырабыз да, кибеткә брак чыгаручыларга тузынып ачулана белмибез?

Була тагы шундый шигырьләр. Боларында нечкә итеп уйлый белү дә юк, шагыйрьнең үз шәхесе дә юк, сөйгән кызы да юк. Аның каравы, күперенке пафослы строфалар су буе сузылган, шагыйрь ул строфалар арасындагы мәгънәви уртаклыкны табарга да тырышмый. Чөнки авторның иң элек үз фикере юк. Бер иптәшнең бик оста тотып алган образлы әйтмешенчә, ул буш мичкәгә чукмар башлы саллы таяк белән сугып тора, сугып тора. Буш мичкәдән зур тавыш чыгып тора, чыгып тора... Ләкин, кызганычка каршы, буш тавыш. Менә нәрсәгә дә китерә ул үз фикерең булмау.

Ренат Харис

# ТАТАРСТАН АРТИСТЛАРЫ ИТАЛИЯДӘ һӘМ МАЛЬТАДА

Кеше гомере буе сәяхәттә. Сәяхәт кешене төрле җирләр, сулар, таулар белән таныштыра, аны көтелмәгән кыенлыклар аша үткәрә, шаккатыра, уфтандыра, уйландыра. Сәяхәт кешене кешегә илтә, илне ил белән тоташтыра. Сәяхәтнең иң олы хасияте тагын шулдыр ки — ул тормышны тагы да ныграк яратырга, туган илеңнең гүзәллеген таный, аның кадерен белергә өйрәтә. Менә мин дә Италиядә, Мальтада язган көндәлегемне кулыма алып укый башлаган идем, җөмлә беткән саен тукталып, әледән-әле Казаным урамнарына, болытлары төрле сурәт ясап аккан күгенә, тротуар буендагы юкәләргә, тыныч кына атлап баручы кешеләргә, төзелешләр тузаны белән кершәнләнгән машиналарга сөеп һәм сөенеп туя алмыйча карыйм. Көндәлегемдәге һәр җөмләм күз алдымда реаль урамнар, шәһәрләр, күренешләр, кешеләр булып яктыра. Ышыксыз тыгызлык уйны тумыштан күнеккән иркенлеккә, тынычлыкка, салмаклыкка борылырга мәҗбүр итә. Нигә сынаганым бар — чит-ят ил иң беренче көннәрне зиһенеңне чуалта, шаккаттыра, ә күп тә үтми, син үзең дә сизмәстән туган илеңне сагына башлыйсың. Туган ил, әлбәттә, җир, су, һава гына түгел. Туган ил, иң беренче нәүбәттә, шул җир, су, һава, шәһәр-авылларны йөрәкләреңдә йөртүче кешеләр, синең фикердәшләрең, хезмәттәшләрең, дусларың, туганнарың. Чит-ят илләр ял иткәндә дә ялыктыра, үз илеңдә эшли-эшли рәхәтлек кичерәсең...

Италиядә һәм Мальтада алып барган көндәлегем, билгеле, матбугатта чыгарып өчен түгел иде. Уйлавымча, куен дәфтәренә теркәлгән уй-фикерләр, төрле тәэсирләр киләчәктә зур бер кульязма я булмаса очерк язарга ярдәм итәргә тиеш иде. Шул исәп белән аны кулыма алдым да. Укый башладым — кызыксынып киттем. Татар җыр һәм бию ансамбленең кырык елдан артыкка сузылган һәм тагын бик күп еллар катламланачак тарихының шул 21 көне кәгазьгә теркәлгән булуы бик мөһим кебек тоелды миңа. Шуңа күрә язмаларымны көндәлек килеш матбугатка бирүне уңайрак санадым.

**29 июнь,1978 ел.** Без — илле кеше, җыр һәм бию ансамбле артистлары һәм җитәкчеләре, тагын берничә рәсми вәкил — ТУ-154 М самолетында, ә самолет унбер мең метр биеклектә. Юлга әзерләнү мәшәкатьләре, самолетка утыру ыгы-зыгылары артта, алда — Италия, Италия коммунистлар партиясе үзәк органы «Унита» газетасының фестивале, «Италия — СССР дуслыгы җәмгыяте» оештырган концертлар. Мин үзем Италиягә республикабыз Культура министрлыгы хезмәткәре буларак, артистларыбыз группасының рәсми җитәкчесе сыйфатында барам.

1978 елның февраль — март айларында РСФСРдагы җыр һәм бию ансамбльләренең смотр-конкурсы булды. Безнең Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле РСФСР күләмендә икенче урынны алды. Аннан элек тә Мәскәүдәге концертларда ул үзен яхшы яктан гына күрсәткән иде. Игътибар иттеләр, бәһаладылар — менә без беренче тапкыр сәнгатьләр мәркәзе булган Италиягә очабыз. Татар совет сәнгатен ничек кабул итәр бу «Ла Скала» һәм Европа балетының туган иле?.. Бигрәк тә безнең җырларны... Биюнең теле интернациональ. Ә җырның сүзләре бар, үзенә генә хас милли моң-аһәңе бар. Күбебезнең күңелендә хәвефле сорау. Ул бигрәк тә Илгиз Мәҗитовның, Нәфисә Василованың, Гали Ильясовның, Лима Кустабаеваның күзләрендә ачык чагыла.

Салонда кемдер нәзек кенә иттереп авыз гармунында «Мәскәү яны кичләре»н сыздырып җибәрде. Италиянең бер төркем врачлары «СССР — Италия дуслыгы җәмгыяте»нең чакыруы буенча Ленинградта һәм Мәскәүдә булганнар. Совет дуслык җәмгыятьләре союзы вәкиле булып баручы В. А. Воронцов алар белән нидер сөйләшә. Италия врачлары делегациясе бе-

лән бергә безнең илгә «Италия — СССР дуслыгы җәмгыяте»нең Комо шәһәрендәге җирле оешмасы җаваплы секретаре Бруно Саба да килгән булган. Безнең маршрут Комо аша да үтә. Бруно Саба безнең киләсене алдан ук белеп тора икән. «Концертларыгыз спорт сараенда булачак», ди.

Өч сәгать ярым вакыт узып та бара. Стюардесса саклагыч билбауларны каптырырга кушты. ТУ-154 Италия өстендә. Таулар. Кайберләренең түбәләрендә кар. Самолет тагын да аскарак төшә. Иллюминаторларда Гоген картинасын я Сарьян полотноларын хәтерләткән күренешләр чагыла. Күз күремендәге бөтен җирдә йортлар, йортлар, йортлар. Кырлар юк, кырлар күренми.

... Исән-сау килеп төштек. Без Милан дип уйлаган урын «кырлар» булган. Аэропорттан шәһәргә 72 километр икән әле. Автобуста барабыз. Италиядә безне «Италтурист» вәкиле Изабелла йөртәчәк. Автобусыбызның шоферы Франко, ансамбльнең багажын һәм реквизитларны ташучы фургонның шоферы Антонио. Өчесе дә Римнан, әлегә кадәр беркайчан да бергә эшләмәгәннәр.

Мәшһүр «Фиат» фирмасында уңайлык өчен бөтен шартын китереп эшләнгән автобус Миланга таба чаба. Артистлар, кызыксынып, Европадагы алга киткән капиталистик илләрнең берсе булган Италиянең «тышкаргы» ягын карап баралар. Юлның ике ягында йортлар, йортлар, йортлар. Йортлар арасында кечкенә-кечкенә басулар. Бодайлар сап-сары. Кайбер кырларда хәтта футбол да уйнап булырлык түгел — бик кечкенәләр. Ашлыкны ничек җыялар икән? Техника борыла да алырлык түгел ич монда!

Автобус юл аша тезеп куелган будкалар янында лып итеп туктады. Таблода өч сан пәйда булды. Беренчесе — машинаның классы, икенчесе — авырлыгы, өченчесе — юл өчен түлисе акча саны. Бу юл кемнеңдер шәхси милке икән. Кердеңме — түлә.

Юл буендагы йортлар әкренләп ешая, тагын да тыгызлана төште, биегәйделәр, ачыклыклар сирәгрәк күренә башлады. Соборлар, һәйкәлләр, мәйданнар... Без инде Милан уртасында икәнбез.

«Эсперна корона» дигән отельгә урнаштык та, кичке аштан соң, шәһәр белән танышырга киттек. Бу очракта кызыксыну талчыгудан көчлерәк иде. Миланда безнең концертлар юк, иртәгә иртүк башка шәһәргә китәчәкбез. Милан белән танышу өчен бердән бер вакыт — шушы төн.

Изабелла, кешеләрдән сораша-сораша, безне Миланның иң күренекле мәйданына алып китте. Кичке сәгать тугыз — ике ярым миллион кеше яшәгән Милан буп-буш. Гидның әйтүе буенча, беравыктанрак урамнарда кеше артачак. Ләкин төнге унберд дә урамнар буш иде. Тикмәгә түгелдер, күрәсең...

Бара торгач, котмәгәндә, Ла Скала бинасы янына килеп чыктык. Тыштан җыйнак кына өч катлы бина. Кайчандыр ул собор булган диләр, сәхнә уйганнар, креслолар урнаштырганнар, иң яхшы җырчыларны, иң атаклы дирижерларны чакырганнар һәм... ходай йорты сәнгать храмына әверелгән. Бу театр сәхнәсендә кемнәр генә җырламаган — Энрико Карузо, Таманьо, Анжелло Мазини, Федор Шаляпин... Ла Скалада соңгы елларда совет җырчылары Владимир Атлантов, Тамара Синявская, Мөслим Магомаев һәм башкалар осталыкларын арттырып кайттылар...

Гали Ильясов атаклы театрның кытыршы стеналарын сыйпый, «шушында хәтле килеп тә кереп булмас микәнни?» — дип уфтана, борын аша гына «Риголетто»дан герцог ариясен көйли. Кызлар, егетләр шаярталар: «Казанга кайткач әйтербез инде — Гали Ла Скалада җырлады, диярбез».

Сезон беткән. Бүген инде төнге сәгать 10, ишекләр бикле, ә күңел моның белән һич кенә дә ризалашмый — «бәлки»гә өмет итә. «Бәлки ачарлар», — ди филармониянең художество җитәкчесе Илгиз Мәҗитов Ла Скаланың ишекләрен шакылдата-шакылдата. Әмма ачучы юк.

Ла Скаланың бикле ишекләренә Италиянең, дөньяның иң атаклы даһиларыннан берсе Леонардо да Винчи һәйкәле карап тора. Ә һәйкәл артында, муниципалитет бинасы астыннан, гаҗәеп бер коридор — Милан салоны башланып китә. Салон аша без зур төркем булып шәһәрнең иң шөһрәтле мәйданына, атаклы Милан соборына килеп чыктык. Тирә-юнь яп-якты. Реклама утлары могҗизалар ясый, «фокуслар» күрсәтә. Албасты зурлыгындагы ханым алты-җиде катлы йорт түбәсендә зәңгәр куллары белән язу машинкасының сары клавишларына басып утыра, икенчесе, ир албасты, трубкасыннан төтен боҗралары җибәрә... Реклама, реклама, реклама.

Яктырак багана астына килеп, Милан соборы фонында фотога төштек. Меңәрләгән вак декоратив детальләрдән торган бу бинага кагылып китсәң, гаҗәеп музыка агылыр кебек. Гигант бина — орган уйнамый, тик тора, әйтерсең лә, йокыга талып бара торган Миланның сулышы җитми, клавишларга баса алырлык көчле бармаклары бихисап күп барларда, ресторннарда, я рюмка, я кызлар тезе тотып утыра...

**30 июнь, 1978 ел.** «Эсперна корона» отеленең бишенче катындагы яхшы гына бер бүлмәдә торам.

Иртәнге җиде. Бүлмәдә автомобильле урам исе. Тәрәзәләрне ачтым. Егерме-утыз метр ераклыктагы күрше йортның бишенче катында да кайбер машиналар «уянганнар», ә йөзләгәне, алты катка тезелешеп, әле «йоклый». Дубултыдагы язучыларның иҗат йортында балконыма кергән нарат ботакларына карап:

> Балтыйк наратлары башы белән
> Башны куеп янәшә...

— дип язган идем, хәзер:

> Милан машиналары белән мин
> Бер этажда йокладым,

— дип, бәлки берәр шигырь язармын әле Казанга кайткач.

Ярар, җитте — озак язарга вакыт юк. Хәзер иртәнге аш, аннары — юлга, Брешиа шәһәренә. Анда безнең беренче концертыбыз булырга тиеш.

Бетон автострада безне бик җайлы гына Брешиа шәһәренә китереп җиткерде. Альп тауларының сөзәк итәгенә урнашкан бу шәһәр металл эшкәртүчеләр каласы икән. Аңа инде 2300—2400 яшь, һәм ул горур рәвештә борынгы Рим дәүләте чорыннан калган хәрабәләрне саклый.

Концертыбыз спорт сараенда булырга тиеш. Отельгә дә урнашып тормыйча, шунда юнәлдек. Тимер һәм пыяладан корылган түгәрәк бина. Капкаларында безнең концертка махсус чыгарылган афишалар.

Зал уртасында бокс рингы сыман сәхнә әзерләнгән. Биючеләр аяк очлары, үкчәләре белән сәхнәне сыныйлар, җырчылар чын көчкә җырлап залның акустикасын тикшерәләр. Биючеләрнең дә, җырчыларның да, Илгиз Мәҗитовның да йөзләре чытык. Тагын бер уңайсызлык — сәхнә уртада. Дүрт якта да тамашачылар булачак. Кемгә йөз куеп, кемгә арка куеп биергә һәм җырларга? Казанда күрелгән хәстәр бу залга яраксыз. Мәҗитов баш вата. Без, группа җитәкчеләре, аңа төрле киңәшләр бирәбез, бер-беребез белән бәхәсләшәбез.

Амбаскиатори дигән отельгә китерделәр. Инде сәгать көндезге ике. Урнашып та тормадык, төшке ашка утырдык. Көндезге өчтә тагын спорт сараена репетициягә киттек.

Артистлар репетицияләрен башлагач, «Италия — СССР дуслыгы җәмгыяте» җирле оешмасының җаваплы секретаре синьор Маэстри группаның рәсми җитәкчеләрен муниципалитет мәйданына, пьяцца делла Лоджага алып китте. Дүрт ел элек, бу мәйданда митинг барган вакытта, фашистлар тарафыннан чүп урнасына яшерелгән бик куәтле бомба шартлаган, дистәгә якын кеше шунда ук үлгән, йөздән артык кеше авыр яраланган. Бөтен Италия фашистларга каршы манифестацияләр оештырган. һәлак булган эшчеләр хөрмәтенә мәйданга, бомба шартлаган урынга, чәчәкләр куйдык.

Муниципалитетта безне Брешианың мэры көтә икән. Кереп киттек. Мэр Требики — илле-илле биш тирәсендәге чандыр кеше. Христиан-демократлар партиясеннән. Ничек килеп җитү, беренче тәэсирләр, кәеф турындагы традицион сораулар, аннары рәсми котлау. Мин мэрны бүген булачак концертка чакырдым һәм без чыгып киттек. Мэр кулында Казан медале, альбомы, грампластинкалар калды, башында татар түбәтәе калды.

Спорт сараенда репетиция тәгәлләнеп килә. Егетләрнең, кызларның йөзләре тынычланган. Хормейстер Лима Кустабаева һәм балетмейстер Раилә Гарипова хәтта елмая алалар. Безнең янга Илгиз Мәҗитов килде дә: «Борчылмагыз, концерт тиешенчә булыр», — диде, аннары радистлар белән микрофоннарны урнаштырырга китте.

20 сәгать 30 минутта башланырга тиешле концерт 21 сәгать 10 минутта башланды. Бу шәһәрдә халык шуннан да иртә җыелмый икән. Халык уен кораллары оркестры беренче аккордны алды, «Сарман»ны җырлап, бизәкле милли киемнәрдән хор килеп чыкты, зал буйлап сәхнәгә үтә башлады. Дүрт мең кеше сыйдырышлы залны көтелмәгән алкышлар күмеп китте... Җырлар да, шаян биюләр дә алкышлар белән каршы алына, «Аулак өй» композициясен дә бик җылы кабул иттеләр.

Концертның беренче бүлеге көтелмәгән дәрәҗәдә, әмма нәкъ без теләгәнчә, уңышлы үтте. Хор һәм җырчылар, залның түгәрәк икәнен истә тотып, йөзләре белән әле бер, әле икенче якка әйләнеп җырлыйлар, биючеләр дә шулай ук. Кыен, ләкин түзәргә туры килә, өстәмә көч сарыф итәлә, нишләмәк кирәк!

Концертның икенче бүлеге башланыр алдыннан мин тагын бер мәртәбә киенү бүлмәләренә кереп чыктым. Хордагы егетләргә дә, кызларга да бер бүлмә, биючеләргә шулай ук уртак бер бүлмә. Кысан. Ун спортчы чишенеп киенә торган бүлмәләрдә — егермешәр кеше һәм һәрберсенә баштанаяк унбишләп өс киеме. Өч-дүрт минут, алты-җиде минут бара торган биюләр, җырлар бар. Шул арада артистларга кием алыштырып, грим салып өлгерергә кирәк. һәр кием, әйбер урынында булырга тиеш, һәр хәрәкәттән төгәллек таләп ителә.

Алда — концертның икенче, катлаулы өлеше. Тамашачының, концертны оештыручыларның безгә карата булган уңай фикерен тагын да ныгытырга кирәк. Артистның даны һәр вакыт үзеннән алданрак йөри, ә ансамбль — коллектив артист. Иң мөһиме — совет сәнгатенең олы данына хилафлык китермәскә! Моны барысы да аңлый. Артистлар тиргә баткан, артистлар тырыша, алар яңадан сәхнәгә елмаеп чыгарга әзер.

Концертның икенче бүлеген көмеш кыңгыраулы «Язгы моң» биюе башлап җибәрде. Ул бик эффектлы көмеш чың белән бетәргә тиеш иде, ләкин чыңны темпераментлы итальяннарның көчле алкышлары күмеп китте. «Егетләр биюе», «Бишле бию», «Әпипә» — алкышлар, алкышлар, алкышлар. Җырчы-солистлар Нәфисә Васильова, Миңнегөл Зәкиева, Гали Ильясовларга итальян тамашачылары алдында имтихан тотарга вакыт җитте. Аларга гына түгел, татар җырына да! М. Зәкиева башкаруында «Сибелә чәчәк», «Фазыл чишмәсе, Н. Васильова башкаруында «Чибәр кыз» һәм «Кәккүк» җырчылар илендә яшәүчеләргә бик хуш килделәр. Итальяннар татарның моңлы озын җырларын яратарак төште. Нәфисәнең күкрәгеннән ургылып чыккан моңлы тавышы тамашачыларга аерата көчле тәэсир итте. Сәхнәгә Гали Ильясов чыкты, оркестр итальяннарның бик мәшһүр халык җыры «Фуникули-фуникула»ның беренче аккордларын алуга, залда алкышлар зилзиләсе купты. Ул зилзиләне фәкать Галинең көчле теноры гына беравыкка баса алды. Бик озак кул чабулардан соң оркестер «Калинка»ны уйнап җибәрде. Гали «каааааааалинка»дип әйтергә өлгермәде, аңа бөтен зал кушылды. «Калинка»ның дәвамы буларак сәхнәгә чыккан рус халык биюенә дә тамашачылар озак кул чаптылар. «Казан кунаклары» биюе беткәч залда «браво»,

«бис», «грацие» дип кычкыра башладылар. Грим бүлмәләре тирәсенә халык җыелды. Бездән значоклар сорыйлар. Без уңыш шатлыгыннан уңга-сулга значок таратабыз — башка көннәргә дә бераз калса ярый инде...

Шунда бер татар кызы да килеп чыкты. Былтыр Чаллыда бер итальян егетенә кияүгә чыккан икән. Әлегә эшләми, итальян телен өйрәнә. «Эшкә керергә бик исәп тә, — ди, — тәрҗемәче булып... алсалар» — ди. «Ә алмасалар?» — дим. «Алмасалар... белмим инде...» — ди. Иреннәре елмая, күзләрендә моң.

Концерттан соң отельнең вестибюлендә «Санта Чечилия» концерт оешмасы татар совет артистлары хөрмәтенә банкет бирде. Ганс Сәйфуллин баянын алып «Мәскәү яңы кичләре»н сыздырып җибәрде. Аңа алтмыш-җитмеш кешелек хор кушылды. Төнге сәгать бер. Иртәгә иртүк юлга.

**1 июль, 1978 ел.** Комо шәһәренә килеп җитәбез дигәндә генә автобусыбыз юл өстендә туктап калды, ә юл өстендә туктап торырга һич ярамый. Карасак — алда машиналар тыгылышы. Юл өчен акча алу пунктлары машиналарны тиз үткәрә алмый икән. Чиратның озынлыгы ике-өч километр. Машиналар биш-ун метр алга китәләр дә тагын тукталар.

Ашыкканда ни эшләмәк кирәк? Кыршап куелган юлдан читкә чыгу шулай ук мөмкин түгел. Бик ашыксаң, юлның керергә ярамый торган рәтенә кер дә, егерме биш мең лир штрафыңны түлә дә, әйдүк, уза бир...

Комо шәһәрендә безне самолеттагы танышыбыз Бруно Саба каршы алды.

Альп таулары эченә елышып, гаҗәеп матур күл буенда утырган бу шәһәр Швейцариягә яп-якын. Ул асылда курорт һәм ял шәһәре. Элек-электән дә, хәзер дә бирегә ял итәргә язучылар, композиторлар, рәссамнар килә икән.

Бруно Саба горурланып Комоның бөек кешеләре турында сөйли. Бирегә Рим чорының мәшһүр ике язучысы һәм хөкүмәт эшлеклеләре, ике туган — Олы Плиний һәм Кече Плиний яшәгәннәр. Комо — электр өлкәсендә зур ачышлар ясаган галим Александро Вольтаның туган шәһәре икән. Вольтаның кабере дә Комода.

Концерт «Габетти» дигән данлыклы мебель фирмасының спорт сараенда булды. Бу фирманың баскетбол командасы (исеме — шулай ук «Габетти») бер-ике ел элек Италия чемпионы булган икән. Спорт сарае — фәкать баскетбол өчен генә. Килеп кергәч үк төрле рекламаларның муллыгы күзгә ташлана. Табло астында, судьялар утыра торган өстәлләр тирәсендә, ягъни күз ешрак төшә торган урыннарда «Габетти»ның үз рекламалары, калган урыннарда — башка фирмаларныкы. Һәр реклама өчен спорт сарае акча ала.

Баскетбол мәйданы шома. Күн табанлы читекләр, туфлялар таеп-таеп китә. Егылып имгәнүең дә бар. Биючеләр Фердинанд Гыймадиев, Равил Хәлиуллин, Мостафа Нигъмәтҗанов, Эдуард Закиров идәнгә канифоль сибеп чыктылар...

Концерт кичәгедән дә оешканрак узды — ни әйтсәң дә хәзер тәҗрибә бар, без бит инде икенче тапкыр спорт сараенда чыгыш ясыйбыз. Дөрес, программада әллә ни үзгәреш булмаса да, оештыру ягыннан бусы да әр-яңа концерт булып чыкты. Бу юлы да ансамбль Италия тамашачылары алдында совет сәнгатенең абруен югары тотты. Изабелла, Франко, Антонио, Бруно һәм концертны оештыруда катнашкан кешеләр килеп, кайсы биюче Мостафа Нигъмәтҗановны, кайсы «Ку-ку, мецо-сопрано, гуд-гуд» дип Нәфисә Василованы мактый, ә кайберләренә Фердинанд Гыймадиев башкаруында гашыйк карт биюе («Әпипә») аеруча ошаган. Концерт бетеп өлгермәде, «Габетти»ның хуҗасы — кырык биш яшьләрдәге миллиардер, баскетбол кырына йөгереп чыгып, аны кулы белән капшарга кереште. Ул безнең концертны бер генә мәртәбә дә кул чапмыйча карады. Күзләрендә борчу иде — күрәсең, татарлар баскетбол мәйданын биеп харап итәрләр дип куркып утыргандыр... Борчылмагыз, синьор миллиардер — бию эзләрен саклаган идәннең абруе зур була.

**2 июль, 1978 ел.** Барыбыз да акклиматизация чоры кичерәбез. Өченче көн Камил һәм Люда Шамуковалар авырып алды. Кичә Нәфисә Василова автобуста гел ятып барды, ә шулай да концертта сер бирмәде. Бүген Нәфисә дә, Раилә Гарипова да авырыйлар. Павия шәһәренә килеп җитеп отельгә урнашкач ук аларны карарга врач чакырттык. Килде, сорашты, тыңлап карады. Градуснигы юк. Мин үземнекен алып кердем. Рецептлар язып бирде. Аптеканың адресын әйтте һәм... кесәсенә 34 мең лирны салып чыгып китте...

Ансамбль, биш-алты кешелек группаларга бүленеп, шәһәр белән танышырга китте. Шәһәр уртасыннан Тичино дигән елга ага. Ярларында сирәк-мирәк кенә көймәләр дә күренгәли. Урамнарда да, яр буйларында да, матур-матур күперләргә дә «Тичино елгасында Павиядә һәм провинциядә су коену катгый рәвештә тыела» дигән зур белдерүләр куелган. Химия предприятиеләре Тичиноны бик тә әшәке, хәтта агулы су коялар икән.

Павиядә һәйкәлләр күп. Гарибальдига, Италияне Австрия илбасарларыннан азат иткәндә җиде улын югалткан анага мәһабәт һәйкәлләр, шагыйрьләргә, композиторларга... Ләкин бер генә һәйкәл дә чистартылмаган. Сыннарның каш аслары, ияк аслары, кием бөрмәләре, култык аслары дегет төсле кап-кара. Бу — ил күләмендәге хәл икән. Куелган һәм онытылган һәйкәлләр!...

Бу юлы концерт Висконти замогында булды. 1360 елдан башлап 400 ел буена төзелгән, ныгытылган бу замокта хәзер төрле музейлар эшли. Замокның квадрат ишегалды ямь-яшел чирәм. Сәхнәнең такта идәне ярганып беткән. Көндез Илгиз Мәҗитов аңа фанера кадаклатып, имгәнүдән курыкмыйча биеп булырдай дәрәҗәгә җиткерткән. Һава салкынча. Артистлар ачык һавада чишенеп киенәләр. Аларга бүген микрофонсыз чыгыш ясарга туры

килә — радиоаппаратуралары юк икән. Ансамбль җырчылары микрофонга ябышып ята торганнардан түгел, үзебезнең илдә һәр вакыт диярлек микрофонсыз чыгыш ясыйлар, ләкин махсус концерт залларында, өч-дүрт мең кеше сыйдырышлы ачык мәйданда ни эшләмәк кирәк? Ярар, бусына да түзәрбез. Концертны 1 сәгать тә 20 минутлык кына итеп бер генә бүлектән бирүне сорыйлар. Бер икән бер, ярый, бусын да үтәрбез. Тагын өр-яңа концерт.

Музыкантларга да, җырчыларга да бүген көчне күбрәк кулланырга туры килде. Концерт уңышлы үтте. Дөрес, инде микрофоннарга күнеккән һәм җайлашкан артистларда да, бездә дә ул бераз сәеррәк тәэсир калдырды. Чәчрәп торган, яңгыравыклы концерт булмады, ә тамашачыларга бик ошады. «Бель канто!» — дип солистларның, хорның, оркестрның чиста яңгыраганлыгын әйтәләр.

Концерттан соң Павиянең компартия шәһәр комитеты вәкиле, аннары «Италия — СССР дуслыгы җәмгыяте» хезмәткәре сәхнәгә чыгып безгә рәхмәт сүзләре әйттеләр, Италия компартиясенең 50 еллыгына багышланган истәлек медальләре тапшырдылар. Без исә аларга Казандагы Владимир Ульянов һәйкәленең бронза копиясен, пластинкалар, альбомнар бүләк иттек.

**3 июль, 1978 ел.** Нәүбәттәге шәһәр — Алассио. 120 километр тизлектә шунда барабыз. Һәр көн иртә белән Виктор Воронцов «автогазет» сәгате үткәрә — Италия газеталарының иң кызыклы хәбәрләрен микрофон аша безгә тәрҗемә итә. Кичә Римда, Миланда неофашистларның бомбалар шартлатулары турында язганнар иде, бүген Италия якшәмбене тыныч үткәргән икән.

Ганс Сәйфуллин баян уйный, бөтен автобус «Бандьера росса»ны өйрәнә. «Кызыл байрак» дигән бу җыры Италия коммунистларының, икенче Бөтендөнья сугышы вакытында Италия партизаннары хәрәкәтенең гимны дип атап була. Автобус — безнең транспортыбыз да, йортыбыз да, эш урыныбыз да, репетиция бүлмәсе дә. Бер уйласаң, гаҗәеп мизгел — бетон автострааны яңгыратып, сәгатенә 120-130 километр тизлек белән сугышчан «Бандьера росса» тып-тыныч курорт шәһәргә барып керде.

Лигурия диңгезе буендагы бу матур шәһәрнең бар белгәне — кешене диңгезгә, диңгезне кешегә тоташтырып табыш алу. Яр буендагы һәр метр җир кемдер өчен акча эшли. Әнә берәү, диңгездән тачка белән сулы ком ташып, авылдагы өй урыны зурлыгындагы пляжын киңәйтә. Ун-унбиш кеше кабул итешле пансионат хуҗасыдыр инде. Тагын бер-ике генә зонт куярлык урынны тир түгә-түгә диңгездән йолкый, ә һәр зонт үз хуҗасына табыш китерә.

Без яшәгән «Тоскана» отеленең дә үз пляжы бар. Пляж хакы отельдә яшәү бәясенә керә. Минем Казан, Мәскәү шартларында тәүлегенә 2 сум 50 тиен, 3 сум тора торган бер бүлмәле номерым 7 мең лир, ягъни 5 сум 80 тиен тора.

Алассиода һәйкәлләр күренми. Бәлки алар бардыр, ләкин күзгә ташланып тормыйлардыр. Концерт афишалары да бик сирәк очрый.

Бүген безнең концертлар юк — ял бирделәр. Күпчелегебез пляжда. Җырчы солистларыбыз гына су коенмыйлар — үзләрен иртәгә булачак концертка саклыйлар.

Пляждан кайтканда артистлар Алассиода политик плакатлар, лозунглар юклыкка игътибар иттеләр. Башка шәһәрләрдә алар һәр стенада диярлек иде. Аның каравы, бередә ярым шәрә я шәп-шәрә хатынкызлар сурәте төшерелгән сәүдә рекламалары күбрәк. Курорт шәһәр сәнгатьтән генә түгел, сәясәтнең көндәлек ыгы-зыгысыннан да качарга тырыша. Аның үз эше бар — диңгезнең җылы, зәңгәр суын кыштырдап торган лирларга, франкларга, долларларга, фунтларга әверелдерү.

**4 июль, 1978 ел.** Алассиода яшәп, күрше-тирәдәге ике шәһәрдә концертлар бирәчәкбез. Бүгенге концертыбыз Альбенгада, муниципалитет мәйданында булачак. Мәйданның муниципалитетка каршы ягында христиан-демократлар партиясе комитеты, түр якта мәһабәт собор, аңа каршы — компартия комитеты. ХДП комитеты ишеге тирәсендә партиянең милли советы председателе, Италиянең элеккеге премьер-министры, күптән түгел генә террористлар кулыннан һәлак булган Альдо Моро турындагы политик плакатлар эленеп тора. Италиянең бу зур политик эшлеклесен, хөкүмәт җитәкчесен үтерүчеләрне әле дә булса эзлиләр, таба гына алганнары юк. Эзләнүне үтенеп хәтта АКШ разведка органнарына да мөрәҗәгать итеп караганнар, ләкин тегеләр эзләшүдән баш тартканнар.

Мәйданга меңнән артык җыелмалы урындыклар тезеп чыктылар. Безнең өчен ясалган өр-яңа сәхнәдән чәер исе аңкып тора. «Болар бездән китерелгән такталар булуы да бик ихтимал»,— ди Владимир Дейнеко. Бер атна яшәргә дә өлгермәдек, туган җиребезнең хуш исен сагындык. Бәлки, Апеннин таулары чыршыларыдыр болар, ләкин алардан өр-яңа бура исе, Казан тирәсендәге ылыслы урманнар исе килә.

Сәхнә өстендә өч флаг җилферди — Италия дәүләт флагы, компартия флагы, ХДП флагы. Альбенганың мэры Анджело Вивери коммунист икән. Аның белән «Бандьера росса»ны җырлау мәсьәләсендә киңәшеп алдык. Аның фикеренчә, «Интернационал» булса шул җиткән. Компартиянең шәһәр комитеты секретаре исә һичшиксез икесен дә җырларга кирәк, ди. Мәйданның бер ягында ХДП комитеты икәнлекне дә искә алып, муниципалитетның культура бүлеге мөдире «Аве Мария!»не дә башкарырга тәкъдим итә. Юк, юк, без «Интернационал» белән дини гимнны янәшә куеп башкара алмыйбыз.

Урындыклар тулды, тамашачылар басып тора башладылар ,ә халык агыла да агыла. Билет сатып торучылар биргән мәгълүматка караганда, мәйданга 3000 кеше керде.

Концерт элеккеләреннән дә уңышлырак үтте. «Фуникули-фуникула»ны җырлый башлагач ук мәйданны алкышлар тетрәтә башлады. «Бандьера росса»ны җырлаганда,

мәйданның яртысы торып басып, безгә кушылып җырлады. «Интернационал»ны җырлаганда Виктор Воронцов һәм мин хор алдына чыктык, иң алга басып җырладык. Мәйдан торып басты, мәйдан йодрыкларын төенләде, мәйдан «рот фронттагы» кебек йомарланган йодрыгын күккә ыргыта-ыргыта җырлады. Күңел ачу концерты политик төс алды. Компартиянең шәһәр комитеты секретаре да, Альбенганың мэры да безгә зур рәхмәтләр әйттеләр, «сез компартиянең һәм муниципалитетның абруен күтәрүдә бик нык ярдәм иттегез!» — диделәр.

Инде бер атна кулга газета алып укыганыбыз юк, үз колагыбыз белән радиодан аңлаешлы хәбәр тыңлаганыбыз юк. Билгеле, үзебез гаепле — итальянча белмибез. Күзгә Алассионың пальмалары, купшы кибетләре, төрле-төрле рекламалар чагыла, ә күңел дөнья хәлләре белән кызыксына.

**5 июль, 1978 ел.** Луано шәһәрендә безнең концертны оештыруны туристлар оешмасы үз өстенә алган. Диңгез ярыннан ерак түгел машиналар туктый торган мәйдан. Бер якта биек стена, икенче якта елгамы шунда, каналмы. Ни булса да суы аз һәм әшәке. Вакытлыча төзелгән сәхнә өстендә галәмәт биек топольләр. Яфраклары сәхнәдәге артистларга кагылам-кагылам дип тора. Җил искән саен алар «шапылдавык» уйныйлар, ә диңгездән искән салкын җил көчәйгәннән-көчәя бара, микрофоннарда улый. Ара-тирә мәйданны сасы ис күмеп китә — әллә каналдан, әллә канализациядән... Мәйдан халык белән тулы, якын-тирәдәге күперләр дә, урамнар да, каналның теге як ярындагы урам да... Бер алты-җиде мең кеше булгандыр.

Җил җырчыларның тавышын йолкый, җил үзе җырламакчы — ул микрофон белән җырчыларның иреннәре арасыннан гүләп узгалый. Аңа тополь яфраклары шавы кушыла. Артистларның чишенеп киенә торган урыннары шактый ерак — алар бертуктаусыз йөгереп йөриләр. «Җылыныр өчен бу бик яхшы булды әле»,— ди Фердинанд Гыймадиев. Ә оркестрдагы кызлар туңалар, алар тиз генә биючеләрнең камзулларын бөркәнеп чыктылар. Диңгездән өргән суык җил җырчыларның тамакларына утыра. «Бандьера росса»ны да, «Интернационал»ны да җырламаска куштылар. Концерт түләүсез, теләсә кем керә. Киңәшләрен үтәдек. Концертны бөтен Европа кешеләренең күңелләренә хуш килгән данлыклы «Катюша» белән тәмамладык. «Италтурист»ның бу шәһәрчектәге җитәкчесе дә, «Италия—СССР дуслыгы җәмгыяте» секретаре Жианкарло Карена да: «Безнең өлкәдә әле мондый концертның булганы юк иде»,— диделәр. Безне киләсе елга фәкать Лигурия өлкәсенә генә кабат чакырмакчылар. Ихтыярыгыз!..

**8 июль, 1978 ел.** Алессандрия шәһәрендә һәм халыкара туризм үзәкләреннән берсе Ил Чиоккодагы чыгышлардан соң без, ниһаять, «Унита» газетасы фестивалендә. Лукка шәһәрендә ике көн күәтле яңгырлар булган икән, шуңа күрә фестиваль үтәчәк мәйданны әзерләп өлгерә алмаганнар. Крепость стенасы буена төрле лареклар тезелеп киткән: китап саталар, спорт товарлары, ювелир әйберләре, кием, су, сыра... Мәйданның бер башын зур-зур плакатлар, лозунг язган фанер щитлар белән әйләндереп алганнар, урындыклар куеп, сәхнә ясаганнар. Билет саталар.

«Унита» газетасы үткәрә торган фестивальләрнең төп максаты — Италия коммунистлар партиясен халык арасында популярлаштыру һәм партия бюджетына акча җыю. «Унита» киләсе елга нормаль чыксын өчен быел кимендә 12 миллиард лир акча җыярга кирәк икән.

Микрофонсыз, ике-өч лампа яктылыгында гына без концерт бирдек. Урамда машиналар гөрелтесе. Артистларның йөзләре дә, киемнәре дә ачык күренми. Концерт бер генә бүлектән булды. Безгә Италия тамашачыларының кызыксынулы күзләре яктылык биреп торды.

Компартия безнең хөрмәткә кичке аш әзерләткән. Мәйданның икенче башында гына шәһәр коммунистлары вакытлыча кафе корып җибәргәннәр. Шашлыклар, итләр кыздыралар, балык куыралар, спагетти пешерәләр. Кафе кереме дә компартия бюджетына.

70—80 кеше сыйдырышлы озын өстәл тирәсенә җыелдык. Мин компартиянең Лукка шәһәре комитеты секретаре Серджо Дардини иптәшкә Казан сувенирлары тапшырдым. Безнең өстәлне 300 гә якын кеше сырып алды. Ганс Сәйфуллин «Бандьера росса»ны уйнап җибәргән иде, иң алдан көчле алкышлар яңгырады, аннары җырны совет — итальян хоры күтәреп алды. Вакытлыча түшәмне тотып торган торба арматураларга малай-шалай менеп тезелде. Без җырлыйбыз, алар кызыл галстуклар болгап торалар.

Мәйдан өстендә «Катюша», «Мәскәү яны кичләре», татар халык җыры «Әй дусларым, дусларым» яңгырый. Иң соңыннан «Интернационал»ны җырладык. Халык безне автобуска хәтле озатып куйды. Отельгә иртәнге 4 тә генә кайтып җиттек. Күңел көр, чөнки зур эш эшләдек — итальяннарга үзебезнең ил турында, эшебез турында сөйләдек, сүзләр, җырлар, тостлар аша күңелләргә дуслык җепләре сузылды.

**9 июль, 1978 ел.** Ардженто шәһәрендә «Унита» фестивале тагы да оешканрак төстә үткәрелә. Бу шәһәрдә 23 мең кеше яши, шуның дүрт мең ярымы коммунистлар.

Күтәренке рухта үткән концерттан соң безне креветка, әкәм-төкәмнәр, еланбалык ите белән сыйладылар. Кайберләребез барысыннан да авыз итте, ә күпчелек тавык итен кулайрак күрде.

**11 июль, 1978 ел.** Форли шәһәренә барабыз. Виктор Воронцов газета хәбәрләре белән таныштыра. Яңа президент синьор Сандро Пертини мәрхүм Альдо Моро каберенә чәчәкләр куйган. Танылган кино актрисасы Софи Лорен инкогнито рәвештә Римга килеп күлмәк тектереп кит-

кән. Ул налог түләүдән куркып, дересрәге — берничә миллион лир түләмичә, туган иленнән Швейцариягә киткән һәм шунда яши икән.

Форлида безне өч отельгә урнаштырдылар.

Концерт стадионда булды. Капка янына ике тартма куйганнар да билет сатып торалар. Билет бәясе 1500 лир. Тамашачылар тартмаларга акча ташлыйлар да үтеп китәләр.

Сәхнә җирдән шактый ук биек. Урындыктагы кешеләргә артистларның билдән тиң өске яклары гына күренә. Еракларак китеп, я басып караганда әле ярыйсы.

Безнең янга компартиянең федерация комитеты секретаре килде. Бераз сөйләшеп тордык. Татарстан турында сорашты. В. И. Ленинның Казанда укыганлыгын белә. Татарларның илдәге саны белән кызыксынды, табигатьне саклау проблемалары хакында сорашты.

Мәйданга бик күп лареклар тезелгән. Авыл хуҗалыгы машиналары күргәзмәсе эшли. Шунда ук машиналар саталар. Арада безнең «Запорожец» һәм «Москвич» та бар. Плакатлар ларегы. Маркс, Ленин, Грамши, Берлингуэр, Кастро портретлары янында, бераз кулагәлерәк җирдә, Мао сурәте. Концерт авыр шартларда узды, чөнки стадионга кергәч үк тагын бер сәхнә куйганнар. Анда гитаралы, саксофонлы, барабанлы эстрада концерты бара. Сакаллы бер яшь композитор үзенең әсәрләрен башкара. Аны 300—400 кеше тыңлый. Ә безнең концертта кимендә 2500—3000 кеше. Стадион «Бандьера росса», «Интернационал»ны башкаручы совет артистларын алкышлый.

**12 июль, 1978 ел.** Бүген Италиядә соңгы концерт. Ул Әдрән диңгезе буена урнашкан Комаккьо дигән кечкенә генә шәһәрчектә. Сәхнәне «Өч күпер мәйданы» дигән урынга ясаганнар. По елгасының тар гына бер тармагында субайлар суккаңнар да сәхнә җиткезгәннәр. Билгеле, шәһәрдә концерт өчен яхшырак мәйданнар да булгандыр, ләкин монда романтика мулрак.

Концерт бик әйбәт узды. Амфитеатр булып урнашкан эскәмияләр, күпер өсләре халык белән шыгрым тулы. Көймәләргә төялеп керәләр дә, күпер ташларына тотынып, я якорь салып безне тыңлыйлар...

Концерттан соң без Римга юл алдык. Иртәнге 9 да без Рим аэропортында булырга тиеш. Автобус бу юлы гостиницага әверелде. Күбебез йокымсырый. Төнге сәгать ике, алда 700 чакрым юл...

**13 июль, 1978 ел.** Иртәнге сәгать 6. Барысы да диярлек йоклыйлар. Франко миңа борылып: «Рома», диде. Мин, микрофонны алып: «Егетләр, кызлар,— Рим», дип кычкырдым. Барысының да йокылары качты. Хәтта йокыны башкаларга караганда ныграк ярата торган җырчы солистлар да сузылып-сузылып автобус тәрәзәләренә карыйлар. Игезәк ике чиркәүне үтеп киттек, пьяцца ди Спанья мәйданына кердек. Италиянең шәһәрләре, гомумән, чиста, ә Рим урамнары исә алардан чүп-чарлы булулары белән аерылып тора. Италия парламенты бинасы янынан узып киттек. Халык мәйданы дип аталган мәйдан уртасында кайчандыр Мисырдан алып кайтып куйган мәһабәт колонна басып тора. Автобус бер мизгелгә генә Виа Каттани дигән урам каршысында тукталды.

Бу урамда террористлар Альдо Мороның үле гәүдәсен машинада калдырып киткәннәр. Шул урыны хәзер, вакытлыча булса кирәк, чардуган белән уратып алганнар. Чардуган өстенә ХДПның кызыл тәреле ак флагы башын игән.

Джованни Бернининың иң олы иҗат эше — Изге Петр мәйданы. Дүрт рәт колонналар белән әйләндереп алынган мәйдан әлегә йоклый. Фонтаннар да уянмаган. Кызгылт гранит һәм мәрмәрдән салынган Изге Петр соборы мәһабәт булып калкып тора. Аның артында руханилар иле — Ватикан. Борынгы Рим чоры хәрабәләрен карарга киттек. Барыбызның да тизрәк Колизейны күрәсебез килә. Башлангыч мәктәп дәреслекләре аша сабый чактан ук хәтергә сеңгән Колизей әле дә мәһабәтлеге белән шаккатыра. Быел Флавийның Колизейны төзеп бетерттерүенә нәкъ 1900 ел.

Колизей янында ук император Константинның триумфаль аркасы. Якында гына борынгы Римның административ һәм сәүдә үзәге булган Форо Романо хәрабәләре... Ләкин барысын да карарга вакыт калмады. Колизей фонында бер-беребезне фотога, киного төшердек, аннары тарихи ташларга соңгы мәртәбә күз ташлап, автобуска таба юнәлдек. Иртәнге тугызда инде без Леонардо да Винчи исемендәге халыкара аэропортта идек. Аэропортка килеп керү белән барыбызны да сагыну хисе биләп алды — илебезгә кайтасы килә. «Инде Мальтага бармыйсы иде»...— диештеләр артистлар.

Уникедә очасы самолет Мальтага 16.30 да гына очып китте. Хуш, Рим! Хуш, Италия!

Самолеттан Мальта республикасы бөтенләе белән күренә — яшькелт-зәңгәр диңгез уртасында көрән-сары ике утрау. Нәкъ география карталарындагы кебек.

Ла Валлетта аэропортында безне «Мальта—СССР дуслыгы җәмгыяте»нең генераль секретаре Пол Аджус каршы алды. Тәрҗемәчебезнең исеме Мария Аттард.

Диңгездән утыз-кырык метр гына ераклыктагы «Баллута» дигән отельгә урнаштык.

Бүген безнең концерт юк. Кичке ашны ашадык та, тизрәк йокларга яттык. Тәүлек ярым йокламау үзен сиздерә. Шуның өстәвенә — иртәгә ике концерт.

**14 июль, 1978 ел.** Иртәнге чәйгә җыелгач бер-беребездән сорашабыз: «Син бүген юындыңмы?» Барыбызның да җавабы бер: «Юк, чөнки су булмады».

Кичә, аны-моны белештермичә, без суны артыграк бетергәнбез. Мальтада төче су һәр өйгә, һәр учреждениегә һәм һәр

отельгә тәүлеклек норма белән генә биреләикән. Артыгын тотсаң я штраф түләтәләр, я су бирми торалар икән. Күрәсең, безнең хуҗа соңгысын сайлаган булган. «Төрле хәл булуы мөмкин — су сатып алып куйыйк», дип барга төштек. Бер литр су ярты литр коры шәрабтан кыйммәтрәк икән. Нишлисең — алдык һәм номерларыбызга менеп тиз генә юынып төштек.

Беренче концерт иртәнге унда балалар өчен булды. Аларның бүген уку еллары тәмамланган. Һәр класс үз укытучылары җитәкчелегендә килгән. Киноконцерт залы мең кешене сыйдыра ала. Мәҗитов, Кустабаева, Гарипова программаны балаларга яраклы итеп үзгәртәләр. Сәгыйть Хәбибуллин оркестрга мальталылар көен өйрәтә. «Һәр вакыт булсын кояш», «Крокодил Гена җыры» да безнең концертны балалар өчен кызыклы итте. Шаулатып кул чабалар. Иң соңыннан оркестр яңа гына өйрәнгән мальталылар көен уйнап җибәргән иде, бөтен зал торып басты. Бу көй Мальта гимны булып чыкты. Ә кичен, Мальтаның мәгариф хезмәткәрләренә биргән концертта, без гимнны хор белән җырладык. Бу очракта да ансамбль үзенең булдыклылыгын күрсәтте. Концертка Мальтаның мәгариф министры килгән иде. Беренче бүлектән соң ул премьер-министр янына киңәшмәгә китте. Аның хатыны ансамбльгә чәчәкләр бәйләме тапшырды. Мин Полдан аның кайда эшләгәнлеген сорадым. «Ничек инде — кайда эшли? Ул — министр хатыны!» — диде Пол.

Концерт тәмамлангач, артистлар миңа безнең концерт турындагы рекламаны күрсәттеләр. Аны кулдан зур итеп ясап мәктәп фронтонына элеп куйганнар: ярым чегән, ярым монгол кыяфәтле, кылый күзле, зур борынлы карсак ирләр киң чалбарлар кигән симез хатыннар белән биниләр. Күрәсең татарларны шулай күз алдына китергәннәрдер инде. Пол белән Мария афишага төртеп күрсәтеп көләләр һәм баш чайкыйлар. Без дә көләбез һәм... уйланабыз. Югары культуралы, алдынгы индустрияле, фән, сәнгать тарихында юылмас эзләре булган совет Татарстаны турында берни дә белмәүче илләр бер Мальта гына түгелдер әле бу түгәрәк Җир шарында...

**16 июль, 1978 ел.** Кичә дә, бүген дә концертка Мальта коммунистлар партиясенең генеральный секретаре иптәш Антони Вассалло килде. Гади, тыныч кеше. Пол Аджус белән алар КПССның XXV съездында булганнар. Иптәш Вассалло үзенең Мәскәүдә булуын еш искә ала.

Мальта тамашачылары да, итальяннар кебек үк, бик тә темпераментлылар — җырларны да, биюләрне дә бик җылы каршы алалар. Соңгы концерт булганга ялындырып тормыйбыз — «бис» саен чыгып биибез, җырлыйбыз. Концерттан соң «Мальта — СССР дуслыгы җәмгыяте»нең президенты Пол Науди сәхнәгә менеп речь сөйләде. Ул күптән түгел генә безнең илдә булган икән. Себерне күреп шаккаткан. Анда үзенең туган көнен үткәргән. Мальтага себер чәчәкләре алып кайткан. Боларның барысын да Пол Науди сәхнәдән сөйләде. «Безнең илнең бу бөек ил белән дус булуына чиксез шатмын һәм бар көчемне шул дуслыкны ныгытуга куячакмын!» — дип тәмамлады ул сүзен.

**18 июль, 1978 ел.** Пол Аджус Виктор Воронцовны, Владимир Дейнеконы һәм мине үзенең «Лада»сына утыртып Ла Валлеттага алып китте. «Мальта — СССР дуслыгы җәмгыяте» бинасына алып керде. Компартиянең генеральный секретаре Антони Вассаллоның эш кабинетын күрсәтте. Үзенең кабинеты да шунда ук. Ике кабинетта да Карл Маркс, В. И. Ленин портретлары, Мәскәү күренешләре. Пол Аджусның китап кибете дә бар икән. Анда хатыны сату итә. Кибеткә дә кереп чыктык. Инглиз, итальян телләрендә Маркс, Ленин әсәрләре, рус телендә басылган совет китаплары, төрле плакатлар.

Бүген кич «Мальта — СССР дуслыгы җәмгыяте» һәм Мальта коммунистлар партиясе безнең хөрмәткә саубуллашу банкеты оештырдылар.

Иртәгә — өйгә!

**19 июль, 1978 ел.** «Боинг» самолетының шассилары җирдән аерылды да, без диңгез өстенә килеп тә чыктык. Әйләнеп карарга да өлгермәдек — кунакчыл Мальта инде әллә кайда еракта калды. Колакта Пол Аджусның: «Советлар Союзына киләсе баруымда һичшиксез Казанга җибәрүләрен үтенәчәкмен»,— дигән ихлас сүзләре яңгырый. Күз алдында чех кызы Мария Аттардның моңаеп калган күзләре. Кичә банкетта ул тост әйтте. Тосты бик кыска булды: «Бер атна мин үземне сезнең белән бәхетле тойдым. Иртәгә сезсез миңа бик ямансу булыр»...— диде. Киев медицина институты студенты Марио, Киев университеты юридик факультетының дүртенче курс студенты Джузеппе — Мальтаның булачак яшь белгечләре — шулай ук әле һаман да безгә кул болгап торалар кебек. Ә алда инде Рим аэропорты.

Көтмәгәндә аэровокзалның пыяла стенасы аша күзләрне иркәли торган таныш силуэт күренде — Мәскәүдән килгән ИЛ-62 самолеты! «Казан самолеты, Казан самолеты!» — дип шатланыштык барыбыз да.

Шереметьево аэропорты бетонына самолет шассилары кагылган мизгелдә кайберләребезнең күзендә шатлык һәм горурлыкның татлы яше иде.

Италия — Мальта — Казан.
1978 ел.

# ӘДӘБИЯТ ФӘНЕ ҮСЕШЕ ТУРЫНДА УЙЛАП...

КПСС Үзәк Комитетының 1972 елдагы әдәбият һәм сәнгать тәнкыйте турындагы мәгълүм карарыннан соң әдәби тәнкыйтебез күзгә күренеп активлашты. Укучы һәм тәнкыйтьче кулына барып ирешкән әсәрләрнең күбесе бәяләнә тора, авторлар һәм укучылар квалификацияле итеп, әдәбият белеме үсеше таләпләренә туры китереп әйтелгән фикерләр ишетә торалар. Газета-журнал мәкаләләре, төрле җыелышларда сөйләнгән докладлардан тыш, ел саен әдәбият белеме һәм агымдагы әдәбият торышына караган хезмәтләр китап булып басылалар. Ул китапларның авторлары арасында М. Әмир, Г. Бәширов, Ф. Хөсни кебек өлкән язучыларыбыз да, М. Гайнуллин, Г. Халит, Х. Госман, Х. Хәйри, И. Нуруллин, Р. Мостафин, Ф. Миңнуллин, Ф. Мусин кебек әдәбиятчы-галимнәр, тәҗрибәле тәнкыйтьчеләр дә бар.

Күптән түгел генә әдәби җәмәгатьчелек һәм киң катлау укучылар кулына тагын бер хезмәт килеп керде, ул «Әдәбият хәзинәләре»[1] дип атала. Авторы — филология фәннәре докторы Нил Юзиев. Бу хезмәтнең үзенчәлеге шунда — ул әдипләр һәм аларның иҗаты турында гына түгел, бәлки әдәбият фәне һәм тәнкыйте өлкәсендә эшләүче каләм әһелләре турында да. Мондый хезмәтне әдәбиятыбыз үсеше һәм язмышы белән кызыксынучылар көтеп алганнардыр.

Беренче бүлеккә мәкаләләр «Әдәбият хәзинәләрен ачу юлында» дигән исем астында туплап бирелгәннәр. Әдәбият фәне белән таныш булу язучы өчен иң әһәмиятле шартларның берсе булса, теоретикларга да язучы «кухнясын» белү зарури. Һәр ике як өчен дә файдалы фикерләр күп монда. Практика теориясез көчсез булган кебек, теория практикага дөрес, акыллы, аны тирән белеп бәя бирсә генә канатлы була.

Әмма шунысын да әйтергә кирәк, автор практиклар белән теоретикларны сөзештерергә җыенмый. Төрле характердагы һәм юнәлештәге мәкаләләрне бергә туплауның уртак бер мәгънәсе дә бар — Н. Юзиев әдәбият фәнен җитлеккән, чын мәгънәсендә фәнни итеп күрергә тели, шуның өчен борчыла.

Агымдагы әдәби тормышны барлау инде җайга салынып килә кебек, тик тәнкыйтьнең үз эчендәге процессны хәзерге әдәбият фәне яктылыгында үтәли карау әлегә җитенкерәми. Дөрес, бу өлкәдә И. Нуруллин һәм Г. Халит уңышлы гына үрнәкләр бирделәр. Шул башлангыч алга таба да дәвам иттерелсә, әдәбият фәне үсешенә җитди өлеш кертелер иде. Әдәбият фәне һәм тәнкыйть методологиясе хакында, сүз уңаенда гына түгел, махсус сөйләшер вакыт җитте. Бу инде зарурлятыбызга әйләнде дисәк тә хата булмас. Шунсыз әдәбият фәнен алга таба хәрәкәтләндерү, хезмәтләребезнең сыйфатын күтәрү мөмкин түгел. Җанлы әдәби тормыштагы яңа күренешләрне күрмәү, аларны иске бизмәнгә салып карау шуннан килә дә инде. Мәсәлән, Ә. Баянов прозасының үзенчәлекләрен, хасиятен аңлауда, иң әһәмиятлесе, бәяләүдә, сер түгел, күпләр кыенсынып кала, кайберләребез аның эпик әсәрләренә шагыйрьлеге йогынты ясый, дип әйтү белән котылу җаен карый. Әдәбиятыбыздагы бу үзенчәлекле күренешне фәнни өйрәнүдә теория ярдәмгә килә алыр иде. Мәсәлән, Г. Халитнең «романтик реализм» агымын аерып чыгару турындагы фикерләрен тагын да үстереп җибәргәндә, аны бүгенге әдәбиятка бәйләп караганда, кайбер томанлы яклар ачыкланырга мөмкин. Н. Юзиев галимнәрне әдәби әсәрне бәяләү принципларындагы, тикшерү алымнарындагы үзенчәлекләрне тирән итеп ачу өстендә эшләргә чакыра. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы җитәкчесенең мондый мәсьәләне бөтен кискенлеге белән көн тәртибенә куюы урынлы, бу татар әдәбияты фәне штабының тоткан юлы дөрес булуын һәм уртак көч белән киләчәктә бу өлкәдә житди казанышларга исәп тотарга нигезебез барлыгын күрсәтә.

Автор куйган сорауларның иң әһәмиятлеләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт: «Әдә-

---

[1] Юзиев Н. Әдәбият хәзинәләре. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1978.

биятчы, традицион ысуллар белән генә эш итеп, бөтенләй яңа принципка нигезләнеп оешкан әдәби әсәрне аңлаганда аптырап калмыйммы? Яңа дип уйлаган тикшерү алымы әсәрнең эчке рухын тирән итеп ачарга булышамы, әллә, киресенчә, комачаулыйммы? Башка фәннәрдә кулланылган методларны әдәбият белемендә ни рәвешле кулланырга? Әдәби әсәрне анализлау ысуллары белән әдәби процессны тикшерү ысуллары арасында нинди уртаклыклар һәм аермалыклар бар? Традицион тикшерү алымнарының яшәүчән көчен, аларның яңалыгын ничек сакларга? Бөтен фәннәрнең нигезендә яткан гомуми методологик принциплар белән аерым фәннәрдәге, шул исәптән әдәбият белемендәге методологик принципларның үзара мөнәсәбәтләре ничек?»[1].

Шул рәвешле, автор китапка гомуми тон бирүче теоретик мәкаләдә шушы сорауларны куя да башкаларында аларга өлешчә җавап бирә бара. Бүген тематик анализ белән генә әдәбиятны үстерүгә әллә ни ярдәм итеп булмый. Эстетика һәм әдәбият теориясенең әдәби процесска йогынтысын үстерү иң актуаль бурыч булып тора. Автор әдәбиятны комплекслы, системалы анализ ярдәмендә өйрәнүдә барлыкка килгән яңалыкларга игътибар юнәлтә, бу юлларның перспективалы булуын искәртә. Әлеге өлкәдә Й. Нигъмәтуллина, Х. Госман, Х. Курбатов һәм А. Яхин алып бара торган юнәлешләр белән таныштыра. Әдәбият белгечләре өчен этәрелеп китәргә мөмкинлек бирерлек кайбер хезмәтләрне атый.

Бүгенге әдәбиятчыга үз өлкәсенең методологик, теоретик һәм практик яклары бик яхшы белү генә дә җитми. Фәнни-техник революция чоры дип аталган безнең көннәрдә кызыклы табышлар төрле фәннәр очрашкан урыннарда табыла һәм гомумән башка тармакларда булган ачышлар әдәбият өлкәсендә яңа сүз әйтергә мөмкинлек бирәләр. Киң карашлылык, эрудициялелек әдәбиятчы өчен һәр вакыт иң кирәкле сыйфатлардан булды, бүген аларның әһәмияте тагын да арта. Бигрәк тә философиянең бу өлкәдә бәя биреп бетергесез терәк булуы үзеннән-үзе аңлашыла. Галимнең «әдәбият теориясенең, әдәби тәнкыйтьнең философик дәрәҗәсен күтәрү» турындагы кайгыртулары шуның белән аңлатыла.

Нил Юзиев күп яза, язучылар һәм үз коллегалары — әдәбиятчылар иҗатын нечкәләп тикшереп бара. Галимнең башкаларга әйтер сүзе бар. Бу китапта тупланган мәкаләләре дә дистәгә якын әдәбиятчы турында. Аларның кайберләрен, аерым алганда Ә. Фәйзи, Г. Кашшаф, М. Гайнуллин, Х. Госман, Г. Халитләргә багышланганнарын, бу әдип һәм галимнәрнең иҗат портретлары дип атарга мөмкин булыр иде.

Әлеге мәкаләләрнең структурасы да кызыклы. Монда методологик, теоретик һәм әдәбият тарихы мәсьәләләре дә күтәрелә, публицистик уйланулар, бәяләмәләр дә бар, кайбер авторлар белән бәхәскә керү дә күзәтелә. Галим мәсьәләләрне тирәнтен төшенеп, җиренә җиткереп күтәрә, үз фикерләрен такт белән, фәнни дәлилләп әйтә. Шул сәбәпле, автор фикерләре белән килешәсең, аларны авырсынмыйча кабул итәсең. Бу шулай ук галимнең матур сыйфатларыннан берсе.

Китапны укыганда авторның үзенчәлекле фәнни стилен, үз йөзен күрәсең. Бер урында ул болай ди: «Әдәбиятчылар төрле сәбәпләр аркасында популяр, фәнни-публицистик стильгә юнәлеш тоталар, шул сәбәпле мәкаләне вакыт-вакыт үтә билгеле нәрсәләр сөйләгән урыннар басып китә, үзенә кадәр галимнәр тарафыннан әйтелгән фикергә дә мөрәҗәгать итеп тору артык эш итеп санала. Нәтиҗәдә авторның үз ачышын, үз фикерен аерып алу кыенлаша»[1]. Н. Юзиев хезмәтләренең үзенчәлеге шунда, ул үткәндә булган казанышларга таяна, әмма башкаларны да, үз-үзен дә кабатламый.

Н. Юзиев патриот-шагыйрь М. Җәлил иҗатын озак еллар дәвамында өйрәнеп килүчеләрнең берсе, бу турыдагы хезмәтләре аерым китаплар булып та чыктылар. «Әдәбият хәзинәләре» җыентыгында да ул М. Җәлил иҗатын һәм тормышын өйрәнүгә карата кызыклы гына фикерләре белән уртаклаша. Г. Тукай, М. Җәлил юбилейларын үткәрүнең матур традициягә әйләнүенә шатлануын белдерә дә, әдәбиятчылар алдында бу шагыйрьләребез иҗатын өйрәнүнең актуаль бурыч булуын раслый, аның кайбер юнәлешләрен күрсәтә. Мәсәлән, М. Җәлил мирасын җыю, туплау буенча эшлисе эшләр, чишәсе мәсьәләләр зур һәм катлаулы. Н. Юзиев аларның кайберләрен атап, тикшеренүчеләр алдына проблемалар, бурычлар куя. М. Җәлилгә кагылышлы материалларны җыйнау, барлау һәм өйрәнү белән махсус шөгыльләнә торган фәнни үзәк кирәклеге турында сүз кузгата. Әдәбиятыбызның иң асыл хәзинәләреннән берсе булган М. Җәлил иҗатына карата тирән кайгыртучанлык белән сугарылган бу тәкъдим игътибарсыз калмас дигән олы ышанычыбыз бар.

Г. Ибраһимов иҗаты һәм тормыш юлы да шактый җентекле өйрәнелгән. «Академиянең 250 нче әгъзасы...» исемле мәкалә шул юнәлештәге фактик материал буларак әһәмиятле. Мәгълүм булганча Галимҗан Ибраһимов татар галимнәреннән беренче булып, сәнгать фәннәре академиясе член-корреспонденты итеп, тагын да дәрәҗәрәге, академиянең почетлы әгъзасы итеп сайлана. Бу эшнең процедурасына кагылышлы төп документларны эзләп табу классик язучыбыз биографиясен ачыклау өчен бик кирәкле өлеш дип саналырга тиеш.

Китапның икенче бүлеге тулысынча әдәбиятыбыз галимнәренә багышланган. Ә. Фәйзи турындагы «Осталык мәктәбе»

[1] Юзиев Н. Әдәбият хәзинәләре. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 9 бит, 1978.

[1] Юзиев Н. Әдәбият хәзинәләре. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 74 бит, 1978.

дип исемләнгән мәкалә дә шагыйрь, прозаик һәм драматург булган әдибебезнең әдәби тәнкыйть һәм әдәбият-сәнгать белеме өлкәсендәге хезмәтләрен тикшерүдән гыйбарәт. Галим Ә. Фәйзинең әдәбият белемен үстерүгә өлеш керткән хезмәтләрен югары бәяли, үз заманындагы кайбер агымнарга нярел әйтелгән хата фикерләрен дә искәртә. Ә. Фәйзинең Г. Тукай иҗатын һәм тормыш юлын өйрәнүгә багышланган эшчәнлеге Н. Юзиев тарафыннан аеруча хөрмәт белән искә алына. Җыйнак кына бу мәкалә Ә. Фәйзи турында бер үзәккә җыеп әйтелгән тыгыз фикерләр тупланмасы булуы ягыннан әһәмиятле. Ә. Фәйзинең әдәбият белеме өлкәсендәге эшчәнлегенең умыртка сөяге булган мәсьәләләрне мәкалә авторы дөрес тотып ала һәм шул нигез фикерләрне ахырынача лейтмотив итеп алып бара. Бу исә яшь әдәбиятчыларны алынган темага турылыклы булырга, шуны логик эзлеклелектә үстерергә өйрәтә. Гомумән, Н. Юзиев иҗаты әдәбиятчылар өчен үзе бер осталык мәктәбе булып өлгерде дисәк, шаять, безне тыйнаксызлыкта гаепләмәсләрдер. Әдәбиятчылар арасыннан беренче булып Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясенә лаек булган галимнең башкалар өчен үрнәк яклары күп.

Н. Юзиев әдәбият мәйданында эшләүче коллегаларын ярата, хөрмәт итә, аларга сак мөнәсәбәт һәм кайгыртучанлык күрсәтә. Гази Кашшафка багышланган «Фидакарьлек» дигән мәкаләне дулкынланмыйча уку мөмкин түгел. Мәрхүм Г. Әпсәләмов күренекле җәмәгать эшлеклесе, галим, язучы, тәнкыйтьче, журналист һәм педагог Гази Кашшафның М. Җәлил турында кайгыртып узган гомеренең бер өлешен «Агыла болыт» романында — матур әдәбият әсәрендә — сурәтләгән иде. Инде менә Н. Юзиев мәкаләсе. Баксаң, герой-шагыйрь М. Җәлил турындагы беренче зур фәнни авторы Г. Кашшафның эшчәнлеге үзе дә фидакарьлек үрнәге икән ич! Әле моннан берничә еллар элек көн саен диярлек аралашып, исәнләшеп йөргән бу тыйнак кеше образы безнең күз алдында ничек калку булып гәүдәләнде. Әйе, әдәбиятыбыз менә шундый фидакарь кешеләр җилкәсендә күтәрелде, аны тагын да алга алып китү әдәбиятка гомерен багышлаган һәркемнең намус эше. Н. Юзиев әйтергә теләгән төп фикер шул.

Журналистикада тормыш фактлары белән агитацияләү дигән төшенчә яшәп килә. Н. Юзиев әдәбиятчылар тормышыннан да шундый тәрбияви әһәмияткә ия булырдай сәхифәләрне сайлап ала. РСФСРның атказанган фән эшлеклесе, филология фәннәре докторы, профессор Мөхәммәт Гайнуллинга багышланган мәкаләсен автор бик төгәл итеп «Игелеклелек» дип атый. Галимнең «Татар әдипләре»[1] дигән җыентыгына язган сүз башын да «Игелекле хезмәт белән узган гомер» дип исемли. Әдәбиятыбызга шактый катлаулы булган утызынчы елларда килеп, бүгенгә кадәр нәтиҗәле эшләп килүче, күпме исемнәрне, әсәрләрне барлап, халкыбызга кире кайтарган галимнең эшчәнлеген игелеклелек дип атамыйча, башкача исемләү мөмкин дә түгел. Күп кенә ак таплардан торган XIX йөз әдәбиятын шактый тулы итеп күз алдыбызга калкытып куючы М. Гайнуллинга без никадәр рәхмәтле бүген. Н. Юзиев, М. Мәһдиев кебек үк[2], галимнең бу хезмәтләрен олылап бәяли, моның белән яшь әдәбиятчыларны да намуслы, хезмәт сөючән, гадел булырга өнди.

Филология фәннәре докторлары Хатип Госман, Гали Халитләр турында язылган бүлекләр белән танышкач та, укучы тикшерү объектларына чын күңелдән бирелгән галим образларын күз алдына китереп бастыра. Мәгълүм булганча, үз эшенә, хезмәтенә гашыйк булган кешедән дә матур кеше юк! Матур булып, әдәбиятка гашыйк булып гәүдәләнәләр алар.

Татар әдәбияты тарихында исемнәре еллар, чорлар үткәч тә тоныкланмаучы, һаман яктыра гына баручы бәхетле галимнәр шактый булды. Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Ибраһимовлар шундыйлардан. М. Гайнуллин, Г. Кашшаф, Х. Госман, Г. Халитләр — бүгенге чорның күренекле галимнәре — аларның иҗаты әдәби хәзинәбезнең алтын фондын баетып тора. Алар эшчәнлегенең төп хасиятләрен бергә туплап укучыга тәкъдим итү кебек мактаулы эш эшләгән Н. Юзиевның үз хезмәтләре дә рәхмәт хисләре белән бәяләнерлек.

**Фоат ГАЛИМУЛЛИН.**

---

[1] Гайнуллин М. Татар әдипләре. Казан, Татарстан китап нәшрияты. 1978.

[2] Мәһдиев М. Мөхәммәт Гайнуллин һәм татар филологиясе.— Кит.: Гайнуллин М. Дуслыкта — көч. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1973.

# СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙНЕҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

## ТУКАЙНЫҢ САДӘ ДУСТЫ

Мең тугыз йөз ундүртенче елның июнь аенда Казан губерна жандармерия идарәсендә көтелмәгән ыгы-зыгы булып ала: яшерен агенттан идарәгә бер китап һәм китапка шәрех килеп төшә. Агент болай дип хәбәр итә: «Малмыж өязе Зур Сәрдек авылы мөгаллиме Сәгыйть Сүнчәләев мөселманнар арасында панисламистик пропаганда алып бара. Ул татарларга 1913 елда «Сабах» китапханәсендә Сәгыйть Сүнчәләев тарафыннан (!) чыгарылган «Әлмансур» диган брошюра укый. Брошюра бик зарарлы юнәлештә...»

Сүнчәләев һәм «Әлмансур»... Чиновниклар өчен әр-яңа исемнәр кебек бу. Эшне каян башларга? Тентүдән! 1914 ел, 26 июнь, өяз исправнигына: Сәгыйть Сүнчәләевтә тентү уздырырга. Өяздән җавап: мөгаллим С. Сүнчәләевтә тентү уздырып булмады, ул Казанга киткән.

С. Сүнчәләй эзәрлекләүләрдән әнә шулай кача, әмма патша чиновникларына зур мәшәкать йөкләп калдыра. Өйрәнә торгач Зур Сәрдек авылында «зарарлы брошюра укып» яткан мөгаллим С. Сүнчәләев белән XIX йөз немец шагыйре Г. Гейненың мәшһүр «Әлмансур» әсәрен тәрҗемә иткән С. Сүнчәләевләр икесе бер шәхес булып чыга. Аннан соң Гейнены өйрәнергә кирәк була. Панисламизмга бәйле рәвештә (!) Гейне исеме телгә керә.

Бу әсәр нәрсәсе белән куркыныч соң? Бөек Гейне анда Испаниянә гарәплләрдән азат итү чорында гөнаһсыз кешеләрнең, гарәп культурасының кысылуы, һәлак булуы турында ачынып яза. Гейненың симпатиясе католиклар тарафыннан җәберсетелгән гарәпләр ягында. Гейне «тәре белән ярым ай» арасындагы канлы көрәшне туктату юлларын бер халыкның икенче халыкны изүендә түгел, бәлки милләтләрнең үзара дуслыгында күрә.

Жандармерия Гейне һәм С. Сүнчәләй үткәргән нәкъ шул идеядән куркып кала да инде. Агентура да дөм-надан түгел: бу әсәрдә сүз испаннар белән гарәпләр арасындагы көрәш турында барса да, эчтәлеге белән бүгенгә көнгә ишарә ясый ул, ди...

Әйе, С. Сүнчәләй үзенең иҗатында бервакытта да тар милли кысалар эчендә торып язмады. Әдәбиятта ул гомумкешелек мәсьәләләрен, әхлак, намус, кешелек җәмгыятенең язмышы, бәхете яки трагедиясе мәсьәләләрен күтәрә иде. С. Сүнчәләй планета халыклары язмышына бик сизгер шагыйрь иде. Унынчы еллардагы Италия-Төркия, Балкан сугышлары мөнәсәбәте белән язган шигырьләрендә катлаулы халыкара хәлләрне тарихи-объектив аңлау дәрәҗәсенә кадәр күтәрелеп җитмәсә дә, Сүнчәләй канкойгыч сугышларга каршы кискен нәфрәтен белдерде, үзен тынгысыз гуманист буларак күрсәтте.

С. Сүнчәләй авыр идеологик көрәш елларында иҗат итте. Яңа революцион күтәрелеш елларында бер яктан великодержавачылык идеяләре, икенче яктан буржуаз милләтчелек шаукымы кыздырылып, эшчеләр арасындагы пролетар интернационализм рухына зарар салырга омтылыш ясалды. Мондый катлаулы рухи атмосфераны нечкә күңелле Сүнчәләй авыр кичерде. Мәсләге, кыйбла эзләве аны Ту-

кайга таба этәрде. Татар демократик әдәбиятына кара көчләр һөҗүм иткән, шымчылык канат җәйгән ямьсез атмосферада С. Сүнчәләй XIX йөз шагыйре Яков Емельяновның «Әләк» шигырендә күтәрелгән усал тәнкыйтьне кабат яңарта. Мондый омтылыш аны, ихтимал, Тукай киңәше беләндер, рус шагыйре И. С. Никитинга алып килә һәм 1911 елда ул Никитинның мәшһүр шигырен тәрҗемә итеп бастыра.

**Изгеләрчә тор, гыйбадәт кыл, җыла,**
**Яки кол, аз уйна, шаула, йөр, дула —**
**Барыбер гайбәт гонаһыңны табар,**
**Җәлладың ул, сүз белән башың чабар.**

**Ул ишек ачмас, ишек астан керер,**
**Таш эченнән, диңгез астыннан йөрер.**
**Бармы гаебең, юкмы — ул шаулап ятыр**
**Мәңгегә исемеңне таплар, пычратыр.**

Соңгы строфада С. Сүнчәләй ирекле тәрҗемә алымына күчә һәм И. С. Никитин шигыренең бөтен мәгънәсен татар тормышына кайтарып калдыра.

1910—11еллар С. Сүнчәләй белән Тукай арасындагы мөнәсәбәтләрнең иң якынайган чоры. Ике шагыйрь очрашып-күрешеп озын төннәр бергә сөйләшеп уздырганнар, күп хат алышканнар. Саф күңелле, эчкерсез иптәшләр эзләгән Тукайның Казандагы таныш-белешләре арасында дуслар даирәсе конкретлаша төшкән. Тукай инде теләсә кем белән түгел, ә халык бәхете өчен көрәшкә үзләрен чын күңелдән багышлаган язучы-журналистлар белән генә аралашкан. Болар — Г. Колахметов, Х. Ямашев, Ф. Әмирхан, Г. Камал кебек кешеләр. Әнә шулар янына 1910—11 елларда яшь шагыйрь С. Сүнчәләй дә килеп кушыла.

1911 елның 15 ноябрендә язган хатында Тукай яңа дусты Сүнчәләйгә үзенең дөньяга карашларын ачып «эчен бушата». Мөселман-буржуаз җәмәгать эшлеклеләренең «Хөррият! Инсаният!» дип кычкырынып йөрүләрен тәнкыйть итә анда Тукай һәм милләтчеләр, сатлык җаннар, бушбугазлар белән тулы мөхиттән С. Сүнчәләйне аерып куя. «Сине мин һәр тугрыда садәдил кеше таптым» ди ул әлеге хатында [1].

*
* *

С. Сүнчәләйнең әдәби мирасы байтак. Ул кыйммәтле мирасның бер өлешен Татарстан китап нәшрияты 1961 елда җыйнак кына бер китапчык итеп чыгарган иде. С. Сүнчәләйнең тулырак басмасын әзерләү, бастырып чыгару мәсьәләсен кузгатырга бик тә вакыт җиткән. Чөнки С. Сүнчәләй шагыйрь дә, тәрҗемәче дә, драматург та, ялкынлы публицист та иде.

Ниһаять, «Марсельеза» белән «Интернационал» җырларының беренче профессиональ тәрҗемәчесе иде...

**М. МӨХӘММӘТ.**

[1] Тукай. Әсәрләр, дүрт томда, 4 нче том, 1977, 320 бит.

# ЯКТЫ ЭЗ

*(1909—1976)*

Шәриф Камалның канәфер тышлы калын томын без, илленче елларның яшүсмерләре, беренче тапкыр бишенче класста укыганда кулга алдык. Егерме елдан артык вакыт үтсә дә, ул көннәр әле дә хәтеремдә. Тәрәзә төбенә куеп китап актарганда рам ярыкларыннан кышның салкын әче җиле өрә иде. Әмма минем тәнне тыштан бәрелгән түгел, китаптагы рәсемнәр чымырдатты, алай гына да түгел, бөтен җанны өшетте.

Түшәктә йөзе сүнгән, кыяфәтендә тереклек әсәре сизелмәгән хәрәкәтсез гәүдә. Аның башыннан саркыган кан суалчан төсле мендәр буйлап сузылган. Шәрә стена, пәрдәсез тәрәзә — өй эче шыр ялангачлыгы, бер төрле караңгылыгы белән фәкыйрьлек, күңелсез хәят хакында сөйли иде. Тик алгы пландагы ач яңаклы шашкан кыяфәттәге ир тагын да үзәк өзгечрәк тәэсир калдыра: аның күзләре атылып чыгар дәрәҗәгә җитеп ялтырый, карашы өметсез, хәрәкәте кискен. Күренеп тора: язмыш рәхимсез кыйнаган, ихтыяр көчен сындырган, үз-үзенә хисап бирмәслек дәрәҗәгә җиткергән бәхетсез кеше бу. Күңел дөньясы чайпалган, акылы томаланган шушы мизгелдә ул тагын берәр мәгънәсезлек, үзенә яңа һәлакәт китерерлек тилелек эшләп ташлар кебек. Сискәндерә, куркыта торган күренеш.

«Уяну» хикәясенең каһарманнары Гафифә белән Муса гәүдәләндерелгән бу рәсемне без ул чакта тыныч кына карый алмый идек. Шул вакыттагы тәэсир кичә генә булган төсле әле дә кайнар, әле дә дулкынландырырлык!

«Бәхет эзләгәндә» хикәясенә ясалган рәсем дә күз алдымда. Бер уйлаганда, мәһабәт күренеш: биек күк, калку таулар, шулар итәгендә тезелеп киткән баһадир нефть манаралары. Тауларга таба атлаучы ике юлаучы да гәүдәгә ярыйсы, эре сөякле күренә. Әмма үзләре таякка таянганнар, аркалары бөкрәйгән, чабата кигән аяклары теләр-теләмәс кенә сөйрәлә сыман. Биштәрләр буш, йодрык хәтле генә калдырып төйнәлгән, хәрәкәтләре дәртсез. Уйлары да күңелсез, кайгылы булса кирәк. Еракка сузылып киткән кара күләгәләре дә нәкъ менә шуңа ишарә ясый шикелле. Күпме бичаралык, мескенлек бу күренештә!

Малай чакта әсәрне укый башлардан элек рәсемнәренә күз төшә. Безнең буын да менә шулай Шәриф Камал каһарманнары белән башта Байназар Әлменов ясаган сурәтләр аркылы танышты. Билгеле, ул чакта рәссамның исеменә әллә ни игътибар итмәгәнбез. Әмма язучының караңгы тормыш сәхифәләрен яктырткан әсәрләре, рәссамның тирән тәэсирле, төгәл рәсемнәре белән бергә, онытылмаслык булып хәтердә калган. Тормыш тәҗрибәсе тупларга, дөньяны танып-белергә өлгермәгән бала, язучы барлыкка китергән хәятне күзаллаганда, рәссам ярдәменә әеруча мохтаҗ икән.

Байназар Әлменовның бер дә күз алдыннан китми торган бүтән рәсемнәре төшерелгән ике китапны мин инде улым белән бергәләп карадым. Г. Тукайның «Шүрәле»сен гәүдәләндергән сурәтләр баланың хыялын кузгатып, бай табигать дөньясына, халкыбызның тапкыр, батыр улларына мәхәббәт уятса, мине рәссамның осталыгы, яшел, зәңгәр, фирәзә төсләр уены сокландырды. Якты акварель буяулар белән эшләнгән ул рәсемнәр әле бүген дә күңелне үзенә тарта.



Менә ул иркен хәтфә яланнар уртасына утырган Кырлай авылы, аның артындагы зәңгәрләнеп торган урман, җир җиләге, чәчкәләр үсеп утырган су буйлары. Зифа каеннардай сылу кызлар җиләк җыеп йөргән аллы-гөлле алан, сунарчыдан өркегән пошилар, аучыны бер кырыйдан күзәтеп торган хәйләкәр төлке... Ниһаять, менә ул — Кырлайның чая егете Былтыр — кояш батып, урманда серле күләгәләр ишәйгәндә, бүреләр төнге кәсепкә китәргә җыенганда утынга бара. Офыкка тәгәрәгән кояш, аның кызгылт нурлары төшкән җыйнак гәүдәле, дәртле хәрәкәтле ыспай егет һәм сөлектәй акбүз юртак гаҗәеп шагыйранә сурәтләнә. Ә Шүрәле исә әкияти каһарманга хас рәвештә сагаю уятырлык җан иясе итеп тасвирлана, озын буйлы, йонлач, көчле, әмма беркатлырак дивана... Рәсемнәр төрле җан ияләре арасында кешенең иң акыллы, иң кодрәтле зат булуын раслый, табигать гармониясен образлы, матур чагылдыра.

Г. Тукайның «Су анасы» китабына ясаган сурәтләр дә табигать күренешләрен ачык, якты акварель буяулар аша күз алдына бастыра. Зәңгәрсу-яшькелт таллар, таҗ яфракчыклары ачылган сары төнбоеклар, куе үлән каплаган яр буйлары җанны иркәли. Су анасының тәне балыкныкы кебек тәңкәләр белән капланган. Ул бака тотып торган көзге алдында чәч арасына төнбоеклар кыстырып көязләнә, икенче рәсемдә үз-үзеннән канәгать төстә басмага утырып алтын тарагы белән озын чәчләрен тарый, өченчесендә — тарагы югалуга кайгыра. Малай су анасын күреп шакката, таракны кулга төшерүенә сөенеп өенә йөгерә, әнисе орышканда таракка орынуына үкенә... Бу рәсемнәр Тукай әсәрләренең тылсымын, сихри шигъриятен тагын да нечкәрәк тоярга булыша.

Тукайның «Таз» шигыренә ясалган рәсемне дә сез хәтерли торгансыздыр: аркасына поднос куйган шәкерт, аның хәйләсен тоткан казый, мәзәк хәлгә исләре киткән балалар гәүдәләндерелә сурәттә. Бала чагыбызда җуелмас эз калдырган бу рәсемне дә Байназар Әлменов иҗат иткән. Күпләргә мәгълүм «Кәҗә белән сарык» әкиятен бизәүче дә Әлменов. Безгә яхшы билгеле «Нәни Габдулла Кырлай авылына килгәч», «Тукай Троицк далаларында» рәсеменең авторы да ул. Байназар аганың иҗатында, гомумән, Тукай темасы зур урынны били. Аның татар китабын бизәү эше Тукай әсәрләрен сурәтләүдән башлана. Беренче чорда ул тышлык, башлам һәм ахырымнар, аннары текст эченә яртышар битле сурәтләр ясый. Тәҗрибә туплагач инде тушь һәм акварель белән тулы канлы күләмлерәк рәсемнәр барлыкка китерә. Менә шулай итеп, 1939, 1944 елларда «Шүрәле», «Су анасы»ның беренче сурәтләре туа.

Б. Әлменовның графикадагы эшчәнлеге киң колачлы һәм төрле-төрле. Аның беренче рәсемнәре тушь белән иҗат ителә. Рәссамның каләме һәр сурәтне җентекләп эшкәртә, еш кына алар агачка төшерелгән гравюраны хәтерләтә. Шул ук вакытта ул төрле дәрәҗәдә сыеклandырылган кара акварельне дә куллана, кайвакыт аңа аксыл-сары төсне дә өсти. Башта аерым каһарманнарны гына сурәтләсә, тора-бара ул мөстәкыйль композицияләр, сюжетлар иҗат итәргә тотына. Аның иң яхшы әсәрләренә психологик тирәнлек, социаль-тарихи җирлекнең анықлыгы, хәрәкәтне баета торган табигать күренешләренең отышлы бирелүе хас. Бу җәһәттән «Шүрәле», «Су анасы» рәсемнәренең аеруча дәртләнеп, илһамланып иҗат ителүен әйтергә кирәк. Бу рәсемнәр техник эшләнеше, композицион төзелеше ягыннан Б. Әлменов иҗатының иң югары казанышы, татар китап бизәү сәнгатенең матур бер табышы булып тора.

Оренбург өлкәсенең Кызыл Мәчет авылында туган Байназар Мостафа улы Әлменов татар культурасының күренекле эшлеклеләре К. Насыйри, Г. Тукай, М. Гафури, Г. Камал, Ш. Камал, Г. Кутуй, Х. Якуповларның портретларын ясады, үзенең хезмәтләре белән республика, зона, РСФСР күргәзмәләрендә катнашты, татар рәсем сәнгатен үстерүдәге уңышлары өчен Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе исеменә лаек булды.

**Т. РАМАЗАНОВ.**

# УКРАИН ХАЛКЫ ҺӘМ ӘДИПЛӘРЕ ИҖАТЫННАН

## ИМӘН МИЧКӘ

Урманда бик биек һәм калын булып үскән бер карт имәнне кисә дә берәү балта остасына китерә. Имән бүрәнәне кисәкләргә турый оста, юка һәм тар такталар итеп эшкәртә. Аннары шул такталарны түгәрәкләп тезә, кыршаулый һәм төп куя — килеп чыга менә дигән мичкә — мактап туймаслык!

Ләкин хуҗасы аны рәтләп карамаганга, буш торганга мичкә бик тиз кибә, кыршаулары тутыга һәм, ниһаять, такталары бөтенләй тарала башлый: кыршауларны бала-чага урамда тәгәрәтеп уйный, такталарны хуҗа үзе җыеп утта яндыра. Кыскасы, мичкә юкка чыга.

Моның гыйбрәте шул: мичкәнең үзен туган ил дип аңларга кирәк. Имән такталар — ата-аналар, аларның бала-чагалары. Кыршаулар — илне бердәм иткән дуслык-туганлык. Такталар кыршаулы чакта — мичкә бар иде. Кыршаусыз калгач — инде берни дә юк.

Һәрчак шулай: дуслык барында — бар халык бердәм. Дуслык какшаса — ил дә таркала.

## СТАРОСТА БУЛАСЫ КИЛГӘН БҮРЕ

Хуҗасы көтүлеккә җибәргән бер Ишәкне күреп чиксез-чамасыз куана урманнан чыккан бер ач бүре: «Бик шәп булды әле бу, хәзер карынымны дөмбәсләп тутырам!»

Янына Бүре килгәч әйтә Ишәк:

— Мин бит сине күптән эзлим инде!

— Ә ник?

— Безнең авылга войт[1] кирәк, шул урынга кемне сайларга белмичә аптырый халык. Риза булмасмы икән дип, сине чакырырга һәм алып килергә куштылар.

— Бәхетең бар икән, бик тиз очраштык менә...

— Әйдә, атлан миңа, киттек!

Авылга барып керәләр. Ишәк бар көченә акыра башлый һәм халык җыела. Бүрене ни эләкте шуның белән тукмарга тотыналар.

Нәфесен тыя алмаган Бүре көчкә качып үлемнән котыла.

---

[1] Войт — староста башлык.

Бер ат үз язмышыннан канәгать булмый:

— Хуҗам миңа я камыт тидерә, я сыртымны ияр белән каезлый,— дип зарлана.

Кичләрнең берендә елга ярына су эчәргә төшкәч ул шунда йөргән бер Аккошны күрә һәм үзенчә уйлый: «Әх, минем дә шундый бөгелмәле-сыгылмалы муеным, хәзергедән бераз кечкенәрәк башым, озынрак һәм нәзегрәк аякларым булса икән... Аркама табигать үзе үстергән ияр дә килешле булыр иде. И язмыш, бирсәңче миңа шундый матурлыкны!»

Икенче көнне Ат үзен бөтенләй бүтәнчә хис итә һәм... матурлыгы белән мактанырга теләп, көтүдәш атлары йөргән болынга китә. Яннарына нindидер шыксыз һәм гарип җан иясе килгәнен күреп исләре киткән атлар кача-таркала башлый.

— Әй, туктагыз әле! Әллә мине танымыйсызмы? Мин бит кичә сезнең белән бу болында бергә йөргән бурлы Атмын!

Атларның кайсы авылгача җан-фәрман чабып үз йортлары янында туктыйлар, куркудан көч-хәл белән сулап, артка карыйлар: янәсе куып җитмиме икән теге куркыныч нәрсә? Ә кыр уртасында катып калган дөянең исә үз уе уй: «Бөтен дусларымның котын алырлык нәрсәм бар соң минем?»

Тагын елга буена төшә ул һәм суда үзенең ике үркәчле ямьсез шәүләсен күрә.

Нәтиҗәдә, ул үз язмышыннан һәм кыяфәтеннән юкка зарлануын аңлый, ләкин... ләкин инде соң була шул.

## САНДУГАЧ КИҢӘШЛӘРЕ

Бер Кеше кулына Сандугач эләгә һәм ул аны ашарга тели.

— Тимә, Кешекәй, җибәр мине. Үзеңә яхшылык эшләп, өч нәрсәгә өйрәтермен.

Кеше куана кала, әгәр дә файдалы киңәш әйтсә, кошны иреккә очырырга вәгъдә бирә.

— Ризык булмаган бер нәрсәне дә һичкайчан авызыңа капма. Инде кайтарып булмас әйберне кызганма. Мәгънәсез сүзләргә ышанма.

Үзе инде ирекле булгач, ул әйткәннәрне Кешенең аңлавын-аңламавын белергә тели Сандугач һәм биеккә очып менә дә әйтә аңа:

— Мине кулыңнан ычкындырып ялгыштың бит син! Карынымда минем нинди хәзинә барын белсәң, җибәрмәс идең! Анда бит чамасыз затлы энҗе кантары ята. Кулыңа шул керсә, баеган булыр идең.

Кеше кайгыга кала. Сандугач кире төшсәче дигәндәй, кулларын күккә суза. Ә кошчык әйтә:

— Синең тинтәк икәнеңне белдем инде мин! Мин өйрәткәннәрнең бөтенесен аяк астына салып таптадың. Инде кире кайтарып булмас нәрсәне кызганасың һәм мәгънәсез сүзләргә ышандың!

Нәтиҗә менә шул: «Күрәсең ич, нинди бәп-бәләкәчмен, нинди энҗе кантары сыйсын ди минем карынга?!.» — ди дә Сандугач очып күздән югала.

## Евген Гребинка

*Евгений Павлович Гребинка (1812—1848) вак дворян семьясында туа, лицейда укый. Нижинский гимназиясен тәмамлагач, хәрби хезмәткә алына. 1834 елда Петербургка күчә. Т. Г. Шевченконы крепостнойлыктан ирекка чыгарыша, украин һәм рус язучылары катнашкан әдәби түгәрәкләр оештыра, «Карлыгач» исемле альманах чыгара. «Малороссия әкиятләренә кушымта» дигән мәсәлләр китабы яза. Украинча һәм русча («Кара күзләр») язган шигырьләре, «Студент язмалары» киң билгеле. «Чайковский», «Доктор» һәм «Кулик» исемле романнарын рус теләндә язган. Пушкинның «Полтава»сын украинчага тәрҗемә иткән.*

### КИНДЕР БЕЛӘН ШАЙТАН ТАЯГЫ

— Нигә, — дип, — мине, эт җан, кысасың? —
Шайтан таягы әйтә Киндергә.
— Мин ничек үсим? Тамырым корый,
Җир калдырмадың миңа син бер дә?!

Шундый чәнечкеле кешеләр була:
Бүтәннәрне ул кысар һәм изәр.
Үз күзем белән күрдем андыйны.
Тик исемен әйтмим... Комиссар сизәр!

## Гулак-Артемовский

*Петр Петрович Гулак-Артемовский (1790—1865) рухани академиядә укый. Харьков университетының башта профессоры, соңыннан ректоры була. 1818 елда басылган «Пан һәм эт» дигән мәсәле аеруча популяр. Гораций одаларын эшкәртә, Гете һәм Мицкевич балладаларын украинчага тәрҗемә итә.*

### БЕР ЧИТЛЕКТӘ ИКЕ КОШ

«Юләркәем, тавышың ник бик кызганыч?
Һаман болай моңаеп син ник сайрыйсың?
Тарысынмы, бодаенмы — сайлап чүплә!
Тагын сиңа нәрсә җитми, ни сайлыйсың?
Ник син, сантый, шул хөрмәткә риза түгел?
Бу читлек бит — якты җәннәт өе безгә!» —
Карабүрек дигән карт кош шулай тирги
Бер яшь кошны. Ә яшь кошның уе үзгә:
«Аңлашылмый миңа синең саташуың,
Буш сүз көйләп юмаларга маташуың.
Ә мин елыйм — хурлыгымны белеп елыйм.
Син кызыккан нигъмәтләрдән көлеп елыйм.
Сиңа рәхәт: син читлектә туган кош бит,
Ә мин — колмын, мин иреген җуйган кош бит».

# Леонид Глебов

*Глибов (Глебов) Леонид Иванович (1827—1893) Полтава якларындагы бер алпавыт утарында хезмәткәр семьясында туа. Нижинский лицеен тәмамлагач, гимназия укытучысы була. Идея-эстетик карашлары Тарас Шевченко һәм рус революцион-демократлары йогынтысында формалаша. 1861—63 елларда прогрессив «Чернигов листогы» дигән басманы редакцияли. Хөкүмәткә каршы агитация алып барган бу газета ябылганнан соң педагогик эштән читләштерелә, полиция күзәтүенә алына. 1867 елдан башлап үлгәнчегә кадәр Черниговта типография мөдире була. «Шигырьләр» исемле беренче җыентыгы 1847 елда Полтавада рус телендә чыга. Аннары украинча бер комедия яза, ахырда исә мәсәл жанры остасы булып танылa.*

## ҖЫЕН

— Сарыклар башлыгы итсәңче син мине! —
Дип килә бер Бүре Арслан янына.
Кыяфәт — кыюдан. Елмаеп сөйләшә.
Бар шартын китереп ялына.
Ә башта күрә ул хәйләкәр Төлкене:
«Зинһар, ди, очрат син Арслан хатынын.
Бик мактап сөйләсен ул минем турыда,
Буш итмәм үзеңне — җәл булмас алтыным!»
Хатыны әйткәнне Арслан ишетә:
Имештер, Бүре ул бик кыю эш итә,
Имештер, күндәм ул, дустанә...
«Акыллы!» диеп тә өстәлә!
Белсә дә Бүредәй ерткыч бик сирәк дип,
Арслан хәл кыла Бүрегә
ризалык бирергә.
Кайчакта хатынга ярарга кирәк бит!
Бер чара булсын дип, шик-шөбһә туса ул,
Урманда зур җыен җыярга куша ул.
Һәм җыен башлана. Сүз сөйләп тормыйлар.
Ашыгып беркетмә сырлыйлар:
«Бүрене башлык дип санарга!» —
Шул карар языла аңарга.
Ә кайда иде соң Сарыклар?
Сүз алар турында барганда
Ник дәшми калдылар җыенда?
Йоклапмы, әллә бик арганга?

Эш шунда: Сарыклар бу хәлне белмәде,
Аларның берсе дә җыенга килмәде:
Чөнки бит әйтүче, чакыручы булмады...
Җыенны Арслан үзенчә юллады.

Җәмәгать! Бу мәсәл — гыйбрәт-карар ул,
Тормышта сезгә дә кирәгер — ярар ул.

≈≈≈≈≈≈

# ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Җәвад Тәрҗеманов

## МИН НИЧЕК ЯЗУНЫ ТАШЛАДЫМ

хикәя

Апрельнең Тукай туган иртәсендә нурлы шәһәребезнең үзәк урамы буйлап чиктән тыш дәртләнепканатланып барам. Бара торгач кинәт үземне Матбугат йортындагы көзгедә күрдем. Элек тә аның каршында тукталгалый идем. Анысы гаҗәп түгел. Урамнан бара идем бит, ничек соң әле мин чал чәчле шагыйрьләребезне дә, башлап язучыларыбызны да үзенә карата торган бу көзге каршына килеп бастым?.. Матбугат йортының туксан тугыз потлы ишекләрен ачып керүемне сизми дә калдым ләбаса. Култык астымдагы өрҗңа кулъязмаммы, әллә инде Тукай туган көнме мине шулай исәрләндереп җибәргән?.. «Причем тут Тукай туган көн?» — дип сорау куюыгыз мөмкин. Алай булса Тукай исемен арттан алга табан укып карагыз: Йакут сүзе килеп чыга түгелме. Якут бу очракта ниндидер асылташ түгел, ә мин булам инде. Әй-йе, метрикага теркәлгән исемем. Тукай туган көнне дөньяга килүем сәбәпле, әни белән әти миңа шулай кушканнар. Фамилиябез — Нургалимов. Берничә шигырем күп тиражлы гәзиттә басылгач, «галим»ен һәм «ов» коерыгын к черту! — дидем. Кыскасы, танышыйк: Якут Нур дигән шагыйрь ул мин булам.

Көзге каршына килеп баскач, үзегез беләсез, һәркем хуплап каршы алырлык кеше рәвешенә керәсең килә. Мин дә тырыша-тырыша чәчемне, галстукны, кием-салымны рәтләргә керештем. Ниһаять, кыяфәтем үземә дә ошап, авыз колакка җитте, күңелем тагы да күтәрелеп китте. Каф тавын кичәрлек, бөтен җир шарын гизәрлек канатлы шигырьләрне бер-бер артлы язып торачагыма нык ышанган хәлдә, коридорга юнәлдем. Ике якта да бүлмәләр, бүлмәләр...

Бер ишекне шакыдым. Ягымлы аваз ишетелде:

— Керегез, кер!

Телефоннан сөйләшүче мин күптәннән белгән хезмәткәр, мине күргә, трубканы бир читкә куеп, сикереп торды һәм, ике кулын җәеп, каршыма килде:

— Син дә, Якут, дөньядамыный?!. Тиле кеше әйтмешли, күрешмәгәнгә биш былтыр булды бит, малай. Әйдә, бер кочаклашыйк әле!.. Күптәннән синең белән гәпләшеп утырасы килә иде, менә бирегә, диванга рәхим ит...

— Сез... сез телефоннан кем беләндер сөйләшә идегез бугай... Гафу итегез, бүлдердем...

— Ничево... тагын шалтыратыр әле...

Трубканы шап итеп куйгач, теге яңадан минем янга диванга килеп утырды.

— Ничек тормышлар... җәмәгатең... бала-чагалар?... Синең хәзер дүртәүме, әллә бишәүме?

— Малай да кыз инде.

— Начар... начар иҗат итәсең икән... Ә эштә ничек, планны үтисезме?

— Үтибез... Әле менә байтак кына шигырь дә яздым. Элек язганнарымны да шомарттым. Барысын бергә туплап, менә сезгә алып килдем. Укып чыгып, киңәшләрегезне...

Сүземне тәмамлый алмадым, теге кинәт сикереп торды.

— Соңга калдың бит, соңга! — дип кычкырды ул, арлы-бирле йөренә башлап.— Унбиш кенә көн элегрәк килгән булсаң да...

— Нәрсә... Әллә бу эшегездән китәсезме?

— Эш миндәмени соң! Безнең инде быелга да, киләсе елга да шигырьләр бар.

Миңа эсселе-суыклы булып китте. Шулай да сынатырга исәбем юк иде.

— Бу... бу... очарга җыенган тургайның канатын кисү бит! Үзегез бүгенге көн турында язарга кушасыз.. Ике ел буе кулъязма хәлендә яткач, аның ни кадере кала ди... Заманыбызның девизы — тизлек, ә сез... Сезнең карабодай коймагы ашаганыгыз бармы?.. Табадан төшкән шәпкә нинди тәмле, нинди файдалы була ул!

— Шулай шул,— дигән булып, теге кинәт кенә сүземә килеп кушылды,— әсәр яхшы икән, нигә куркырга. Тагын ун, йөз, мең елдан соң басылса да аны халык яратып укыячак.

Әйтерсең лә шунда башыма чүкеч белән суктылар. Маңгаема бөрчек-бөрчек салкын тир бөртекләре бәреп чыкты.

Моны күргәч теге миңа көмеш портсигарын сузды.

— Әйдә, бераз көйрәтеп алыйк...

— Рәхмәт, мин бит хәзер тартмыйм. Исеңдәдер, узган ел беренче шигырьләремне китергәч бу бүлмәнең стеналарын ничек ыслаган идем. Хәзер баш та авыртмый, язганда да...

— Әйттем бит. Минем киңәшне дә исәпкә алдың, алайса.

— Әй-йе. Бу кулъязмада гел мәзәк һәм сатирик шигырьләр генә.

— Нәрсә?!. Ишкәнсең икән ишәк чумарын. Аны бит мин былтыр әйттем, быел түгел. Ә быел соңга калдың, дус.

— Ярый, соңга калдым, ди. Теге чакта үзегез: «Сезнең талант юмор өчен бит, мәзәк шигырьләр күбрәк языгыз,» — дигән идегез ич.

— Диалектиканы белмисең, Якут дус, диалектиканы: һәммәсе ага, һәммәсе алышып тора. Хәзер безнең редакциядә тирән хисле лирикага кытлык, юк-бар юмор белән мавыгу модасы узды инде.

— Гафу итегез, белмәдем. Хушыгыз!

Йөрәк шул кадәр ярсыган иде, бу сүзләрне ничек әйтүемне дә, торып китүемне дә сизми калдым. Ишекне ачканда тегенең:

— Тукта әле, Якут, нишләвең бу...— дииюе шып туктатты. Шул арада ул култык астындагы кульязманы тартып алды.

— Хәзер үпкәләргә генә торасың, нәкъ сабый бала инде син,— дип, мине култыклап өстәл янына алып килде.— Утыр! Кульязмагыз бер генә данә икән. Ике булса әйбәт булыр иде. Ярар инде алайса, калдырыгыз. Башта үзем укып чыгармын. Шигырьләрегезне ошатсак, тагын сөйләшербез. Димәк, бигайбә! Үзем шалтыратырмын.

Редакциядәге таныш шулай дигәч, бераз тынычланып, өйгә кайтып киттем. Шәһәр элеккечә гөрләп тора. Әмма миндә иртәнге шигъри дәрт шактый сүрелгән иде инде. Үзем барам, үзем уйлыйм: «Теге хәйләкәр таз мине кәкре каенга терәттереп калдырмадымы?..» Бу сорауга үзем түгел, шайтан зиһененә ия булган хатыным да дөрес җавап таба алмавын белгәнгә күрә, өйгә кайткач: «Алып калдылар» — дип, сүзне кырт кистем. Бәйрәм каршылау ыгы-зыгысы башлангач, гәп сатырга вакыт аз кала бит ул.

Беренче Майдан соң эшкә чыктым.

Дүрт атна чамасы узгач, дүшәмбе көнне эштән кайтып керүгә хатыннан:

— Редакциядән миңа шалтыратмадылармы? — дип сорадым.

Хатын:

— Юк шул,— дип моңсу гына җавап бирде. Икенче, өченче, дүртенче, бишенче кичне дә мин шул ук сорауны кабатлагач, өйдәгеләр тора-бара күнектеләр. Ишектән күренүем була, кызчык, малай һәм хатын өчесе өч яктан хәбәр итәләр:

— Ю-юк.

— Ю-юк.

— Юк!

Көннән-көн көчлерәк тәэсир итә барган бу кайтаваздан минем йокым качты. Шулай да уйлана калдым, теге дус тикмәгә генә шалтыратмый тормас. Бәлки ул каты авырып түшәктә ята торгандыр, ә мин, аның хәлен беләсе урында, үпкәләп йөрим.

Ниһаять, урамдагы телефон-автоматка кереп кирәкле номерны җыйгач, таныш тавыш ишетелде:

— Редакция слушает.

— Исәнмесез! Мин... бу... Якут. Сез миңа шалтыратырга булган идегез. Әллә авырып...

— Тфу-тфу, авызыңнан җил алсын! Җәй көне авырырга ярыймы соң. Бездә хәзер, дускай, урак өсте. Ялга киткәнче, дүртенче кварталда басылырга тиешле барлык кульязмаларны типографиягә төшерәсе бар. Ә синекенә бит әле ут капмаган... Бигайбә, дускай. Хуш! Үзем шалтыратырмын...

Шулай диде дә, трубканы куйды теге. Мин ык-мык итәргә дә өлгерә алмый калдым.

Телефон-автомат будкасыннан чыккан гына идем, сөт савыты күтәреп хатын килә.

— Нәрсә... берәр хәл булдымы әллә?.. Син, Якут, өйгә шалтыраттыңмы?

— Юк ла, редакциягә шалтыраттым.

— Редакторга?!.— дип кабатлап сорады ул, күзләрен зур ачып. — Бер ай буена өйдән дә чыкмыйча, үзем дә, балалар да телефон саклап утырдык бит. Нигә шалтыратып торасың инде аңа. Ташла шул редакцияңне дә, шигырь-шыгырыңны да, эшлә әнә үз эшеңдә әйбәт кенә.

Шулай итеп, хатын миңа редакция белән телефоннан сөйләшүне дә, шигырь язуны да тыйды.

Шигырь язуын язгалыйм, әмма хатынга сиздермим һәм редакциягә шалтыратмыйм. Шулай тынычрак икән. Әсәрләрем яхшы булса, үзе әйтмешли, йөз елдан соң да халкым яратып укыр әле.

Редакциядәге кульязмам турында оныта ук башлаган идем инде, тик менә көз көне бик шәпләп искә төшерделәр. Бу хәл эштә булды.

Иртәнге унга мине директор кабинетына киңәшмәгә чакырдылар. Азрак алданрак килгәнмен ахрысы,— халык җыелып бетмәгән иде әле. Шулай да бүлмәдә берничә кеше бар иде инде.

Шунда директор кинәт миңа мөрәҗәгать итте:

— Якут Рәхимович, ялгышмасам, сез күптән әдәби иҗат эше белән шөгыльләнәсез...

Бүлмәдәгеләр, ни өчендер, үзара пырхылдашып көлеп алдылар. Мин дә, аларга кушылып, авызымны ера башлаган гына идем, директор:

— Ләкин менә бүгенге көнгә кадәр матбугатта шигырьләрегезне күргәнем юк,— дип сүзен бик җитди тәмамлагач, йөрәгемне ток кыргандай, кинәт сикереп тордым. Нәрсә дә булса әйтергә кирәк иде.

— Барып чыкмады... шигырьләремне ошатмадылар,— дип, бөтен гаепне үз өстемә алуымны сизми дә калдым.

Миннән берничә кеше аша гына утыручы баш инженер:

— Болай булгач, Якут дус, гел үзебезнең эш белән генә мәшгуль буласың инде, бик шәп! — диде чын күңеленнән шатланып.

Тукта, тукта, теге чакта, урамдагы телефон будкасы янында хатын да шундый киңәш биргән иде түгелме соң? Әйе шул, болар дөрес киңәш бирәләрдер, нинди әйбәт бит минем туган комбинатымдагы үз эшем.

Җыелыш бетүгә редакциягә, теге дуска шалтыраттым, мин башкача шигырь язмаячагымны, редакциядәге кульязмаларымны да кире алып китәчәгемне әйттем. Әй шатланды да соң инде дустым! Минем шигырьләремне укуны өч елга сузган дус кульязмаларымны миңа кире кайтарып бирү эшен һич тә сузмаячагын, аларны бүген үк машина белән өемә китереп бирәчәген әйтте.

Ә мин бу хәбәр белән хатынымны шатландырырга өйгә ашыктым.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ IX СЪЕЗДЫ

Шушы елның 23—24 маенда Татарстан АССР язучыларының чираттагы IX съезды булып узды. Анда СССР Язучылар союзы членнарыннан һәм башлап язучылардан өч йөзгә якын кеше, башкалабыз Мәскәүдән, союздаш һәм автономияле республикалардан килгән кунаклар, республикабызның партия, профсоюз һәм комсомол оешмалары вәкилләре, сәнгать эшлеклеләре, промышленность, авыл хуҗалыгы һәм культура работниклары катнашты. Кунаклар арасында СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, РСФСР Язучылар союзы идарәсе председателе, Социалистик Хезмәт Герое С. Михалков, СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре, Башкортстан Язучылар союзы идарәсе председателе Ә. Мирзаһитов, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретарьлары М. Кәрим, М. Шевченко, РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре, Чувашия Язучылар союзы идарәсе председателе А. Емельянов, Украина Язучылар союзы идарәсе секретаре А. Мороз, Удмуртия Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Перевощиков, Казагыстан Язучылар союзы идарәсе секретаре Ш. Муртазаев, язучылар Л. Прокша (Белоруссия), С. Жунусов (Казагыстан), К. Абрамов (Мордовия), О. Абдирахманов (Каракалпак), «Волга» журналы редакторы Н. Палькин, «Современник» нәшриятының РСФСР милли әдәбиятлары редакциясе мөдире Н. Нефедов һәм башка иптәшләр бар иде.

Съездны өлкән шагыйрь Сибгат Хәким ачып җибәрде.

Республика язучыларының иҗаты һәм ТАССР Язучылар союзы идарәсенең эше турындагы отчет докладын идарә председателе Гариф Ахунов ясады. Ревизия комиссиясенең отчеты белән комиссия председателе Рәис Даутов таныштырды. Аннары жанрлар буенча өстәмә докладлар тыңланды. Ике съезд арасында иҗат ителгән проза әсәрләре турында Атилла Расих, поэзия буенча — Нил Юзеев, драматургия буенча — Азат Әхмәдуллин, тәнкыйть турында — Мөхәммәт Мәһдиев, балалар һәм үсмерләр әдәбияты буенча Шәүкәт Галиев, очерк һәм публицистика буенча — Марсель Зарипов, рус язучыларының иҗаты турында Геннадий Паушкин сөйләде. Яшь язучылар белән эшләү турында шагыйрь Илдар Юзеевның, ТАССР Язучылар союзының Әлмәт бүлеге эше турында язучы Әдип Маликовның өстәмә докладлары тыңланды. Фикер алышуларда Ләбибә Ихсанова, «Казан утлары» журналының баш редакторы Зәки Нури, Рафаэль Мостафин, Әхәт Гаффар, Флүн Мусин, Кояш Тимбикова, ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе Әнәс Тумашев, ТАССР Журналистлар союзы идарәсе председателе, «Социалистик Татарстан» газетасы редакторы Ш. Хамматов, Татарстан китап нәшриятының баш редакторы Вакыйф Нуруллин, ВЛКСМ өлкә комитеты секретаре Ф. Газизуллин, ТАССР Композиторлар союзы идарәсе председателе урынбасары Фасил Әхмәтов катнаштылар.

Съездны Түбән Кама «Нефтехим» производство берләшмәсе аппаратчысы, СССР Верховный Советы депутаты Л. Панькова, Актаныш районының Шәймәрдәнов исемендәге колхозы бозау караучысы А. Гарипова, тугандаш әдәбиятлар вәкилләре Ә. Мирзаһитов (Башкортстан), А. Мороз (Украина), Ш. Муртазаев (Казагыстан), Л. Прокша (Белоруссия), А. Емельянов (Чувашия), О. Абдирахманов (Каракалпак), «Современник» нәшриятыннан Н. Нефедов иптәшләр тәбрикләде.

Аннары Сергей Михалков сүз алды. Ул үзенең чыгышында язучылар съездының җанлы һәм эшлекле узуын, отчет докладының һәм өстәмә докладларның, гомумән съездда сөйләшүләрнең эшлекле һәм принципиаль булуын билгеләп үтте.

Съездда КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев чыгыш ясады.

Съезд эшендә КПСС өлкә комитетының беренче секретаре Ф. Ә. Табеев, ТАССР Верховный Советы Президиумы Председателе С. Г. Батыев, КПСС Үзәк Комитетының культура бүлеге инструкторы А. В. Цветков, КПССның Казан шәһәр комитеты беренче секретаре Р. М. Мусин, профсоюзларның Татарстан өлкә советы председателе С. Г. Сафин, СССР Верховный Советы депутаты, Социалистик Хезмәт Герое Г. Ә. Әсхәдуллин, ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов, КПСС өлкә комитетының бүлек мөдирләре Ю. М. Воронов һәм М. М. Мусин катнашты.

Съезд Татарстан Язучылар союзы идарәсен түбәндәге составта сайлады: Гариф Ахунов, Азат Әхмәдуллин, Әхсән Баянов, Шәүкәт Галиев, Тәлгат Галиуллин, Әдип

Маликов, Мәдинә Маликовоа, Туфан Миңнуллин, Фәрваз Миңнуллин, Роберт Миңнуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Зәки Нури, Вакыйф Нуруллин, Геннадий Паушкин, Атилла Расих, Хәсән Туфан, Равил Фәйзуллин, Сибгат Хәким, Ренат Харис, Илдар Юзеев.

Союзның ревизия комиссиясенә Рәис Даутов, Шамил Бикчурин, Кояш Тимбикова, Михаил Скороходов һәм Гөлшат Зәйнашева сайланды.

*
* *

ТАССР Язучылар союзының яңа идарәсе үзенең беренче утырышын уздырды. Ул оештыру мәсьәләләрен карады.

Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе итеп Гариф Ахунов, аның урынбасарлары итеп Фәрваз Миңнуллин һәм Илдар Юзеев, секретарь итеп Мөсәгыйт Хәбибуллин сайланды.

Республика Язучылар союзының ревизия комиссиясе председателе итеп Рәис Даутов сайланды.

Литфонд председателе итеп Азат Әхмәдуллин сайланды.

## ТУГАНЛЫК ҺӘМ ДУСЛЫК БӘЙРӘМЕ

Май аенда Украинада Россия Федерациясе әдәбияты көннәре уздырылды. Ул чын мәгънәсендә олы бәйрәм төсен алды. Украинаның Россиягә кушылуына 325 ел тулуга багышланган тантаналы әдәби кичә, әдәбият сөючеләр белән очрашулар, хезмәт коллективларында булу Ватаныбызның төрле почмакларыннан җыелган күренекле язучылар һәм шагыйрьләрдә кабатланмас хатирәләр калдырды. Бәйрәмдә Татарстаннан Гариф Ахунов катнашты.

## ӘДИПЛӘР ЧИТ ИЛДӘ

Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин СССР Язучылар союзы делегациясе составында Төркиядә булып кайтты. Стамбул, Анкара һәм Кони шәһәрләрендә булган чакта төрек язучылары, журналистлары һәм сәнгать эшлеклеләре белән очрашулар, әңгәмәләр уздырылды. Ион Друцэ, Микаэл Шатирян, Рафаэль Мостафин һәм төрек язучысы Азиз Несин катнашкан пресс-конференция Стамбул телевидениесе буенча күрсәтелде.

Анкарада Рафаэль Мостафин белән Микаэл Шатирян сәнгать работниклары клубында чыгыш ясап, татар һәм әрмән әдәбиятлары турында сөйләделәр. Анкарада чыга торган «Енигюн» исемле прогрессив төрек газетасы 1979 ел, 25 март санының бер битен татар һәм әрмән әдәбиятларына багышлады.

## «ҮЛЕМСЕЗЛЕК»

Мәскәүнең «Прогресс» нәшрияты чыгарган шигырьләр җыентыгы шулай дип атала. Анда Бөек Ватан сугышында һәлак булган шагыйрьләрнең шигырьләре тупланган. Инглиз һәм рус телләрендә басылган бу китапта Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлилнең дә җиде шигыре бар.

## МОЛДАВАН ТЕЛЕНДӘ

Молдавиянең «Литература артистикэ» нәшрияты язучы һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафинның «Герой-шагыйрь эзләре буйлап» исемле китабын молдаван телендә бастырып чыгарды. Муса Җәлилгә багышланган әлеге китапны танылган молдаван шагыйрәсе Агнесса Рошка тәрҗемә иткән. Татар укучылары А. Рошка исеме белән «Синең җырың, Җәлил» исемле поэмасы буенча яхшы таныш. Ул аерым китап булып, татарча басылып чыккан иде.

## ХӘЙРЕТДИН МӨҖӘЙ ТУРЫНДА

Башкортстан китап нәшрияты Вәли Бикташевның «Мы старше своей смерти. Записки узника Дахау» дигән документаль повестен бастырып чыгарды. Китапка Бөек Ватан сугышы каһарманы, патриот-шагыйрь, полковник Хәйретдин Мөҗәйнең Каршылык хәрәкәтендәге эшчәнлегенә дә зур урын бирелгән, аның көндәлегеннән өзекләр дә урнаштырылган.

## УКРАИН СӘХНӘСЕНДӘ

Черкассы шәһәренең Т. Г. Шевченко исемендәге музыкаль-драма театрында Аяз Гыйләҗевнең «Без унике кыз идек» пьесасы буенча эшләнгән спектакль зур уңыш белән бара. Пьесаны украин теленә Д. Гринько тәрҗемә иткән.

*
* *

Мәскәүнең «Политиздат» нәшриятында «Наши праздники (советские, общегосударственные, трудовые, воинские, молодежные и семейно-бытовые праздники, обряды, ритуалы)» дигән китап басылып чыкты. Китапта әлеге бәйрәмнәрне уздыру буенча бай тәҗрибә гомумиләштерелгән.

«Старым праздникам — новые содержания» («Иске бәйрәмнәргә — яңа эчтәлек») бүлегендә татар халкының иң борынгы, иң күңелле бәйрәмнәренең берсе — сабан туйга да зур урын бирелгән.

## «СИБГАТ ХӘКИМ»

Тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин «Советская Россия» нәшриятында русча басылып чыккан бу китабында шагыйрьнең зур сән-

гатькә килү юлы, аның иҗат үзенчәлекләре турында сөйли.

Әлеге хезмәтнең ахырында шагыйрьнең рус телендә басылган китаплары исемлеге дә бирелгән.

## ОЧРАШУЛАР

Түбән Кама шәһәренең яшь нефтехимиклар әзерли торган 44 нче профессиональ-техник училищесында язучы Гариф Ахунов укучыларга үзенең иҗаты турында сөйләде, сорауларга җаваплар бирде. Соңыннан кунаклар китабына мондый сүзләр язып калдырды: «Биредә Галиҗанаб эшче сыйныфының өлкән буынына лаеклы алмаш әзерләнә. Искиткеч! Якты йөзләр, якты фикерләр, якты елмаюлар!»

*
* *

Мәгариф работникларының республика йортында Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов белән драматург Аяз Гыйләҗев Казан мәктәпләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән очраштылар. Очрашуда сүз театрда соңгы вакытта куелган әсәрләр, хәзерге заман драматургиясе, балаларны эстетик яктан тәрбияләү турында барды.

*
* *

Шагыйрь Ренат Харис культура институтының китапханә факультеты студентлары һәм укытучылары белән очрашты һәм үз иҗаты турында, бүгенге поэзия алдында торган җитди бурычлар турында сөйләде. Кичәдә шагыйрьнең шигырьләре яңгырады.

*
* *

Шагыйрь Роберт Миңнуллин Казанның 9 нчы һәм 93 нче мәктәпләрендә укучылар белән очрашу уздырды. Укучылар шагыйрьнең шигырьләрен, бүгенге балалар әдәбиятының соңгы еллардагы казанышлары турында сөйләвен яратып тыңладылар.

*
* *

Электрон-исәпләү машиналары заводының 10 нчы цехында эшчеләр белән очрашуга драматург Туфан Миңнулин һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин килгән иде. Язучылар соңгы вакытта дөнья күргән яңа китаплар, әдәбиятка яңа килгән яшь язучылар үзләренең иҗатлары турында сөйләделәр, иҗат планнары белән таныштырдылар.

## «ЛӘЙСӘН» ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕНДӘ

Чаллының «Ләйсән» әдәби берләшмәсе әгъзалары Түбән Кама ГЭСын төзүчеләр белән тыгыз бәйләнештә торалар: яшь язучылар эшчеләр яши торган тулай торакларда еш булалар, алар алдында чыгышлар ясыйлар. Түбән Кама ГЭСын төзүчеләргә культура хезмәте күрсәтүдә һәм аларның мактаулы эшен пропагандалауда актив катнашулары өчен, «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе парткомы «Ләйсән» берләшмәсенең кайбер әгъзаларын «Түбән Кама ГЭСын төзүче» значогы белән бүләкләде. Бу бүләккә лаек булучылар арасында Н. Мадьяров, К. Сибгатуллин, Х. Хөснуллин, Р. Лотфуллин, Р. Юнысов, Ф. Хәлиуллина, С. Шәрипова, Т. Сәгыйтова да бар.

*
* *

Чаллының Автозавод районындагы 18—06 нчы тулай торагында укучылар белән очрашып, язучы Эдуард Касыймов КамАЗның шәһәр яңы зонасы кешеләре тормышы турындагы «Шиңмәсен гөлләрең» исемле яңа романының язылу тарихы турында сөйләде, әсәреннән өзекләр укыды.

*
* *

Шул ук тулай торакта яшәүчеләр «Ләйсән» берләшмәсе әгъзалары белән очраштылар. Шагыйрь К. Сибгатуллинның, яшь авторлар Ф. Бәширова, В. Хәбибрахманова, Ә. Сабирова, Ә. Гайнуллиннарның чыгышларын яшьләр яратып кабул итте.

## ХЕЗМӘТЛӘРЕН ХӨРМӘТЛӘП

Татар совет әдәбияты әсәрләрен рус теленә тәрҗемә итеп бастыруда актив һәм нәтиҗәле эш күрсәтүләре өчен түбәндәге иптәшләр КПСС өлкә комитеты һәм Татарстан АССР Министрлар Советының **Почет грамотасы** белән бүләкләнделәр:

**Нефедов** Николай Николаевич — «Современник» нәшриятының РСФСР халыклары әдәбиятлары редакциясе мөдире.

**Корнеева** Елена Ивановна — «Современник» нәшриятының өлкән гыйльми редакторы.

**Имбовиц** Евгения Николаевна — «Советская Россия» нәшриятының милли редакциясе мөдире.

**Чивилихин** Владимир Алексеевич — язучы, тәрҗемәче, Мәскәү шәһәре.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан АССР Дәүләт җыр һәм бию ансамбле җырчысы Анастасия Петровна **Васильевага** (Нәфисә Василовага), Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 16 апрель Указы белән, **Татарстан АССРның халык артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Әлмәт дәүләт драма театры артистлары Камил Шакирович **Вәлиевка** һәм Рамазан Миннехакович **Ихсановка**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 3 май Указы белән, **Татарстанның халык артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет сынлы сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен художник-график, СССР Художниклар союзы члены Валентин Валерьевич **Карамышевка**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1979 ел, 3 май Указы белән, **Татарстан АССРның халык художнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет музыкасы өлкәсендәге хезмәтләре өчен Казан дәүләт консерваториясенең сольный җыр кафедрасы доценты вазифаларын башкаручы Светлана Нәҗиповна **Җиһановага**, Татарстан АССР хор җәмгыяте идарәсе председателе Владислав Георгиевич **Лукьяновка**, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Указы белән, **Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

## Хөрмәтле укучылар!

Тиздән вакытлы матбугатка язылу башланачак. Бу турыда газеталарда һәм радиодан хәбәр ителәчәк.

Киләсе ел өчен «Казан утлары» журналына язылырга теләсәгез, моны подписка башланган көннәрдә үк эшләргә тырышыгыз. Соңгы көннәргә калдыру журналга язылуны кыенлаштыра.

«Казан утлары» Бөтенсоюз каталогына кертелгән. Индексы — 73210. Журналга Советлар Союзының теләсә кайсы төбәгендә язылырга була. Подписка һәркайда җирле почта бүлекләрендә һәм «Союзпечать» агентлыкларында кабул ителә.

Урыннарда теге яки бу сәбәп белән журналга яздырмасалар, еллык подписка бәясен түбәндәге адрес белән җибәрергә мөмкин:

**420066, Казань,**
**ул. Декабристов, 2,**
**республиканское агентство «Союзпечать»**
**(для подписки на журнал «Казан утлары»)**
**Журналга язылу хакы 1 елга — 6 сум.**

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210